АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

## *Татары Челябинской области*

2-е издание

КАЗАНЬ 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Чиләбе өлкәсе татарлары*

2 нче басма

КАЗАН 2021

УДК 398+811.512.145
ББК 81.2=632.3+82.3(2=632.3)+85.12
М48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2014 – 2019)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында әзерләнде

**Редколлегия:**

***К.М. Миңнуллин*** *(рәис),* ***И.И. Ямалтдинов*** *(фәнни мөхәррир),*
***Л.Х. Мөхәммәтҗанова, Д.Р. Галиуллина***

**Төзүче һәм җаваплы мөхәррир**

филология фәннәре докторы ***Л.Х. Мөхәммәтҗанова***

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары.** – 2 нче басма. – Казан, 2021. – 444 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).
ISBN 978-5-93091-344-6

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Чиләбе өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел-авыз иҗаты, сөйләш үзенчәлекләре, археографик һәм эпитафик истәлекләре турында бай мәгълүмат бирә.

**ISBN 978-5-93091-344-6**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017, 2021

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

---

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

# КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда яшәүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар китерә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение мифах и легендах, песнях

чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә! Аларны төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстандагы академик фән, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкаль-әйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның тел-сөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер иярләре кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да туктаЛмый. 1940–1980 елларда аерым тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ.б.), диалектларны (Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ.б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче

и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только увидеть, понять, изучить и правильно интерпретировать эти явления. Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности! Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском, Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском,

татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшеренүләр уздырыла. Экспедицияләрдә тупланган материал «Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кулъязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йолагадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кулъязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайга-системага салына.

Спасском, Челнинском, Чистопольском районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследования по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016),

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында.

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядән 20 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфат-билгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр кая гына яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Мензелинского, Муслюмовского (2017), Азнакаевского, Буинского (2019) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Оренбургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Пензенской, Тюменской областях и Республике Узбекистан (2019).

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день завершается работа над фундаментальным 25-томным сводом «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә сакланып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Кабер таш язмалары, борынгы китаплар һәм кульязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении (рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский, узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно проживающих на разных территориях, ценны для нас сохранением

боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигърияткә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б.э.к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк

особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение, имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей

ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

* * *

Урал тауларының һәм тау үзәннәренең көньягына урнашкан Чиләбе өлкәсе Урал федераль округы составына керә. Ул 1934 елда оеша, территориясе 88,5 км$^2$ны били. Өлкәдә барлыгы 3 497 274 кеше яши, 2010 елгы статистик мәгълүматлар буенча, шуларның 180 913 енең татарлар булуы мәгълүм. Чиләбе, Магнитогорск, Златоуст, Копейск, Троицк, Озерск, Югары Уфалей кебек шәһәрләрдә, шулай ук Конашак, Саткы, Аша, Варна, Нязепетровск, Чибәркүл, Уй районнарында милләттәшләребез компактлы яши, аларның һәркайсында татарларның саны 2 128 дән алып 54 400 кешегә кадәр җитә[1].

[1] Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / отв. ред. Л.М. Айнутдинова, Б.М. Хамидуллин. Казань: Ин-т тат. энцикл. и регионоведения АН РТ. 2016. С. 280 – 282.

республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Не случайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды её наследники создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа духовные ценности. Академия наук Татарстана, её институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы

Чиләбе өлкәсе – татарларның тарихи ватаны. Бу территорияләр Урта гасыр төрки дәүләтләренең берсе – Кимак каганлыгына караган, XI йөздә үк инде татарларның каганатта аерым этногенетик тармак тәшкил иткән булулары мәгълүм. Алтын Урда чорында бу тирәләр татар җире булуын дәвам иткән. Казан алынганнан соң Чиләбе өлкәсе территориясенә Идел буе татарлары күпләп күченгән. XVIII йөзнең утызынчы елларыннан Чиләбе, Чибәркүлдәге һ.б. дәүләт ныгытмалары төзелешенә һәм алга таба алардагы хәрби хезмәткә бу төбәккә Идел-Урал буйларыннан татар мигрантлары агылган. Статистика буенча, 1740–1760 елларда бирегә күченеп килүчеләрнең күпчелеге Казан губернасының Казан, Зөя, Сембер өязләреннән булган. Чиләбе өлкәсе территориясендә татарлар элек-электән Казакъстан, Урта Азия, Көнчыгыш Төркестан халыклары белән алмаш сәүдәдә алдынгы рольне биләп киләләр. Ә инде XIX йөз – XX йөз башыннан Көньяк Уралда (бигрәк тә Оренбург губернасының Верхнеуральск, Троицк, Чиләбе өязләрендә) интенсив үсеш алган сәнәгать регионда янә татарларның саны артуга китерә. Шушы чордан Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәре, әйтик, Россия татарлары мәдәни һәм икътисади тормышында иң эре үзәкләрнең берсенә әверелә. 1917 елга кадәр биредә 7 мәчет, 6 мөселман хәйрия һәм мәдәни-мәгариф җәмгыятьләре эшли. Чиләбедә, Верхнеуральскида шулай ук мәчетләр, зур-зур татар җәмгыятьләре оеша. XIX йөз ахыры – XX йөз башыннан Көньяк Уралда татар мәдәни тормышын оештыруда Габдрәшитов, Бакиров, Вәлиев, Габбасов, Дәминов, Идрисов, Нигъмәтуллин, Рәмиев, Уразаев, Учаров, Хәсәнов, Яушевлар кебек мәшһүр татар байларының зур роле мәгълүм. Мәчетләр төзелешенә, мәдрәсәләр, дөньяви милли уку йортлары ачуга, хәйрия һәм мәдәни-мәгариф җәмгыятьләрне тотуга, милли матбугат чыгаруга алар үзләреннән биниһая өлеш керткәннәр. Октябрь инкыйлабыннан соң Троицкида Милли халык комиссариатының Татар бүлеге ачыла, «Ирек» (1920), «Кызыл Урал» (1920–1922), «Коммунист» (1931–1938) кебек газеталар дөнья күрә.

Совет чорында Чиләбе өлкәсенә татарларның яңа дулкыны агылу Магнитогорск металлургия комбинаты төзелү белән бәйле. 1922–1932 елларда биредә татар-башкорт мәктәбе эшли, «Магнит эшчесе» исемендәге газета басыла. 1935 елда Чиләбенең үзендә

исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

* * *

Челябинская область расположена в южной части Уральских гор и на прилегающей к ним Западно-Сибирской равнине. Она входит в состав Уральского федерального округа. Область была сформирована в 1934 году, ее территория составляет 88,5 км$^2$. Население области – 3 497 274 чел., согласно статистическим данным в 2010 году в области проживало 180 913 татар. Наши соплеменники проживают компактно в городах Челябинск, Магнитогорск, Златоуст, Копейск, Троицк, Озерск, Верхний Уфалей, а также в селах Кунашакского, Саткинского, Ашинского, Варненского, Нязепетровского, Чебаркульского, Уйского районов, количество татар в населенных пунктах варьируется от 2128 до 54 400 чел.[1]

Земли на территории Челябинской области – это историческая родина татар. Когда-то они относились к одному из средневековых тюркских государств – Кимакскому каганату. Известно, что уже в XI веке татары представляли отдельную этногенетическую ветвь в составе каганата. В эпоху Золотой Орды эти земли продолжали оставаться татарскими. После падения Казани в этот край переселилось много поволжских татар. С 30-х гг. XVIII в. на строительство пограничных крепостей в Челябинске и Чебаркуле начали съезжаться татары с Волги и Урала, которые впоследствии оставались там служить. Согласно историческим источникам,

---

[1] Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / отв. ред. Л.М. Айнутдинова, Б.М. Хамидуллин. Казань: Ин-т тат. энцикл. и регионоведения АН РТ. 2016. С. 280–282.

өлкә колхоз-совхоз татар театры төзелә, ул Бөек Ватан сугышына кадәр эшли. 1941 елда Троицкида ачылган мөстәкыйль татар театры исә эшчәнлеген 1980 елга кадәр алып бара. 1957 елда Чиләбе өлкәсендә «Маяк» җитештерү берләшмәсендә булган авариядән соң иң зур зыян күрүчеләр дә татарлар гомер итә торган Мөслим, Татар Караболагы кебек пунктлар булганлыгы билгеле факт.

Бүгенге көндә биредә Чиләбе өлкәсе Татар конгрессы (1998 елда оеша), «Татар һәм башкорт мәдәнияте үзәге» өлкә иҗтимагый оешмасы, Чиләбе өлкәсе татар яшьләре берлеге, «Юлдаш» хәйрия фонды, «Дуслык» мәгълүмат һәм мәдәният үзәге, «Уралым» өлкә мәдәният-ял клубы, Магнитогорскида «Төп йорт» татар мәдәнияте һәм мәдәни-социаль үзәге, Саткыда татар-башкорт мәдәни үзәге, Югары Уфалейда «Мирас» татар-башкорт мәдәният үзәге кебек оешмалар милли традицияләребезне саклау һәм үстерү юнәлешендә актив эш алып баралар.

2010 елда алынган статистик мәгълүматларга караганда, бүгенге көндә Чиләбе өлкәсенең Агаповка районында 1825, Аргаяш районында 1679, Аша районында 5538, Варна районында 2367, Верхнеуральск районында 2075, Югары Уфалейда 2244, Еманжелинскта 1341, Еткүл районында 828, Златоустта 10546, Карталы районында 1017, Копейск шәһәрендә 7785, Красноармейск районында 2913, Конашак районында 10315, Куса районында 1257, Магнитогорск шәһәрендә 20433, Миасста 5407, Нязепетровск районында 2255, Озёрскида 3680, Октябрь районында 915, Пласт шәһәрендә 2015, Саткы районында 10303, Сосновка районында 2539, Троицкида 5509, Уй районында 2018, Усть-Катав шәһәрендә 1006, Чибәркүл районында 827, Чесма районында 731, Чиләбенең үзендә исә 54400 татар гомер итә. Гасырлар аша безнең көннәргә килеп җиткән әлеге саннар Чиләбе туфрагының милләттәшләребез өчен гаять мөһим урын булуын раслый.

Берничә гасыр дәвамында төрле җирләрдән килеп урнашкан булуларына карамастан, Чиләбе өлкәсе татарлары телендә татар теленең урта диалекты үзенчәлекләре өстенлек итә. Биредә әлеге диалектның нагайбәк, эчкен, сафакүл сөйләшләре киң таралган. Әлеге сөйләшләр формалашуда, нигездә, Идел буйларыннан килгән татарлар, йомышлы татарлар, Уфа губернасының Бәләбәй өязе нагайбәкләре катнашкан.

большинство из переселенцев 1740–1760-х гг. прибыли сюда из Казанского, Свияжского и Симбирского уездов Казанской губернии. Татары Челябинской области издавна играли ключевую роль в развитии торговли с народами Казахстана, Средней Азии, Восточного Туркестана. Резкий подъем промышленности в XIX – нач. XX века на Южном Урале (особенно в Верхнеуральском, Троицком, Челябинском уездах Оренбургской губернии) привел к росту численности татар. В тот период город Троицк, например, становится одним из самых крупных в России центров культурной и экономической жизни татар. До 1917 года там функционировали 7 мечетей, 6 мусульманских благотворительных и культурно-просветительских организаций. В Челябинске и Верхнеуральске также были построены мечети и созданы татарские объединения. Известно, что с кон. XIX – нач. XX вв. большую роль в организации культурной жизни татар играли известные татарские предприниматели и купцы Габдрашитов, Бакиров, Валиев, Габбасов, Даминов, Идрисов, Нигматуллин, Рамиев, Уразаев, Учаров, Хасанов, Яушев. Они внесли существенный личный вклад в строительство мечетей, открытие медресе и светских учебных заведений, содержание благотворительных и культурно-просветительских организаций, развитие национальной печати. После Октябрьского переворота в Троицке открылось Татарское отделение Народного комиссариата по делам национальностей, начали издаваться газеты «Ирек» (1920), «Кызыл Урал» (1920–1922), «Коммунист» (1931–1938).

В советское время новая волна переселения татар в Челябинскую область была связана со строительством Магнитогорского металлургического комбината. В 1922–1932 гг. здесь работала татарско-башкирская школа, издавалась газета «Рабочий Магнитки» (на тат. яз.). В 1935 году в Челябинске был создан областной колхозно-совхозный театр, который работал до начала Великой Отечественной войны. А независимый татарский театр, открывшийся в Троицке в 1941 году, продолжал свою деятельность до 1980 г. Также известно, что от аварии на комбинате «Маяк» наиболее пострадали татарские села Муслюмово и Татарская Караболка.

Сегодня активную работу по сохранению и развитию национальных традиций ведут Конгресс татар Челябинской области

Чиләбе өлкәсе белән Татарстан Республикасының икътисад ягыннан, фән, сәламәтлек саклау, мәдәният буенча инде күптәннән үзара файдалы элемтәдә, регионара дуслыкта яшәве мәгълүм. Шунысы мөһим: Россиянең бу ике регионы арасында хезмәттәшлек дәүләт дәрәҗәсендә алып барыла. Татарстан Республикасы һәм Көньяк Урал арасында фән, техника, мәдәният һ.б. өлкәләрдә үзара ярдәмләшү, хезмәттәшлек турында килешүләр төзелә. Бу килешүләр, әлбәттә, үз эченә күп бурычлар куя. Берберсе белән тыгыз бәйләнештә яшәү, бергә эшләү, тәҗрибә алмашуның төп максаты – Чиләбе һәм Татарстанның төрле өлкәләрендә уңай нәтиҗәләргә ирешү.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты даими оештыра торган комплекслы фәнни экспедицияләрнең берсе 2016 елда нәкъ менә Чиләбе өлкәсенә билгеләнү дә югарыдагы чараларның берсе буларак бәяләнергә хаклы. Көньяк Уралда 200 мең татар яши. Берничә ел элек Чиләбегә эшлекле сәфәрләренең берсендә ясаган чыгышында Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов: «Мин, Татарстан Президенты буларак, биредә яшәүче татарларның тормышын, эшләрен, аларның нинди шартларда яшәүләрен, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне ни рәвешле саклауларын белергә тиеш», – дигән иде. Татарстан Республикасы җитәкчелеге Чиләбедә яшәүче татарлар белән кызыксынуны бүгенге көндә дә актив дәвам итә. 2012 елда III Бөтенроссия авыл Сабан туеның нәкъ менә Чиләбе өлкәсендә үткәрелеп, әлеге мәдәни чараның 50 меңләп халыкны үзенә җәлеп итүе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Чиләбедә гомер итүче татарларга бирелгән игътибарның Республикакүләм дәрәҗәдә булуы исә Институтыбыз тарафыннан Чиләбе өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең фольклорын, тел үзенчәлекләрен, сәнгатен, археографиясен фәнни өйрәнүнең актуальлеген янә бер баскычка күтәрә.

Институт тарафыннан комплекслы фәнни экспедицияләр оештыру соңгы елларда дәүләт тарафыннан яклау таба, алар махсус программалар аша тормышка ашырыла. Әйтик, Чиләбе өлкәсе татарларын өйрәнүгә багышланган, 2016 елда үткәрелгән комплекслы фәнни экспедициянең «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау» ТР Дәүләт программасы кысаларында уздырылуы шуны

(организован в 1998 г.), областная общественная организация «Центр татарской и башкирской культуры», объединение татарской молодежи Челябинской области, благотворительный фонд «Юлдаш», Центр информации и культуры «Дуслык», областной клуб культуры и отдыха «Уралым», культурно-общественный центр «Төп йорт» (Магнитогорск), татаро-башкирский культурный центр (Сатка), татаро-башкирский культурный центр «Мирас» (Верхний Уфалей).

Согласно статистическим данным 2010 года численность татар Челябинской области по городам и районам выглядит примерно так: Агаповский район – 1825, Аргаяшский район – 1679, Ашинский район – 5538, Варненский район – 2367, Верхнеуральский район – 2075, г. Верхний Уфалей – 2244, г. Еманжелинск – 1341, Еткульский район – 828, г. Златоуст – 10546, Карталинский район – 1017, г. Копейск – 7785, Красноармейский район – 2913, Кунашакский район – 10315, Кусинский район – 1257, г. Магнитогорск – 20433, г. Миасс – 5407, Нязепетровский район – 2255, г. Озерск – 3680, Октябрьский район – 915, г. Пласт – 2015, Саткинский район – 10303, Сосновский район – 2539, г. Троицк – 5509, Уйский район – 2018, г. Усть-Катав – 1006, Чебаркульский район – 827, Чесменский район – 731, г. Челябинск – 544000. Эти цифры пережили столетия и свидетельствуют о том, что Челябинская земля всегда была и остается для наших соплеменников родным местом.

Челябинские татары – это общность, формировавшаяся на протяжении веков из татар, прибывавших сюда из разных мест. Однако в их языке преобладает средний диалект татарского языка. Широко распространены нагайбакский, ичкинский, сафакульский говоры среднего диалекта. В формировании этих говоров участвовали, в основном, поволжские татары, служилые татары и нагайбаки Белебеевского уезда Уфимской губернии.

Челябинская область и Республика Татарстан уже многие десятилетия поддерживают взаимовыгодное сотрудничество в сфере экономики, науки, здравоохранения, культуры. Важно то, что деловые и дружеские связи между ними поддерживаются на государственном уровне: подписываются соглашения о сотрудничестве. Разумеется, это ко многому обязывает.

раслый. Галимнәрнең халык белән турыдан-туры аралашуы фән үсешенә зур йогынты ясый. Шушындый файдалы аралашуны тәэмин итүгә дәүләт тарафыннан күрсәтелгән игътибар галимнәргә, һичшиксез, тагын да нәтиҗәлерәк эшләргә мөмкинлекләр ачты.

Чынлыкта, бу юлы максатчан төстә өйрәнү объекты итеп Чиләбе өлкәсе авылларын сайлау борын-борыннан милләттәшләребез ватаны булган әлеге төбәкнең мәдәни байлыгына фәнни күзәтү ясауга инде шактый вакыт узган булу белән дә бәйле. Оешуының беренче көннәреннән алып, 80 елдан артык татарны өйрәнү, аны милләт буларак саклау мәсьәләләрен кайгырта килгән Институтның Чиләбе өлкәсендәге татар авылларына фольклор экспедицияләре узган гасырның җитмешенче еллар ахырында оештырылган булган. Бу вакыйгага бер буын алышырлык вакыт үткән, шуңа да әлеге бушлыкны тулыландыру көн кадагындагы мәсьәлә иде.

Соңгы ун елда интенсив оештырала торган комплекслы фәнни экспедицияләр, чыннан да, – Институтыбызда татар телен, әдәбиятын, сәнгатен, халык иҗатын төрле яклап өйрәнү юнәлешендә киң колач белән алып барылган эшләрнең берсе. Экспедицияләрнең комплекслы булуы, бер яктан, аларның составында әдәби һәм мәдәни хәзинәләребезне барлау, өйрәнүдә Институтның югары һөнәри осталыкка ия тәҗрибәле галимнәре янәшәсендә яшьләрнең дә катнашуын тәэмин итә. Икенче яктан, комплекслы өйрәнгәндә тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән шигъри сүзе, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, ягъни фольклоры, милли сәнгатебез үрнәкләре, музыкасы, бәйләү-чигү осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе җентекләп барлана-туплана. Мондый чараның төп нәтиҗәсе – халыкта булган матди яисә рухи хәзинәләрне бөртекләп җыйнау, реконструкцияләү һәм халыкның үзенә кире кайтару.

Кулыгыздагы китап – «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә дөнья күргән хезмәтләрнең чираттагысы, экспедиция барышында җыйналган мирасны һәм алар хакында галимнәр сүзен китап итеп чыгару традициясенең дәвамы. Аңлашылганча, китап Чиләбе өлкәсе татарларының милли-мәдәни хәзинәләрен барлауга багышланган. Анда Чиләбе өлкәсендә яшәүче

Комплексная экспедиция Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ, организованная в Челябинскую область в 2016 году, по праву может считаться одним из направлений этой политики взаимовыгодного сотрудничества. На Южном Урале живет 200 тысяч татар. Несколько лет назад во время деловой поездки в Челябинск президент Республики Татарстан Рустем Минниханов сказал в своем выступлении: «Я, как президент Татарстана, должен знать, в каких условиях живут, работают здешние татары, как они сохраняют наши традиции, обычаи, культуру». Руководство республики и сегодня активно интересуется челябинскими татарами. О многом говорит и тот факт, что в 2012 году III Всероссийский сельский Сабантуй прошел именно в Челябинской области и привлек к себе около 50 тысяч человек. Это лишний раз подтверждает актуальность научного изучения фольклора, языка, искусства, археографии челябинских татар.

Организация комплексных экспедиций института в последние годы получила поддержку государства: они реализуются по специальным программам. Например, комплексная научная экспедиция 2016 года в Челябинскую область была проведена в рамках Государственной программы РТ «Сохранение национальной идентичности татарского народа». Непосредственный контакт ученых с носителями культуры, традиций, языка и пр. оказывает большое влияние на развитие науки. Поддержка государством этой деятельности открывает перед специалистами более широкие возможности.

Институт с момента своего основания, вот уже более 80 лет, занимается исследованием духовной и материальной культуры татарского народа, сохранением его как нации. Предыдущая научная экспедиция в Челябинскую область состоялась в конце 70-х гг. прошлого века. С тех прошло значительное время, произошла смена поколений, поэтому возникла необходимость актуализации накопленных сведений.

Комплексные экспедиции, организуемые в последнее десятилетие, – одно из направлений деятельности института по широкомасшабному научному исследованию языка, литературы, искусства, фольклора татар. Комплексный характер экспедиций,

милләттәшләребезнең гореф-гадәтләре, әле хәзер дә популяр саналган тел-авыз иҗаты, сөйләш үзенчәлекләре, археографик һәм эпитафик истәлекләре, күренекле шәхесләрнең шәҗәрәләре һ.б. турында бай мәгълүмат тупланган. Басманың нигезен, алда әйткәнебезчә, 2016 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан бер төркем галимнең нәкъ менә шушы төбәк татар авылларында комплекслы фәнни экспедиция вакытында туплап кайткан материаллары тәшкил итә.

Чиләбе өлкәсенә соңгы экспедиция составында барлыгы биш белгеч эшләде, эш планында фольклор, тел-диалектология, археография һәм кабер ташъязмалары, шулай ук милли сәнгать юнәлешләренә игътибарны юнәлтү каралган иде. Фольклор белгече Ильмир Ямалтдинов җитәкчелегендә галимнәребез Чиләбе өлкәсенең Нязепетровск, Чибәркүл, Уй, Нагайбәк районнарына кергән татар авылларында булдылар. Маршрут бу өлкә татарларының этник һәм этноконфессиональ үзенчәлекләре ягыннан төрле катлам һәм төркемнәрен өйрәнүне күздә тотып төзелде, ягъни борынгы чорлардан бирле биредә җирле халык булып яшәп килгән төркемнәрне, керәшен этник төркеме вәкилләре – нагайбәкләрне һәм күп еллар элек Казан арты яисә Урал буйларыннан күченеп төпләнгән татарларны өйрәнү принципларына нигезләнде.

Әлеге экспедициядә катнашкан фән докторлары – фольклорчы Лилия Мөхәммәтҗанова белән телче-диалектолог Флёра Баязитова, сәнгать белгече Людмила Шкляева, борынгы кульъязмалар һәм эпитафика белгече Айгөл Әхмәтова – һәркайсы үз юнәлеше буенча эш алып бардылар. Җыентыкта экспедиция әгъзаларының билгеле максатны күздә тоткан шәхси күзәтүләре, сәфәрдән алган тәэсирләрен гомумиләштерү, Чиләбе өлкәсе информантлары белән аралашулары, экспедиция нәтиҗәсендә табылган табышларын барлау-анализлау характерындагы фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре урын ала. Әйтик, Ф. Баязитованың «Чиләбе төбәгендә җирле сөйләшләр һәм халык традицияләре» һәм «К реконструкции традиционной культуры нагайбаков (обряд и текст)» дип аталган, Лилия Мөхәммәтҗанованың «Чиләбе татарларында сүз сәнгате», Ильмир Ямалтдиновның «Чиләбе өлкәсе татарлары

с одной стороны, дает возможность молодым ученым работать рука об руку с опытными специалистами и учеными. С другой – позволяет одновременное изучать все сокровища духовного наследия исследуемого региона – устное народное творчество, передаваемое от поколения к поколению, традиционные праздники, обряды, обычаи, образцы национального искусства, музыки, ремесла, орнаментальные украшения домов, специфику национальной одежды, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. Главный результат таких экспедиций – анализ собранных материалов, реконструкция и возвращение духовного наследия народу.

Предлагаемая вашему вниманию книга – очередная из серии «Из сокровищницы научных экспедиций» и посвящена национально-культурному наследию татар Челябинской области. В книге собрана информация об обрядах и обычаях, устном народном творчестве, особенностях языка, эпиграфических и археографических памятниках, генеалогиях известных личностей и т.д. Основу издания составили материалы, собранные учеными Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ во время полевых исследований 2016 года.

В составе экспедиции работали пять специалистов, по плану предполагалось изучение фольклора, местных говоров, рукописей, старопечатных книг, надмогильных камней и народных ремесел. Под руководством фольклориста Ильмира Ямалтдинова наши ученые побывали в татарских селах Нязепетровского, Чебаркульского, Уйского и Нагайбакского районов. Маршрут и принципы исследования строились с учетом того, что татары области состоят из различных групп со своими этническими и этноконфессиональными особенностями: татар, живущих на этих землях с самых древних времен, представителей кряшенской этнической группы – нагайбаков и татар, много десятилетий назад переселившихся сюда из Заказанья или Предуралья.

В экспедиции приняли участие доктора наук – языковед-диалектолог Флера Баязитова и фольклорист Лилия Мухаметзянова, искусствовед Людмила Шкляева, специалист по древним рукописям и эпиграфике Айгуль Ахметова. В сборник вошли статьи членов экспедиции, в которых содержатся их личные

фольклоры (Халык иҗаты үрнәкләре)» исемле мәкаләсе һәм материаллары, сәнгать фәннәре кандидаты Людмила Шкляева һәм Айгөл Әхмәтова мәкаләләре – халык теленең, тел-авыз иҗатының, милли сәнгатьнең, мәдәниятнең һ.б.ның үсешен, яшәешен күреп, белгеч күзлегеннән бәя биреп язылган хезмәтләр. Аларда шушы төбәктән туплап кайткан фольклор үрнәкләре чагылыш тапкан. Әлеге материалларның беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелүләре дә, нигездә, нәкъ менә шушы җыентыкта тормышка ашырыла.

Китапта болардан тыш та берничә мәкалә урын алган. Фәрит Йосыповның «Нагайбәк сөйләшенең лексик үзенчәлекләре», Лилия Мөхәммәтҗанованың «Чиләбе – дастаннар бишеге», Зөфәр Мөхәммәтшинның «Көньяк Урал татарлары XX гасыр башы матбугатында, шәҗәрәләрдә» дип аталган мәкаләләре Чиләбе өлкәсе татарларының тел үзенчәлекләре, эпик фольклор, текстология кебек мөһим мәсьәләләренә багышланган. Җыентык Чиләбе өлкәсенә үткәрелгән комплекслы экспедиция фотолары белән баетылган.

«Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясендә дөнья күргән, Чиләбе өлкәсендә гомер итүче милләттәшләребезнең тормыш-көнкүрешен, тарихын, гореф-гадәтләрен яктырткан, шушы төбәккә хас тел үзенчәлекләре, сәнгать, кульязма мирас, күренекле милләттәшләребез, атаклы шәхесләр, гомумән, милләтебезнең күп гасырлык югалту-табышлары хакында зур мәсьәләләрне күтәргән фәнни язмаларны туплаган әлеге җыентык ике регион арасындагы милли элемтәбезне тагын да ныгытыр, Россия Федерациясенең алдынгы субъектлары – Чиләбе өлкәсе белән Татарстан Республикасы арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне тагын да тирәнәйтүгә яңа бер этәргеч бирер, милли хисләребезне яңартыр, бердәм татарлыгызны тагын да ныгытуга йогынты ясар дип ышанабыз.

**_Ким Миңнуллин,_**
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*

наблюдения и впечатления, итоги их общения с информантами, анализ найденных материалов: «Местные говоры и народные традиции Челябинской области» и «К реконструкции традиционной культуры нагайбаков (обряд и текст)» Ф. Баязитовой, «Искусство слова у челябинских татар» Л. Мухаметзяновой, «Фольклор татар Челябинской области (образцы народного творчества)» И. Ямалтдинова, статьи Л. Шкляевой и А. Ахметовой. В этом сборнике материалы экспедиции впервые вводятся в научный оборот.

Кроме этого, в книгу включены еще несколько статей: «Лексические особенности нагайбакского говора» Фарита Юсупова, «Челябинский край – колыбель дастанов» Лилии Мухамметзяновой, «Татары Южного Урала в периодической прессе и генеалогиях начала XX века» Зуфара Мухамметшина, которые посвящены особенностям языка, эпическим жанрам фольклора и текстологическим вопросам, связанным с татарами Челябинской области. Сборник содержит фотоматериалы, привезенные из экспедиции.

Выражаем надежду, что книга, в которой представлена история, современная жизнь, традиции и обряды, особенности языка, образцы искусства, рукописного наследия, известные личности татар Челябинской области и, говоря в целом, поднимающая значимые вопросы о непростой судьбе татарского народа, его потерях и приобретениях, еще более укрепит национальное единство, а также даст толчок к углублению сотрудничества между передовыми субъектами Российской Федерации – Татарстаном и Челябинской областью.

***Ким Миннуллин,***
*директор Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова,*
*член-корреспондент Академии наук*
*Республики Татарстан*

# ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШЛӘР ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Флёра Баязитова*

Идел–Урал төбәге – татарларның төп гомер иткән урыны. Көньяк Урал һәм Урал артындагы Чиләбе, Курган өлкәләрендә, Урта Уралдагы Пермь краенда һәм Свердловск өлкәсендә, Башкортстанда да татарлар күпләп яшиләр. Урал төбәгенә татарлар Казан ханлыгы җимерелгәннән соң күпләп күчеп утыра башлаганнар. Ләкин, кайбер тарихчылар, Уралда (мәсәлән, Красноуфим тирәләрендә) электән үк татарларның борынгы бабалары яшәгән, дип күрсәтәләр.

Татарларның Идел буе өлкәләреннән көнчыгышка, Урал төбәгенә күчеп утырулары төрле сәбәпләр: җир азлыктан, сәяси яктан кыерсытулар, көчләп христианлаштыру һ.б. аркасында булган.

Урал төбәге татарларының бай тарихы, борынгылыкны саклап калган җирле сөйләшләре, гореф-гадәт, йолалары бар. Урта һәм Көньяк Урал, Урал арты төбәкләрендә татар халкының үзенчәлекле җирле сөйләшләре: красноуфим, нагайбәк, сафакүл, эчкен атамалары белән фәнни әйләнешкә кертелгәннәр.

Биредәге авылларда гаилә йолаларыннан *башкода* килү, *борындык инәй, борындық әтәй, аргыш, озатқыч* сүзләрен, туйда *божал куйу, тастымал элү, кумәч сандыгы, қыз куйыны* һ.б. бик күп йолалар һәм йола сүзләрен язып алдык. Ел фасылларына бәйле йолалардан *теләк, йаңгыр теләү, қорбанның, қарга боткасы, саламат пешерү, кичкуйын, тын тыңлау, сөрән, бот*

*көрәштерү, тастымал җыйу* һ.б. шулай ук халык хәтерендә саклана һәм кайберләре, йола буларак, бүгенге көндә дә башкарыла.

## НЯЗЕПЕТРОВСК РАЙОНЫ АРЫСЛАН АВЫЛЫ СӨЙЛӘШЕ

Чиләбе өлкәсенең Нязепетровск районына караган **Арыслан** авылы тарихы 1663 елдан башланган, башкорт җирләрендә урнашкан татар авылы буларак билгеле. Уфа елгасы бассейнына караган Арыслан авылы төбәге тарихи истәлекле урыннары, археологик табылдыклары белән билгеле. Биредә археологик яктан кыйммәтле унлап истәлек тапканнар.

Арыслан авылында урта мәктәп, музей, клуб бар, фольклор ансамбле эшли. Бу авыл электән үк Свердловск өлкәсе Түбән Сырга (Нижне-Сергинский) районының Шөкүр, Әрәкәй авыллары халкы белән аралашкан, кунаклашкан. Тел үзенчәлекләрендә уртаклыклар күп булу, йолалар бер булу да биредәге халыкны үзара якынайткан. Элегрәк *Гөбе юасы* дигән җыенны да бергәләп, кара-каршы йөрешеп бәйрәм иткәннәр. Хәзерге чорда да Әрәкәй авылының күренекле фольклор җитәкчесе Салават Гобәев бу төбәктәге халыкны оештырып, үзара аралаштырып торуда көчен кызганмый.

### Фонетик үзенчәлекләр

**Сузыклар***:* *а* авазы, нигездә, иренләшә, ләкин көчле иренләшү юк: *$а^{о}$лма, $а^{о}$лтын, $а^{о}$рба, қ$а^{о}$рға.*

*ә – а: йәбешә* – әд. йабыша (график. ябыша), *сәленә* – салына, *йән* – җан, *әхирәт* – ахирәт, *әтнә* – атна*, әнән әре* – аннан ары, *әләсәң* – алайса, *әждәһә* – аждаһа, *сәтин* – сатин.

*ы ~ а: йаңы* – әд. йаңа (график. яңа), *уwылып* – *уwалып* (граф. уалып), *аудыра* – аудара.

*а ~ ы: қапқан* – капкын, *қатырға* – катыргы, *қаңғырау* – кыңгырау, *қабак* – кабык, *қазарға* – казырга, *қайа* – кайый, *қайарға* – кайырга (график. каерга).

*ә ~ и: сәтләwек* – әд. чикләвек, *кәштә* – киштә, *кәрәк* – кирәк, *кәмә* – көймә, *кәм* – ким, *тәрән* – тирән, *шәкәр* – шикәр, *шәрбәт* – ширбәт, *кәбән* – кибән, *кәртә* – киртә, *әпәй* – ипи, *кәгәwен* –

кигәвен, *кәләплей* – киләпли, *бәк* – бик, *этәй* – эти, *тәкбәр* – тәкбир.

*и ~ ә: инәкәй* – әд. әни, *сискә* – чәчкә, *сике* – сәке, *печин* – печән, *бели* – белән, *чеперик* – чүпрәк, *печиннек* – печәнлек, *пилмин* – пилмән, *гулбич* – гөлбәч (әд. идән асты базы), *фирештә* – фәрештә.

*и ~ е (э): әкрин* – әкрен, *чебин* – чебен, *бөрлигән* – бөрлегән.

*ә ~ өй: кәмә* – әд. көймә. Ләкин: *өй, сөйәк, көйәнтә, сөйәл.*

*и ~ у: минча* – әд. мунча, *минчала* – мунчала.

*е ~ ү: сепрәк* – әд. чүпрәк.

*е ~ и: дегәнәк* – әд. тигәнәк.

*ө ~ ү: төгөл* – әд. түгел, *бөгөн* – бүген, *бөкәй* – бүкәй, *төбәтәй* – түбәтәй, *чөмәлә* – чүмәлә, *төбә* – түбә, *мәк* – мүк, *көзәтү* – күзәтү.

*ү ~ ә: җүгән* – җөгән (әд. йөгән), *күпшә* – көпшә, *йүткерә* – йөткерә.

*у ~ о: сурый* – әд. сорый, *сура* – сора, *туқмач* – токмач, рус сүзләрендә: *кулча* – рус. кольцо, *кутумка* – рус. котомка, *путулук* – рус. потолок.

*о ~ у: йоқа* – әд. йука (график. юка), *йобану – йуwану (*график. юану*), богаз* – бугаз.

*ы ~ у: мынса* – әд. мунча, *быйау* – буйау (график. буяу), *была* – була, *былай былған* – болай булган, *шыл* – шул, *йыwындыра* – йуындыра (график. юындыра), *алабыта* – алабута.

*у ~ ы: сандук,* – әд. сандык.

**Дифтонглар.** Сөйләштә исемнәр һәм алмашлыкларда, фигыльләрдә сүз ахырында килгән -*ай/-әй* дифтонгларының әдәби телдәге -*ый/-ий* дифтонглары белән тәңгәлләшү күренеше дә бар: *инәй* – эни$^{й}$, *җизнәй* – җизни$^{й}$, *қартнәй* – карт әни, *үгәй* – үги$^{й}$, *қодағай* – кодагый, *кәнүшнәй* – рус. конюшня, *әпәй* – ипи$^{й}$, *тәпәй* – тәпи$^{й}$, *андай* – андый, *шундай* – шундый, *бармай* – бармый, *эшләмәй* – эшләми, *таwышланмай* – тавышланмый, *тапмайынсы* – тапмыйчы, *кәләпләй* – киләпли, *тәрәпләй* – тәрәпли.

*ү ~ өй: түмә* – әд. төймә, *үрәнә* – өйрәнә, *үрә* – өйрә, *сүләй* – сөйли, *сүрәй* – сөйри.

*-ей* дифтонгы ачык иҗектә килгән тар *и* сузыгы урынына әйтелә: *кейем* – әд. кийем (график. кием), *тейеш* – тийеш (график. тиеш), *ней* – ни, *кейек* – кийек (график. киек).

Иҗек һәм сүз азагындагы ирен-ирен *у – ү* сузыкларына *-ыw/-еw* дифтонглары туры килә: *қыwақ* – әд. куак, *сыw* – су, *тыwған* – туган, *сыwған* – суган, *сыwық* – суык.

**Тартыклар.** Тартык авазлар системасы составы һәм ясалышы ягыннан әдәби телдән аерылмый. Аермалыклар аваз тәңгәллекләрендә генә күзәтелә.

*б ~ в: бидрә* – рус. ведро (әд. чиләк).

*б ~ м: буйынса* – әд. муенса.

*м ~ б: чымылдық* – әд. чыбылдык, *мөрө* – бөре, *қорман* – корбан, *майтақ* – байтак, *минаwат* – рус. виноват.

*н ~ м: йаwын* – җаwым (график. явым), *тырнау* – тырмау, *ағын (сыу)* – агым (су), *тырнаwыс* – тырма.

*н ~ л: сөрнегү* – сөрлегү.

*п ~ ф: йапрақ* – йафрак (график. яфрак), *керпек* – керфек, *қалпақ* – калфак, *қәнәпер* – канәфер, *панар* – фонарь, *шәпқәтле* – шәфкатьле. Ләкин: *Фатих, Хафиз, Фатыйма һ.б.*

*з ~ р: тотқыза* – әд. тоттыра, *йатқыза* – йатқыра (әд. яткыра), *үткәзә* – үткәрә.

*з ~ д: изән* – әд. идән, *қазақ* – кадак, *казый* – кадый.

*д ~ т: дегәнәк* – әд. тигәнәк, *дәгәрмәс* – тәгәрмәч, *дуғару* – тугару, *дары* – тары.

*т ~ д: тиде* – диде, *җите* – җиде, *тип* – дип.

*с ~ ч* күренеше аеруча күрше Свердловск өлкәсе Түбән Сырга районы татар авылларында актив күренеш: *себен* – чебен, *сәй* – чәй, *салғы* – чалгы, *сабата* – чабата, *сормау* – чормау, *бесән* – печән, *бесү* – печу, *бысқы* – пычкы, *сыбыртқы* – чыбыркы. Үткән заман хәл фигыль формаларында: *барғас* – әд. баргач, *килгәс* – килгәч.

*ч ~ ш: шишмә* – әд. чишмә, *шыршы* – чыршы, *шебеш* – чебеш, *шитләwек//сәтләwек* – чикләвек.

*ч ~ т: чөчө* – төче.

*ч ~ җ: ченаза* – әд. җеназа.

*ж ~ җ* күренеше Түбән Сырга районының Үрмәкәй, Әрәкәй, Өфө Шигере авылларында билгеләнде: *бажа* – әд. баҗа, *жиләк* – җиләк, *кәжәнкә* – кәҗәнкә, *жите* – җиде, *өмөже* – өмөҗе (әд. кура җиләге), *жыйылыш* – җыелыш, *жизнә* – җизнә, *хәжәт* – хәҗәт, *ожау* – уҗау (әд. аш чүмече).

*җ//й* параллель кулланыла, ягъни сөйләшкә *җ*-ләштерү дә, *й*-ләштерү дә хас: *йул//җул, йахшы//җахшы, йәшел//җәшел, йел//җил, йеләк//җиләк, йимеш//җимеш, Йамал//Җамал, Гөлйәмилә//Гөлҗәмилә, йан//җан, дөнйа//дөнҗә.*

*з ~ җ/й* түбәндәге сүзләрдә: *кәзә* – әд. кәҗә, *зибәрә* – җибәрә, *кизеле* – киҗеле, *зөзек* – йөзөк, *мәзелес* – мәҗлес.

*г ~ қ: йаға* – әд. йака (график. яка), *тығырық* – тыкырык, *чигерткә* – чикерткә.

*қ ~ г: сулақай* – әд. сулагай.

*қ ~ х: рәқмәт* – әд. рәхмәт, *қодай* – ходай.

**Ассимиляция күренешләре.** Тамырдагы *н, м* авазлары тәэсирендә кушымчадагы *л* тартыгы тулысынча ассимиляцияләнә, ягъни *н* авазына күчә: *уннап* – әд. унлап, *чыннап* – чынлап, *көннәшә* – көнләшә, *урманнық* – урманлык, *болыннық* – болынлык, *бөтөннәй* – бөтенләй; *ашамнық* – әд. ашамлык, *исемне* – исемле, *имнәде* – имләде, *моңно* – моңлы, *тәмне* – тәмле, *онната* – онлата, *төннә* – төнлә.

Ирен-ирен яңгырау *б, м* тартыклары алдында тел очы *н* авазы ирен-ирен *м* авазына күчә *(нб > мб, нм > мм).* Бу күренеш түбәндәге шартларда күзәтелә:

*-ган* формалы хәл фигыльләргә I зат берлек *(-мин/-мен*), күплек (*-быз/-без*) һәм сорау (*-мы/-ме*) кушымчалары ялганганда: *баргаммы* – әд. барганмы, *эшләгәмме* – эшләгәнме, *күрмәгәмме* – күрмәгәнме, *теккәмбез* – теккәнбез, *үскәмбез* – үскәнбез, *алғаммын* – алганмын.

Нигезе *н* тартыгына беткән хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасында: *белеммәй* – әд. беленми, *кейеммәй* – киенми, *йылыммый* – җылынмый.

Боерык фигыльнең юклык формасында: *сүләммә* – әд. сөйләнмә, *қайымманң* – кайынма (график. каенма, әд. чикмә).

Ике сүз янәшәлегендә: *барғам була* – әд. барган була, *төм буйы* – төн буе.

Әдәби телдәге кебек үк, тирән тел арты *қ–ғ* һәм тел арты *к–г* тартыклары үзләреннән алда килгән *н, л* сонорларын, өлешчә ассимиляцияләштереп, *ң* тартыгына күчерәләр: *тоқоңға* – әд. токынга, *урмаңға* – урманга, *қазаңға* – казанга, *төңгә* – төнгә.

**Диссимиляция күренешләре.** Сонор *н, м, ң* тартыкларына беткән исемнәргә һәм алмашлыкларга, әдәби телдән аермалы буларак, чыгыш килешендә *-дан/-дән* кушымчалары ялгана: *урмандан* – әд. урманнан, *йаландан* – йаланнан (график. яланнан), *болондан* – болыннан, *андан* – аннан, *кемдән* – кемнән.

Диссимиляция күренешенә тагын түбәндәге мисалларны теркәргә мөмкин: *төндөк* – әд. төнлек, *борондык* (инәй) – туйда йола буенча икенче «әни» итеп куелган кеше, *миндек <миннек < биннек* – рус. веник.

Аваз төшү:

*ы* төшә: *қайдым* – әд. кайыдым (график. каедым).

*й* төшә: *қачан/қасан* – кайчан, *қачы/қасы* – кайчы.

*л* төшү түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *йугату* – әд. йуғалту (график. югалту), *итеү* – илтү, *көчәп* – көчләп.

*г* төшә: *нийә* – әд. нигә.

*б* төшә: *арта(а)* – артаба < ары таба.

*р* төшә: *тәликә* – әд. тәлинкә, *икә* – икән, *микә* – микән, *белә* – белән, *асат* – ансат, *муча* – мунча.

Икеләтелгән тартыкларда (геминатларда) берсе төшерелеп әйтелә: *эсе* – әд. эссе, *кәкүк* – кәккүк; чыгыш килешендәге алмашлыклар һәм исемнәрдә: *анан* – әд. аннан, *монан* – моннан, *өйөнән* – өеннән; *-ым/-ем* тартым кушымчасына беткән исемнәр һәм алмашлыкларда: *қулыман* – әд. кулымнан, *суземән* – сүземнән, *үземән* – үземнән.

**Иҗекләр төшеп калу:** *қыну* – әд. кылану, *йүри қынаңмы* – әд. юри кыланасыңмы? *мә қынаң* – нәрсә кыланасың, *йәшенә* – яшеренә, *қараулый* – караwыллый (график. каравыллый), *қам беләм* – каян беләм, *арта* – ары табан, *әләнди* – әллә нинди.

Рус теленнән кергән алынма сүзләрдәге фонетик үзгәрешләр сузык авазларга да, тартык авазларга да карый: *әчки* > рус. очки – күзлек, *мишәк* > мешок – капчык, *әбизәтелни* > обязательно, *бал'ниса* > больница – шифаханә, *милисе* > милиция, *дум* > дом – өй, *кантур* > контора, *көзнич* > кузнец – тимерче, *чистра* > сестра, *кулча* > кольцо – боҗра, *сип* > цепь – чылбыр, *өлгөт* > льгота, *кутумка* > котомка, *кутулук* > котелек, *бырт* > пруд – буа, *куруб* > короб – тартма, *гелин* > глина – балчык, *бакус* > покос, *кушувка* > кошовка, *хәзәин* > хозяин, *бидерә* > ведро, *кәртүк* > картофель – бәрәңге, *малатук* > молоток – чүкеч, *эрис* > рис – дөге.

## Грамматик үзенчәлекләр

**Исемнәр.** Күплек санын белдерә торган *-лар/-ләр* кушымчасы әдәби телдә тиешле булмаган очракларда да саннарга, исемнәргә һ.б. сүз төркемнәренә ялгана һәм көчәйтү төсмере өсти: *Алар икәүләр* (икәү) *килгәннәр ийе. Сез әле малайлар* (малай) *ийегез без эшләгәндә. Йылаплар* (елап) *киттем аwыл буйлап. Үз күзем белә күрепләр қайттым қаланы.*

*-кай/-кәй* иркәләү кушымчасы, әдәби телдән аермалы буларак, җанлы предметны белдерә торган исемнәргә генә түгел, бәлки җансыз предметны белдерә торган сүзләргә һәм башка сүз төркемнәренә дә ялгана һәм иркәләү мәгънәсен югалта төшә.

*-кай/-кәй* кушымчасының туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләргә ялгану очракларына мисаллар: *Энекәйе қайтып ишекне ачып җибәргән. Абышқасын салдатқа алганнар бу бичәкәйнең. Балақайым, сине танымыймын қый. Ике хатынқай утырган да сеңнәгән. Сеңлекәйемнең хаты килгән. Кинжәкәй* (төпчек кыз) *қайтып килә.*

*-кай/-кәй* кушымчасының хайван атамаларына ялгану очракларына мисаллар: *Әнә, танакайым қайтып утыра. Сыйырны өйдә саудылар, бозауқайы да өйдә булды қышқыда. Кәжәкәйебезнең сөте күп. Инәкәй, танақайыбыз қайтмады. Борондық инәй булыр кеше танақайга тайандыра киленне. Шундыйларны бәк күп күрдек қолқайым. Анақай бәрәнем йугалды.*

*-кай/-кәй* кушымчасы ялгану очракларына тагын түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *Қолақай* (чукрак) *булгангадыр, быйыл кәкүк сақырганын* (кычкырганын) *ишетмәдем. Матур бизәкәйле түбәтәй кигән. Қалпақайны үзем бастым қызларга.*

Сөйләштә бер генә очракта түбәндәге форма теркәлгән: *пешмәкәйрәк* – пешеп җитмәгән. *Әллә пешмәкәйрәк* (пешеп җитмәгән) *булғанмы минең шәңгәләр?*

**Килешләрне кулланудагы үзенчәлекләр.** Исем сүз төркеменә караган үзенчәлек тартымлы исемнәрнең чыгыш килеше төрләнешендә табыла: *Сыйырыман* (әд. сыерымнан) *айырылдым исә, сөтсез утырым инде. Қаберемән* (әд. каберемнән) *эзне сыwытма. Син баламан* (баламнан) *дога көтәм. Күземән йуғалсын, эзе булмасын өйемдә. Қулыман* (кулымнан) *тотып атқа утырттылар мине. Өйөмән* (өемнән) *сыгып қастым.*

Сөйләштә исемнәр һәм алмашлыкларда бер килеш урынына икенче килешне куллану күренешләре дә бар:

*Букәннән утырың* – әд. бүкәнгә утыр.

*Айағынан* (аягында) *йөреп йатайы.*

*Безне* (бездән) *көлмә инде.*

*Сине* (синнән) *көләм мин тей.*

*Бер-береңне* (бер-береңнән) *көләң инде, син қарт сарық тоттың, қарт кешегә бараң тип.*

*Мийә* (мине) *ороша, мийә қырыша.*

**Тартым кушымчалары**. Урал татарлары сөйләшендә исемгә исем кушылып ясалган изафәнең тартым кушымчасыз вариантьы актив кулланыла: *Көлтә бау* (әд. көлтә бавы) *йасыйбыз. Барып қараң, теркелек арада* (наратлык арасында) *мәшкә табарсыз... Қул аркалар* (кул аркалары) *туңып китә. Қозоқ сыу* (бәке суы) *эсәбез қышқыда. Печин кәбән* (печән кибәне) *кәртә буйда. Өйкәртә уртада* (ишек алды уртасында) *тапчық* (йомычка) *йата. Аштабақ* (аш табагы) *кәрәксә мин үзем алырмын. Қолақ сырға* (колак алкасы) *тагып йөрделәр қызлар. Қарсыуга* (кар суына) *керәбез дә чыгабыз. Чыныйақ тыш* (чынаяк тәлинкәсе) *кәрәк.*

Татар телендә, билгеле булганча, *-ныкы/-неке* кушымчалары алган алмашлыклар һәм исемнәр аергыч функциясендә килә ал-

мыйлар. Ә Урал татарлары сөйләшендә *-ныкы/-неке* формалы алмашлыклар һәм исемнәр еш кына аергыч функциясен дә үтиләр һәм аерылмышның алдында да, артында да килә алалар: *Уралныкы сүзләрен* (Урал сүзләрен) *йазамсыз? Бүкән йабуныкы* (урындык япкычның) *өлгесен сурайыңмы? Безнең аwылныкы* (безнең авылның) *кыз бу. Бисәнеке энесе* (хатынның энесе) *балдыз була, сеңнесе дә балдыз була катынныкы* (хатынның). *Миснеке капкасын* (мич капкачын) *гелин* (< рус. глина – балчык) *белән сылый.*

Әдәби телдәге *бер күлмәге, олы кызы* кебек сүзтезмәләр сөйләштә *-сы/-се* тартым кушымчалары белән әйтелә: *Берсе малайы* (бер малайы) *киткән. Бу олсы кызныкы* (олы кызның) *малайы. Олсы кызыма* (олы кызыма) *бирдем бу мендәрне. Зурсы танакай* (зур тана) *көтүдән кайтмаган. Берсе шәкәр* (бер шикәр) *изәнгә төшкән.*

**Алмашлыклар.** I зат *мин* алмашлыгы иялек килешендә *минең* (әд. минем) формасында кулланыла: *Минең* (минем) *кызым сыйыр саwа фирмедә. Минең* (минем) *инәй бик күп сукты тастымалны. Минең* (минем) *ашны ашыймсыз? Минең* (минем) *сүз күп сүләргә.*

*Мин, син* зат алмашлыклары юнәлеш килешендә *мийә* (әд. миңа), *сийә* (сиңа) формаларында кулланыла: *Бер бидерә кәртүк (*бер чиләк бәрәңге*) бирә мийә* (миңа), *җитте сийә* (сиңа) *тей. Мийә* (миңа) *йуғыйы йер. Сийә* (сиңа) *саwыт кәрәкми. Мийә* (миңа) *асуланды. Сийә* (сиңа) *тындык* (тынычлык) *йук. Бирнәне инде аны бир сийә* (сиңа) *дә бир мийә* (миңа) *дип әйткәннәр.*

Аерым очракларда *мин, ул, шул* алмашлыклары юнәлеш килешендә *минеңә* (миңа), *аныңа, аныға* (аңа), *шуныга* (шуңа) формаларында кулланыла: *Минеңә* (миңа) *бер нәмә дә кәрәкмәй. Аныңа* (аңа) *каймак, саламсың? Аныға* (аңа) *барыға уйлама, нәселе шундый диләр. Алар кемгә бирәсе килә, шуныга* (шуңа) *бардык кейәүгә. Аныңа* (аңа) *килеп суға. Минеңә* (миңа) *күлмәк кайынып утыраңмы?*

Чыгыш килешендә алмашлыклар түбәндәге формаларда кулланылалар:

*мийән* (әд. миннән), *сийән* (синнән): *Ул мийән* (миннән) *олорак, мийән* (миннән) *кечкенәсе энекәй була. Мийән* (миннән)

*сурашып тора. Сийән* (синнән) *зурырағы тутай була. Мийән* (миннән) *азаққы балалар тастымал суқтылар, алчепрәкләр қайыдылар. Сийән* (синнән) *кечкенә қыз. Мийән* (миннән) *кече быратым бар.*

*Миңән* (миннән), *сиңән* (синнән), *аңан* (аннан), *моңан* (моннан), *үземән* (үземнән): *Миңан* (*әд.* миннән) *алда эшләделәр. Аңан* (аннан) *бер сүз дә ишетә алмассың. Моңан* (моннан) *белеки баласы. Үземән* (үземнән) *үзем ойалам. Аңан* (аннан) *оло кыз. Моңан* (моннан) *суңырақ килде.*

*Минеңән* (миннән): *Минеңән* (миннән) *сурадылар қый.*

Урын-вакыт килешендә *шуңында* (әд. шунда), *моноңда* (монда) формалары да очрый: *Шуңында* (шунда) *өйләнде, шуныңда* (шунда) *тора. Ике кис аныңда* (анда)*, ике кис моноңда* (монда) *қуналар.*

*Нәрсә* сорау алмашлыгының сөйләштә түбәндәге фонетик һәм лексик вариантлары кулланыла:

*мәсә: Мәсә* (нәрсә) *дигән аwыл? Мәсә* (нәрсә) *қондырып салалар мыса? Әллә мәсә* (әллә нәрсә) *қыландырып бетте. Мәсә* (нәрсә) *алып төштең бәй? Мәсә* (нәрсә) *дигән аwыл.*

*мәстә: Исеме мәстә* (нәрсә). *Мәшкә бик йақшы мәстә* (нәрсә).

*нәмә: Нәмәгә* (нәрсәгә) *матчаны сырлыйсың аны?*

*нә: Нә қый, мин малайға қыз алдым исә, җиңгә әзерләде ашсуны.*

*нимә: Бөтөн нимәне* (нәрсәне) *йыwаң.*

*нимәстә: Нимәстә* (нәрсә) *телийең, шуны эшлийем. Нимәстә* (нәрсә) *уқыйдыр, белмим. Безгә теләсә нимәстә* (нәрсә) *йарый. Нимәстә* (нәрсә) *генә салмыйлар ашқа.*

*мәә* – әд. нәрсәгә: *Мәә гәрәк* $у^{w}$*?*

Сөйләштә түбәндәге күрсәтү алмашлыклары бар: *әнә/ана, у/wы, бы/был, шуw/шул*. Сирәк очракларда төрле килеш кушымчалары алган *анау* (ул)*, монау* (бу) күрсәтү алмашлыклары да кулланыла: *Тастымалларны ағартырға монау* (бу) *тауға менә торған ыйық. Анауға* (аңа) *күп салдың, мийә* (миңа) *әз салдык, дип қыйышалар балалар. Әле мин монауда* (монда) *үзем генә торам. Әнә бәләкәй өй, минеке у* (ул). *Анау* (ул) *мүгештә тора. Аның*

*менәwе* (менә бу) *төшендә чире бар ыйы. Был* (бу) *әби йырақтан килгән. Урман был* (бу) *йақта, уw. Анау* (ул) *таудан монау* (бу) *тауға баралар. Ана* (әнә) *қый, йәш йегетләр қайтып килә. Анау нимәне* (ул әйберне) *алам тигән дә йығылған. Бы* (бу) *аwылда үзе генә тора.*

**Саннар.** Сөйләштә җыю саннары актив кулланыла: *Шулай өчәү* (әд. өч) *малай килеп керделәр өйгә. Икәүме* (икеме)*, дүртәүме* (дүртме) *мендәр кәрәк киленгә әзерләргә. Берәүне* (берне) *генә алып чығығыз ый. Үзе чыққан икә хуҗа, күргән, маңлайында берәү* (бер) *мөгөзе бар, дей. Берәү* (бер) *малай сандыққа утырып килә, сандықсы була. Алар бelә имеш, минең икәү* (ике) *бала туwарны. Эшләп йатайым, тағын берәү* (бер) *бала килеп тыуды, икәү* (ике) *булып киттеләр. Мин өс улан таптым, өсәwен* (өчесен) *дә өйдә таптым. Икәwен* (икесен) *дә қороталар, солоны да, бодайны да, арта тирмәндә тартып талқан оно йасыйлар. Туйда биш ат булды, бишәwендә* (бишесендә) *дә тастымал дугасында. Әтей дийеп энекәйем белән икәwебез* (икебез) *дә қысқырып йибәрдек.*

Җыю саннарының III зат берлек сандагы тартым кушымчаларын катлауландырып (*-сы/-се* өстәп) сөйләү очраклары бар: *Үзеңнең тыуған-тумаларыңның берәүсе* (берсе) *сыу йулы күрсәтергә сыға. Болар икәwесе* (икесе) *бер хөкемдә.*

Бүлем санына караган үзенчәлекләрдән *бер* санының *берәй* (әд. берәр) формасында кулланылуын күрсәтеп китәргә мөмкин: *Берәй* (берәр) *бәйрәмдә, ашта берәй* (берәр) *кеше сийа ошаса, әхирәт дус итәң, эләсең берәй* (берәр) *нимә. Берәй* (берәр) *нәрсә йапқандыр инде бидерәгә ныгытып. Қуwып қына чығарсалар ыйы, китәр ийе берәй* (берәр) *җиргә. Берәй* (берәр) *көн килерем сезгә. Менә берәй* (берәр) *сарығың сирләсә, өшкердең исә, терелә. Уйнарға кәрәк берәй* (берәр) *урында. Берәй* (берәр) *төрле бабайдыр дип атқа утыртып алып киткәннәр.*

Аергычлы сүзтезмәләрдә килгән *бер* санына *-сы/-се* тартым кушымчалары ялгану күренеше дә еш очрый: *Берсе* (бер) *малайы әрмийәдән килгән, берсе* (бер) *малайы киткән. Берсе* (бер) *күлмәге күренмей баланың. Берсе* (бер) *қызым агранум, берсе* (бер) *сыйыр*

*саwа. Берсе* (бер) *малайым Ҡазанда эшли. Берсе* (бер) *тастымалым кылупта тора.*

**Рәвешләр.** Сөйләштә вакыт рәвешләрен белдерә торган формалар әдәби телгә караганда киңрәк. Биредә вакыт рәвешләре кушымчалар, бәйлекләр һ.б. ярдәмендә ясалырга мөмкин.

*-кы/-ке* + *-лык/-лек* + афф. *-та/-тә*: *Арҡа суғыш уйныйбыз кичкелектә. Ҡышҡылыҡта утын күп кәрәк.*

Әдәби телдәге *ҡыш буйы, көн буйы* тибындагы конструкцияләр сөйләштә вакыт белдерә торган сүзләргә иялек килеше кушымчасы ялганып кулланылалар: *Ҡышның буйына* (кыш буе) *арҡан иштем. Әтнәнең буйы* (атна буе) *мунса индерә кендек әби уланны. Ҡырыҡ көннең буйына* (көн буе) *мунса йағып, ҡырыҡ көннең буйына* (көн буе) *мунса индерәләр уланны. Җите йылның буйына* (ел буе) *ҡорбанныҡ күтәрдем. Биш көннең буйы* (көн буе) *туй булды.*

Әдәби телдәге *йаз көне, җәй көне* тибындагы сүзтезмәләр урынына сөйләштә *йаз, җәй* дип кенә әйтелү очраклары да бар: *Йаз кеше кәрәкмәде аларға. Җәй китерербез сийа утын, тейделәр. Йаз ҡайтмасаҡ, көз ҡайтырбыз ҡунаҡҡа.*

Сөйләштә *-лый/-лей, -лай/-ләй/-лий/-ли* кушымчаларының рәвеш ясау активлыгы әдәби телгә караганда киңрәк: *Йәшләй киттем кейәүгә. Йылылый* (җылы көе) *тутырмыйлар күмәсләрне сандыҡҡа. Сөтләй бирәбез хөкүмәткә. Дүртенчелей суҡты паралис. Икенчелей керем дей. Беренчелей күрәм сезне. Йыларди булып чыгып киттем. Йөрердәй кешеләрне чаҡырыға кәрәк. Үзәккә үтәрди төртмәкәй теле бар. Ҡыйарларны ашарди булып үскән. Эшләрди йәшләр дә эшләми хәзер. Торғас сөйләрди булам төшемне. Мин беренселәй барғанда шартлама бешмәгән ийе әле, туңнай* (өлгермәгән көйе) *җыйалар шартламаны.*

*-лата/-ләтә* кушымчалары белән рәвеш ясау да еш очрый: *Ҡызға мәһәр сурыйбыз, әйберләтә, кийемнәтә дип. Майлата да, сөтләтә дә сатабыз. Итләтә түләдек бурычны.*

**Фигыльләр.** Әдәби телдән аермалы буларак, хикәя фигыльләрнең *-ай/-әй* зат кушымчалары белән ясалган очраклары еш күзәтелә: *йә ҡыз бармай* (бармый)*, йә малай алмай* (алмый)*,*

*йаратмай, малны кире қайтара қыз атасы. Кәртүкләр дә үсмәй* (үсми) *быйыл. Ашай* (ашый) *да йоқлай* (йоклый) *бу бала.*

Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең II зат берлегендә, әдәби формалар белән беррәттән, кыскартылган (диалекталь) вариантлар да кулланыла: *Бәлеш бешерәң* (пешерәсең), *сарық суйаң* (суясың). *Тоқмас кисеп салаң* (саласың) *үрәгә. Безгә киләңме* (киләсеңме)*? Қыйық та сүләшеп қуйаң* (куясың). *Бәләкәйдән ат өстендә йөрдем, беләңме* (беләсеңме), *белмиңме* (белмисеңме), *сыбай булдым. Башынан сыйпыйың* (сыйпыйсың), *арқасыннан сыйпыйың* (сыйпыйсың) *баланы. Қыйық та сүләшеп қуйаң* (куясың), *исәңгерийең* (исәнгерисең) *дә қалаң* (каласың). *Кемне көтәң* (көтәсең), *шул булып килә икә wы бисура. Мал қарыйсың инде аwылда.*

Хикәя фигыльләргә хас булган *-мын/-мен, -быз/-без, -сың/ -сең, -сыз/-сез* хәбәрлек кушымчалары фигыльләргә генә түгел, башка сүз төркемнәренә дә ялганырга мөмкин: *Без үсеп килгән кызларбыз* (кызлар). *Илле туғыз йәшмен* (яшь), *мин йәш түгелмен* (түгел) *инде. Мин сыбаймын* (сыбай – әд. атка атланган), *ыргыдым да саптым, йәш wахыт бит. Син шәпсең* (шәп) *айақсы булырға, син шундый остасың* (оста). *Барыбыз да йәш балалыбыз* (балалы), *баймын* (бай), *биш балам бар. Хәзер без бай кебекбез* (кебек). *Үгәй балалар қарадым бишне, шуңа лыстырмын* (*лыстыр* – начар) *мин. Кеше сүләсәләр мин ике қолағыма мамық тығып утырамын* (утырам), *мин саңғыраумын* (саңгырау) *дим. Мин тыңлап та утырмыймын* (утырмыйм) *кеше сүләгәнен. Тыңлап утырсаң да барыбер кеше сүләгәнен. Тыңлап утырсаң да барыбер кеше сүләгән кебексең* (кебек). *Син мөнәҗәткә остасыңдыр* (остадыр). *Икмәк исе искәп үскән кешемен* (кеше). *Сине әрләсә әхирәт дусың, син бер сүз дә әйтмичә борылып қына сыгып китәргә тейешсең* (тиеш). *Мин аwыл баласымын* (баласы) *қый. Нихәлдәсен?*

Сирәк очракларда хикәя фигыльнең *-ып/-еп* формалы хәл фигыль + *утыра* ярдәмче фигыле белән ясалган төре дә кулланыла. Мондый конструкцияле фигыльләр эш-хәлләрнең нәкъ сөйләү моментында, сөйләүченең күз алдында башкарылуын хәбәр итә:

*Минеке сыйыр килеп утыра. Килеп утыра икә кунаққа кейәү. Урамда сыбай ғына йөреп утыра. Ат үтеп утыра қый. Теге қортқа қаршы килеп утыра. Менә шундый хәл килеп утыра бездә.*

Гадәти, һәрвакыт булып тора торган эш-хәлләрне *-а, -ә, -й* формалы хәл фигыль + *торган* ярдәмче фигыле белән ясалган форма белдерергә мөмкин: *Йеләк бу йердә күп була торған. Урманда йылан күп була торған. Китәр йерем былса йоқлый алмый торған әле мин.*

Сөйләштә киләчәк заман хикәя фигыльнең I зат берлеге, тамыр яки нигезе *-р, -ыр, -ергә* беткән очракта, кыскартылып, *-ым, -ем* кушымчасы ялганып ясала: *Мин үзем барып алырым* (алырмын) *тей. Соңынан ғына әйтерем* (әйтермен)*, сине эзләтерем* (эзләтермен). *Торалғанчы тором* (торырмын) *да, торалмый башлагач қызыма китәрем* (китәрмен). *Бәйләп қуйарым* (куярмын) *бу танақайны. Камзул кийәрем* (киярмен)*, әмәйлек кийәрем* (киярмен) *дә барым* (барырмын) *әле. Өйдә мал қарарға тырышырым* (тырышырмын). *Мин үләрем* (үләрмен)*, син қалырсың.*

Категорик үткән заман формасы, татар әдәби телендәге кебек *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалары ярдәмендә ясала һәм зат кушымчалары алып төрләнә: *Байна чәй эчтем қый. Тимер миснең өстөндә кәртүкне өтөп сәй эстек. Ғәйнәгә барды қый. Сөрәндә суптарлы тастымал биреп йибәрдем.*

Нәтиҗәле үткән заман фигыльләрнең I зат берлек һәм күплек саннарында *-ган* кушымчасындагы *н* тартыгы төшеп калу актив күренеш: *Без сыуны итеп қуйғабыз* (куйганбыз) *мунсага. Без барып қайтқабыз* (кайтканбыз) *қалаға. Без қысылып қалғабыз* (калганбыз) *урыс араға. Без суқынмағабыз* (чукынмаганбыз). *Мин аш қуймағамын* (куймаганмын). *Мин ипи салғамын* (салганмын) *кесәмә. Саташқамын* (саташканмын) *қый. Менә монда аралық, мин сығып басқамын* (басканмын). *Мин инде бүлнистә булғамын* (булганмын). *Җуwына торған саwытқа салғамын* (салганмын) *сыуны.*

Аерым очракларда I зат кушымчасы бөтенләй кыскартыла: *Кәртүк бешергәм* (пешергәнмен). *Мин бөгөн йатым йоқлағам* (йоклаганмын). *Мин инде эштән қайтқам* (кайтканмын).

Тәмамланмаган үткән заман, әдәби телдәге кебек үк, *-а, -ә, -ый, -и* кушымчалы хәл фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясала һәм зат кушымчалары алып төрләнә. Ләкин *иде* ярдәмче фигыле фонетик яктан үзгәреп, *-ыйы/-ийе* формасында кулланыла: *Сыу буйына төшәйек* (төшә идек), *аймақ-аймақ булып утырайық* (утыра идек) *өйләрендә. Без көләйек* (көлә идек) *аның сүләшүwеннән. Эштән килүләренә ашарға әзерләп торайық* (тора идек). *Сыу ағайы* (ага иде) *урам буйлый.*

Сөйләштә әдәби телдәге *-ган + иде* формасына *-ды + иде* формасы туры килә, ягъни үткән заман хикәя фигыльнең *-ды/-де, -ты/-те* формасына *иде* ярдәмче фигыле кушылып, күптән үткән заман формасы ясала, *-ды + иде* формасында зат кушымчасы төп фигыльгә ялгана: *Қызым магазиндан алдыйы* (алган иде) *күлмәк. Җегерме җәштә килдем ийе* (килгән идем) *монда. Мин белеки чақта аwырдым ыйы* (авырган идем). *Бик әйбәт эшләдийе* (эшләгән иде), *бардыйы* (барган иде) *кейәүгә. Абзый аwылдан алдыйы* (алган иде) *қызны, шунда қунақлаштылар. Малайым үлде минең, ике қызы қалдыйы* (калган иде). *Алар кәртүк алдылар ыйы* (алганнар иде). *Мин эшләп бетердем ийе* (бетергән идем) *бу эшне. Син мөрҗәне ачтың ыйы* (ачкан идең). *Қалай мичтә пешердем ийе* (пешергән идем) *шәңгә. Мин күршегә бешердем ий* (пешергән идем) *қыз бәлеше.*

Кабатлаулы үткән заманның *-а, -ә, -ый/-и + торган* (*бара торган*) формасы актив кулланыла, бу яктан сөйләш әдәби телдән аерылмый: *Сүлей торғаннар ыйы, сыуның ийәсе бар дип. Элек ышкулда татарча уқый торғаннар ыйы. Шәңгәне күп пешерә торған ыйық туйга. Көне буйына кәбән қуйа торған ыйық. Малга кәртүк ашата торғаннар ыйы. Кәртүкне сатып ала торғаннар ыйы.*

Сөйләштә сирәк очракта түбәндәге форма да кулланыла: *торғабыз ыйы* – торган идек. *Икешәр қат беләзек ийе тәңкәле, шулай кейә торғабыз ыйы* (кия торган идек).

**Боерык фигыль.** Сөйләштә II зат боерыкның күплеге һәм берлеге *-ың, -ең, -ң* кушымчасы белән ясала: *Сәй эсеп утырың* (утыр). *Әйдә, сығың* (чык), *ашаң* (аша). *Кереқ* (кер) *безгә дә,*

*сүләшербез. Йуҡ әкийәтне сүләп утырмаң* (утырма). *Бер әтнәсез өйгә кермәң* (кермә). *Сураң* (сора) *да сураң* (сора) *аңан. Җиләккә барың* (барыгыз) *әле балалар. Әйдәң* (әйдәгез), *сәй эсәргә.*

**Теләк фигыль.** Татар әдәби телендәге һәм урта диалект сөйләшләрендәге кебек, *-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыль һәм *килә* ярдәмче фигыле белән ясалган форма субъектив теләкне белдерә: *Мынча инәсең киләме? Эшлисе килде исә, эшли. Ҡалаға китәселәре килми. Уҡысы килмәсә, эшләр.*

Боерык яки билгесез киләчәк заман хикәя фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән килгән формалар теләк-киңәш мәгънәсен белдерә: *Алыйы син ул китапны. Салмаң ыйы айағығыздан. Шунда чығ ыйы, безне көт ийе, берни булмас ыйы сийа.*

*-са/-сә + ыйы, ийе* (*иде*) формасы белән көчле теләк белдерелә: *Әзерәк җиләзрәк булсайы печин ҡороға, әйбәт булыр ыйы. Уҡытучы ҡыз мийә фатирға керәйе ҡый.*

Сөйләштә теләк-ният мәгънәсен *-ырга/-ергә + итә* конструкциясе дә белдерергә мөмкин һәм ул форма шактый еш очрый: *Сезгә йыр йырларға итәм. Кем беләҫ ҡайтырға итәң. Син мине сүләттерегә итәсең ҡый. Аны эшкә ҡуйарға итәм. Уҡымый ҡалырға итә. Ҡасарға иткән икә, тотҡаннар. Безне йәхәннәмгә йебәрегә итәләр. Барыға иткәйе* (иткән иде), *бармады.*

**Шарт фигыльләр.** Сөйләштә шартны белдерүнең *кәрәксә* (әд. кирәк булса) формасы актив: *Кисеб алың кәрәксә* (кирәк булса). *Ипей килеб алың кәрәксә* (кирәк булса). *Сезгә кәрәксә* (кирәк булса) *мичкә йағарбыз. Кәрәксә* (кирәк булса) *бездә җырлар бар. Кәртүк кәрәксә* (кирәк булса) *апҡалың. Сәй эсетәбез кәрәксә* (кирәк булса).

**Хәл фигыльләр.** Хәл фигыльләрнең әдәби телдәге *-гач/-гәч* формасы белән параллель *-гас/-гәс* кушымчалы формасы да актив кулланыла: *Син йазып беткәс* (язып бетергәч) *сыу төшәргә* (су коенырга) *барабыз. Ҡартайғас* (картайгач) *рәт йуҡ ҡый. Тирмән булмағач бырт йуҡ* (Тегермән булмагач буа юк). *Ике ҡызымның туйына бардым ҡартайғас* (картайгач). *Ҡунаҡлар килгәс* (*килгәч*) *сыйламый булмый. Баланны туңдырғач ҡына сыудан алам, сыwын түгәсең туңдыргач.*

Әдәби телдә *-ып/-еп* кушымчаларына беткән хәл фигыльнең юклык формасы тамырга *-мый/-ми, -мыйчы/-миче* кушымчалары ялганып ясала. Сөйләштә исә, хәл фигыльләрнең әдәби формалары белән бергә, *-май/-мәй, -майынчы/-мәйенче/-мыйынчы* кушымчалары белән ясалган юклык формалары да актив: *Қунақлар килгәс җырламый* (*җырламыйчы*) *утырма. Таwышланмый* (*тавышланмыйчы*) *ғына йыйыштым. Мичкә йақмай* (*якмыйчы*) *бер дә былмай. Эшкә сықмай* (*чыкмыйчы*) *утыра. Кәртүкләр дә үсмәй* (*үсмиче*) *утыра. Балтырған тапмайынсы* (*тапмыйчы*) *қайттық урманнан. Иңгелек қайтмайынсы* (*кайтмыйчы*) *интектерде танақай. Чәй дә эчми* (*эчмиче*) *көтеп утырадыр қызым. Күрмейенче* (*күрмиче*) *генә йазамсыз?*

Сөйләштә *-ганчы/-гәнче, -гансы/-гәнсе, -гынчы/-генче, -гынсы/-генсе* формалы хәл фигыльләр, әдәби телдәге кебек үк, төп эштән соң булган эшне, төп эшнең үтәлү вакытын яки үтәлү дәрәҗәсен белдерә: *Мин сыққансы* (чыкканчы) *көтөп утыра. Әтийем килгәнсе* (килгәнче) *торалар. Без килеп җиткенче* (җиткәнче) *йаныпбетте әйе.*

Сөйләштә югарыда күрсәтелгән формаларга параллель *-мас/-мәс* кушымчалы сыйфат фигыль + *борон* бәйлеге белән ясалган форма да еш очрый: *Уналтыға чықмас борон* (чыкканчы) *тотып кейәүгә бирделәр мине. Тормас борон* (торганчы) *чәй қуйған. Эшкә китмәс борон* (киткәнче) *сырла идәнне. Ашамас борон* (ашаганчы) *китеп барды. Чәй эчмәс борон* (эчкәнче) *эшкә кушалармыни. Без җатмас борон* (ятканчы) *ашығып килеп җитте. Намаз wахытта, көн тыумас борон* (туганчы) *баралар таңсыуға. Машинадан чығармас борон* (чыгарганчы) *җиргә мендәр салдылар киленгә бастырыға. Никах булмас борон* (булганчы) *кийәү өйөнә йорт күрегә баралар.*

*-мастан + алда* сүзе белән белдерелгән кушма форма шулай ук *-ганчы/-гәнче* формасына параллель кулланыла: *Йыраққа йибәрмәстән алда* (җибәргәнче) *барып килдем йанына. Кешегә суғардай алда* (сукканчы) *уйлаң әзерәк. Әрмийәгә китмәстән алда* (киткәнче) *без ул аwылға бардық. Үлмәстән алда* (үлгәнче) *гел сөйләде. Үзләре китмәстән алда* (киткәнче) *хатлары килде.*

*Сез килмәстән алда* (килгәнче) *атлы туй узғардылар аwылда. Бабай үлмәстән алда* (үлгәнче) *тау боронына сыу қарарға бардық.*

**Сыйфат фигыльләр.** Сөйләштә киләчәк заман сыйфат фигыльләрнең *-ыр/-ер* кушымчалы формасы кулланылышы һәм мәгънәсе ягыннан, әдәби телгә караганда, киңрәк. Мәсәлән, *-ыр/-ер* формалы сыйфат фигыль предметның хәзерге заманга карый торган билгесен, сәләтен белдерә һәм бу очракта *-а + торган* формалы сыйфат фигыльгә туры килә: *Қызны шул алып китер сақта сеңнейләр. Қарар кешесе былмаса, үзе эшкә чықса, аптырый баланы нишәтергә. Элек чабыр җир бирмәделәр, йыраққа китеп печин чаптық. Өшкерүнең әйтер сүзләре бар анықлы. Басилка килер wахыт йетте. Инде чақырыр кешем дә бетте. Мал сығарыр йер йуқ. Менә йүкә төшөрер wахыт йеттеме әле. Китер әле қабар нәрсә. Кейәүгә китер қыз қайтты.*

*-ыр/-ер* формалы сыйфат фигыль киләчәктә булырга тиешле эш-хәрәкәтне ачыклый һәм бу очракта татар әдәби телендәге *-асы/-әсе, -ачак/-әчәк* формалы фигыльләргә туры килә: *Нимәстә күрерне белмибез, нимәстә күрергә йазған, шуны күрәбез. Изге сүз әйтерне көтөп торабыз. Туй төшкәндә, қапқадан кереткәндә, борондоқ инәй булыр кеше сарық тотоп тора.*

Сөйләштә *-у/-ү* формалы фигыльгә *-лы/-ле* кушымчасы ялганып ясалган сыйфат фигыльләр дә актив кулланыла: *Мунча йағулы, пилмин қайнатулы, қоймақ пешүле булды кейәүгә. Чымылдық қайулы, күлмәк қайулы, запун қайулы, кейәү мендәре дә қайулы булды.*

**Инфинитив.** Әдәби телдә һәм сөйләшләрдә еш кулланыла торган *-ырга/-ергә* кушымчалы фигыльләр инфинитивның төп формасы булып тора: *Мин эрләргә үрәндем, менә қәйнәм эрләргә белмәй.*

*-ырга/-ергә* формалы инфинитив *белү, башлау* ярдәмче фигыльләре белән килгәндә, әдәби телдәге *-а/-ә, -ый/-и* формалы хәл фигыльләр мәгънәсендә кулланыла: *Үземнең исемне йазарға беләм* (яза беләм). *Бездә киптерергә белмәйләр* (киптерә белмиләр) *мәшкәне. Эш күп, чәчәргә башладық* (чәчә башладык).

*Чәч ағарырға башлады* (агара башлады). *Уқырға белмим* (укый белмим) *доғаны. Намаз уқырга белгән* (укый белгән) *җите әбейгә хәйер таратабыз қорбаннықта. Аwылда үсеп ничек йөзәргә белмәсең* (йөзә белмәссең)*, кәмәдә ишәргә дә беләм* (ишә беләм), *йөзәргә дә беләм* (йөзә беләм). *Син аңлатырға белмийеңме* (аңлата белмисеңме)*?*

Сөйләштә инфинитивның, *-ма/-мә, -мага/-мәгә* формасы *итә* ярдәмче фигыле белән килеп, теләк-ният мәгънәсен белдерү очраклары бар: *Йегетләрне күрмә итәңме? Тағы йаумаға итеп тора йаwын. Қайнама итә самаwыр. Бы йаққа чығарып қуйма итәм. Син мине сүләндермә итәң қый.*

Сирәк очракларда инфинитивның *-мага/-мәгә* кушымчалы формасы да кулланыла: *Йегетнеке эти-әниләре қызнықы эти-әниләренә йәрәшмәгә* (ярәшергә) *киләләр, димләмәгә* (димләргә). *Қачан боҗал қуйабыз* (вакытын куябыз) *туйға дип сурамаға* (сорарга) *киләләр.*

Сөйләштә сирәк очракларда инфинитивның борынгы *-мак/-мәк* формасы *кәрәк* сүзе һәм *ничек/нисек* сорау алмашлыгы белән кулланыла: *Нисек моно алмақ кәрәк!*

**Эшнең үтәлеш дәрәҗәсен белдерә торган фигыльләр.** Татар телендә *-гала/-гәлә* кушымчасы фигыльләргә эш яки хәлнең эзлекле кабатланып тору мәгънәсен өсти. Ләкин сөйләштә бу кушымчаның *-гыла/-гелә, -кыла/-келә* формасындагы әйтелеш үзенчәлеге бар: *Мәшкә кискеләп* (кискәләп) *пычағымны йуғаттым. Әпәй кисә белмим, өзгелим* (өзгәлим)*, йыртқылыйм* (ерткалыйм). *Тотқыламаң* (тоткалама) *әпәйне, абыйың жирәнер. Булғалый* (булгалый) *өмөже бездә. Хаты килгели* (килгәли) *қызның, үзем дә барғыладым* (баргаладым). *Барғылыйбыз* (баргалыйбыз) *балыққа, қышқыда балық тотқыладық* (тоткаладык). *Қыз бәлешен кискелиләр* (кискәлиләр) *туйда, бөтә кеше аwыз итә.*

**Фигыль юнәлешләрендәге үзенчәлекләр.** Сөйләштә фигыль юнәлешләренең түбәндәге үзенчәлекләре күзәтелә.

Татар әдәби телендә төп юнәлештә йөри торган кайбер фигыльләрне сөйләштә кайтым юнәлеше күрсәткече белән

куллану бар: *Қулың үрәнеп китә қайынырға* (каерга). *Тегендем* (тектем) *дә, қайындым* (каедым) *да ғомер буйы. Кичтән утырғанда уйнадық та, бәйләндек* (бәйлэдек) *тә. Қаз қанаты белән себеренәбез* (себерәбез). *Сез ашаның* (ашагыз) *элеке. Йазынып* (язып) *қына эшлимсез? Йазынсаң йазын* (язсаң яз). *Аwыртындым* (авырдым) *қый быйыл.*

*Бетү* фигыле йөкләтү юнәлешендә *-ыр, -ер, -р* кушымчаларыннан башка әйтелә: *һаман кисеп бетмиләр* (бетермиләр) *урманны. Арышны урып беттеләр* (бетерделәр). *Печинне кәбәнгә қуйып беттек* (бетердек). *Қақсыны* (казылыкны) *ашап беттек йазгыда. Кәртүк қазып беттек* (бетердек).

Сөйләштә әдәби телдәге *-кыр/-кер* кушымчалары белән әйтелә торган сүзләрне йөкләтү юнәлешендә *-кыз/-кез, -гыз/-гез* кушымчалары белән ясау киң таралган: *Қулына тотқозды* (тоттырды) *бүләкне. Тайансық дип сарық китереп тотқызалар* (тоттыралар) *қызга. Таудан ғына күргәзгәннәр* (күрсәткәннәр) *аwылны. Ашлық башын бетереп җиткезә* (җиткерә) *йәшен. Бақчасында маллар йатқыза* (яткыра). *Өч йөзгә җиткезә* (җиткерә) *бәйәне. Сезне идәнгә йатқызырым* (яткырырмын). *Безнең хәзрәтебез үлде, шуның тәүлеген үткәзделәр* (үткәрделәр). *Җитенне қар астында йатқызып* (яткырып) *йомошаталар.*

*Үстерү* сүзе, әдәби телдән аермалы буларак, *үскерү* формасында еш кулланыла: *Ашлық үзебез үскердек* (үстердек). *Җирне күберәк алган кеше күб үскергән* (үстергән) *ашлықны. Минең қәрт әтийем күп үскергән* (үстергән) *ашлықны.*

Әдәби телдәге *эсселәндерү* сүзе сөйләштә *эсетү* вариантында очрый: *Сәй эсеттем* (эсселәндердем)*, эсеп алың.*

**Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр.** Сөйләштә түбәндәге бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр кулланыла.

Әдәби телдәге *чаклы, кадәр, хәтле* бәйлекләренең сөйләштә фонетик һәм лексик вариантлары күзәтелә:

*чикле: Иртәгә әбиткә чикле* (чаклы) *йоқларсыз;*

*сәкле: Утызға сәкле* (чаклы) *өйләнмәде;*

*тикле: Қараңғыға тикле* (кадәр) *эшләде;*

*тиңке: шул тиңке* (кадәр) *ақыл бирдем;*

*Өчен* бәйлеге, төрле сүз төркемнәре белән килеп, әдәби телдәге *булганга күрә* мәгънәсенә туры килә: *Йалқыч өчөн* (күңелсез булганга) *бәйләп утыра. Кәҗинкәдә салқын өчөн* (салкын булганга) *май қуйабыз. Чирле өчөн* (чирле булганга) *пинсийәгә чығардылар. Торба қысқа өчөнгә* (кыска булганга) *қайтара төтенне. Шоморт күп үскән өчөнгә бездә шоморт оны йасыйлар:*

*тәңгәлендә* – әд. янында. *Кылуп тәңгәлендә тора;*

*тәңгәл* – нәкъ. *Белеки баласы тәңгәл өс йәштә;*

*қабырғасына* – әд. янына. *Күрше өйнең қабырғасына килеп йатқан сыйыр;*

*чүрәсенән* – әд. тирәсеннән. *Аның чүрәсенән қышның буйы китеп булмый;*

*бөрнә* – әд. саен. *Өй бөрнә кереп йөрде бер малай;*

*арта, артабан* – әд. аннан соң. *Сықтым да киттем арта. Мылтық аталар артабан. Арта йылға буйда сыу төшәң, теләк телиң йаwын йаумағанда;*

*шай, шайы* – әд. кебек. *Безгә килде шай. Ул бармады шай. Хәзер йуқ шай қақсы тутыручы. Хәзер шәңгә пешермиләр шай. Йаланда күп булаты шоморт, быйыл йуқ шай. Суққан тастымаллар бар шай. Қызы бар шай.*

**Теркәгеч һәм кисәкчәләр.** Сөйләштә *исә* теркәгече, әдәби телдәгегә караганда, активрак кулланыла: *Қандаланың берсе чәйнәдисә, йоқы қача. Сурадылар исә, үзем кереп алам. Печин нық үстисә, чабам. Сөреме чықтисә, башқа тийә. Беренче боз йаудисә, бала-чага ашыйлар. Җилләде исә, йаңғыр йаwа.*

Сөйләштә *мыса, маса* > *мы исә* кушылмасы икеләнүне, шикләнүне белдергән очракларда кулланыла һәм ул шактый актив: *Ул йегерме алтының маса. Қызыл күлмәк кигәне кем маса. Нимәстә салалар мыса имнәп. Нимәсә дигән аwыл мәсә? Берәй ыстакан бал бирделәр мыса, йуқ мыса, шул өчәү малайга.*

Сөйләштә әдәби телдәге *-да/-дә* теркәгеченең *-дагын/-дәген* формасы да еш очрый: *Баланы чапты дағын* (чапты да) *арта төндөктән бәрде йапырақны. Менә өстәлгә әзерләп қуйған дағын* (куйган да) *абыйың ашанып китеwенә башынан қойоп та җибәргән бозло сыуны. Бардым дағын* (бардым да) *кердем*

*өйләренә. Бирдем дәген* (бирдем дә) *қайттым йазыуны. Писук алып қуйаң дағын* (куясың да)*, варинйә қайнатаң.*

Сөйләштә *қый* кисәкчәсе актив кулланыла: *Бал қорт сага қый. Саwытны сайқап тутырыға кәрәк қый. Қайынып утырғас күзең бетә қый. Хәзер ақтан кийенә қый қызлар.*

Сөйләштә сорау җөмләләренең ахырында *бәй* кисәкчәсен куллану хас: *Башы ничек сың әле бәй? Җырның башы ничек бәй? Мәсә алып төштең бәй? Мәсә қынаң бәй?*

Сорау кисәкчәләренең кулланылуында түбәндәге үзенчәлекләрне күрсәтергә мөмкин:

Әдәби телдә сорау кисәкчәсе һәрвакыт фигыльнең яки хәбәрнең азагына ялганып килә (*күрәсезме?*)*,* ә сөйләшләрдә берлек һәм күплек санда II заттагы хәзерге заман хикәя фигыльләрдә сорау кисәкчәсе фигыльнең нигезенә ялгана: *Син аны beләмсең* (беләсеңме)*? Қазанда торамсың* (торасыңмы)? *Сыуған ашыйымсыз* (ашыйсызмы). *Исән йатамсыз* (ятасызмы)*? Журнал сығарамсың* (чыгарасыңмы)*? Сабантуйны қаршаламсыз? Песәнгә барамсың йаланға?*

Сирәк очракларда *барамсыңмы* (әд. барасыңмы) формасы да очрый: *Сабантуйга тастымал бирәмсеңме, шәл бирәмсеңме* (бирәсеңме)*?*

II зат *-сың/-сең* кушымчалы фигыльләргә *-мы/-ме* сорау кисәкчәсе ялгануда түбәндәге үзенчәлек күзәтелә. *Барасың, киләсең* формалы хәзерге заман хикәя фигыльләр кыскарып, *бараң, киләң* формасын ала, сорау кисәкчәсе фигыльнең азагына ялгана: *Урманға йүкә төшерергә бараңмы* (барасыңмы)*? Сәй эсәңме* (эчәсеңме)*? Атыңны йәллиңме* (жәллисеңме)*, үзеңне йәллимсең?*

Сирәк очракларда түбәндәге диалекталь форма да очрый: *Қызыңны сагынмыйыңмы* (сагынмыйсыңмы)*? Син белмийеңмени* (белмисеңмени)*?*

## Тормыш-көнкүреш һәм фольклор

### *Йүкә өмәсе*

– Йүкәне суға салып йомшартабыз. Карт йүкә кәрәкми, йәш йүкә әйбәт төшә.

### *Чупта сугу*

– Йүкәдән чупта суктылар. Шул чуптаны кыш көне тирләгән атның аркасына йаптылар. Йоқақ қына була ул чупта. Барыбыз да суқтық чуптаны.

Йүкә ул өлгергәнче суда йата. Аны төшерәләр мунчаласын, чабатага да, чуптага да йарый.

Йүкәне урманнан қыш көне дә алып қайтабыз, аны пешеклибез. Ул йомшара йүкә. Шулай қубып тора пешекләгәч.

### *Чабата*

– Чабата үрәбез, қалыбы бар чабатаның. Шөшлесе бар, без шуларны күреп үстек. Урыс чабатасы, татар чабатасы була. Жыл әйләнәсе чабата кидек.

Чабатаның асты туза, җамап кийәбез. Тула ойоқ белән чабата кидек, туласы булса әле.

Кимә ката, ки чабата,  
Чабата җайлы җата…  
Чабата җасый белмәгән  
Ташу суwына бата.

Чабатаны үреп, базарда ипигә алыштырып кайта торган ыйык.

*Әптерәк авылы*

Аwыр сугыш йылларында тудык,  
Балда-майда гына үсмәдек.  
Аwыл йулларында шадраланып калды  
Минем кигән чабата эзләрем.

Йаңа чабатага сөйенеп,  
Бик күп шатлык күрдек ул чакта.  
Йаңа чабатаны күкрәкләргә кысып,  
Куана идек без ул чакта.

Йаңа чабаталар киеп
Күрше йегете үсеп җитте.
Үсеп буйга җитүгә ул
Сугыш кырларына китте.

Бала чагым белән бергә
Күрше йегете китте – кайтмады.
Ул бит миңа чабаталар йасый иде.
Ул бит миңа бер сүз әйтмәде.

### *Агыйделләрдә йумасам*

Агыйделләрдә йумасам,
Агармый беләкәйем.
Әллә суларга актымы
Теләгән теләкәйем?
Әллә җилләргә истеме
Теләгән теләккәйем?

Йырла, дустым, йырларыңны
Йыр йуwатыр үзеңне.
Уйың булса да уйлама,
Уй саргайтыр йөзеңне.

Карлыгачкай кара, муйыны ала
Аwаларга менеп йугала.
Аталардан бала йәш кала,
Күкрәк көче белән мал таба.

Аwаларга менгән аккошларның
Каурыйлары койыла җирләргә.
Үзе дә йук, сүзе дә йук
Калды инде сагынып сөйләргә.

Уфа дисең дә карыйсың
Уфаның йакларына.
Үкенечле сүзең булса,
Йаз, иркәм, хатларыңда.

Ай йанында йакты йолдыз,
Минем йолдызым гына.
Таң алдыннан ул да сүнә,
Калам йаңгызым гына.

*Чулпан авылы*

### *Арыслан авылында кунак каршылау җырлары*

Арыслан буйларын су алган
Басулар күмелеп калган.
Кунакны җырлап каршылау
Ата-бабадан калган.

Басмыйм дисәң дә басарсың
Баскычларын сырлаган.
Сезне җырлап каршылыйбыз
Бик ераклардан килгән.

Алын алыйык микән?
Гөлен алыйык микән?
Сезнең өчен алма булып
Өзелеп төшиек микән?

Кайдан килдегез сез безгә
Батмайынча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә
Ни хөрмәт итийек сезгә.

### *Сайрый былбыл гөлләрдә*

Сайрый былбыл, сайрый былбыл,
Сайрый былбыл гөлләрдә.
Бәгырем бергә булсак икән
Без киләчәк көннәрдә.

Былбыл булсам бакчаларда
Бер агач сайлар идем.
Шул агачта сине мактап
Иртә-кич сайрар идем.

Бакчаларга кергәнем юк
Гөлләр тигез үсәме?
Җил аркылы сәлам әйтәм
Җилләр сезгә исәме?

Тәрәзәмнең төпләрендә
Зәйтүн дигән гөлләр бар.
Сиңа ошатып сөйләр идем
Сиңа ошаган кемнәр бар.

Йөгерә-йөгерә җитә алмыйм
Тал чыбыктан үтә алмыйм.
Син матурым исемә төшкәч,
Капкан ашны йота алмыйм.

Өй артындагы бакчада
Син тирәк булсаң иде.
Шул тирәкнең төпләрендә
Мин җиләк булсам иде.

Җыйдым җиләк, җыйдым җиләк,
Җыйдым да кабалмадым.
Сиңа ошаган алсу чәчәк
Эзләдем – табалмадым.

Безнең янда салкын чишмә
Гәрәбә эри торган.
Бер сандугач булсын икән
Арада йөри торган.

Иртән торып тышка чыксам,
Ишек алларым томан.
Шул томан араларында
Син бәгырем торган сыман.

*Арыслан авылы*

### ***Никрут озату***

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм, кайталмам инде
Сынса сабыр канатларым,
Сабыр итә алмам инде.

Китәм инде, китәм инде,
Китәм, инде кайгырма.
Мин тайанган кулбашыңа
Йатларны тайандырма.

Китәм, диден, китәм, диден,
Китсәң, мине алып кит.
Йә утларга, йә суларга
Йәлләмәсәң салып кит.

Китәм, диден, китәм, диден,
Китәм, диден дә киттең.
Минем нурлы йөзләремә
Лимун сарысы сиптең.

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китсәң, кала күлмәгең.
Күлмәгеңне энең кийәр,
Сөйгәнеңне кем сөйәр?

Китәм, дустым, китәм, дустым,
Китәм, дустым, каласың.
Мин булмагач, кемнәр сөйәр
Син сандугач баласын.

Без аwылдан чыккан чакта
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар!

– Ат белән озатканнар, кулҗаулык болгап. *Күрәчәй* йылгасында туктап, тап-такыр итеп йегетнең чәчен алганнар. Чәчен әнисе өйенә алып кайтып, төреп матчага кыстырып куйган.

*Арыслан авылы*

МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

**Нязепетровск районы**

**Арыслан авылы:** Хәбибуллина Земфира Фатих кызы (1972 елгы), Арсланова Мәрьям Мозаффар кызы (1963 елгы), Гарифуллина Любовь Анатольевна (1957 елгы), Василова Лена Булатовна (1973 елгы), Хөснуллина Динә Зиннәт кызы (1956 елгы), Хаттабова Җәүһәрия Сәет кызы (1962 елгы), Рәхмәтуллина Гөлнур Хәмидулла кызы (1953 елгы), Мөхәррәмова Ләлә Низам кызы (1954 елгы), Бәдретдинова Янисә Хаттаб кызы (1954 елгы), Мөхәррәмова Роза Низам кызы (55 яшь).

**Әптерәк авылы:** Нурисламова Нәфига Әдһәм кызы (80 яшь), Усманова Бибимәккә Вәли кызы (1939 елгы), Байгильдинова Шәмсийамал Касыйм кызы (79 яшь), Хәсәнов Руфан Мәгъсум улы (50 яшь), Нәбиева Мәсүрә (85 яшь), Хәйруллина Вәсилә.

**Аргавыл** (Юсупово): Хәйруллина Вәсилә, Гыйлемшина Раилә Бәдертдин кызы (79 яшь), Ямалтдинова Мәсхүдә Гыйльметдин кызы (1932 елгы).

**Чулпан авылы:** Галиуллина Әния (1932 елгы), Гыйззәтуллина Мәдинә, Гыйззәтуллин Вагыйз, Вафина Фагыйлә Хәбиб кызы (78 яшь), Сакаева Тутыя Әгъзәм кызы (76 яшь), Нурисламова Нәфига Әбелйан кызы (80 яшь).

**Уй районы**

**Әмин авылы:** Сәгыйтова Миңсылу Сәлимйан кызы (92 яшь), Бикулова Фәнүзә (укытучы).

## НАГАЙБӘК СӨЙЛӘШЕ

Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районы Кили (Кассель), Сарашлы (Остроленко), Париж, Фершампенуаз, Астафьевка, Требий авылларында һәм Чибәркүл районы Варлам, Попово, Болотово, Краснокаменка, Ключевская авылларында нагайбәкләр дип йөртелә торган керәшен татарлары яши. 1924 елга кадәрге административ бүленеш буенча бу авыллар Оренбург губернасының Верхнеуральск өязенә караганнар.

Нагайбәкләр – биргә патша хөкүмәте тарафыннан күчереп утыртылган татарлар. Алар XIX гасыр урталарына кадәр Уфа губернасының Бәләбәй өязе Нагайбәк ныгытмасы карамагында казнага ясак түләп яшәгәннәр. Соңыннан, башкорт бунтларында катнашмаган өчен, Нагайбәк ныгытмасы территориясендә көн күргән керәшеннәр ясактан азат ителгән, җирләр үз кулларына бирелгән. 1748 елдан башлап, бу керәшеннәр казак катламына кертелгәннәр һәм алардан махсус казак полклары төзелгән. Нагайбәкләр 1842 елга кадәр Бакалы авылы (хәзер район үзәге) һәм Нагайбәк ныгытмасы тирәләрендә яшәгәннәр. Ләкин 1842 елда казак кантоны бетерелгәч, Бакалы һәм Нагайбәк станицаларына караган авыллардан казак гаиләләрен Оренбург губернасының Верхнеуральск өязенә күчереп утырткannар. Рус армиясенең сугышларда ирешелгән уңышларын мәңгеләштерү максатыннан, нагайбәк керәшеннәре яшәгән авылларга чит илләрдәге шәһәрләрнең исемнәре бирелгән: Париж, Варлам, Фершампенуаз, Требий һ.б. Халык хәтерендә әле бүгенге көннәрдә дә авылларның элекке, борынгы исемнәре дә саклана. Мәсәлән: *Балылы* (Париж), *Сарашлы* (Остроленко), *Кили* (Кассель) һ.б.

Шулай итеп, нагайбәкләр күп еллар дәвамында татар халкының төп өлешеннән читтә, башка халыклар (казакъ, башкорт, руслар) чолганышында яшәгән. Шуңа карамастан, сөйләш үзенең төп фонетик һәм грамматик үзенчәлекләрен югалтмаган, зур үзгәрешләргә дучар булмаган. Чөнки аларның күчереп утыртылуларына да әле күп вакыт узмаган. Башка сөйләшләрне бүлеп чыгаргандагы кебек, нагайбәк сөйләше дә территориаль-лингвистик принципларга таянып билгеләнә.

Хәзерге вакытта нагайбәкләр үзләре дә Казан ягы керәшеннәре белән кардәш икәнлекләрен онытмаганнар, алар үзләрен «иске ил керәшеннәре» дип атыйлар. Нагайбәкләрнең һәм элекке Казан, Уфа губерналарында яшәгән керәшеннәрнең теле берберсеннән бик аз аерыла. Бу турыда моңа кадәр Көньяк Урал һәм Урал арты төбәкләрендәге татар сөйләшләрен өйрәнүче галим Ф.Й. Йосыпов хезмәтләрендә дә ачык һәм нигезле итеп әйтелгән.

Нагайбәк сөйләшендәге әдәби телдән аермалы булган үзенчәлекләр урта диалектның башка сөйләшләре, бигрәк тә Казан арты керәшеннәре сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтәләр.

## Фонетик үзенчәлекләр

**Сузыклар**. Кайбер авазларны исәпкә алмаганда, сузыкларның әйтелеше ягыннан сөйләш татар әдәби теленнән нигездә аерылмый. Үзенчәлеге итеп, түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

Казан арты керәшеннәре сөйләшенең Мишә буе, керәшен пакшин, ташкирмән, Кукмара урынчылыкларындагы кебек, нагайбәк сөйләшендә дә *а* авазы ачык, иренләшмәгән сузык аваз: *аш, алты, арба, баш, сал, қар, қарға.*

Ләкин *а* авазының сөйләштәге әйтелеше барлык фонетик позицияләрдә дә бертөрле түгел. Ул беренче иҗектәге ирен-ирен *о* авазы йогынтысында берникадәр иренләшә: *бора$^{о}$у, боза$^{о}$у, бодa$^{о}$й, монда$^{о}$ғы, тора$^{о}$лар* һ.б.

Нагайбәк сөйләшендә *ә* авазының ике төрле варианты бар: 1) әдәби вариант. Ул төрле фонетик шартларда һәм һәртөрле позицияләрдә килә ала: *әнә, әкрен, әби, бәке, бәлеш, тәкә, күгәрчен* һ.б.; 2) Казан арты керәшеннәре сөйләшенең Мишә һәм Кама буе урынчылыклары, шулай ук нократ һәм мордва-каратай сөйләшләрендәге кебек, әдәби әйтелешкә караганда таррак *ә* варианты. Ул нигездә тар, *и, э* (*е*) сузыклары булган иҗекләрдән соң килгәндә кулланыла: *җиргә, киңәш, эченә, пешерә, кешеләр, шикәр, печәннәр* һ.б.

Сөйләштәге башка сузыкларның әйтелеше татар әдәби теленнән аерылмый.

Аваз тәңгәллекләре. Нагайбәк сөйләше сузык авазлар системасындагы тәңгәллекләр белән дә урта диалект сөйләшләренә якын тора. Әдәби телдән аермалы булган үзенчәлекләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

*ы, е ~ а, ә -ғынчы/-генче* формалы хәл фигыль кушымчаларында күзәтелә: *җатқынчы* – йатканчы (ятканчы), *булғынчы* – булганчы, *торғынчы* – торганчы, *җыйылғынчы* – җыйылганчы (җыелганчы), *күргенче* – күргәнче һ.б.;

*у ~ о.* Әдәби телдәге ирен-ирен *о* сузыгын ирен-ирен *у* авазы белән алыштыру түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *сурашу* – сорашу, *суң* – соң, *бутқа* – ботка;

*ы ~ у* күренеше бер төркем сүзләрдә генә теркәлгән: *быйау* – буяу, *былышу* – булышу, *җамансылау* – йамансулау (ямансулау);

*ө ~ ү.* Бу күренеш Астафьевка авылында *бөгөн* – бүген, *төгөл* – түгел сүзләрендә теркәлгән;

*ү ~ ө: үнәр* – һөнәр.

Сингармонизм күренешләре. Сүзләрдәге калынлык-нечкәлек һәм ирен гармонияләре, әдәби телдәге кебек, эзлекле рәвештә үткәрелә. Шулай да сингармонизм күренешләрендә нагайбәк сөйләшен татар әдәби теленнән аерып торган кайбер үзенчәлекләр бар.

Ирен-ирен *о–ө* сузык авазлары үзләреннән соң килгән иренсез *ы–е* сузыкларын иренләштерәләр, ягъни әдәби орфоэпик норма саклана: *болон* – болын. Ирен-ирен *о–ө* сузыклары үзләреннән соңгы иҗекләрдәге киң *а, ә* сузыкларына да тәэсир итәләр, ягъни *а, ә* сузыклары берникадәр дәрәҗәдә иренләшәләр: *боза*$^{о}$*у, қола*$^{о}$*қ, көйә*$^{ө}$*нтә, көрә*$^{ө}$*ш, көлтә*$^{ө}$*, төймә*$^{ө}$*, өйлә*$^{ө}$ һ.б.

Әдәби телдә калын әйтелә торган сүзләрне нечкәртеп (*әрчү* – арчу, *җәбешү* – йабышу, график. ябышу), яки, киресенчә, нечкә әйтелә торган сүзләрне калын итеп (*макрум* – мәхрүм, *мына* – менә) сөйләү очраклары бар.

**Дифтонглар.** Нагайбәк сөйләшендә, нигездә, татар әдәби теле һәм урта диалект сөйләшләренә хас дифтонглар кулланыла. Үзенчәлек итеп *-ей/-ый, -эw>/-ыw* дифтонгларын күрсәтергә мөмкин.

*-ей* дифтонгы ачык иҗектәге алгы рәт тар *и* сузыгына тәңгәл килә: *кей* – ки, *кейтер* – китер, *кейәү* – кийәү (кияү), *җитмей* – җитми, *Күчтей* – Костя, *үгей* – үги һ.б.; *-ий* > *-ей* күренеше татар сөйләшләре өчен чит күренеш түгел. Мәсәлән, ул Урал һәм Себер төбәкләрендәге татар сөйләшләре өчен дә характерлы үзенчәлек булып тора.

Әдәби телдәге иҗек һәм сүз азагындагы (бигрәк тә исем фигыль кушымчасында) ирен-ирен *у–ү* сузыкларына сөйләштә *-ыw/-еw* дифтонглары туры килә: *тыwған* – туган, *қыw* – ку, *җыw* – йу (ю), *ырыw* – ыру, *сыw* – су, *сыwсау* – сусау, *китеw* – китү, *бетеw* – бетү һ.б.

Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр сөйләшендә әдәби телдәге *-өй* дифтонгын монофтонглаштыру, ягъни ирен-ирен алгы рәт озын *ү* сузыгы әйтү очраклары түбәндәге сүзләрдә теркәлгән: *үрәтеw* – өйрәтү, *сүрәү* – сөйрәү, *үрә* – өйрә.

**Тартык авазлар.** Аларның әйтелеше ягыннан нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый.

Үзенчәлекләр, нигездә, аваз тәңгәллекләренә, ассимиляция һәм диссимиляция, авазлар өстәлү яки төшү күренешләренә кайтып кала. Ирен-ирен яңгырау *б* тартыгы, шулай ук рус һәм рус теле аркылы кергән алынмалардагы ирен-теш *в* тартыклары берничә сүздә ирен-ирен *м* соноры белән тәңгәлләшә: *майтақ* – байтак, *мәндә* – бәндә, *қорман* – корбан, *нирмы* – нервы, *минаwат* – рус. виноват, *митамин* – витамин.

*б ~ w: бағыт* – wакыт (вакыт), *бәғдә* – wәғдә (вәгъдә). Урта диалект сөйләшләренә хас булганча, нагайбәк сөйләшендә бу күренешнең киресе дә бар, ягъни *w ~ б: таwып* – табып, *қаwып* – кабып.

*н ~ л: җондоз* – йолдыз.

*н ~ м* күренеше билгеле бер төркем сүзләрдә: *җаwын* – йаwым (явым), *ағын сыw* – агымсу.

Әдәби телдәге *чорнау, тырнау, җилен* сүзләрендә, киресенчә, тел очы *н* тартыгына ирен-ирен *м* авазы тәңгәл килә: *чормау, тырмау, җилем.*

Чибәркүл районындагы нагайбәкләр сөйләшендә *ң* авазы кайбер очракларда тел очы *н* тартыгына туры килә: *мен* – мең, *тан*

*ата* – таң ата, *сун* – соң, *туна* – туңа, *сезнен* – сезнең, *beләсенме* – беләсеңме һ.б.

Түбәндәге сүзләрдә саңгырау *т* тартыгына яңгырау *д* авазы тәңгәл килә: *дән* – тән, *дигәнәк* – тигәнәк, *дары* – тары, *дөркөм* – төркем.

*п ~ ф.* Билгеле булганча, татар теле сөйләшләре өчен өрелмәле *ф* авазы хас түгел. Күп кенә сөйләшләрдә ул ирен-ирен саңгырау *п* тартыгы булып әйтелә. Нагайбәк сөйләшендә дә татар әдәби телендәге ирен-ирен, рус телендәге ирен-теш *ф* тартык авазларына *п* тартыгы тәңгәлләшә: *тупыраҡ* – туфрак, *пайда* – файда, *җапыраҡ* – йафрак (яфрак), *нәпес* – нәфес, *таупиҡлы* – тәүфыйклы, *сыпат* – сыйфат, *җепәк* – йефәк (ефәк), *Марпа* – Марфа, *Упа* – Уфа һ.б.

*с ~ ч.* Берничә сүздә генә әдәби телдәге *ч* тартыгына *с* авазы тәңгәлләшү теркәлгән: *сийә* – чийә (чия), *сит кеше* – чит кеше, *әтәс* – әтәч. Рус алынмаларында исә, киресенчә, *с* тартыгын *ч* авазы белән алмаштырып сөйләү системалы характерда: *эчтинә* – рус. стена, *начыла* – насилу, *Нәчти* – Настя, *Мәкчем* – Максим, *Ычтапан* – Степан һ.б.

Казан арты һәм Түбән Кама керәшеннәре сөйләшләрендәге кебек, нагайбәк сөйләшенә дә *җ*-ләштерү хас. Әдәби телдә тел уртасы *й* тартыгы белән әйтелә торган сүзләр биредә *җ* авазы белән әйтеләләр: *җәм* – йәм (ямь), *җаҡын* – йакын (якын), *җыл* – йыл (ел), *җөрөй* – йөри; алынма сүзләрдә: *дөнжа* – дөнйа (дөнья), *пыраулинжа* – рус. правление, *личинжә* – рус. лечение, *памилжә* – рус. фамилия.

Гомумкерәшен сөйләшләренә хас булганча, әдәби телдәге тирән тел арты *х* тартыгына, системалы рәвештә, тирән тел арты *ҡ* тартыгы тәңгәлләшә: *ҡалыҡ* – халык, *ҡат* – хат, *ҡәбәр* – хәбәр, *мәҡрүм* – мәхрүм, *җаҡшы* – йахшы (яхшы).

*ғ, ғ~ҡ, к* күренеше түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *бағыт* – әд. бәхет, *игенче* – икенче, *тығырыҡ* – тыкрык, *гәрәз* – кәрәз.

Ассимиляция күренеше. Прогрессив ассимиляция. *м, н, ң* авазларыннан соң кушымчаларда *л > н: җәннек* – җәнлек, *урманныҡ*– урманлык, *көннәшә* – көнләшә, *җаwымны* – йаwымлы (график. явымлы), *зийенне* – зиһенле.

Регрессив ассимиляция. *б, м* авазлары алдында килгән *н > м: килгәмме* – килгәнме, *барғамбыз* – барганбыз, *куреммu* – күренми. Бу күренеш ике сүз янәшәлегендә дә булырга мөмкин: *уйым белән* – уйын (уен) белән, *қолом бар* – колын бар һ.б.

*к/к, ғ/г* алдында килгәндә, *н, л* авазлары, еш кына, *ң* авазына күчәләр: *урманға* – урманга, *әңки* – әнки, *суңга* – сулга, *җаңғыш* – йалгыш (ялгыш), *җаңғыз* – йалгыз (ялгыз).

Саңгырау *ш* тартыгы үзеннән алда килгән беренче яки икенче иҗектәге *ч* тартыгын тулысынча охшашландыра: *шишмә* – чишмә, *шаршау* – чаршау, *шәршәмбе* – чәршәмбе, *шыршы* – чыршы.

Регрессив ассимиляция түбәндәге сүзләрдә дә чагыла: *чыйырчық* – сыйырчык (сыерчык), *систый* – рус. чистый, *сусинкы* – рус. чёсанки.

Аваз өстәлү. Әдәби телдән аермалы буларак, түбәндәге сүзләрдә аваз өстәлү күренеше хас: *быргыту* – ыргыту, *җеп җегерләү* – җеп эрләү, *гәрләү* – әрләү.

Сүз уртасында һәм сүз ахырында *р* авазыннан соң *т* өстәлә: *җомортқа* – йоморка ( йомырка), *чыбыртқы* – чыбыркы, *кәбәрткә* – кәбәркә (мич аралыгы); *т* авазы алдыннан *р* өстәлү бер генә сүздә: *шарт күңелле* – шат күнелле; юнәлеш килешендәге алмашлыкларда *ң* авазыннан соң *г* өстәлү: *шуңгар* – шуңа, *моңгар* – моңа, *аңгар* – аңа; *ң* өстәлү *тәңгәрәтү* – тәгәрәтү сүзендә дә теркәлгән.

Аваз төшү. Татар әдәби теленә гарәп-фарсы телләреннән кергән фарингаль *h* тартыгы нагайбәк сөйләшенә дә хас түгел: *әwәс* – һәwәс, *аwа* – һаwа, *җәнәм* – җәһәннәм, *шәәр* – шәһәр, *аман* – һаман.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрдә тирән тел арты *ғ* тартыгы, кагыйдә буларак, төшә: *әдәт* – ғәдәт (гадәт), *айып* – ғәйеп (гаеп), *үмер* – гомер, *за*$^{й}$*ип* – зәғиф (зәгыйфь).

*н* авазы түбәндәге сүзләрдә төшә: *қурқыч* – куркыныч, *муча* – мунча; *асат* – ансат, *җәнәм* – җәһәннәм, *муйса* – муйынса.

*Булу, килү, тулу, илтү* фигыльләре нигезендәге *л* авазы түбәндәге очракларда әйтелми:

а) нәтиҗәле үткән заман формасында: *буған* – булган, *тыуған* – тулган, *кигән* – килгән, *иткән* – илткән;

ә) *-ғанчы/-гәнче* кушымчалы хәл фигыльләрдә: *буғанчы* – булганчы, *тыуғанчы* – тулганчы, *кигәнче* – килгәнче, *иткәнче* – илткәнче;

б) хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасында *л* тартыгы *булу, илтү* фигыльләрендә генә төшә: *бумый* – булмый, *итмей* – илтми.

Саңгырау *п, т* тартыклары кыскару: *ҫутару* – куптару, *тапау* – таптау.

Тел уртасы *й* тартыгы түбәндәге сүзләрдә төшә: *ҫачан* – кайчан, *ҫачаҫ* – кайчак, *сыпат* – сыйфат.

### Грамматик үзенчәлекләр

Грамматика өлкәсендә нагайбәк сөйләшен әдәби телдән аерып тора торган үзенчәлекләр күп түгел. Сөйләштә табыла торган үзенчәлекләрдән күренгәнчә, ул урта диалектның башка сөйләшләренә, бигрәк тә казан арты һәм керәшен сөйләшләренә якын тора.

**Исем.** Ялгызлык исемнәренең ясалышындагы үзенчәлекләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

Нагайбәкләрдә, гомумән керәшен татарларындагыча, кыскартылган ялгызлык исемнәренә төрки телләргә хас борынгы эндәшү килеше күрсәткече *-ай/-әй, -ый/-ей* ялгап сөйләү киң таралган: *Ибый* – Иван, *Гөрей* – Григорий, *Пилей* – Филин, *Татый* – Татьяна, *Анный* – Анна, *Сабый* – Савелий, *Лизый* – Лиза, *Үлей* – Ульяна һ.б.

Үз итеп, иркәләп яки кечерәйтеп әйткәндә, ялгызлык исемнәренең кыскартылган нигезенә *-ук/-үк, -кай/-кәй* кушымчалары ялгана: *Санук* – Александр, *Барук* – Варвара, *Кәтүк* – Катя, *Мәтүк* – Матрена, *Үлкәй* – Ульяна, *Пидуҫай* – Федора, *Урекәй* – Ирина, *Аннуҫай* – Анна һ.б.

Кеше исемнәренә *-уш/-үш* кушымчасы ялгап сөйләү үз итү мәгънәсен өсти: *Баруш* – Варвара, *Натуш* – Наталья, *Пидуш* – Федора.

*-ҫай/-кәй* кушымчасы ялгызлык исемнәренә генә түгел, җансыз әйберләрне белдерә торган сүзләргә дә, башка сүз төркемнәренә дә ялгана ала, бу яктан сөйләш Түбән Кама тирәсе керәшеннәре һәм Урал төбәгендәге башка татар сөйләшләре белән

охшашлык күрсәтә: *Бәрмәнчекәй* (бәрмәнчек – «песи»ле тал ботаклары) *була оло көнгә атна қалдырып. Малайлар китә бәрмәнчекәйгә. Монда жыйылып бәрмәнчекәй боткасы пешерәбез. Инәбезнең инәсен жырақай дибез. Ашадықай эчтек, қөрмәт күрдек, Тау итийек* (рәхмәт әйтик) *чибәрләп. Жырақай жирләрне жақын итеп, Наруш килдем сезне күрергә. Сезнең кеwекәй асыл кеше Жәнәшә дә тирәдә қайда бар? Жулқайларға чығып жуллар уңса, айырылмас дуслар булабыз.* (Халык жыры)

Исемнәрнең килешләр белән төрләнүендә диалекталь үзенчәлекләр күзәтелми. Тик Чибәркүл районында яшәүчеләр сөйләшендә генә юнәлеш килешендәге исемнәрне килеш кушымчасыннан башка да куллану очраклары бар: *Ызлатаwыс* (Златоустка) *китәсезме? Мийәс* (Мийасска) *китәсезме? Сез Қазан қайтасызмы инде?* Мисаллардан күренгәнчә, бу үзенчәлек ялгызлык исемнәре һәм *киту, бару* фигыльләре янәшәлегендә генә күзәтелә.

**Алмашлыклар** өлкәсендә түбәндәге үзенчәлекләрне күрсәтергә мөмкин.

*Мин, син* зат алмашлыклары юнәлеш килешендә *мыйа/мийә, сыйа/сийә* формаларында кулланыла: *Ул кеше мыйа* (миңа) *әйтә болай дип. Сийа* (сиңа) *бер майлаған сийә* (чия) *ашатып буламы, жуқмы инде? Бирнә буғач бир сийа* (сиңа) *да бир мийа* (миңа) *дигәннәр элекеләр. Оло көндә* (пасхада) *күкәй жыйабыз, мийа* (миңа) *тәбикмәк кирәкми, күкәй кирәк, дибез.*

*Ул* зат алмашлыгының юнәлеш килеше *аңға, аңғар, аңар* формаларында әйтелә: *Аңға* (аңа) *ғына әйтермен дә үзем киткән булырым. Жырлап бирәм мин аңғар* (аңа). *Жаңа кийәүгә киткән жәш киленнәр була, аңар* (аңа) *бара да бистәр* (сөлге) *сорый сөрәндә.*

Сөйләштә *әнә, менә* күрсәтү алмашлыкларының *ана, мына* вариантлары да йөри: *Минем қызым ана* (әнә) *теге өйдә генә тора. Мына* (менә) *малай қайтып килә. Мына* (менә) *нардуған тақмағын Бируш* (Вера) *әйтеп күрсәтер қәзер.*

Нагайбәк сөйләшендә *шул* күрсәтү алмашлыгының борынгы *шу* варианты да кулланыла: *Шу* (шул) *кеше кергәнийеме безгә? Шу* (шул) *кешегә бара да әйтә. Мына шу* (шул) *зур қазанға сыу*

*салдылар, иман уқып баланы чуқындырдылар. Без қызны шу* (шул) *җегеткә бирмибез, диләр.*

Нагайбәк сөйләшендә, Түбән Кама керәшеннәре сөйләшенең бакалы урынчылыгындагы кебек, *ней, нәмә, нәмәкәй, нәстә, нәстәкәй, нәмәстәкәй* сорау алмашлыклары актив: *Нәмәкәй* (нәрсә) *сурасаң да белә ул қарт. Мин дә бер нәмә* (нәрсә) *әйтийем әле. Бичуркаға* (рус. вечеринка) *кем нәмәкәй* (нәрсә) *алып килә, мин ипей алып киләм, син алып киләсен май.*

Сөйләштә борынгы *қандай* алмашлыгы да кулланыла. Мәгънәсе һәм функциясе белән бу алмашлык татар телендәге *нинди* сорау алмашлыгына туры килә: *Қандай* (нинди) *кеше ул? Қандай* (нинди) *гына кешеләр күрмисез инде сез! Қандай* (нинди) *җырулар турысында килдегез? Қандай* (нинди) *озон күлмәкләр кийеп җөрей?*

**Рәвеш.** Сөйләштә кушымчалар ярдәмендә ясалган рәвешләр үзенчәлекле.

*-ча/-ча* кушымчасы, зат алмашлыкларына һәм *шул* күрсәтү алмашлыгына турыдан-туры ялганып, охшату-чагыштыру рәвешләре ясый: *Син беччә* (безнеңчә) *үрәнеп бетптен инде. Минчә* (минемчә), *анда сыйа барырға кирәгийе, Питүккә* (Петяга) *түгел. Синчә* (синеңчә), *без кем булабыз инде? Синчә* (синеңчә) *ничек әйтергә кирәк? Минчә* (минемчә), *болай җырлау дөрес түгел. Беччә* (безнеңчә) *алай тәберсен итәләр. Синчә* (синеңчә), *аш, тәмне буғанмы?*

*Қыш, йаз, җәй, көз, иртән* кебек вакыт белдерә торган сүзләргә *-лық/-лек* + *-қа/-кә* кушымчасы ялганып, вакыт рәвешләре ясала. Мәгънәләре буенча бу рәвешләр әдәби телдәге *көнозын, көн буйы, төнозын, төн буе* һ.б. тезмәләргә туры килә: *Кенәген көннөккә* (көн буе) *шуны сөйләп утырды. Көннөккә* (көн буена) *эшкә чығып китәсен.* Шундый ук типтагы (*-лық/-лек*) рәвешләрнең урын-вакыт килеше кушымчасы белән кулланылу очраклары да бар: *Қышлықта* (кыш көне) *итне күп, ашыйбыз. Көзлектә* (көз көне) *җаwымнар күп булды.*

Вакыт рәвешләре вакыт белдерә торган исемнәргә катлаулы *-ғылықта/-гелектә* кушымчалары ялгану юлы белән дә ясала:

*Сыйырны төнгелектә* (төнлә) *абзарда тотарға кирәк, тышта салқын була. Маллар җәйгелектә* (җәен) *аман җаланда җөри. Элгәре тула суғарларыйы төнгөлектә* (төнлә), *өмә җасарларыйы.*

Нагайбәк сөйләшендә *көнозақ* (көнозын), *төнозақ* (төнозын) сүзләре дә кулланыла: *Бу бала көнозақ* (көнозын) *җаза да җаза. Төнозақ* (төнозын) *җоқладым рәқәтләнеп.*

**Фигыльләр**. Затланышлы формалар. Хикәя фигыль. Нагайбәк сөйләшендә, Казан арты һәм Түбән Кама керәшеннәре сөйләшендәге кебек, *-ый/-ий* хәл фигыленнән ясалган хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлеге теләк фигыльләр белән бер төрле ясала, ягъни *-ыйым/-ийем* (*барыйым* – барыйм, *эшлийем* – эшлим) формасында әйтелә.

Бу фигыль, әдәби телдәге кебек, берничә мәгънә төсмере белдерергә мөмкин:

эш-хәлләрнең нәкъ сөйләү моментында башкарылуын: *Җуқ әле, җоқламыйым* (йокламыйм)*, сезгә иртәгә ашарға, ашау пешереп җөрийем* (йөрим). *Менә чебешләрне санызйым* (саныйм) *әле, ничә қалған;*

сөйләү вакытына туры килмәгән, һәрвакыт гадәти булып торган эш-хәлләрне: *Мин әр җаз сайын үлән ашы ашыйым* (ашыйм). *Кешенекен күрмийем* (күрмим) *дә, белмийем* (белмим) *дә. Мин қайнар аш ашамыйым* (ашамыйм);

башлану вакыты ачык билгеле булмаган дәвамлы эш-хәлләрне: *Қарт булсам да эшлийем* (эшлим);

теләк мәгънәсен: *Бүген китмийем* (китмим) *әле. Безгә барып бер самавыр чәй эчийек* (эчик) *бергә-бергә.*

Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр сөйләшендә хәзерге заман хикәя фигыльнең I затын *-мын/-мен* кушымчалары белән ясау очраклары да бар: *Мин аны җақшы беләмен* (беләм). *Уйлыймын да, уйлыймын* (уйлыйм). *Қаз өмәсендә бер җыл да қалғаным җук, күзикмәк пешерәмен, җоланы тотамын* (тотам). *Җорт ийәләре бар, шуларға атап җыл да бер қаз суйамын* (суям).

Сирәк кенә булса да хикәя фигыльнең *-ып/-еп* формалы хәл фигыль һәм *утыра* яки *җата* ярдәмче фигыльләре белән ясалган

төре кулланыла. Бу форма эш-хәлләрнең нәкъ сөйләү вакытында башкарылуын белдерә: *Мин ашарға пешереп утырам. Қайан килеп утырасың. Сыйыр көтүдән қайтып җата. Ана Аннау* (Анна) *килеп җата. Урманда җаңғыр җаwып утыра. Қазаннан килеп утырасыңмы?*

Билгеле үткән заман формасы, татар әдәби телендәге кебек, *-ды/-де* кушымчасы ярдәмендә ясала һәм икенче төркем зат кушымчалары белән төрләнә: *мин алдым, без алдық* һ.б.: *Нардуғанда дөйә булып кийендем дә чығып киттем урамға. Җапрақ бәйрәмендә қайын алып қайттық урманнан.*

Нәтиҗәле үткән заман, әдәби телдәге кебек, сыйфат фигыльнең үткән заман формасына нигезләнә һәм зат белән төрләнә. I затта берлек һәм күплек санда килгәндә, фигыль нигезендәге *н* авазы кушымчадагы *м, б* авазларына охшашлана: *Мин барғаммын да баргаммын* (барганмын), *анда барасы түгел икән. Без эшләгәмбез дә эшләгәмбез* (эшләгәнбез) *элгәре, күлмәк тә теккәмбез* (теккәнбез), *ипей дә пешергәмбез* (пешергәнбез).

Тәмамланмаган үткән заман, әдәби телдәге кебек, *-а/-ә, -й/-и* кушымчалы хәл фигыль һәм *иде* (сөйләштә: + *-ыйы/ -ийе*) ярдәмче фигыле ярдәмендә ясала һәм зат кушымчалары белән төрләнә: *Без Нәчтей* (Настя) *белән бергә барайық, ул лафкадан чығып килә. Сез теге көнне нәрсә эшлийегез? Нардуғанда өй барончы бийергә чығайық.*

Күптән үткән заман, әдәби телдәге кебек, *-ган* формалы сыйфат фигыль + *-ыйы/-ийе* (иде) ярдәмче фигыле белән ясала, зат кушымчалары ярдәмче фигыльгә ялгана: *Барғаныйық әле кичә генә алар җағына, ул күренмәде. Без килеп җиткәндә, афтабуз киткәнийе инде. Утырмаға киткәннәрийе, тиз генә қайтып та җиттеләр.*

Кабатлаулы үткән заманның сөйләштә берничә төре бар.

Хәл фигыльнең *-а/-ә, -й* формасына борынгы *-дыр/-дер* кушымчасы + *-ыйы/-ийе* (иде) ярдәмче фигыле белән ясалган форма үткәндә булган гадәти, кабатланып торган эш-хәлләрне белдерә: *Элек кийәү ат белән чығадырыйы. Дәдәй безне бик*

*йаратадырыййы. Элек май чабадырыйыйк мачлинчада* (рус. масленица). *Без киндер суғадырыйыйк күлмәк-ыштанға.*

Югарыда күрсәтелгән формаларның синонимы буларак, *-ыр/-ер* кушымчалы хәл фигыль + *-ыйы/-ийе* (иде) ярдәмче фигыле белән ясалган конструкция дә сөйләштә бик актив. Юклык (*-мас/-мәс*) кушымчасы фигыль нигезенә, ә зат кушымчалары ярдәмче фигыльгә ялгана: *мин барырыйым, син барырыйың, ул барырыйы; без барырыйык, сез барырыйығыз, алар барырыйы // барырларыйы; мин бармасыйым, син бармасыйың, ул бармасыйы; без бармасыйык, сез бармасыйыгыз, алар бармасларыйы.* Мәсәлән: *Раштуwа* (рус. Рождество) *көнне балалар чығарларыйы, сийа керә, мийа керә, җырлый. Кеше танытмыйынчы өй барончы җөрөрләрийе.*

Кабатлаулы үткән заманның *-а/-ә, -й торган + -ыйы* (иде) формасы нагайбәк сөйләшендә шулай ук еш кулланыла: *Мин җәш багытта да бик җырлый торғаныйым. Алар сату итә торғаннарыйы. Без элек ат белән җөрөй торғаныйык.*

К и л ә ч ә к з а м а н х и к ә я ф и г ы л ь н е ң сөйләштә түбәндәге формалары кулланыла:

*-ыр/-ер* формасы. Әдәби телдән аермалы буларак, сөйләштә аның кыскартылган варианты да очрый: *Мин мунчаны үзем булдырып кайтырым. Өйне җыйыштырым син қайтыуга. Үзем барым да бирем.*

Киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә *-асы/-эсе* кушымчалы фигыльләр дә шактый актив: *Ул да иртәгә барасы* (барачак, барырга тиеш). *Анда җиләкнең бетәсе* (бетәчәге) *дә җуқ. Қыш урталарында кайтасы* (кайтачак, кайтырга тиеш), *ди.*

Нагайбәк сөйләшендә, сирәк кенә булса да, *-ачақ/-әчәк* формасы да очрый: *Шулай дисәң генә күңелле булачақ. Алар эрәтләнәчәк қәзер.*

Т е л ә к ф и г ы л ь. Нагайбәк сөйләшендә теләк, теләк-ният мәгънәләрен белдерә торган түбәндәге формалар һәм конструкцияләр күзәтелә:

*-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыль һәм *килә* ярдәмче фигыле белән ясалган аналитик тезмә, татар әдәби телендәге кебек, субъ-

ектив теләкне белдерә: *Минем дә барып, қарыйсым килә аларның өйләрен. Қунақларның ашыйсылары килә торғандыр инде;*

II зат боерык фигыль һәм *иде* (*-ыйы/-ийе*) ярдәмче фигыленнән торган төзелмә киңәш мәгънәсендә кулланыла. Ләкин ярдәмче фигыль, әдәби телдән аермалы буларак, зат күрсәткече алмый, зат мәгънәсе *син* алмашлыгы ярдәмендә ачыклана. Мондый форма әд. *-ырга/-ергә иде* (*+ ыйы/-ийе*), *-ырға кирәк иде* тезмәләренә туры килә: *Син тегесен дә алыйың* (ал идең), *монасын да алыйың* (ал идең). *Бәләкәй қараватта йатыйы син* (йат идең – ят идең);

*-ыр/-ер* кушымчалы сыйфат фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле тезмәсеннән торган форма зат, берлек һәм күплек санда төрләнә, әдәби телдәге кебек, сөйләүченең киләчәктә булачак эш-хәлләрне үтәргә, башкарырга теләген белдерә: *Мин дә синең белән Сарашлыға барырыйым* (барыр идем), *бергәләп иркенгә чығып қайтырыйық* (кайтыр идек). *Их, урманға барырыйым* (барыр идем) *айақларым аwыртмаса, җиләк җыйып қайтырыйым* (кайтыр идем) *чәй эчәргә;*

II зат берлек һәм күплек санда бу форма киңәш, киңәшле теләк, боеру төсмерләрен чагылдыра: *Айағыңа кийәрийең* (кияр идең), *бүген көн салқын бит. Син дә барырыйың* (барыр идең) *шунда, кеше барғанда.*

Киләчәк заман хикәя фигыльнең III зат күплеге дә, *-лар* кушымчасы һәм билгеле бер интонация белән әйтелгәндә, сөйләүченең башкарылырга тиешле эш-хәлләргә карата уңай мөнәсәбәтен, теләк-киңәшен белдерә: *Утырырлар, аш эчәрбез. Аны анда калдырмаслар, җыйыбрақ қуйарлар.*

Нагайбәк сөйләшендә *-ғай/-гәй* кушымчасы, урта диалектның башка сөйләшләрендәге кебек, юклык кисәкчәсе *-ма* белән генә килә ала һәм булуы мөмкин эш-хәлләрне белдерә: *Җаңғыр җаумағайы әле, чамалағыз. Җәй бик эссе торды, урақ бағытында җаңғырлар башланып китмәгәйе. Чәй қуйығыз, қунақлар килеп җитмәгәйе.*

*-ғай/-гәй* кушымчалы фигыльләр, ихтималдан саклану, булырга мөмкин эш-хәлләрне белдерү белән бергә, татар әдәби телендәге кебек, искитмәү мәгънәсендә дә кулланыла: *Абзар*

*түбәсеннән сыу үтә, үтмәгәйе, печән бетте инде, череп җатасы җуқ.*

*-мақ/-мәк* кушымчалы фигыль һәм *була* ярдәмче фигыле белән ясалган тезмәләр теләк-ниятне белдерә: *Син аның белән ничек тормақ* (тормакчы) *буласың? Ул анда үзе бармақ* (бармакчы) *булды.*

Татар әдәби телендә ният-максат мәгънәсендә *-мақчы/-мәкче* һәм *була* (бармакчы була), *-мақчы/-мәкче* һәм *иде* (бармакчы иде) аналитик формалары да йөри. Нагайбәк сөйләшендә, әдәби телдән аермалы буларак, ният-максат мәгънәсендә I зат берлектәге *-мақчы* + *-м* синтетик формасы да кулланыла. Мәсәлән: *Көтеүгә берәрсен җаллап та кушмақчым* (кушмакчы булам), *беркемне дә таба алмыйым. Мин аларға бармақчым әле* (бармакчы булам).

*-мәкче* кушымчасы алган *әйтү* фигыле (әйтмәкче) сөйләштә, себер диалектларындагы кебек, кереш сүз буларак йөри, әдәби телдәге *әйтмешли* сүзенә туры килә: *Син әйтмәкче* (әйтмешли), *әллә нинди уйлар уйлап утырам. Ул әйтмәкче* (әйтмешли), *җырчы таwық кеwек берүзем утырам җыру җырлап.*

Максатлы ният, теләк мәгънәсен сөйләштә *-ырға/-ергә* кушымчалы инфинитив һәм *итә* ярдәмче фигыле белән белдерү дә актив: *Идән җыwарға итә* (юмакчы була) *минем қызым. Бүген буран чығарға итә* (чыкмакчы була).

Урта диалект сөйләшләрендәге кебек, ният-максат мәгънәсендә *-асы/-әсе* һәм *була* (яки *иде*) конструкциясе дә килергә мөмкин: *Аш пешерәсе* (пешермәкче) *булып тотондым. Иртә белән киләсе* (килмәкче) *булып китте әле ул безгә.*

Б о е р ы к ф и г ы л ь л ә р н е ң формалары һәм мәгънә төсмерләре ягыннан нагайбәк сөйләше әдәби телдән аерылмый: *Бар әле, дәдәңнең қапчық аwызын тотоп тор. Нәчтә, безгә қунаққа кил.*

Ф и г ы л ь ю н ә л е ш л ә р е. Нагайбәк сөйләшендә фигыль юнәлешләренең төркемчәләре, аларның күрсәткечләре, нигездә, әдәби телдәгедән аерылмый. Бу өлкәгә караган үзенчәлекләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Казан арты һәм Түбән Кама керәшеннәре, Урал һәм Себер төбәге сөйләшләрендәге кебек, *уздыру* фигыленең йөкләтү юнә-

леше *-ғар/-ғыр* кушымчасы белән ясала: *Аннары тийәберсенен* (искә алу мәҗлесен) *узғарғанда* (уздырганда) *ашын бирә, өчөн, туғызын, қырығын узғаралар, җылын узғаралар. Бездә узғаралар* (уздыралар) *икән тәберсен, минем инәмә алар табақ җасый. Быйыл ике таwык, бер әтәч суйып, тәберсен узғардым* (уздырдым), *моннан болай узғара* (уздыра) *алырмынмы, җуқмы.*

Йөкләтү юнәлешендә *-қыз/-кез* кушымчасын куллану аерым фигыльләрдә генә күзәтелә: *Әйбер пешереп җиткезә* (җиткерә) *алмыйм. Аны йуғарға менгезеп* (менгереп) *җибәрдем. Җепне үткәзәсең* (үткәрәсең) *көрөдән, қылычтан.*

Чибәркүл районында яшәүчеләр сөйләшендә, сирәк кенә булса да, төп юнәлеш мәгънәсен кайтым юнәлеше күрсәткече белән белдерү очраклары бар: *Бу җегетебез туқтаусыз җазынып* (йазып – график. язып) *утыра. Малайым аwыртынып* (авырып) *тора.*

Әдәби телдәге йөкләтү юнәлеше формасында әйтелә торган *бетерү* фигыле сөйләштә төп юнәлеш формасында әйтелә: *Идәнне дә җыwып, эшен эшләп беткән* (бетергән). *Шулай итеп, сабанны бетеп* (бетереп) *қайта торғаныйык. Әйберне элеп беткәч* (бетергәч) *тә күчтәнәч чыға.*

Эшнең үтәлеш дәрәҗәсе нагайбәк сөйләшендә, нигездә, *-ғала/-гәлә, -ыңқыра/-еңкерә* кушымчалары ярдәмендә белдерелә. *-ғала/-гәлә* кушымчасы мәгънә ягыннан әдәби телдән аерылмый.

*-ыңкыра /-еңкерә* формасы эш-хәрәкәт, хәлләрнең бераз кимлеген, тулы булмавын белдерә. Сөйләштә бу форманың кулланылышы әдәби телдәгегә караганда киңрәк: *Қапчығың тулыңқырап* (тулып) *җитмәгән. Мин белеңкерәмим* (белеп җиткермим) *аны. Безнекеләр җаратыңқырамый* (яратып бетерми) *аны. Алырға ақчам җитенкерәмәде* (җитеп бетмәде). *Пируқның ите пешеп җитенкерәмәгән* (пешеп җитмәгән). *Җаулықлар кибеп җитенкерәмәгән* (кибеп җитмәгән).

Югарыда күрсәтелгән формалардан тыш, тагын бер үзенчәлекне күрсәтеп китәргә кирәк: күплек кушымчасы *-лар/-ләр, -ып/-еп* формалы хәл фигыльләргә ялганып, аларга көчәйтү төсмере өсти. Әдәби телдә бу мәгънә *бик, күп* сүзләре белән белдерелә

яки мондый фигыльләр кабатланып әйтелә: *Җылаплар* (елый-елый) *җөрдөм, дәдәй безне ташлап чыққачын. Әйтепләр* (әйтеп-әйтеп) *қарадым әллә ничә қабат, сүзләрне генә тыңламадын бит. Җырлаплар* (җырлап-җырлап) *печән чабарыйық, җырлаплар* (җырлап-җырлап) *урақ урырыйық җәш бағытыбызда.*

Затланышсыз формалар. Инфинитив һәм исем фигыль. Сөйләштә инфинитивның татар әдәби теленә хас *-ырға/-ергә,* исем фигыльнең *-у/-ү* формалары актив кулланыла. Мәгънә һәм функцияләре, нигездә, әдәби тел белән уртак булса да, аларны куллануда кайбер үзенчәлекләр күзәтелә.

Юнәлеш килеше кушымчасы алган *-ырга/-ергә* кушымчалы фигыль *-у/-ү* формалы исем фигыль (*-у* + *-га*) функциясен башкарырга мөмкин: *Син инде самаwыр қайнарға* (кайнауга) *қайтып җиттең. Кейәүгә барып җылы туларға* (тулуга) *малайы тыуды. Болар урамнан керергә* (керүгә) *бар да әзер.*

Киресенчә, юнәлеш килешендәге *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльне (*-у* + *-ға*) *-ырға/-ергә* формалы инфинитив урынына куллану очраклары да бар: *Минем карт печән қарауға* (карарга) *барған. Нинаулар* (Ниналар), *Вералар җырлауға* (җырларга) *кичен килербез, дип әйткәннәр. Минем әтей тийәтер қарауға* (карарга) *барған.*

Нагайбәк сөйләшендә сирәк кенә исем фигыльнең архаик *-ыш/-еш* формасы да кулланыла: *Җөгөреш була торғаныйы элек бәйрәмнәрдә. Аннан китә бийеш җәшләрнең.*

*Сыйфат фигыль*. Нагайбәк сөйләшендә сыйфат фигыльнең, әдәби телдәге кебек, *-ар/-әр, -ыр/-ер, -асы/-әсе, -ған/-гән, -а торған* формалары актив кулланыла.

*-асы* формасы киләчәктә булачак яки һичшиксез булырга тиешле эш, хәлләрне белдерә һәм әдәби телдәге *-ачак* формасына туры килә: *Алар анда бетәсе* (бетәчәк) *дә түгел.*

Ният-максатны белдерә, әдәби телдәге *-мақчы/-мәкче* формасына туры килә: *Нәрсә пешерәсе* (пешермәкче) *булдың? Шуннан инде қызны бирәсе* (бирмәкче) *булалар.*

Инфинитив функциясендә кулланыла: *Қойаш қызарып байыса, җаңғыр җаwасы* (яварга) *була. Сайрама, турғай баласы, без дә шунда барасы* (барырга тиеш).

*-асы* + *-ыйы/-ийе* (*иде*) формасы үткәндә булырга тиешле, ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында башкарылмый калган эш, хәлне белдерә һәм әдәби телдәге *-макчы/-мәкче* конструкцияле киләчәк заман мәгънәсенә туры килә: *Ул анда үзе дә барасыйы* (бармакчы иде). *Без бүген қаз суйасыйық* (суймакчы идек).

*-асы/-әсе* кушымчалы фигыль һәм *-ыйы/-ийе* (*иде*) ярдәмче фигыле белән ясалган тезмә көчле теләкне белдерә: *Мыйа шунда барасыйы бер. Аласыйы, бәйлисейе шул шәлне.*

Х ә л  ф и г ы л ь. Сөйләштә хәл фигыльнең *-а/-ә, -ып/-еп* формалары кулланыла һәм алар мәгънәләре ягыннан әдәби телдән аерылмыйлар.

*-а/-ә, -ып/-еп* формалы хәл фигыльләрнең юклыгы сөйләштә түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясала:

*-мыйча/-мичә*: *Қабаланмыйча ғына аша. Аwыртқанға чыдый алмыйча қычқырып җибәрдем. Бер барып қайтмыйча булмый әле;*

*-мастан/-мәстән* (*-мае/-мәе* формалы сыйфат фигыль күрсәткече + *-тан/-тән* чыгыш килеш кушымчасы): *Күрмәстән* (күрмичә) *җазамсыз? Өстән салмастан* (салмыйча) *күфәйкене кейеп қарады қызым. Ақчасын түләмәстән* (түләмичә) *генә май алып қайттым;*

*-ғач/-гәч* формалы хәл фигыльнең *-ғачын/-гәчен, -ғачыннан/-гәченнән* вариантлары актив: *Тәберсенгә* (үлгән кешене искә алу мәҗлесенә) *барғачын* (баргач) *бис өстәл җанында җөрөп keләү итәбез. Урманға кергәчен* (кергәч) *дә қаты итеп сызғырып җибәрде. Аш пешкәчен* (пешкәч) *бер малайны ат атландырып чығаралар. Җыйыла инде хәрендәш-ыру, җыйылғачын* (җыелгач) *аш эчәргә утыралар. Бала тыуғачын* (тугач) *бер ун көннән чуқындырырларыйы. Ул қалага барғачыннан* (баргач) *үз күзе белән күреп қайтқан.*

Сөйләштә *-ғанчы/-гәнче* формалы хәл фигыльнең *-гынчы/-генче* фонетик варианты да кулланыла: *Алар киткәнче керерсең әле. Кеше торғынчы бәрәңгегә чығып тотондық. Таң атқынчы уйлап җаттым.*

Нагайбәк сөйләшендә төп эштән алда башкарыла торган эш-хәрәкәт, хәлләрне *-мае/-мәе* кушымчалы сыйфат фигыль һәм

*борын, элек* сүзләреннән торган аналитик формалар да белдерергә мөмкин: *Утынны китермәс борон, қантурға барып әйттем. Үзе килмәс борон сәләмен алдың. Сез тумас элек буған қәлләр болар. Сыйыр саумас элек чәй эчтек.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлек** һәм **бәйлек сүзләр.** Баш һәм иялек килешен таләп итә торган бәйлекләр: *белән, өчөн, кебек, қадәр, чақлы, буйынча, сайын, талай, тиңентен.* Сөйләштәге *белән, өчөн, қадәр, чақлы, буйынча, сайын* бәйлекләре мәгънә һәм функцияләре ягыннан әдәби телдән аерылмый. Диалекталь бәйлекләрдән түбәндәгеләр актив:

әдәби телдә, үзе бәйләнгән сүзләр белән килеп, төрле охшату-чагыштыру мәгънәсен белдерә торган *кебек* бәйлегенең сөйләштә *kewek* варианты кулланыла: *Күз алларында торасың, Бақчада үскән гөл kewek. Аның kewek* (кебек) *әйбәт кеше булмас дөнҗада. Утырмаға барған қыз қаз kewek* (кебек) *утыра да утыра, җерли, тәрәшле җасый, сүсе беткәчен өйгә қайта;*

*талай* бәйлеге күләм-чама мәгънәсен белдерә: *Ни талай* (ни кадәр) *бәрәңге алдың! Бер талай* (берникадәр, бераз) *бақча утыртабыз, пинсийанирлар дип кенә өйдә җатмыйбыз;*

әдәби телдә, үзләре ияргән сүзләр белән килеп, охшату-чагыштыру, күләм-чама мәгънәләре белдерә торган *кадәр, чақлы* бәйлекләренең сөйләштә *қадәрле, чикле* фонетик вариантлары кулланыла: *Шул қадәрле қәстәрле дә торасың инде син. Аның чикле* (кадәр) *матур җырлаучы җуқ;*

шушы ук мәгънәне *тикле, тиңентен* бәйлекләре дә белдерергә мөмкин: *Ул тикле* (хәтле) *җиргә барырсың дип кем уйлаған. Монда аның тикле* (аның хәтле) *белгән кем бар тагын аwылда. Шул тиңентен* (хәтле) *эшләп-эшләп тә йаратмадылар. Ни тиңентен* (ни хәтле) *бәрәңге алғансыз;*

әдәби телдәге *турыда, хакында* мәгънәсендә *тарафтан* бәйлеге кулланылырга мөмкин: *Ул тарафтан* (турыда) *ишеткәнийек. Ул тарафтан* (турыда) *сурашмадың;*

юнәлеш килешен таләп итә торган бәйлекләр: *қадәр, чикле, чәре, таба, шайы, қаршы;*

*чикле, кадәрле, чәре* бәйлекләре, юнәлеш килешендәге сүзләр белән килгәндә, башкарыла торган процессның урын яки вакыт ягыннан чиген белдерә: *Без аларны күпергә чикле* (хәтле) *озата бардық. Анда қадәрле киткәннәр. Қыр чийәсенә чикле* (хәтле) *кибеп беткән, көн қызу булғанға. Оло көнгә* (пасхага) *қарышы күкәй буйисын йөзгә чәре* (хәтле). *Бер җылға чәре* (хәтле) *айағым сызлады.*

Чибәркүл районында яшәүчеләр сөйләшендә кулланыла торган *шайы* бәйлеге, үзе бәйләнгән сүзләр белән бергә килеп, башкарыла торган эш яки хәлнең урын ягыннан чиген белдерә: *Урманға шайы* (хәтле) *бардық. Аларны қайа шайы* (кадәр) *озата бардығыз?*

Чыгыш килешен таләп итә торган бәйлекләр: *башқа, бүтән, бирле, соң, түбән.*

Үзенчәлек итеп *түбән* бәйлеген куллануны күрсәтергә мөмкин. Бу бәйлек эш-хәлнең башкарылу вакытын белдерә: *Ирәтәдән түбән* (соң) *қазан астына җағарға итәм. Аш эчкәннән түбән* (соң) *киләбез, дип киттеләр җырчы қарчықлар. Моннан түбән* (соң) *бақчама эт бәйләп қуйарым тип торам.*

Нагайбәк сөйләшендә *бәйлек* ролендә түбәндәге сүзләр кулланыла: *ас, өс, тыш, эч, ал, арт, баш, қыр, қабырға.* Шулардан *қыр, қабырға* сүзләре сөйләшнең үзенчәлекле билгеләреннән санала.

*Қыр* бәйлек сүзе, килеш кушымчалары алып, башкарыла торган эш яки хәлнең әйләнә-тирәгә булган юнәлешен, урынын, чыгыш ноктасын белдерергә мөмкин: *Без элек Магнит қырында* (янында) *йәшәдек. Мин сийа эчәк қырында* (мич янында) *урын җәйеп бирәм. Улымның қырына* (янына) *утырып чәй эчәсем килә. Урман қырыннан* (ягыннан) *җил исеп тора.*

Сөйләштә шактый еш кулланыла торган *қабырга* бәйлек сүзе дә шундый ук мәгънәне белдерә: *Әле генә минем қабыргамда* (янымда) *утырды.*

**Теркәгечләр.** Нагайбәк сөйләшендә татар әдәби теленә гарәп-фарсы телләреннән кергән *һәм, әгәр, ки, әмма, ләкин, хәтта* теркәгечләре кулланылмый. Сөйләштә татар теленең түбәндәге

теркәгечләре һәм ярдәмче сүзләре күзәтелә: *ни... ни, тағын, ә, тик, йә, шунлықтан, шуңа күрә, исә.*

Әдәби телдән аермалы буларак, сөйләштә *исә* теркәгеченең кулланылыш сферасы киңрәк. Ул, *-ды* формалы үткән заман хикәя фигыль белән килеп, эш-хәлләрнең башкарылу шартын, вакыт һәм сәбәбен белдерә: *Малай бикле ишеккә қайтты исә, җайсыз була. Саудың исә, сөт бирерсең. Китәр бағытлары җитте исә, қодаларның әйберләрен бирә торғаннарыйы. Бер батыр җықты исә, бистәр бирәләр.*

## Лексик үзенчәлекләр

Й о л а  т е р м и н н а р ы: *ақлашу* – кыз ярәшү; *аққа салу* – кыз ягыннан вәгъдә билгесе итеп бүләк бирү; *қыйәмәтлек* – туйда кияү белән кызга икенче әти-әни итеп билгеләп куелган ирле-хатынлы кешеләр; *пипарат* – туйда мәзәк итеп, үзен танытмас өчен төрле киемнәргә киенгән кеше; *килен майы ашау* – туйда килен котлау мәҗлесе; *тәберсен/тийәберсен* – үлгән кешене искә алу мәҗлесе; *гүр тәберсене* – launched зиратта кабер янында үлгән кешене искә алу; *тау итү* – рәхмәт әйтү; *май, май чабу* – масленица бәйрәме; *оло көн* – пасха, бәрмәнчек; *чыбық келәwе* – руслардагы вербный праздник көне; *сөрән* – җәйге бәйрәм, *труйсын/тручын* – рус. троицын день; *нардуған* – кышкы бәйрәм, руслардагы святки; *раштуwа* – яңа ел; *чүг итү* – кырга чыгып яңгыр теләү һ. б.

Т у г а н л ы к  т е р м и н н а р ы: *нәнәй, нәнәү, мамау* – әни; *тәтәү, папау* – әти; *тута, түти, түтәй* – апа; *ақ түти* – яратып, олылап эндәшү сүзе; *җырақ түти* – әнисенең апасы; *җырақ ағай* – әнисенең абыйсы; *җырақ әби* – әнисенең әнисе; *җырақ бабай* – әнисенең әтисе; *бийем* – каенана; *ақ бийем* – иренең апасы; *җанағай* – иренең энесе; *печкәчәм* – иренең сеңлесе.

Т о р м ы ш - к ө н к ү р е ш  ә й б е р л ә р е ,  с а в ы т - с а б а л а р: *бадийа чиләк* – зур чиләк, *түмрәй* – кырга барганда су йөртә торган савыт, *бақрач* – аш чүмече, *тустаған//тустыған* – стакан, *әрҗә*– агач сандык, *кәнди* – агач табак, *атлаwыч* – гөбе пешкәге, *шабала* – күмер соскыч, *пычу* – утын кисү.

К и е м - с а л ы м атамалары: *алчүпрәк* – алъяпкыч, *балан итәк* – бала итәк, *бистәр* – сөлге, *сүрәкә* – баш киеме, *қата* – күн аяк киеме.

А ш - с у атамалары: *аш эчү* – аш ашау, *тамақ* – ашамлык, *шишара* – бавырсак, *көрник* – бәлеш, *сөр ит* – тозланган ит, *дурчмақ* – бәрәңге пәрәмәче, *тәкә* – бөккән, *шәнгә* – эремчек пәрәмәче.

**Сөйләү үрнәкләре**

Туйға өч кеше килә ақлашқан чақта // әтки / әнки / дружки сине ақлашалар // сездә қыз/ бездә ул бар/ диләр инде / айағ астына бүкән / утырырға мендәр / диләр // утырталар / аш салалар // ул аш пешә / хуҗайқы аш утырта // қодалар аштансыwдан аwыз итегез // киштәгез нық бусын дип // төйөнчеккә ақча эләләр // сез инде қаты тормағыз / без сибәп белән килдек / синәк белән тормағыз // чәй эчәләр // безнең малай сезнең қызығызны җарата / қызығызны бирәсезме // қайсы әйтә бирмибез ди / қайсы бирәбез ди / ақлашқанда муйса / йә изү мийа бир ди // күлмәген йә бистәр // баралар қызны ақлашқач / бирегә соғласийе булғач әтки-әнки баралар алырға // инәсе-атасы бирә // бистәр бирәләр үзенә // айағ астына баш ыра // килен кертә / аш сала / қунақлар чақыра / өстәл көйли // җәш килен белән җәш кийәүне шаршау эченә утырталар // җәш киленне кийендерәләр / күрсәтмиләр // җепәк эшәл бәйләтәләр / бер ир бала килә / җәш киленнең йөзен күрсәтегез ди // җаулықны ача / аңар акча салалар / бәйрәм иткәнен таралалар // җегетнең өйөнә қызны алып китәләр // җөзен ачқанда оло-қары бәйрәм итә // җәш килен идәнсәке жыйа / муча җаға // җәш килен мучасы дип муча керәләр / сыw җулы күрсәтәләр / көйәнтә чиләк белән сыw китерә // әйбер эләләр / җәш килен атына тийиләр түшәк-җастық / қыз җағыннан кигән кеше әйберне элә / чөй қаға / бистәрләрне элә // түшәкне җәйәләр / қийаматлық ирле-хатынлы кеше / ағасымы-тутасымы // әнкәй-эткәй дип әйтә килен аларға // күчтәнәч җибәрәләр қарақаршы / ул сийа җибәрә / син аңар җибәрәсен // күчтәнәч башлыйлар / күчтәнәч башлағанда әйтәләр / җәнлекме / қанатлы кошмы

дип / мал әйтәләр // ишеғалдым түгәрәк / җаңғыр җаwа сибәләп // ашадық эчтек көрмәт күрдек / таw итийек чибәрләп ди // өстәлдән қузғалған чақта айағ өсте торып таw итә җырлап//

Май чабу // җыйылабыз бер җиргә қызлар / малайлар // әйдәгез бүген бит май көне / май чабыйық / сез безгә барығыз / без сезгә килербез // инә-әти пешеренә // мин ат җигәм бүген / кашаwый бирегез безгә // өчәр-дүртәр өйле җыйыла // урам әйләнәбез / җырлашабыз / чәбәкәйлибез // аннан керәбез өченче өйгә // кемнен өйөнә керәсен / шунын аты җигүле // чуқлибыз атларны / қыңғыраулар тағабыз // берсеннән-берсе көннәшә // мичәүдәге ат йақшы була // үзләре суққан күлмәкләрне җиләннәрен кийәләр / җепәк җаулықлар бәйлиләр // тәңкәле балдақлар / тәңкәле беләзекләр / қызыл җиләннәр кийәләр//

*Чиләбе өлкәсенең Чибәркүл районы Попово авылы.*
*1983 ел. Язып алучы: Ф.С. Баязитова*

Тийәберсен итү // тийәберсенгә барырга әйтәбез қарендәшырыwға // ипей салабыз / әзерләнәбез // шуннан табақны җасыйбыз үзебезчә // анда җаwлығ аппарабызмы / бистәр аппарабызмы хәйер бирергә // теге кешегә барып җитәбез дә табақларны өстәлгә бич утыртабыз шушылай // утыртабыз да қалық җыйылғанчы табақ җасарға кирәк дип / мына мынсы җан табағы / мына мынсы уша башы / мынсы қартлар табағы // эч табаққа шул табақлардан табақ җасыйбыз / қаждыйына бүлеп-бүлеп саласын // бу табақлы утыртабыз уша башына / бу табақны утыртабыз өстәлгә / җан табангын утыртабыз җан чыққан җиргә / хуҗайын үзе кемгә бирергә тийеш / җан табағын үзе бирә // уша табағын ушаға инде / бич йөреп тәберсен итәбез / дисен инде / бусын / ашлы-сыwлы булсын / дисен / без шунар атаб итәбез / ашлы-сыwлы бусын / қодай ризықлы итсен / дисен инде / урынға итеп салабыз да утырып аш ашибыз / теге оло табақны биргән кешегә тағын китәбез чәй эчәргә / әйдәгез безгә табақтан тәберсен итәргә дип // қажныйы утыртып куйа өстәлгә // бездә узғыралар икән тәберсен минем инәмә алар табақ җасый / ә мын-

сы қартларға / элекке үлгән кәрендәш-ырыwға ди / ә ансы инде исемсез / җитем балаларға ашаталар инде // атадан-инәдән шулай калған җола буғачын инде // тәберсен итә беләбезме инде / белмибез // кәрендәш-ырыw / аwыл-күрше җыwа / җыйыштыра // кем киләсе килә / килә бар да // үзенең күңелендә бар кеше килә бар да / күтәргән кешеләргә бистәрләр бирәләр / җырлаған кешеләргә җаулықлар өләшәләр / күмеп қайтқач урын сакланыла / түшәк сақлау була // күмеп кайткан көнне / җәшрәк булса қызғанып утырасың / қартырақ булса, уйнисын көләсен / қызықлар сөйләп төн узғара / сөйләшмичә дә утырып булмый бит // шушылай дөм берүзебез утырабыз // қартырақлар булса шайарып та утырасын // кайын җапырағы салалар ғырупқа // мин күргәнем җуқ / син әллә күргәндерсен // тәберсен итүче хуҗайын көрник пешерә / тәберсен көнне мичкә җағасын / қоймаңны тугисын / күзикмәкне басасын / җәйәсен // қырық күмәче дибез / аны җасыйсың бер қырықны / илле дигәндәй // шуны өстәлгә жыйылғачын табақ җасарға қушабыз ике әбигә / менә монсы үлгән кешегә җан табағы / монсы уша табағы / монсы қартлар табағы / өч табақ җасайлар шул кигән табақлардан қажныйыннан / анда ничек саласы килә / шуны җасап беткәчен теге табақларны берәү җыйып тора бушағанын / бер күзикмәкне салып / қоймақны салып / бер күмәчне салып қуйа да табақларға / теге табаққа тәберсен итәбез / җан табағыннан / уша табағыннан бич җөрөп тәберсен итәбез дә берсен утыртабыз уша башына / берсен монда / шунардан тәберсен итеп беттисә өзгән нәстәне сынықларны чығарып сала түбәгә / кош-җәннек ашасын дип // җан табағын бирә бирәсе кешегә // қартлар табағы тора / уша табағы балаларға // аш утыртабыз // ашны эчәбез / бутқа утыртабыз // бутқаны утыртқачтын / мына мин аппарам бер бистәр / теге аппара бер җаулық / теге аппара бер таwар / шуларны өләшәләр // кемгә атап бирәсе кигән кешегә бирә // бутқа артыннан көрник / җә ит бирә // менә сийа тәберсен // қырық күмәч тәберсен сайын була // ничә кешегә әйтә / күмәч бирә//

*Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районы Париж авылы.*
*1983 ел. Язып алучы: Ф.С. Баязитова*

## Туй боткасы, килен майы ашау

– Қызны алырга баралар. Пар атлар җигәләр ийе қыңгыраулы.

Қыйаматлық итеп қуйылган кеше була туйда. Кыйаматлықның қатыны қызны алып қайтырга бара, кызның иптәшләреннән сатып ала күпмедер ақча биреп. Иптәшләре әйтәләр, қызны буш бирмибез, дип. Қызның атасы белән инәсе, туганнары җыйылып, чәй қуйып торырлар ыйы. Өстәл арасына утырталар.

Ин алдан җегет күрешер иде қызның атасы белән, аннан инәсенә баш ороп күрешер ийе. Аннан қыз шулай изгелекләр, бәқиллекләр сорар ыйы инәсе белән атасыннан.

Шулай қызын алып қайтып китәрләр ийе җегетнең өйенә. Җегетнең өйенә қайтып ишегалдына керәләр. Аттан төшәләр дә тезелеп торалар ипей-май тотып шушылай. Тегеләр ипейдән аwыз итеп, теге қыйаматлык қатынына бер нимә йабар ийы, иренә бер нимә йабар ыйы, бүләк инде. Аннан болай қызны қыйаматлық өйенә алып китәләр. Қыйаматлыққа барырга атлар көтеп тора.

Қәзер килеп кертергә әзерләнә башлыйлар, кеше җыйалар кийәү өйендә. Җыйыла инде қәрендәш ыру. Җыйылғачын **аш эчәргә** утыралар. Аш артыннан – бутқа. Бутқа чыққасын киленне апқайтырга инде кыйаматлық өйеннән.

**Туй бутқасы** – ин азактан чыга. Бутқа чыққачын инде килennең бейеме, бездә шулай бейем дигән (кайнана ул сездәгечә). Қар базыннан май апкердергән.

**«Килен майы»** ашаганнар, килен қотлаганнар. Нәстә саласын, күлмәк саласынмы, ақча саласынмы. Җәшләр шулай килен майы ашаганнар. Менә кәзер Кылау сөйләр инде. Килен кийәүнең ата-инәсенә элек *нини, әти* дип әйтте, қәзер *мамау, папау* инде.

Кийәүнең олы агалары – *би агай,*
кийәүнең энеләре – *җанагай,*
кийәүнең туталары – *ақ бийем,*
кийәүнең сеңнеләре – *печкәчәм,*
тутасының ире – *җизней.*

### Кода сыйлау

– Кодаларны түр башында гына утыртып сыйлыйларыйы, җырулар җырлап, қәдерләп. Менә безнең бөтен затыбыз, инәү җагы – җыручылар. Бетәсе түгел безнең җырлар көне-төне җырласаң да.

**Сонучылар** булды элек туйларда.

**Қода сыйлаучылар, сонучылар** қодаларга тустаган тоттырып, айақ өсте торып җырлап қына сыйлыйлар ыйы.

**Тустаган җырларын** да әйтеп күрсәтим.

Тустаганнар бирсәң – тутырып бир,
Патнус эчләренә түгелсен.
Тушы тустыганнын балын эчмәсән,
Безнең қодалар түгел сез.

Қодаларым, сезгә ниләр бирийем,
Қазаннардан алган малым җүқ.
Җаннарымны җарып бирер идем,
Җаннан башқа торыр қәлем жуқ.

Чеметеп-чеметеп кенә қамчы үрдем
Атқайларым күндәм булсын дип.
Арқаларым тирләп, торам җырлап
Сезнең күңелләрегез булсын дип.

Су буйында балтырган
Җаңа бәбәкләргә утырган.
Өстәл өскәйләрен җәмне итеп
Кодаларым килеп утырган.

Күк қабақайлары ачылса,
Күк эчләрен шунда күрербез.
Қодай бәқытләрне ким итмәсә,
Гумер буйы бергә җөрербез.

Шыңгыр-шыңгыр дугалар,
Теге очлардан килә кодалар.
Нигә бер дә җырламыйсыз,
Әллә ошамыймы, қодалар?

Бу ди өйләрнең нигезен
Җалан бақыр белән батырган.
Бу кодалар безне ник чақырган?
Җырлап баш орырга чақырган.

Ишек алларында чатыра,
Чатырада күке чақыра.
Ибан қоданың сыйы бетмәс,
Инде Паwал қода чақыра.

*Париж авылы*

**Утынчы малай**

*(әкият)*

Никанур бабай сөйли торган ыйы балаларга кич утырганда.

Борын-борын заманда бер әби белән бер бабай булган, ди. Аларның бер малайлары да булган, ди.

Берзаман боларның йагарга утыннары беткән, ди. Малайга әйткәннәр:

«Улым, йагарга утын алып кайтырга кирәк, урманга барып утын алып қайт әле».

Җарар, малай атын җиккән дә урманга утынга дип чыгып киткән, ди.

Кайынны кискән бу. «Қайын бик аwыр, күтәреп салып булмас, сыразы арбаға гына җыгыйым әле агачны», – дип, аты белән арбасын қайын җанына китереп қуйган. Қайынны аударган икән, ул малайның аты белән арбасы өстенә ауган да төшкән, ди. Арба wатылган, аты үлгән, ди, қайаен астында қалып.

Қайтып киткән бу балтасын тотып. Менә монда Төбәк күле дигән күл бар, шул күлдә үрдәкләр йөзеп йөри икән. «Их, бер үрдәкне тотып алып қайтсам, нәнәү итле аш пешереп эчертер ийе», – дигән малай. Балтасын қулында тотып, үрдәккә төбәп ыргытқан. Ә үрдәк очып киткән, малайның балтасы суга төшеп йугалган.

Болай булмый инде, дип, теге малай күлмәк-ыштанын салган да балтаны эзләргә күлгә кереп киткән. Эзләгән-эзләгән бу, күл

төбеннән балтаны тапмаган. Күлдән чыкса, күлмәк-ыштанын карақлар урлап киткәннәр, ди. Нишләсен, судан чыгып, шәрә килеш қайтып киткән, ди, малай.

Малай шыпырт кына өйгә кергән дә сүндәрәгә менеп җатқан, ди. Ойат бит инде. Малайның қарны әчеп беткән. Шунда инде бер нәмә табып кийеп, үренеп кенә шүрлектән ипей алмақчы булган икән, сүндәрәдән җыгылган да төшкән, ди. Инәсе күреп кенә калган малайны. Бу ойатыннан өйдән чыгып киткән, ди. Бер атна қайтмаган, ди. Нишләсен, бик қарны әчкән, хәле беткән, кайтқан инде.

*Сарашлы авылы*

Менә безнең Миңкә җырақ бабай сөйли торган ыйы, без җыйылып, аwызыбызны ачып тыңлап торадырыйық қызық табып.

**Бармақбаш малай**

*(әкият)*

Бабай әйткән: «Мин, әби, қырға барыйым бүген, ашлық чәчейем», – дигән.

«Җарар, мин синең ашарыңа илтеп биремен». – дигән әби.

Шулай итеп, бабай киткән, ди, сабан сөрергә. Әби ашыгып-ашыгып тоқмач кисә башлаган икән, бармагын кисеп алган. Бармақтан бармақбаш бала килеп чыққан, ди.

Бармақбаш бала әйткән:

«Әби, мин тоқмачны үзем кисәрем».

«Җуқ, балам, син бәләкәйсең әле, син кисә алмассың», – дигән әби.

«Кисәрем, әби, кисәрем», – дигән бармақбаш.

«Әби, син мийа ашны сал, мин үзем илтеп бирем қырга бабайға, сабан да сөремен, бабайга булышырым», – дигән.

«Ай, балам, син бик бәләкәйсен әле, ашны илтәлмәссен», – дигән.

«Илтәрем, әби илтәрем», – дигән бармақбаш.

Кырга барып җиткән, әйткән бабайга:

«Бабай, бабай, кил ашарга, мин сийа аш китердем. Син ашап ал, ә мин сабан сөреп алыйм», – дигән.

«Син бәләкәйсен бит әле», – дигән бабай.

«Җуқ, мин булдырам, мин сөрермен».

Бер әйләнгән, ике әйләнгән бу, бармақбаш малай җуқ.

Бурлар килгән икән атны урларга. Бурлар килгәч, малай атының қолагыннан кергән дә қачып утырган.

Бабай әйтә икән: «Малай да җуқ, ат та җуқ, бурлар атны алып киткәннәр. «Айт-тайт, бабай, мин монда», – дип кычкыра икән малай.

Атны суйганнар, ди, бурлар. Шунда бүреләр җыйылып килгәннәр дә атны ашаганнар, ди. Бармакбаш малай бүреләр эченә кергән дә бүреләрнең қолагыннан чыккан, ди.

«Айт-тайт» дип қычкыра икән малай. Ул бүреләрне қурқыткан, кайтып киткәннәр, ди, бабай белән.

Мин аны күргән ийем үзем дә, кенәген бардым, бүген қайттым. Бабайларыбыз, әбиләребез сүлидерийе шулай.

*Варлам авылы*

## Җырак бабай көйе

### *Газиз кардәшләр*

Менә аңлатып әйтийем әле сезгә. Хәзерге йәшләр бик белеп бетермиләр инде.

Нәнәүнең *(әнинең)* җагыннан инәсен-атасын *җырақ әби, җырақ бабай* диделәр.

Агай-энеләр үзләре бергә җыйылып, сүзен чыгарып, үзләре көйен табып җырлашып утырганнар.

Туганнарым, сез икәнсез
Алтын баганаларым.
Сезнең белән бергә үтсен
Калган заманаларым,
И, газиз кардәшләр!

Көрән шәлем, көрән бүрек,
Көрәннәрдән мин кийәм.

Күкрәгемдә җаным ничек,
Мин сезне шулай күрәм
    И, газиз кардәшләр!

Бәйлә, дустым, билләремне,
Син бәйләсәң билем бушамый.
Бу дөнҗада дус-ишләр күп,
Көйе генә безгә ошамый.

И, газиз кардәшләр! – дип әйтеп куйалар ыйы жырлап бетергәчен.

*Сарашлы авылы*

**Париж көйе**

Йалан күкәй тәгәрәттем, аппагым,
Йалан күкәй тәгәрәттем, аппагым,
    Париж, Париж,
    Парижларга җитсен, дип.

Сәләм йазып хат җибәрдем, аппагым,
Сәләм йазып хат җибәрдем, аппагым,
    Җәйгә, җәйгә,
    Җәйгә кайтып җитсен, дип.

Утыр, диде, урын бирде, аппагым,
Утыр, диде, урын бирде, аппагым,
    Нигә, нигә,
    Ник утырмадым икән?

Хуш бул, диде, кулын бирде, аппагым,
Хуш бул, диде, кулып бирде, аппагым,
    Нигә, нигә,
    Ник кул бирмәдем икән?

Йалан күкәй тәгәрәттем, аппагым,
Йалан күкәй тәгәрәттем, аппагым,
    Париж, Париж,
    Парижларга җитсен, дип.

**Париж чишмә буйлары**

Парлы күкеләр чакырганда
Шаулый безнең урман буйлары.
Җанган җөрәкләрне җарсыта
Безнең Париж чишмә буйлары.

**Парижларның асыл җегете**

Урман кошы – түше чыбар,
Кара урманнарның бөркете.
Атларга менсә, ат уйната
Парижларның асыл җегете.

Җилле җилкәйләрне бик мактыйлар
Париж җегетенә ни җитә.
Бу гумерләр бик тиз үтә-китә,
Татулыкларга ни җитә.

*Париж (Балыклы) авылы*

**Туганнар түгәрәге**

Анда оча, монда оча
Карурман күбәләге.
Менә шулай була икән
Туганнар түгәрәге.

Йөгерә-йөгерә тоталар
Кырда йөргән үрдәкне.
Гомерем булса, онытмамын
Монда күргән хөрмәтне

Алла бирсә, карлар йауса,
Төлке тотарбыз әле.
Без дә атинә баласы
Дөнҗа көтәрбез әле.

Аллар булганда гына,
Гөлләр булганда гына.
Күтәрелә күңелләрем
Бергә булганда гына.

Таулардан тауларга җепәк тарттым,
Тарта гына тарта тарыктым.
Сез, туганнар, килә дигәч,
Көтә генә көтә зарыктым.

Капканнар куйдым әле бүрегә,
Имәннәр дә кистем шүрегә.
Ичбер җомошларыбыз жугыйы
Наруш килдем сезне күрергә.

Җәмнеләр икән бу җаланнар
Ак тирмәләр корып җәйләргә.
Кайларга ла барса дус-иш кирәк
Каршы чыгып атларны бәйләргә.

**Кили (Кассель) җырлары**

Кили җулы, Кили җулы
Адым сайын багана.
Безнең Кили бигерәк җәмне
Карап күзләрем тала.

Кили суwы тирән су,
Дулкыны киртә-киртә.
Кили аwылы бигерәк йәмне
Сокланабыз кич, иртә.

Җегетләре бигерәк матур,
Җылтырый итекләре.
Атка менсә, ат уйната
Килинең җегетләре.

Кили кызларының шәле
Аллы-гөлле шакмаклы.
Килиләрдән сәләм сезгә
Урал таулары чаклы.

Кили урамнары җәмне
Бәйрәм көннәр булганда.
Килигә кушып җырлыйбыз
Сез, дуслар, җыйылганда.

## Шелекәй буйлары

Шелекәй буйлары киңнәр җалан,
Түмгәкәйләре бардыр аның,
ай, шул җаман.
Бергә җөрүләре берләр заман,
Айырылып китүләре бик җаман.

Шелекәй буйларына курпыга
Атлар җибәрегез, ашасын.
Азрак-азрак җырлап җибәр,
Тулган эчләрегез бушасын.

МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

### Чибәркүл районы

**Попово авылы:** Бигашова Людмила Микулаевна (62 яшь), Степанова Анна Афанасьевна (90 яшь), Юртаева Полина Дмитриевна (92 яшь), Ишкулова Эмма Георгиевна (70 яшь), Уряшева Тамара Николаевна (63 яшь), Степанов Николай Николаевич (58 яшь), Юртеева Галина Прокопьевна (77 яшь), Федоров Матвей Сереевич.

**Варлам:** Михайлова Евдокия, Уряшева Надежда Николаевна.

### Нагайбәк районы

**Париж:** Ишимова Нина Николаевна (1921 елгы), Иванова Матрена Евдокимовна (80 яшь), Алексеева Анна Александровна (Анук түти), Иванова Таиса Осиповна (82 яшь), Иванова Вера Лазаревна.

**Кассель (Кили):** Артемьева Анна Ильинична (66 яшь), Неверова Зоя Прокопьевна, Хөснетдинова Екатерина Кирилловна (77 яшь), Сафронова Галина Афанасьевна (68 яшь), Букачова Роза Прохоровна (78 яшь), Сафронова Ирина Семеновна (68 яшь), Тихонова Зоя Георгиевна (76 яшь), Бижанова Ольга Семеновна.

**Остроленко (Сарашлы):** Бидянова Аудакия Макаровна (100 яшь), Исаева Евдокия Семеновна (67 яшь), Жукова Елизавета Андреевна (66 яшь), Байкина Евдокия Ильинична (75 яшь), Артемьева Зоя Евгеньевна (75 яшь).

# НАГАЙБӘК СӨЙЛӘШЕНЕҢ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Фәрит Йосыпов*

Нагайбәк сөйләшенең сүзлек составында төп өлешне гомумтатар сүзләре алып тора. Диалектизм саналган сүзләрнең дә күбесе фәкать нагайбәк сөйләше өчен генә үзенчәлекле түгел, бәлки татар теленең башка сөйләшләрендә дә табыла. Бу бүлектә нагайбәк сөйләшеннән теркәлгән барлык лексик диалектизмнарны күрсәтү түгел, бәлки сөйләшнең тарихына, аның татар әдәби теленә һәм татар теленең башка сөйләшләренә мөнәсәбәтен объектив билгеләргә ярдәм итәрлек фактларга киңрәк анализ ясау бурыч итеп куела. Биредә күрше төрки телләр белән чагыштырып баруга да әһәмият бирелде, чөнки нагайбәкләр, бигрәк тә хәзерге урыннарына күчерелгәч, күрше башкорт, казакъ ырулары белән бәйләнешкә кергәннәр.

Нагайбәк сөйләшеннән теркәлгән лексик диалектизмнарны әдәби телгә мөнәсәбәттә түбәндәгечә төркемнәргә бүләргә мөмкин:

I. Саф диалектизмнар: а) конкрет предметларны атаган сүзләр; ә) абстракт мәгънәле сүзләр.

II. Формасы белән әдәби, мәгънәсе белән үзенчәлекле сүзләр.

III. Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләрен чагылдырган сүзләр.

## I. Саф диалектизмнар

Сөйләштән теркәлгән лексик материалларны түбәндәгечә төркемләргә мөмкин.

### *Туганлык терминнары*

Нагайбәк сөйләшендә гомум туганлык мөнәсәбәтләре берничә төрле термин-сүз белән белдерелә. Ләкин сөйләштә иң актив кулланыла торганы – **туғанай** сүзе.

Мисаллар: *Сезнең бу аwылда туғаннарыгыз бармы суң?* (Астафьевка) *Өч җез сумның атлар җигеп, туғанайлар килгән қунаққа.* (Җырдан, Париж) *Безнең туғанай була силсәwиттә эшләгәнә дә.* (Остроленко)

Әдәби телдәге туган сүзенә борынгы төрки эндәшү кушымчасы өстәлеп ясалган *туғанай* сүзенең бу мәгънәсе татар теленең башка сөйләшләрендә билгеле түгел. **Туғанай** формасында бу термин тау ягы – кама тамагы сөйләшендә килен белән каенсеңел яшьтәш булганда, ә казан арты – дөбьяз сөйләшендә килендәшләрнең үзара сөйләшү сүзе буларак кулланыла.

**Җебер.** Әдәби телдә туган-тумача, нәсел-нәсәбә сүзләре белән белдерелә торган гомуми туганлык төшенчәсе сөйләштә *җебер* сүзе белән белдерелә. Мисаллар: *Җеберләре белән килгәннәр, барлық балалары белән дә.* (Фершампенуаз) *Аларның җеберләреннән җырақ тор, дип әйтә торғаныйы нәнәү.* (Париж)

Нагайбәк сөйләшеннән башка бу сүз *җеwер//йәwер* вариантларында татар теленең урта диалект сөйләшләрендә бар.

### *Кан ягыннан туганлыкны белдерә торган терминнар*

**Нәни** – әни. Мисаллар: *Нәни өйдә булмаган ул бағытта.* (Париж) *Нәни ул кешеләрне белә.* (Остроленко)

**Нәнәү.** Эндәшкәндә яки эмоциональ-экспрессив төсмер белән әйтелгәндә *нәни* сүзе *нәнәү* формасында кулланыла: *Нәнәwемне сағындым дип әйтеп җибәргән қызым.* (Астафьевка) *Нәнәwем алтмышта ғына әле.* (Кассель) *Нәнәү, чәй җасап бир әле.* (Попово)

**Нәнә//нәнәй** сүзенең татар телендә таралышы шактый киң. *Нәнә* формасында бу сүз ата-ананың әнисе мәгънәсендә – бөре,

ана, әни мәгънәсендә – казан арты (балтач), казан арты һәм зәй керәшеннәре сөйләшләрендә билгеле, тау ягының кама тамагы сөйләшендә *нәнә* үги анага яки әти-әнинең җиңгәсенә эндәшү сүзе буларак кулланыла. *Нәнәй* сүзе исә ата-ананың әнисе мәгънәсендә тау ягы (кама тамагы), эчкен сөйләшләрендә теркәлгән, ә чистай, зәй, казан арты керәшеннәре, казан арты (мамадыш, балтач), шулай ук ләмберә, сергач сөйләшләрендә ана, әнине белдерә. Бу сүз темников, кузнецк сөйләшләрендә дә бар. Биредә ул өлкәнрәк хатыннарга, карчыкларга туган тиешлеләрнең, күршекүлән балаларның эндәшү сүзе буларак кулланыла.

Төрки телләрдән *нәнә* сүзе кырым татарлары һәм төрек теле өчен хас. Биредә ул әнигә иркәләп эндәшкән очракларда әйтелә.

**Нәни//нәнәү** сүзе нагайбәкләр яши торган барлык территориягә дә таралмаган, ул бигрәк тә Нагайбәк районында яшәүчеләр сөйләше өчен генә үзенчәлекле. Чибәркүл районында яшәүчеләр сөйләшендә исә бу төшенчә *инәй* сүзе белән белдерелә. Мисаллар: *Инәйем белән бер туған сеннекәшем ул минем.* (Варлам) *Инәйе, моны қалдырып, кийәүгә китте.* (Болотово)

**Инәй** (әни мәгънәсендә) термины да татар теленең күп кенә сөйләшләрендә (мәсәлән, бөре, минзәлә, пермь татарлары, эчкен), шулай ук Оренбург һәм Куйбышев өлкәләрендә таралган татар сөйләшләрендә дә теркәлгән. *Инә* сүзе бу мәгънәдә башкорт сөйләшләрендә дә бар.

**Мамау.** Сөйләштә тагын әни кешегә иркәләп эндәшкәндә рус теленнән кергән *мамау* сүзе дә кулланыла: *Мамау, ашыйсым килә.* (Париж) *Мамау, син тағы қайчан киләсең инде?* (Фершампенуаз)

**Тәтәү** – әти. Мисаллар: *Қайттыңмы, тәтәү эштән?* (Кассель) *Мин қайтсам, өйдә нәнәү белән тәтәү утыра.* (Астафьевка)

**Папау.** Эндәшү сүзе буларак, сөйләштә рус теленнән кергән *папау* сүзен куллану да актив. Мисаллар: *Папау, чалбар алып қайт әле.* (Фершампенуаз) *Син мине Чиләбегә аппарам дип тә әйткәнең барыйы, папау.* (Попово)

Бу яктан нагайбәк сөйләшенең мордва-каратайлар сөйләше белән уртаклыгы күренә. Эчкен сөйләшендә *татакай* сүзе бар. Биредә ул әти яки әнинең әтисенә эндәшү сүзе буларак әйтелә.

*Тәтәү* сүзен кайбер төрки телләрдә кулланыла торган *дәдә* сүзе белән чагыштырырга мөмкин. В.В. Радлов күрсәтүенчә, бу сүз караим телендә – ага, төрек, чыгатай телендә бабай мәгънәсендә йөри.

*Тәтәү* сүзе сөйләштә икенче термин ясауга да нигез була. Мәсәлән, *оло тәтәү, бәләкәй тәтәү*. Оло тәтәү, бәләкәй тәтәү дип әнисенең абыйларына эндәшәләр. Мисаллар: *Мине оло тәтәү уқытып чыгарды. (*Париж) *Бәйрәмгә оло тәтәүнең малайларын да чағырғаныйыйқ әле.* (Фершампенуаз)

*Оло тәтәү* терминының ясалышы ягыннан нагайбәк сөйләшенең минзәлә *(дур әтәй),* бөре *(зур әтәй),* казан арты, зәй керәшеннәре нократ, шулай ук кайбер мишәр сөйләшләре белән дә уртаклыгы күренә.

**Тута//түти//түтәй** – апа. Сөйләштә эндәшү сүзе буларак күбрәк *түти//түтәй* вариантлары кулланыла. Мисаллар: *Минем бер туған тутам кийәүгә китте.* (Париж) *Мәтүк түти өйдә жүгыйы.* (Фершампенуаз) *Ул мыйа түтәй тийешле.* (Попово)

*Тута//түте//түтәй* терминнары Октябрь инкыйлабына кадәрге татар әдәби телендә дә актив кулланылган.

Бу яктан сөйләшнең казан арты, минзәлә, пермъ татарлары, бөре сөйләшләре белән уртаклыгы зур.

**Ак түти** дип апа кешегә яратып эндәшкән очракларда әйтелә. Мисаллар: *Ақ түти, син Париждан қайчан килдең?* (Остроленко) *Син, ақ түти, белгән җырыуларыңның барсын да җаздырып бетердеңме?* (Кассель)

**Җырак түти** – әнисенең апасы. Мисаллар: *Җырақ түтиләрнең сатлары бик зур.* (Остроленко) *Без җырақ түти белән икәүләп теге җырыуның сүзләрен таwып қуйдық.* (Париж)

**Ағай//ағачай** – абый. Нагайбәк сөйләшендә бу сүз үзе белән бертуган абыйсын белдерә. Мисаллар: *Бу йағларға ағайым зур булып килгән инде.* (Попово) *Безнең ағай Қазанда ыслужит итте.* (Болотово)

Татар әдәби телендә *агай* сүзе үзеннән олы ир кешегә эндәшү сүзе буларак кулланыла. Татар теленең күп кенә сөйләшләрендә бу сүз белән үзеннән зур ир туганны атыйлар.

*Агай* сүзе без өйрәнә торган сөйләштә кулланыла торган вариантта төрки телләрнең күбесендә бар. Тел арты [г] авазы белән бу термин азәрбәйжан, гагауз, кыргыз, төрекмән телләрендә, тирән тел арты тартыгы [ғ] авазы белән башкорт, казакъ, каракалпак, төрек, хакас, якут телләрендә әйтелә (Радлов В.В. Күрсәтелгән хезмәт).

**Агачай** сүзе эмоциональ-экспрессив төсмер белән эндәшкәндә кулланыла. Мисаллар: *Ағачай, бөтенләй қайчан қайтасың инде?* (Фершампенуаз) *Минең ағачай Қазанда булды.* (Париж) *Минем ағачай йәшләтә килгән дип сүләрийе нәнәү.* (Варлам)

*Ағачай* термины халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм пермь татарлары сөйләшендә генә теркәлгән. Үзенең ясалышы белән бу сүзне татар теленең күп кенә сөйләшләрендә очрый торган *җиңәчәй* термины белән чагыштырырга мөмкин.

**Җырак ағай** – әд. әнинең абыйсы, энесе. Мисаллар: *Җырақ ағайым үлде минем.* (Париж) *Җырақ әбийеңне җаратасыңмы, улым?* (Остроленко)

Бу үзенчәлек урта диалектның минзәлә, бөре, шулай ук күп кенә керәшен сөйләшләре өчен дә хас.

Эмоциональ-экспрессив төсмер белән куллану очракларында бу сүзне **жыракай** формасында әйтү киң таралган. Мисаллар: *Җыраққайны күргән җуқ бик күптән.* (Париж) *Җырақайны да чақырығыз.* (Астафьевка)

*Җырақай* сүзе, без өйрәнә торган сөйләштән тыш, тагы минзәлә сөйләшендә дә теркәлгән.

**Җырак бабай** – әнисенең әтисе. Мисаллар: *Җырақ бабай аwырған әле.* (Париж) *Безнең қыз да җырақ бабайына кунаққа китте.* (Кассель)

Әни ягыннан булган туганлыкны *җырақ* сүзе ярдәмендә ясалган терминнар белән белдерү керәшен сөйләшләренең күбесе өчен хас. Болардан тыш, мондый күренеш урта диалектның минзәлә, бөре сөйләшләрендә дә бар.

**Әбәү** – әтисенең әнисе: *Папамның әбәwе монда килгәнен хәтерли әле.* (Варлам) *Әбәү қарт булса да бар нәрсәне эшләп җөргән була.* (Попово)

**Бабау** – этинең этисе: *Мин бабау белән йоҡлыйым бүген.* (Free-шампенуаз) *Бабауы малайын бик тә җаратайы инде.* (Астафьевка)

Туганлык терминнарын *-ау, -әү* кушымчалары ярдәмендә ясау, без өйрәнә торган сөйләштән тыш, татар теленең көнчыгыш диалекты өчен хас. Биредә дә бу кушымча белән ясалган исемнәр эндәшү очракларында әйтелә[1].

*-ау, -әү* кушымчасы үзенең тамыры белән хәзерге төрки телләрдә шактый гына актив кулланылган *-ай, -әй* эндәшү кушымчасына барып тоташа. Чөнки борынгы төрки телдә сүз ахырындагы [г], [к] тартыклары кайбер телләрдә – [й], [ә] кайберләрендә [у] авазына күчкән. Татар телендә моның ике очрагы да булганлыгы билгеле. Мәсәлән, *баг – бау, бәй.* Без өйрәнә торган сөйләшнең кайбер туганлык терминнарын *-ау, -әү* кушымчасы белән әйтү менә шушы тарихи фонетик күчеш законнары белән бәйле булса кирәк.

**Баш бала** – беренче бала: *Илҗә баш бала ул минем.* (Болотово) *Синең баш бала Санукмы әле?* (Кассель)

Бу яктан сөйләш башкорт теленең көнчыгыш диалект сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә.

Бу терминның синонимы булып **тончык** сүзе дә кулланыла: *Минем тончыҡ балам күп тормады.* (Варлам) *Үлгән түти безнең тончыҡ бала иде.* (Попово)

Чагыштыр: башкорт әдәби теле һәм көнчыгыш диалекты сөйләшләрендә *тоңкос, тоңгос* – беренче бала.

Сөйләштә *эне, сеңел, ул, кыз* сүзләре мәгънәләре һәм формалары ягыннан да әдәби телдән аерылмыйлар.

### *Никахка бәйле булган туганлык терминнары*

Сөйләшнең бу өлкәгә караган *килен, кийәү, хатын, ир, бажҗа* һ.б. терминнары татар әдәби теленнән аерылмый.

Хатынга ир ягыннан туган булган мөнәсәбәтләрне атый торган терминнар *би* тамыры белән ясалалар.

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле: грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. Б. 231.

**Бийем** – кайнана. Мисаллар: *Бийем бида* (әд. *бик*) *усалыйы.* (Попово) *Бийем белән тора қызым*. (Кассель) *Бийем узған җәйдә генә үлде.* (Париж)

*Бийем* сүзе күрсәтелгән мәгънәдә урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә кулланыла. Бу яктан да нагайбәк сөйләшенең урта диалект сөйләшләренә якынлыгы күренә.

Килен иренең әнисенә, кагыйдә буларак, *нәнәү* дип эндәшә.

**Бийата** – кайната. Мисаллар: *Минем тәтәү қатынға бийата була инде.* (Варлам) *Минем бийата бийанадан мийа сүз әйттерми торғаныйы.* (Астафьевка)

*Бийата* термины алабуга керәшеннәре, минзәлә, бөре, шулай ук Оренбург өлкәсендә таралган татар сөйләшләре өчен дә хас.

Килен иренең атасына *тәтәү* дип эндәшә. Күреп үткәнебезчә, бу термин әдәби телдәге *әти* сүзенә туры килә.

**Бийағай** – иренең абыйсы. Мисаллар: *Бийағай қайтып керде шул бағыт қырдан*. (Париж) *Бийағай белән қалаға килдек.* (Фершампенуаз)

*Бийағай* сүзе тагын урта диалектның казан арты һәм нократ сөйләшләрендә кулланыла.

**Акбием** – иренең апасы: *Ақбийем өйдә җуқ, өйләрен мийа қалдырып киттеләр.* (Кассель)

*Ақбием* термины, нагайбәк сөйләшеннән тыш, алабуга һәм куйбышев керәшеннәре сөйләшләрендә дә теркәлгән.

*Би* тамыры ярдәмендә никах ягыннан булган туганлык мөнәсәбәтләрен белдерү татар, чуваш телләре (чув. *паятам* – кайнатам, *паянам* – кайнанам һ.б.) һәм башкорт теленең кайбер сөйләшләре өчен хас. Бу – болгар чорыннан ук килгән күренеш булырга да мөмкин.

*Би* тамыры күп кенә төрки телләрдә хуҗа, кенәз, түрәләрне белдерә торган *бәк* (бек) тамырына килеп тоташа. Төрки халыкларда өлкән кешеләргә, бигрәк тә өлкән туганнарга шушы сүз белән эндәшү киң таралган була. Килен, иренең өенә төшкәч, үзенең ир ягыннан булган туганнарына да шул исемне кушып әйткән.

Татар теленә килгәндә *би* тамыры урта диалектның төп сөйләшләренә (казан арты, минзәлә, бөре, пермь татарлары,

нократ-глазов) хас, ә *кан* тамыры мишәр сөйләшләрендә актив[1].

Сөйләштә тагын никах ягыннан туганлыкны белдерү өчен *кайын* тамыры белән дә ясалган терминнар кулланыла:

**Кайнаға** – иренең апасының ире яки хатынының абыйсы. Мисаллар: *Безнең кайнаға быригадир булып эшли.* (Кассель) *Теге бағытта қайнақалар белән бәйрәм иттек.* (Остроленко)

**Кайнигәч** – хатынның апасы. Мисаллар: *Қайнигәчләр, яғшы қайтып җиттек дип, Ташкиннан сәләмнәре килде.* (Париж) *Қайнигәч белән сеңлем қалаға бирып қайттылар.* (Астафьевка)

Никахка бәйле булган туганлык терминнарын кан тамырыннан ясау төрки телләрнең күпчелеге өчен хас[2]. Шундыйлардан алтай, хакас, шор, тува, якут, казакъ, башкорт, кыргыз, каракалпак, үзбәк, гагауз, азәрбайҗан телләрен күрсәтергә мөмкин.

**Оло нәнәү.** Бу термин-сүз абыйсының хатынына эндәшү өчен кулланыла. Мисаллар: *Оло нәнәү, пычақ қайда?* (Париж) *Абыйының катыны оло нәнәү була.* (Фершампенуаз)

**Бәләкәй нәнәү** термины абыйсы энесенең хатынына эндәшкән очракларда кулланыла. Мисаллар: *Бәләкәй нәнәү, сыйырны саwып қына ла әле.* (Остроленко) *Бәләкәй нәнәү белән бер баласы балнистан қайтқанда безгә килеп чәй эчеп чықтылар.* (Болотово)

*Оло нәнәү, бәләкәй нәнәү* терминнарын куллану белән нагайбәк сөйләше татар теленең башка сөйләшләреннән аерылып тора. Ләкин бу терминның ясалышы ягыннан ул урта диалект сөйләшләренә якын. Чагыштыру өчен бөре, камышлы сөйләшләрендә *зурнәй//зур инәй* (этисе белән бертуган абыйсының хатыны) минзәлә сөйләшендәге *дур әнәй//дурний//дурный* (әби, этисенең әнисе), казан арты, зәй керәшеннәрендәге *ызур әнәй* (этисенең әнисен, әнисенең әнисен) терминнарын күрсәтергә мөмкин.

[1] *Мухамедова Р.Г.* Некоторые итоги изучения жилища и поселения татарского колхозного крестьянства Мордовии // Вопросы истории Татарии. Казань, 1962. С. 248.

[2] *Покровская Л.А.* Термины родства в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. М., 1961. С. 68–69.

**Җанагай** – иренең энесе. Мисаллар: *Килен булып килгәчен, җанагайга күлмәк бүләк иттем мин.* (Фершампенуаз) *Шундый матур, тазайы җанагайым, агачайы белән шугыштан қайтмады.* (Париж)

*Җанагай* термины гарәп теленнән кергән *җан* һәм татар теленең *агай* сүзләреннән ясалган.

Бу күренештә без өйрәнә торган сөйләшнең минзәлә, нократ, глазов, казан арты һәм күп кенә керәшен сөйләшләре белән якынлыгы ачыла.

**Печкәчем** – иренең сеңлесе. Мисаллар: *Печкәчем дә килгән ийе туйга.* (Краснокаменка) *Печкәчәмнәр белән торасы килмәде, башқа чықты?* (Болотово)

*Печкәчәм* гомумән керәшен сөйләшләре өчен хас. Чагыштыру өчен тагын нократ-глазов сөйләшләрендәге иренең сеңлесен белдерә торган *бикәчем* сүзен дә китерергә мөмкин.

Димәк, күреп үткәнебезчә, нагайбәк сөйләшендә кулланыла торган туганлык терминнары, беренче чиратта, гомумән керәшен татарлары белән уртак сыйфатларны били, икенче яктан, китерелгән үзенчәлекләрдә без өйрәнә торган сөйләшнең урта диалектның төп сөйләшләре (казан арты, минзәлә, нократ, глазов, пермь татарлары) белән якынлыгы күренә.

### *Йорт-җир, каралты төзелешләренә, йорт җиһазларына караган сүзләр*

**Айак очо** – каралтылар артындагы бәрәңге бакчасы. Мисаллар: *Айақ очон киртәләп алганыйық былтыр, быйыл багыт теймәде инде.* (Астафьевка) *Башта айақ очондагы бақчаны алып бетерийек әле.* (Остроленко)

Бу үзенчәлек урта диалектның казан арты (мамадыш), шулай ук казан арты һәм зәй керәшеннәре, минзәлә сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән.

**Баз** – идән асты. Мисаллар: *Баз салқын булгач, өй дә салқын була.* (Фершампенуаз) *Бәрәңгене базга қуйсаң, өйдә ис була, дибез дә қуймыйбыз.* (Кассель)

Париж авылында бу төшенчәне **сайғак асты** термины белән белдерү дә бар: *Сайғақ астына ғына төшеп қаймақны алып мен әле.* (Париж)

Урта диалектның казан арты, минзәлә, зәй керәшеннәре сөйләшләрендә дә *сайгак асты* шушы ук мәгънәне белдерә.

**Иннек** – татар әдәби телендә һәм шулай ук аның күп кенә сөйләшләрендә кулланыла торган *иннек* сүзенең нагайбәк сөйләшендә ике мәгънәсе бар. Беренчедән, ул коймаларны тотып тора торган киртә агачны аңлата, икенчедән, киртәләрдән генә торган җил капканы белдерә. Мисаллар: *Инекне алып булмый микән арба кертергә.* (Остроленко**)** *Иннекне йабып қуйсақ, чит маллар керми.* (Болотово)

*Иннек* сүзен капка мәгънәсендә куллану урта диалектның минзәлә, бөре, казан арты, мамадыш, тау ягы, кама тамагы сөйләшләре өчен дә хас.

**Күтәрмә** – ачылмалы тәрәзә: *Күтәрмәләрне ачып җибәр әле.* (Кассель)

*Күтәрмә* сүзе казан арты, минзәлә, пермь татарлары, шулай ук мишәр диалектының байкыбаш сөйләшләрендә – болдыр, нократ, глазов һәм эчкен сөйләшләрендә үкчә төшенчәләрен белдерә.

**Ниргә** – өйдәге бүрәнәләрнең рәте. Мисаллар: *Унҗиде ниргәле безнең өй.* (Париж) *Тағын берәр ниргә өстәргә кирәк булған, болай тәбәнәк түгелме соң?* (Варлам)

Сөйләш бу яктан казан арты, бөре сөйләшләренә якын. Бәрәңге татарларында исә *ниргә* дип бураны яки өйнең нигезен атыйлар.

**Пийәш** – мич янына куела торган терәк багана. Мисаллар: *Бистәр пийәштә эленеп тора.* (Париж) *Син нийә пийәшне сырламый калдырдың?* (Астафьевка)

*Пийәш* сүзе шушы мәгънәдә зәй керәшеннәрендә дә теркәлгән.

**Сайғак** – идән. *Сайғақларны сөртеп ал.* (Астафьевка) *Мучаның сайғағын ачтық, базға төшмә.* (Болотово)

*Сайғақ* сүзе татар теленең күп кенә сөйләшләрендә кулланыла. Без өйрәнә торган сөйләш күрсәтелгән үзенчәлеге белән урта диалектның казан арты, минзәлә сөйләшләренә якын тора. Биредә дә *сайғақ* термины идән төшенчәсен атый.

*Сайгак* сүзе төрки телләрдә киң таралган һәм төрле мәгънәләрне аңлата. Мәсәлән, чуваш телендә *сайхак* – киртә агачлардан ясалган тезмә; башкортларда *һайҡау* – түбәдәге салам астына салып калдырган киртәләр; казак. *сайғағ* – озын таяк, кабер тактасы; к.калп. *сайгак* – кабергә тыгып калдырыла торган озын таяк; шор. *сойгу,* хакас. *сырғай* – озын таяк; азәрб. *сайгак,* алтай. *сайға,* ойрот. *сайгак* – балык кадагыч. Бу сүз кыргыз, алтай, ойрот телләрендә кадауны белдергән *сай* фигыленә нигезләнеп ясалган.

## *Тормыш-көнкүреш әйберләре, хуҗалык коралларына караган сүзләр*

### *Савыт-саба исемнәре*

**Бадийа чиләк** – зур чиләк. Мисаллар: *Бадийа чиләк сыу китерергә аwыр була.* (Болотово) *Ашлы сыу чиләгебез дә бадийа чиләк.* (Варлам) *Бадийалар булайы элек.* (Фершампенуаз)

Мишәр диалектының чистай һәм ләмбрә сөйләшләрендә рус теленнән кергән бу сүз (рус. *бадья*) белән кое чиләген атыйлар.

**Түмрәй** – кырга су илтә торган савыт. Мисаллар: *Қырға түмрәйне алабызмы?* (Фершампенуаз) *Түмрәйгә шишмә сыwы ал.* (Париж)

**Бағрач** – аш бүлгеч. Мисаллар: *Бағрачны алып бир әле.* (Болотово) *Бағрачны җуwып қуйдым.* (Париж)

*Бағрач* сүзе урта диалектның Казанга якын территориядә формалашкан сөйләшләр өчен хас. Бу сүз казан арты, тау ягы, минзәлә, алабуга керәшеннәре сөйләшләрендә билгеле. Күрсәтелгән сөйләшләр белән уртак булган бу сүзне нагайбәкләр яңа урынга күчкәч тә онытмаганнар.

**Тусатаған//тустыған** – кырлы рюмка. Мисаллар: *Тустағын белән эчә торғаныйық.* (Париж) *Тағын бер тустыған китер әле.* (Остроленко)

*Тустыған* сүзе дә татар сөйләшләрендә *тустыған//тустаған//дустыған* формаларында киң таралган. *Тустыған* сүзен шушы мәгънәдә куллану белән нагайбәк сөйләше казан арты һәм зәй керәшеннәре сөйләшләренә якын. Казан арты (мамадыш, балтач),

бәрәңге, тау ягы, минзәлә сөйләшләрендә бу сүз кечкенә табак, чынаяк мәгънәләрендә кулланыла. Мишәр диалектында *дустыган* су чүмечен аңлата.

**Чәркә** – билле рюмка. Мисаллар: *Бер генә чәркә эчеп җуйсаң, нәрсә булыр дип җурҗасың?* (Париж) *Минем теге йәмне чәркәләр wатылып беттеләр.* (Краснокаменка)

Бу урында чагыштыру өчен чуваш телендәге *черке,* рус телендәге *чарка* (рюмка) сүзләрен дә китерергә мөмкин.

**Әрҗә** – иске киемнәр салып куя торган сандык формасындагы тартма: *Иске күлмәгең әрҗәдә бугай.* (Фершампенуаз)

*Әрҗә* сүзе әдәби телдә ящик яки тартманы аңлата.

Бу сүз чүпрәле, пермь татарлары сөйләшендә – сандык сыман кәрзинне, нократ, глазов сөйләшендә гомумән сандыкны белдерә.

*Әрҗә* сүзе сандык, киемнәр салып куя торган тартма – ящик мәгънәсендә каракалпак, казакъ, кыргыз телләрендә һәм аларның сөйләшләрендә дә билгеле.

**Кәнди** – агач табак. Мисаллар: *Кәндигә сал да җатыҗ аша.* (Париж) *Кәндигә салып җына җуйдым бит әле.* (Кассель)

Фарсы теленнән кергән бу сүз татар теле сөйләшләрендә киң таралган. Тау ягы, казан арты (лаеш), камышлы, чистай, мәләкәс сөйләшләрендә *кәнди* сүзе кечкенә эмаль табакны, тау ягы (кама тамагы), чистай сөйләшләрендә һәртөрле кечкенә табакны белдерә.

**Мәшкә** – әд. бөке: *Йөшелнең* (әд. бутылка) *мәшкәсен ачып булмый.* (Париж)

Бу үзенчәлеге белән нагайбәк пермь татарлары сөйләшенә якын тора.

## *Эш, көндәлек тормыш-көнкүреш коралларын атый торган сүзләр*

**Аталаwыч//атлаwыч** – гөбе пешкәге: *Аталаwычны әрәтлисеңме син, бабай? (*Болотово)

Бу сүз шушы мәгънәдә минзәлә сөйләшендә дә теркәлгән. Атлавыч сүзе казан арты, шулай ук мишәр диалектының сергач, темников сөйләшләрендә май язу, туглау мәгънәсен белдерә торган *атлау* сүзе һәм *-ыч* кушымчасыннан тора: *атлау + ыч =аталаwыч.*

**Шабала** – күмер соскыч: *Шабала күмер алырга уңай ул, көле аста кала, күмере өстә генә була.* (Попово)

*Шабала* сүзе, нагайбәк керәшеннәреннән тыш, эчкен татарлары һәм Курган өлкәсендә яшәүче мишәрләр сөйләшендә дә шушы мәгънәдә кулланыла. Урта диалектның нократ сөйләшендә аш чүмечен аңлата торган *шабалка* сүзен дә күрсәтеп китәргә кирәк. Бу яктан сөйләшнең башкорт теленең күрше сөйләшләре белән дә якынлыгы күренә.

*Шабала* сүзе төрки телләрдә дә бар: чуваш телендә *сапала* – аш соскыч, аш бүлгеч; чуваш сөйләшләрендә, алтай телендә – кашык; казакъларда *шабала* – тишекле чүмеч; төрек. *сапылак* – озын саплы чүмеч.

В.Г. Егоров бу сүзнең этимологиясен авыз ияртүеннән килеп чыккан дип аңлата[1].

**Киги** – тәгәрмәч тугымнары: *Тәгәрмәчнең кигиләрен алыштырасы бар.* (Остроленко)

Казан арты (лаеш) сөйләшендә *киги* тырнак (коготь) мәгънәсендә кулланыла.

**Шулы** – җилпуч: *Онны ипи шулысыннан алдым.* (Ключевская)

*Шулы* сүзе урта диалектның минзәлә сөйләшендә дә шушы ук мәгънәне белдерә.

**Айа** – кәҗә мамыгын чистарта торган тарак формасындагы җайланма. Мисал: *Айаны тотоп күршеләргә кереп утырдым.* (Варлам)

**Айалау** – кәҗә мамыгын кылыннан чистарту: *Мамык айалап утырам әле шәлгә былыр дип.* (Остроленко) *Моноң машыгы айаланмаган әле.* (Кассель)

*Айа, айалау* сүзләре, нагайбәк сөйләшеннән тыш, казан арты һәм Оренбург сөйләшләрендә дә билгеле.

**Пычу** – утын кисү. Мисал: *Берәр кеше булса, утынны пычтырып җуйарыйым.* (Париж)

Эчкен сөйләшендә бу фигыль *пыцу* вариантында әйтелә.

---

[1] *Егоров В.Г.* Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары, 1964.

Борынгы төрки *печү//пычу* сүзләренең беренчел мәгънәсе[1] татар теленең мишәр һәм себер диалектында[2] һәм казан арты керәшеннәрендә генә саклантан. Хәзерге татар әдәби телендә бу сүзнең мәгънәсе чикләнгән. Нагайбәкләрдәге варианты татар теле өчен нигез форма булырга тиеш. Шул ук тамырдан әдәби телдәге *пычкы, пычак* сүзләре дә ясалган.

Бу сүз шушы ук мәгънәдә төрки телләрдә *бес* (башкорт), *быш* (тува), *быс* (якут), *пач* (чуваш) формаларында кулланыла.

***Кием-салым, урын-җиргә караган сүзләр***

**Алчүпрәк** – алъяпкыч: *Алчүпрәгеңне бәйлә алдыңа.* (Париж)

*Алчүпрәк//алчепрәк//алчеприк* вариантларында бу сүз нократ һәм пермь татарлары сөйләшендә теркәлгән.

**Балан итәк** – хатын-кызлар күлмәгенең итәк очына тотыла торган киңрәк бала итәк. Мисал: *Балан итәкле күлмәгемне кидем.* (Париж)

Рус телендәге сүздән үзгәртелеп ясалган бу сүз мишәр диалектының ләмберә сөйләшендә дә кулланыла.

**Бистәр** – сөлге. Мисаллар: *Менә генә бистәр, ҫулыңны сөрт* (Краснокаменка). *Бистәреңне ҫайа элдең?* (Варлам)

*Бистәр* сүзе бигрәк тә керәшен сөйләшләре өчен үзенчәлекле. Казан арты сөйләшләрендә аның *бистер//бестәр* вариантларында әйтелеше дә бар.

**Ката** – ботинка, гомумән күн аяк киеме. Мисал: *Ҫатаңны тышка салып ҫалдырма.* (Фершампенуаз)

Урта диалектның казан арты сөйләшләрендә *ҫата* – кыска балтырлы киез итек. Эчкен татарлары сөйләшендә *ката* дип туфлигә охшатып тегелгән күн аяк киеме, күн башмакларны атыйлар.

**Сүрәкә** – хатын-кызлар баш киеме. Мисаллар: *Мин элеккеге сүрәкәләрне дә кийеп килим әле дигәнийем.* (Париж) *Минем заманға ҫалмады инде ул сүрәкәләр.* (Краснокаменка)

---

[1] Древнетюркский словарь. Л., 1969. С. 104.

[2] *Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле: грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. Б. 185.

*Сүрәкә* керәшен татарларының күпчелек төкеменә билгеле. Мондый үзенчәлек мари халкында да сакланып калган һәм шушы исем белән үк аталып йөртелә. Диалектологик сүзлектә бу сүз мари теленнән кергән дип аңлатыла.

***Аш-суга караган сүзләр***

**Аш эчеү** – аш ашау. Мисаллар: *Син безнең белән эш эчәргә утырмадың.* (Краснокаменка) *Аш эчәргә утыр.* (Болотово)

*Аш эчү* дип сөйләү, нагайбәк сөйләшеннән тыш, урта диалектның минзәлә, пермь татарлары, казан арты, зәй керәшеннәре өчен дә характерлы.

**Тамак** – азык: *Тамақ әзерләргә бағыт җитте.* (Варлам)

*Тамак* сүзе сөйләштә сакланып калган борынгы үзенчәлекләрдән санала. Шушы мәгънәдә ул хакас, алтай, кыргыз телләрендә дә кулланыла. Чагышт.: хакас. *тамах хайнант* – ашарга әзерләү.

**Тамаклану** – ашау. Мисаллар: *Тамақланырға барасыңмыни?* (Попово) *Тамақланып алыгыз инде йоқлағанчы.* (Париж)

*Тамаклану* сүзен ашау мәгънәсендә куллану эчкен сөйләшендә бар.

**Дүречмак** – ачы камырны җәеп, өстенә каймак, изелгән бәрәңге һ.б.ш.ны ягып пешерелгән ашамлык, шәңгә. Мисаллар: *Дүречмақның өстенә қаймақ йағып пешерсәң дә була.* (Попово) *Дүречмағың тәмле булған.* (Париж)

Бу сүзне куллану белән нагайбәк сөйләше алабуга керәшеннәре (*дурочмак*), казан арты (мамадыш) (*дурычмак*) сөйләшләре белән якыная.

**Көлчә** – ачыга изелгән арыш яки бодай камырыннан, кул белән юкарак итеп җәйеп, ут каршында табада пешереп алынган азык. Мисал: *Көлчә пешергәнийе тутаң, тәмне булғанмы?* (Астафьевка)

Бу азык һәм аны *көлчә* дип атау, нагайбәкләрдән тыш, урта диалектның казан арты (мамадыш, лаеш), минзәлә сөйләшләрендә дә бар.

**Кысыр аш** – итсез пешерелгән аш. Мисаллар: *Қысыр аш қына пешердем әле бүген.* (Париж) *Җәй көне ит булып тормый, ашның қысырын да пешерәбез.* (Фершампенуаз)

Бу үзенчәлек казан арты (этнә), эчкен сөйләшләрендә теркәлгән.

**Шишара** – бавырсак. Мисал: *Шишараны кукәйгә генә басасың да, майға қайнатып пешерәсең.* (Ключевская)

*Шишара* сүзе зәй һәм куйбышев керәшеннәре сөйләшләрендә дә шушы ук мәгънәдә кулланыла. Минзәлә сөйләшендә *шишара* – төче камыр, камышлы һәм мишәр диалектының чистай сөйләшләрендә камырны вак-вак кисеп, эченә повидло салып пешерелгән камыр ашы.

### *Терлек һәм кош-кортларны атый торган сүзләр*

**Асау ат** – җигәргә өйрәтелмәгән ат. Мисаллар: *Асау ат күwен йөрисең сүз тыңнамый.* (Париж) *Асау атқа суқтың ни, суқмадың ни, бер бармаса бармый инде.* (Остроленко)

*Асау* сүзе шушы мәгънәдә көнчыгыш диалект өчен дә хас[1]. Бу яктан сөйләшнең башкорт һәм казакъ сөйләшләре белән дә уртаклыгы бар.

**Буйдак** – бер яшьлек эре мөгезле терлек яки бозауламаган тана. Мисал: *Буйдақ қына бар, сыйырлары да җуқ.* (Париж)

Татар теле сөйләшләрендә *буйдак* сүзенең берничә төрле мәгънәсе бар. Казан арты (лаеш), казан арты керәшен татарлары сөйләшләрендә бу сүз белән җәяүле кешене атыйлар. Оренбург өлкәсендәге татар сөйләшләрендә *буйдак* – ялчы мәгънәсендә дә йөри. Күп кенә татар сөйләшләрендә бу сүз өйләнмәгән яки туган-тумачасы булмаган кешегә карата да әйтелә. Пермь татарларында *үзбуйдак* кеше дип үз белдеге белән эшләп йөрүче кешене атыйлар. Казакъ телендә *бойдак* – ялгызак кеше, 1 яшьлек печкән тәкә, *бойдақ мал* – кысыр терлек; кыргыз, каракалпак *бойдак;* башк. *буйзак* – ялгызак; чув. *путеп* – сарык, кәҗә бәрәне дигән мәгънәләрне аңлата.

**Гөлкәй** – әд. *колын: Бу атның да гөлкәйе бар икән.* (Париж)

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле: грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. Б. 104.

**Бүлтерек** – көзен туган бәрән: *Бүлтерек булса да җарый, зур булып үсәр әле.* (Болотово)

Бу яктан без өйрәнә торган сөйләш башкорт теле белән якыная.

Урта диалектның минзәлә сөйләшендә кулланыла торган *бүлтерек* сүзе тәбәнәк буйлы кешегә карата әйтелә.

Бу сүздән *бүлтерекләү* фигыле ясала. Ул сарыкның көзен бәрәнләвен аңлата. Мисаллар: *Сарығыбыз синтәбердә бүлтерекләгәнийе.* (Фершампенуаз) *Сарықның көзен бүлтерекләwе әйбәт түгел аның бер дә.* (Астафьевка)

Урта диалектның бөре, минзәлә сөйләшләрендә *бүлтерекләү* дип сарыкның җәен бәрәнләвен дә атыйлар.

**Җәннек** – кош-корт. Мисаллар: *Җәннекләр күп асырыйбыз, мендәрләр шуңа күп безнең.* (Варлам) *Җәннекләрегезгә бодай кирәк түгелме?* (Кассель)

*Җәннек* сүзе шушы мәгънәдә, без өйрәнә торган сөйләштән тыш, урта диалектның пермь татарлары сөйләшендә дә бар. Биредә *җәннек* сүзенең мәгънәләре киңрәк, ул 1) гомумән кыргый хайван, 2) мал-туарны белдерә.

**Күгәри** – күгәрчен; *Күгәриләр гөрләмиләр, сыwық булыр.* (Париж)

**Чыпый** – чыпчык. Мисал: *Чыпыйлар таwықларға ашарға ирек бирмиләр әй.* (Фершампенуаз)

### *Табигать күренешләрен һәм җир-суларны атый торган сүзләр*

**Кырлач** – кышкы каты суыклар. Мисаллар: *Қырлач бағытларыйы буғай ул көннәрдә, көннәр шундый салқын, без Варлам арқылы Чибәркүлгә киттек.* (Париж) *Қырлачларда өйгә ике җағабыз.* (Остроленко)

Бу яктан нагайбәк сөйләше минзәлә сөйләше белән уртаклык күрсәтә.

Нагайбәк керәшеннәрендә, салкын көннәрне кайвакытта һәм ни дәрәҗәдә салкын булуына карап, *ағам қырлач // оло қырлач, энем қырлач // бәләкәй қырлач* дип йөртү бар.

**Ағам қырлач // оло қырлач** дип декабрь ахыры, гыйнвар башларында була торган салкын көннәрне атыйлар. Мисаллар: *Ағам қырлач әйтә икән, мин китәм, менә минем энем күрсәтер сезгә кирәкне.* (Париж) *Оло қырлач дикәбернең соңнарында ғына башлана ул*. (Варлам)

**Энем қырлач // бәләкәй қырлач** – гыйнвар ахырында февраль башларында була торган салкын көннәр. Мисаллар: *Мин үсеп кенә җиттем, қыш та бетте дип әйтә ди энем қырлач.* (Кассель) *Кече қырлач фиврал айларында була.* (Астафьевка)

Кыш айларында була торган салкыннарны шушы рәвешчә атап йөртү керәшен татарларының күбесенә хас. Чулым татарларында *хурлач ай* – буранлы айны аңлата. В.В. Радлов сүзнең мәгънәсен түбәндәгечә аңлата: *ағам қырлач* – декабрь, *энем қырлач* – гыйнвар.

Бу сүз кайбер төрки телләрдә дә табыла. Мәсәлән, чуваш телендә *ман карлач* – гыйнвар, *кесен карлач* – февраль айларында була торган салкыннарны, ә хакас телендә *кичиг хырлас өй* – каты салкын була торган айны (декабрьне), караим телендә *улу кырлаш* – каты салкын, *кичи кырлаш* – көчсез салкынны белдерә.

Н.И. Золотницкий бу сүзне татар телендәге *кырылык* сүзе белән бәйләп аңлата[1]. В. Сбоев, *кырлач* сүзен катырып калдыру, барысын да туктату һ.б. мәгънәләрне белдергән *кырилак* сүзеннән килеп чыккан, дип исәпли.

**Ақман-туқман** – кыш айларында була торган каты бураннар: *Ақман-туқман бураннар башлауга безнең дәдәй ахутаға китәйе.* (Париж)

*Акман-тукман* сүзе шушы мәгънәдә Башкортстанның көнбатыш районнарында таралган татар һәм учалы типтәрләре сөйләшләрендә дә кулланыла.

**Комайак** – елга ярындагы комлык. Мисаллар: *Қазақ китә, озатайық қомайаққа җиткенче.* (Париж) *Анда бик йахшы, күл буйлары қомайақ.* (Краснокаменка)

---

[1] *Золотницкий Н.И.* Корневой чувашско-русский словарь, сравненный с языками и наречиями разных народов тюркского, финского и др. племен. Казань, 1875.

*Ҡомайаҡ* сүзе, без өйрәнә торган сөйләштән тыш, казан арты (лаеш), минзәлә сөйләшләрендә дә бар. Биредә бу сүз елга ярында ком салынган урынны белдерә.

**Сыза** – иңкүлек: *Сызаға җибәрдем малларны.* (Попово)

Казан арты һәм зәй керәшеннәрендә *сыза* – ышна, казан арты (дөбьяз) сөйләшендә зур булмаган ярлы җирләрне аңлата.

**Сазамак** – баткак, сазлы җир: *Ишек алдына сазамаҡ буғач, таш җәйдек.* (Париж)

Бу үзенчәлеге белән нагайбәк сөйләше казан арты (балтач) сөйләшенә якын. Шушы ук мәгънәдә тау ягы сөйләшләрендә – *сазамыҡ,* мишәр диалектының мәләкәс сөйләшендә *сазамык* вариантлары да теркәлгән.

**Уба** – зур булмаган калкулык. Мисаллар: *Убаға да менеп ҡарадым, күренмәде.* (Париж) *Безнең җаҡларда күп кенә убалар бар.*

Бу сүз камышлы сөйләшендә, көнчыгыш диалектта да шушы ук мәгънәдә кулланыла[1]. Минзәлә һәм Оренбург татарлары сөйләшендә *уба* – җиргә казылып ясалган чокыр, җәнлек оясын белдерә. Татар телендәге *җир убу, убылу* сүзләре белән дә чагыштыр.

*Уба* сүзе Урал һәм Себер территориясендә таралган күп кенә төрки телләрдә дә бар. Мәсәлән, башк. *уба* – курган, калкулык; алт. *оба* – кыя таш; хакас. *обаз* – курган ташы. Чагыштыр: төрек телендә *оба* – тигез урын.

Бу сүз борынгы төрки язма истәлекләрдә *опа//оба* вариантларында билгеле[2].

**Уйаз җир** – уйсу җир: *Уйаз җирдә җөри бозау.* (Париж)

Бу сүз эчкен һәм Пермь татарлары сөйләшләре өчен дә характерлы. Үзенең ясалышы белән *уйаз* сүзе *уй-йаз* элементларыннан тора. *Йаз* тамыры басу, кыр мәгънәсендә, Казан арты топонимнарында еш очрый. *Уй* тамырыннан әдәби телдә иңкүлек җирне белдерә торган *уйсу* сүзе ясалган.

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле: грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. Б. 211.

[2] *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М.; Л., 1959. С. 66.

### *Үсемлекләрне атый торган сүзләр*

**Айбағыр** – көнбагыш. Мисаллар: Бүген колхоз айбағырын ташыйлар. (Попово) Айбагыр утыртқаныйым, карчыклар ашап беткәннәр. (Париж)

Бу яктан да нагайбәк сөйләшенең Казан арты керәшеннәре сөйләше белән якынлыгы күренә. Урта диалектның казан арты сөйләшләрендә бу сүзнең *айбағыр,* мишәр сөйләшләрендә *айбагыр* вариантлары бар. Чагыштыру өчен Казан арты керәшеннәрендәге *айбағыш,* чистай сөйләшләрендәге *айбар, айбаһар* сүзләрен дә әйтеп китәргә кирәк.

*Көнбагыш* (рус. *подсолнечник*) үсемлеген татар теле сөйләшләрендә төрлечә атыйлар. Ләкин бу атамаларның күбесе вариантлар гына булып, ике сүздән (атамадан) таралганнар: *айбагар//айбагыш*, 2) *көнбагыр//көнбагыш. Айбагар//айбагыр//айбагыш//айбар* атамасы бигрәк тә мишәр диалекты сөйләшләрендә һәм урта диалектның Казан арты һәм Алабуга керәшеннәре, казан арты (балтач) сөйләшләрендә сакланып килә. Нагайбәкләрдә бу сүз Казан арты керәшеннәрендәгечә әйтелә.

**Каудан** – узган елдагы үлән. Мисаллар: *Анда қаудан ғына, әйбәт итеп чабып та бумый.* (Париж) *Мал қауданда ғына чемченеп җөри.* (Фершампенуаз)

*Қаудан* сүзе Казан ханлыгы территориясендә формалашкан сөйләшләрдә (казан арты, тау ягы, минзәлә) актив кулланыла. Бу сүз соңгы елларда чыккан әдәби тел сүзлекләренә дә кертелгән. Бу сүзнең Пермь татарлары һәм нагайбәк керәшеннәрендә булуы борынгылыкның сакланып килүе турында сөйли. Эчкен татарлары сөйләшендә мондый печәнне *кау* дип атыйлар, себер татарларында *кау* сүзе, әлеге мәгънә белән бергә, агач гөмбәсе яки кипкән агач гөмбәсеннән ясалган сүсне дә аңлата. Чагыштыру өчен Пермь татарларында хайван ябагасы һәм елан кабыгын аңлата торган *кау* сүзе дә барлыгын әйтеп китәргә мөмкин.

*Каудан, кау* сүзләре узган ел чабылмый калган печән мәгънәсендә күп кенә төрки телләр (тува, хакас, шор һ.б.) өчен дә хас. Чуваш телендә *хавша* – кибү, борчылу; казак. *каудыр* –

коры-кипкән;, якут. *хаздарый* – кору, кибү; башкорт телендә *кау* – кар астыннан чыккан былтыргы печән мәгънәсен белдерә.

**Уксын** – кыргый сарымсак: *Уқсыннарны бақчаға утыртып қарадық әле.* (Париж)

Пермь татарлары сөйләшләрендә сарымсакны *уксын* дип атыйлар. Шушы мәгънәдә бу сүз башкорт теле сөйләшләрендә дә бар. Пермь һәм нагайбәк сөйләшләрендә кулланылган бу сүз башкорт сөйләшләре йогынтысы нәтиҗәсендә булырга мөмкин.

**Чауқа** – каен. Мисаллар: *Әнә чауқа үсеп утыра.* (Варлам) *Сез урманға барғач чауқа да кисеп апқайтығыйзыйы*. (Попово)

Бу үзенчәлеге белән без өйрәнә торган сөйләш минзәлә сөйләше белән уртаклаша. Мишәр диалектының чистай, сергач сөйләшләрендә бу сүз яшь каен мәгънәсен белдереп, *цаука* формасында әйтелә. Эчкен татарлары һәм себер татарлары сөйләшләрендә цаwыл яшь каенны, пермь татарлары сөйләшендә кулланыла торган *чаwыл* сүзе гомумән каен мәгънәсен аңлата.

Бу сүз *саwыл* (башк.), *чаал* (тув.), *чал* (хакас) вариантларында күрше төрки телләрдә дә кулланыла.

**Чаукалык** – каенлык. Мисаллар: *Сыйыр чауқалықта җөри әле, кичен генә апқайтырсыз.* (Краснокаменка) *Бер чауқалыққа да барып утырып булмады.* (Кассель)

*Чаукалык* сүзе шушы ук мәгънәдә төрле фонетик вариантларда югарыда күрсәтелгән сөйләшләрдә дә актив кулланыла. Эчкен һәм себер татарлары сөйләшендә дә *цаwыллык* – яшь каенлык, пермь татарлары сөйләшендәге *чаwыллык* – гомумән каенлык төшенчәсен аңлата.

**Бүтәгә** – үлән төбендә үсә торган вак үлән: *Шелекәй буйлары өй бүтәгә, Ат айаққайларын күтәрә.* (Җырдан, Париж)

**Шелек** – гөлҗимеш: *Шелекнең чәчәге бик матур була.* (Остроленко) Минзәлә сөйләшендә *шелек* дип чәнчи торган үләнне атыйлар. Димәк, бу сүзне нагайбәкләр элеккеге территорияләрендә үк белгәннәр. Гөлҗимешне *шелек* дип атау аның кадау, чәнчү сыйфатыннан чыгып кабул ителгән.

**Үрмәкәй** – эт эчәге: *Үрмәкәй генә бәрәңге бакчалары.* (Фершампенуаз)

***Кешенең тән төзелешенә, физик һәм рухи хәленә караган сүзләр***

а) **Тән төзелешенә караган сүзләр:**

**Боғозлау** – бугаз. Мисаллар: *Бүре атның боғозлаwына җабышҡан.* (Париж) *Боғозлаwына сыwыҡ тигән.* (Болотово)

*Богозлау* сүзе башка сөйләшләрдә теркәлмәгән. Чагыштыру өчен бөре сөйләшендә сүз көрәштерүдә, бәхәсләшүдә җиңеп чыгуны аңлата торган *богачлау* сүзен китерергә мөмкин.

*Богозлау* сүзе ярдәмендә сөйләштә *боғозлау башы* дигән термин да ясала. Ул бугаз төенен аңлата. Париж авылында моны *дөмби* дип тә атыйлар.

**Касык** – бүсер: *Малайым ҡасығын тотоп чирли.* (Попово)

**Кәүсә** – гәүдә: *Кәүсәсен сузып урам буйлап йөри.* (Париж)

**Чекрән** – сеңер: *Чекрәнем сузылған.* (Болотово)

**Танау** – борын: *Баланың танаwын сөрт.* (Ключевская)

Борынгы татар телендә дә бу сүз актив кулланылган булса кирәк. Аның күп кенә сөйләшләрдә (минзәлә, камышлы, оренбург сөйләшләре һәм мишәр диалектында) таралган булуы шуны күрсәтә.

ә) **Кешене физик һәм рухи яктан характерлый торган сүзләр:**

**Алчак кеше** – ачык кеше: *Без инде үзебез дә алчаҡраҡ кешеләр идек, килгәнгә сүз әйтмибез.* (Париж)

Бу сүз урта диалект сөйләшләре өчен характерлы. Шушы мәгънәдә ул казан арты, бәрәңге, минзәлә, тау ягы, камышлы сөйләшләрендә теркәлгән.

**Айаулы** – кадерле: *Берәүнең бер айаулы ғына баласы булғандыр инде.* (Попово)

*Айаулы* сүзен шушы ук мәгънәдә куллану тагын мишәр диалектының темников сөйләшендә билгеле. Эчкен сөйләшендә бу сүз авырта торган җирне аңлата: *Айаулы җиренә тидегезме әллә?* (Эчкен)

**Байғыш** – мескен (кызганып әйтелә торган сүз). Мисал: *Байғыш, туңып йөридер инде.* (Париж)

Бу сүз төрки телләрдә дә киң таралган. Мәсәлән, чуваш теле сөйләшләрендә *пайкуш* – ялгызак, яки ярлы кеше; азәрб. *байкуш* –

ялгызак кеше, мәче башы ябалак; уйгур. *байкуш* – ябалак, мескен кеше; башк. *байғыш* – ярлы, мескен кешене аңлата.

**Исала** – тиле: *Бигрәк исала инде бәләйәк малайлары.* (Кассель)

**Дәмәк** – шат күңелле, сүзгә оста кеше. Мисаллар: *Аларға бар, алар бик дәмәк кеше.* (Варлам) *Безнең ғодача да сүзгә бик дәмәк кеше.* (Париж)

*Дәмәк* сүзе, нагайбәк керәшеннәреннән тыш, зәй керәшеннәрендә дә бар. Бередә ул *кызык, мәзәк* мәгънәләрендә кулланыла.

**Йуашлау кеше** – юаш кеше: *Мин үзем йуашлау кеше.* (Париж)

**Илем** – ачык, киң күңелле. Мисал: *Җәкәүләр бик илем кеше алар барсы да.* (Париж)

Шушы ук мәгънәдә *илем* сүзе эчкен сөйләшендә дә теркәлгән.

**Иҗекләү** – үчекләү, үртәү: *Мине иҗекләп көлеп тора бит.* (Париж)

*Иҗекләү* сүзе шушы ук мәгънәдә зәй һәм казан арты керәшеннәре сөйләшләрендә дә билгеле.

**Иргәләшү** – сүз көрәштерү, бәхәсләшү. Мисаллар: *Иргәләшеп утырдық, малайымнарда.* (Попово) *Алар күп сөйләшеп утырсалар, хәзер иргәләшеп китәләр.* (Астафьевка)

*Иргәләшү, иргәләштерү* сүзләре дә урта диалект сөйләшләре өчен хас. Шундыйлардан бу сүз казан арты (әтнә, дөбьяз), минзәлә сөйләшләрендә билгеләнеп үтелгән.

**Ызғыту** – котырту: *Ызғытма үзеңнән оло кешене.* (Варлам)

*Ызгыту* шушы ук мәгънәдә нократ, глазов һәм зәй керәшеннәре сөйләшләрендә кулланыла.

**Исәңгерәү** – аптырау, баш кату. Мисаллар: *Эзли-эзли исәңгерәп беттем.* (Варлам) *Син мине нигә җуқ нәрсәләр соратып башымны исәңгерәтеп җатасың?* (Париж)

Бу сүз шушы мәгънәдә *исәңгерәү//исәңрәү//исеңерәтү//исәнкерәү* вариантларында тагын казан арты – дөбьяз, минзәлә сөйләшләрендә кулланыла. Моннан тыш минзәлә, пермь татарлары сөйләшләрендә бу сүзнең һуштан язу, аңын югалту мәгънәләре дә бар.

**Кыw кеше** – мактанчык: *Күрше малайы бик кыw кеше.* (Кассель)

Бу сүзнең сөйләштә *қый* һәм *мәшкә* синонимнары бар. Мисаллар: *Мәшкә бит ул, жҫөри шунда қыйланып.* (Париж) *Қый кешене жҫаратмыйым мин.* (Астафьевка)

**Миндәү//минкәйү** – имгәнү. Мисал: *Аның бер айагы миндәгән.* (Фершампенуаз)

Бу сүзнең татар теле сөйләшләрендә *миңдәү//минтәү//минкәйү* вариантларында да кулланышы бар һәм төрле сөйләшләрдә мәгънәләре дә төрлечә: казан арты (балтач, дөбьяз), минзәлә сөйләшләрендә *миндәү* гомумән авыруны аңлата, тау ягы һәм эчкен сөйләшләрендә *миңдәү* миңерәүләнү, *минкәйү* ябыгуны белдерә, пермь татарлары сөйләшендә *минтәү* бетеренү, ябыгу мәгънәсендә йөри.

Нагайбәк сөйләшендә бу сүз, күргәнебезчә, казан арты (балтач) һәм минзәлә сөйләшләрендәгегә якын мәгънәдә кулланыла.

**Имгәкле** – имгәк, гарип: *Жҫығылып имгәкле була күрмә тағын.* (Краснокаменка)

**Сорамчақ** – соранучан, сорарга яратучы кеше. Мисаллар: *Безнең күршеләр бик сорамчақ кешеләр, бернәрсә күрсәләр, сорарга ғына торалар.* (Краснокаменка)

Урта диалектның пермь татарлары сөйләшендә *соранчы,* мишәр диалектының сергач сөйләшендә *соранцы* сүзләре теләнче мәгънәсендә йөри.

**Сансыз** – тыңламаучан, санга сукмаучы, хөрмәт итмәүче: *Ул сансызга бер сүз дә әйтә торған түгел.* (Кассель)

*Сансыз* сүзе татар теленең күп кенә сөйләшләрендә дә кулланыла. Урта диалектның казан арты (дөбьяз, этнә), тау ягы сөйләшләрендә, мишәр диалектының кузнецк, чүпрәле сөйләшләрендә *сансыз* сүзе шушы ук мәгънәне белдерә.

**Сыпы** – нәзберек, аз ашаучан. Мисал: *Пәрит, син бик сыпы икәнсең.* (Попово)

Казан арты керәшеннәрендә бу сүз *сыпый* формасында теркәлгән. *Сыпы//сыпый* сүзләре татар теленә гарәп теленнән кергән *суфый* сүзеннән үзгәртелеп ясалган булырга тиеш.

**Тамаксау** – күп ашаучан: *Син тамақсау түгелсен икән.* (Болотово)

*Тамақсау* сүзе шушы мәгънәдә күп кенә керәшен сөйләшләрендә, шулай ук тау ягы (кама тамагы, мишәр диалектының кузнецк, чистай, чүпрәле, мәләкәс сөйләшләрендә (*тамаксау*) дә билгеле.

*Тамаксау* сүзе әдәби телдә исә терлекләргә карата гына әйтелә.

**Тастарау//тастару** – җыйнаксыз, тәртипсез. Мисал: *Син алай тастару булып өйрәнмә, салдатта үзеңә дә қыйын булыр менә.* (Ключевская)

Бу сүз татар теленең башка сөйләшләрендә теркәлмәгән.

**Томсару кеше** – караңгы чырайлы, төмсә кеше: *Җөзенә карарга қурқыч, томсару кеше ул әллә нинди.* (Остроленко)

Минзәлә, байкыбаш сөйләшләрендә мондый кешене *томса кеше* дип атыйлар. Без өйрәнә торган һәм күрсәтелгән сөйләшләрдә күк йөзенең төмсәләнүе шулай ук *томсару* сүзе белән белдерелә.

Татар теле сөйләшләрендә, *том//төм* тамыры белән ясалган сүзләр байтак кулланыла. *Том* тамыры урта диалект сөйләшләре өчен характерлы.

**Эчкел** – эчкече: *Эчкел кеше эчәр өчен генә керә магазинға.* (Попово)

Пермь татарлары сөйләшендә мондый кешене *эчкелекле кеше* дип йөртәләр.

**Курсыныу** – хурлану: *Синең белән қурсынмый ничек йөрим.* (Попово)

Бу сүз аналогия законы нигезендә гарәп теленнән кергән *хур* һәм татар теленең – *сыну* кушымчасы ярдәмендә ясалган. Чагыштыр: *юксыну, үзсену* һ.б.

**Көйәләнү** – көю, кайгыру: *Өйдәге кеше берәрсе йулда булса, көйәләнеп утыра.* (Краснокаменка)

### *Вакыт аралыгына караган сүзләр*

Нагайбәк сөйләшендә вакыт төшенчәсе **ара, вакыт, мизгел** сүзләре белән белдерелә. Татар әдәби телендә бу сүзләр вакыт аралыгын төрле яктан билгеләсәләр, сөйләштә әлеге сүзләр гомумән вакыт төшенчәсен генә белдерәләр.

**Ара** – вакыт. Мисаллар: *Барырға ара йуқ әле ул җақларға.* (Болотово) *Син бер ара табып безгә килеп чық, Мәтүк, бергә искә төшерербез бу җегет сораған җырыуларны.* (Париж)

*Ара* сүзе шушы мәгънәдә мамадыш, казан арты керәшен сөйләшләрендә дә актив кулланыла. Бу сүз шулай ук мишәр диалектының темников һәм чистай сөйләшләрендә дә бар.

**Мизгел** – вакыт: *Бер мизгел малайымның арқасын тук белән личит иткәннәр.* (Попово) *Бер мизгел таwып безгә кил.* (Париж)

Казан арты (әтнә) сөйләшендә бу сүз чор, билгеле бер вакыт төшенчәләрен белдерә. Билгеле булганча, татар әдәби телендә *мизгел* сүзе бик кыска булган вакыт аралыгын аңлата.

Көн исемнәрен билгеләү өчен гарәп, фарсы телләреннән кергән һәм сөйләшнең үзендә ясалган сүзләр дә кулланыла. Гадәттә мондый сүзләр *атна* сүзе ярдәмендә ясалалар. Алар түбәндәгеләр:

**Татар атнасы** – җомга. Мисаллар: *Малайлар татар атнасы көнне китте.* (Болотово) *Татар атнасында райунға бардым.* (Ключевская)

**Атна арты** – шимбә: *Атна артында муча йағабыз.* (Краснокаменка)

Татар әдәби теленә фарсы теленнән кергән *якшәмбе* сүзе **атна көн** яки **урыс атнасы** сүзләре белән белдерелә. Мисаллар: *Атна көн без эшкә бармыйбыз.* (Париж) *Атна көн магазин ачық була безнең.* (Болотово) *Урыс атнасында қалаға барып қайтырбыз дип торам.* (Астафьевка)

Көн исемнәрен шушы рәвешчә атау татар теленең күп кенә сөйләшләре өчен дә хас.

### *Төрле этнографик моментларга караган сүзләр*

Нагайбәк керәшеннәре сөйләшендә төрле борынгы ритуаллар, мәҗүсилек һәм христиан дине белән бәйле булган сүзләр дә шактый сакланып калганнар.

Тарихи чыганакларга караганда, нагайбәкләр христиан динен Казан ханлыгы җимерелгәч тә кабул иткәннәр. Ислам дине бу вакытта халыкның аңына сеңеп җитмәгән. Аны морзалар, түрәләр, төрле сарай кешеләре генә тоткан. Халык борынгыдан ук килгән

мәҗүсилек йолаларын үтәп килгән. Бу хәл христиан динен кабул иткәч тә дәвам итә. Авыл картлары мондый гадәтләрнең күбесен әле дә яхшы хәтерлиләр. Ә аларның кайберләре халык тарафыннан бүгенге көндә дә үтәлеп килә.

### ***Туй йолаларына караган сүзләр***

**Ақлашу** – ярәшү, кызны яучылаган егеткә бирергә риза булу: *Кызны бирергә риза булса, ата-анасы ақлашалар қызыны җегет җиқтан килгән кешеләр белә.* (Фершампенуаз)

**Акка салу** – ярәшү билгесе итеп егет ягына кыз тарафыннан бирелгән бүләк. Мисал: *Аққа салырға дип қыз нәстә әзерләп қуйған: шарып бәйләп қуйғанмы, әллә әйбәт итеп бистәр чигеп қуйғаммы – шуны бирәләр инде җегет җаққа.* (Париж)

Казан арты керәшеннәрендә вәгъдә бүләген *ак* дип атыйлар. Бу яктан да нагайбәк сөйләше калган керәшен сөйләшләре белән якыная.

**Аш җаулығын қотлау** – туй вакытында май ашаганнан соң, киленне котлап, акча бирү. Мисал: *Туйда май ашыйлар, килен майы дип, аннан аш җаулық җәйеп қуйалар, аннан аш җаулық қотлыйлар.* (Париж)

**Қалын табағы** – кызны вәгъдәләшкәннән соң, вәгъдә билгесе итеп, ниндидер бер савытка (поднос яки табакка) куеп, егет ягыннан килүчеләргә тапшырыла торган бүләк. Моңа җавап итеп егет ягы шул савытка акча сала. Мисал: *Ақлашабыз диләр инде. Шулай дигәч, қыз җағы чығара бер нәмә салып қалын табағына. Қалын табағы дигәне бер паднусны, тәлинкәме инде. Шуңа қыз әзерләгән әйберне салып чығара. Аңа ақча сала қода-қодачалар.* (Астафьевка)

**Қода-кодағый булышу** – кыз вәгъдәләшкәннән соң егет ягына барып чәй эчү. Мисал: *Қыз җағында қыз ақлашып ашап эчкәннән соң килгән кешеләр, җәгез, қодалар, инде қода булышабыз, кодағый булышабыз, қәзер безгә барып, бер самаwыр чәй эчийек инде, диләр.* (Париж)

**Туйчы** – ике яктан да туйда катнаша торган қодалар. Алар туй мәҗлесен үзләренә чақырырга тиеш булалар. Мисал: *Ике җақтан*

*да туйчы кирәк. Туйчы буласы кеше җалыныбрақ қына ризалаша. Туғаннары була инде туйчылар.* (Астафьевка)

**Төп кода** – кияү белән киленнең эти-әниләре бер-берсенә шулай туры килә. Мисаллар: *Шулай бер көнне уйламағанда ғына төп қода килеп төште безгә.* (Ключевская) *Төп қоданы түр башқа утырталар, қыйаматлық аның да қәлен белеп җөри.* (Париж)

**Кече қода** – туйда төп қодадан башкалар шулай дип аталып йөртеләләр: *Башта төп қода утыра, аннан кече қодалар.* (Остроленко)

**Кыйамәтлек** – керәшен туйларында һәрвакыт кыз белән кияү арасында булып, аларны тәрбияләп йөрүче хатын-кыз. Ул, гадәттә, кыз яки егетнең туган тиешле яки башка шундый якын кешесе була. Мисаллар: *Мин қыйаматлық булып бардым ул кешегә.* (Париж) *Қыйамәтлек қыз белән җегетне туй алдыннан үзенең өйөндә қундыра.* (Остроленко)

Бу термин да барлык керәшен сөйләшләренең уртак үзенчәлекләре булып исәпләнә. *Қыйамәтлек* терминын куллану ягыннан да нагайбәк сөйләше калган керәшен сөйләшләреннән аерылмый.

Кияү белән килен қыйаматлеккә *әнки* дип, аның иренә *әтки* дип эндәшәләр. Мисаллар: *Туйдағы қалық бер җиргә җыйыла, битенә җаулық җә шәл җабынып килен утыра. Аның битен күргәннәре җуқ әле. Ул аны үзе ачмый. Уқлау белән әнки булған кеше ача киленнең битен.* (Париж)

*Әнекий* термины урта диалектның күп кенә сөйләшләрендә берничә мәгънәдә йөри. Казан арты сөйләшләрендә ул каенананы аңлатса, бәрәңге, тау ягы сөйләшләрендә кияү кешенең әбисенә эндәшү сүзе буларак та кулланыла. Керәшен сөйләшләрендә *әнки* сүзе күбрәк без өйрәнә торган сөйләштәге мәгънәдә сакланган.

**Түшәк-җастық сатулашу** – кызны егет күчергән вакытта озата килүчеләрдән кыз әйберләрен сатып алу йоласы. Мисал: *Озата килүче қызны түшәк-җастығын сатулашмый ғына бирми.* (Париж)

**Қатайсаға чығу** – туй вакытында яшь кияү һәм киленнең иптәшләре белән, атка утырып, урам әйләнүләре. Бу сүз рус телендәге *кататься* фигыленнән үзгәртелеп ясалган (*кататься́ға – катайсаға чыгу*). Мисаллар: *Җәшләр бутқа ашыйлар да*

*катайсаға чығып китәләр атқа утырып. Гармунчы да утыра. Җегет белән қыз түргә утыра, иптәшләре ике җағына терәккә басалар, қыз затқан көйне җырлап урам әйләнәләр.*

**Килен майы** – туй вакытында чыгарыла торган май. Мисал: *Ақырыдан май утырталар, моно килен майы диләр, аны ашыйлар да ақча салалар.* (Париж)

**Пипарат** – кыз күчергәндә мәзәк итеп үзен танытмас өчен төрле киемнәргә киенгән кеше. Мисал: *Боларның алдында пипарат була инде җегет җағыннан килгән. Бу пипарат қайа бара, болар шунда баралар. Пипарат кийенә инде бер төсле танытмаслық итеп.* (Париж)

**Мәрәкә** – туй азагында кешеләрне көлдерү өчен махсус чыга торган кеше. Мисаллар: *Мәрәкә чыға безнең туйларда.* (Варлам)

*Мәрәкә* сүзе Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарындагы яшәүче типтәр, шулай ук Оренбург өлкәсендә таралган мишәр сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән. Биредә бу сүз – уен-көлке, мәзәк, шаярту мәгънәләрендә кулланыла. Шушы мәгънәдә ул Учалы типтәрләрендә дә теркәлгән.

Чуваш телендә *мерекке* – уен-көлке, кызык, искиткеч, шаккаткыч әйбер; төрек телендә *мерак* – кызыксыну, дәрт, теләк, *меракли* – кызыксынучан; азәрбайҗан телендә *марак* – кызыксыну, омтылу; казак, каракалпак *мереке* – бәйрәм, тантана, кичә, күңелле итеп вакыт уздыру, *мерекләү* – бәйрәм итү; төрекмән *мәкере* – җыелган халык, тантана; башкорт *мәрәкә* – кызык, уенкөлке мәгънәләрендә йөри.

Татар теленең күп кенә сөйләшләрендә кызык, күңелле төшенчәсе *ирмәк* сүзе белән белдерелә. Без өйрәнә торган сөйләштәге *мәрәкә* сүзе *ирмәк* сүзе белән бер тамырдан булырга тиеш.

### ***Төрле бәйрәм исемнәренә бәйле булган сүзләр***

Нагайбәк керәшеннәренә ислам дине кереп җитәргә өлгермәгән, ә христиан дине барлык таләпләре белән үзләштерелмәгән. Дин нагайбәкләргә көчләп тагылган. Чиркәүгә авыл халкын староста һәм старшина гына китерә торган булган. Кайбер кешеләр,

христиан дине белән бергә; ислам динен дә тоткан, ике дингә дә ышанган. Иконаларны авылга зур түрәләр килгән көнне генә элгәннәр. Халык догаларны рус телендә дә, татар телендә дә белмәгән, гыйбадәт кылучылар да бик аз булган.

Нагайбәкләрдә, христиан бәйрәмнәре белән беррәттән, мәҗүсилек чорыннан калган бәйрәмнәр дә зурлап үткәрелгән. Христиан бәйрәмнәренең күбесе, башка керәшен татарларындагы кебек үк татарча атап йөртеләләр яки сөйләшнең фонетик закончалыкларына җайлаштырып әйтеләләр.

**Бәрмәнчек** – рус. Вербное воскресенье: *Җаз башында була ул бәрмәнчек.* (Болотово)

*Бәрмәнчек* сүзе Казан арты керәшеннәрендә яңгыр теләп үткәрелгән яңгыр боткасы йоласын белдерә.

**Кач ману** – рус. Святое Крещение. Мисал: *Қач манған көнне бардық бит без тәтәүләргә.* (Варлам)

**Май бәйрәме** – рус. Масленица: Нагайбәкләрнең яратып үткәрә торган бәйрәмнәреннән берсе. Бу бәйрәмдә бер авыл халкы икенче авыл белән кунакка йөрешә торган булган. Сөйләштә моны **пырушти** дип тә атау бар. Бу сүз рус телендәге *прощаться* – кыш белән саубуллашу сүзеннән үзгәртелеп ясалган. Мисал: *Май бәйрәмен бик җаратайық. Безгә Сарашлыдан күп җәшләр киләйе.* (Париж) *Май бәйрәмен без пырушти дип тә әйтәбез.* (Остроленко)

**Микула** – рус. Миколин день: *Син микуланың қайчан икәнен беләсеңме?* (Фершампенуаз)

**Оло көн** – рус. Пасха. *Оло көн алдыннан була торғаныйы бәйге.* (Париж)

**Пықрау** – рус. Покров день: *Бүген пықрау көне, пықрау пируглары пешерәбез.* (Болотово)

**Чыбық бәйрәме** – рус. Троицын: *Чыбык бәйрәме җәйнең матур бағытында гына була.* (Париж)

**Көзге бәйрәм** – нагайбәкләр бу бәйрәмдә аш бирү йоласын үтиләр. Мисаллар: *Ағачайның ашын көзге бәйрәмдә бирдек.* (Кассель) *Ашны қайчан бирсәң дә була, үлгәненә бер җыл гына тулсын.* (Варлам)

**Җиде атна ураза** – рус. Великий пост. Мисал: *Җиде атна ураза да килеп җитә инде.* (Краснокаменка)

### ***Төрле йолаларга караган сүзләр***

**Аш биреү** – үлгән кеше исеменә атап корбан чалу. Нагайбәк керәшеннәренең борынгыдан яшәп килгән йолаларының берсе. Мисал: *Ашны үлгән кешегә атап бирәләр, ашлы-сулы булып җатсын дип. Кеше үлгәч, ашны җыл тулмыйча бирмиләр. Җыл тулғаннан соң, икенче җыл биреме, өченче җыл биреме. Шу чағында қарендәш ырыуны, аш бирәм дип, җыйа. Аңар чыйыр суйасың атап, үгез җарамый.* (Париж)

**Табақ җасау** – иске йолаларның берсе. Үлгән кешеләрнең исеменә атап корбан чалган җиргә аш илтү. Мисал: *Палыйларның тийәберсененә табақ җасарға кирәк. Аш биргән җиргә кәрендәш-ырыwы табақ белән килә. Бүләкләр китерә инде, бистәрме, җаулықмы, ашандымы. Шу бүләкләрне аш биргән җиргә килгән кешеләр бер-берсенә бирәләр, теләгән кеше қужаға бирә. Аннан үлгән кешегә атап табақ җасыйбыз. Әнә шул табақны берәүгә бирәбез. Анда кампитмы, пиругмы, таwықлармы була инде. Ул кеше мондағыларны ашқа ала.* (Париж)

**Тийәберсен** – иске йолаларның берсе, үлгән кешегә атап корбан чалу мәҗлесе: *Палыйларның тийәберсенә сине чақырдыlargeмы, Татый?* (Попово)

**Тийәберсен итү** – әд. авыз итү. *Мин пешергән ашлардан тийәберсен итеп кенә ал инде.* (Париж)

*Тийәберсен//тәберсен итү* сүзләре татар теленең башка сөйләшләрендә билгеле түгел.

**Айазымнау** – әд. сихерләү: *Ул қарт-қорларны айазымнап җөргән.* (Попово)

*Айазымнау* фигыле татар теленең башка сөйләшләрендә теркәлмәгән. Чагыштыру өчен зәй керәшеннәрендә һәм минзәлә сөйләшләрендә котырыну, шашыну төшенчәләрен белдерә торган *аша кубу* тезмәсе барлыгын искәреп китик.

**Пештемә қуу** – мәҗүсилектән калган иске йола. Яз көне, чәчүләр беткәч, кырау төшмәсен өчен таякка беркетелгән

себеркегә ут төртеп йөртү. Мисал: *Қажныйыбыз бер тайаққа себеркене кийертәбез дә аны қырға алып барып җандырабыз. Анда кеше күп була. Борынғылар сүзе буенча, шулай эшләсәң, қырау төшми икән. Шуны пештемә қуу диләр.* (Остроленко)

Казан арты (балтач), тау ягы (кама тамагы) сөйләшләрендә *пештеле* дип аталган борынгы балалар уены барлыгы билгеле.

**Бәйрәм итү** – кунакка йөрү: *Берәүгә қунақлар қайтса, бәйрәм итәбез бергәләп.* (Астафьевка)

**Җыйын** – кунак табыны: *Қунақлар кигенче җыйынны кәстәрләп қуйыйық инде.* (Болотово)

**Җыйын җыю** – әд. кунак җыю: *Җыен җыйып аласы булыр малай қайтқач.* (Фершампенуаз)

*Җыйын* сүзе татар теле сөйләшләренең күбесендә бар. Бу сүз казан арты (балтач, этнә) сөйләшләрендә – авылның бер төбәгендә яшәгән ыру, нәсел; пермь татарлары сөйләшендә – авылның бер очы; казан арты, бәрәңге сөйләшләрендә элек бер төркем авылларда ел саен үткәрелә торган бәйрәм яки сабан туе мәгънәләрендә кулланыла.

Нагайбәк татарлары, *җыйын җыю* белән беррәттән, **бәйрәм җыю** дип тә сөйлиләр: *Қунақлар барда бәйрәм җыйып алыйық әле.* (Париж)

**Теләк үтеү** – теләк теләү: *Җылға буйына барып қартлар қарчықлар теләк үтәләр.* (Кассель)

Татар теленең хвалын, минзәлә сөйләшләрендә бу мәгънә *теләү* фигыле белән белдерелә.

### *Уен исемнәре*

**Ат алмаштыру** – яшьләр уенының бер төре. Мисал: *Ат алмаштыру болай: бер башта өйөм җегетләр генә тора, бер җақта қызлар ғына. Шуларны бер қызға бер җегетне алмаштырабыз. Кем-кемгә килешә инде.* (Париж)

**Бәйге** – борынгыдан ук үткәрелеп килгән спорт бәйрәме. Мисал: *Иртәгә бәйге дигән көнне атқа, көрәшкә бистәр, җаулық башы җыйу була торғаныйы.* (Фершампенуаз)

*Бәйге* сүзе урта диалект сөйләшләрендә генә теркәлгән. Минзәлә, бөре, казан арты (балтач) сөйләшләрендә бу сүз сабан туенда уеннар үткәрелә торган мәйданны, бәрәңге сөйләшендә сабан туенда җиңүчеләргә өләшә торган бүләкне белдерә.

Бу яктан нагайбәк сөйләшенең казак, каракалпак, кыргыз телләре белән дә уртаклыгы бар. Биредә дә *бәйге* сүзе йөгереш яки ат чабыштыруны белдерә.

**Сөрән –** нагайбәк татарларында борынгыдан бирле үткәрелә торган ат чаптыру бәйрәме. Мисаллар: *Җегетләр белән атқа атланып сөрәнгә чығаларыйы элек.* (Кассель)

*Сөрән* сүзе татар теленең Казанга якын территориясендә таралган сөйләшләрендә билгеле: тау ягы һәм чистай сөйләшләрендә *ғазиз//ғәзиз сөрән* дип сабан туен, казан арты (мамадыш) сөйләшләрендәге *сөрән көне, сөрәнгә чыгу* дип сабан туе алдыннан, атларга атланып, йорт саен әйбер җыярга чыгуны атыйлар.

*Сөрән* сүзе күп кенә төрки телләр өчен дә хас. Мәсәлән: борынгы төрки телдә *сүрән* – сугышчан чакыру (рус телендәге *ура* сүзенә туры килә). Чуваш телендә *серен* – авылдан мәетләрне куу йоласы; кырг. *сурон* – сугышчан чакыру; казак. *сурен* – тавыш, кычкырыш, тревога; үзбәк. *суран* – кычкыру, хәрби өндәү; алт. *сурин* – коточкыч хәл, чагыштыр: уйг., азәрб., төркм., шор., тув., хак., алт. *сур* – куу мәгънәләрен аңлата.

Югарыда китерелгән телләрдә күренгәнчә, бу сүзнең төп мәгънәсе *сур//сор//сер* – куу фигыленә кайтып кала. Шушы уңайдан татар әдәби телендәге *сөрү, сөрген* сүзләрен дә китерергә мөмкин. Димәк, без өйрәнә торган сөйләштә *сөрән* сүзенең татар халкының борынгыда үткәрелгән спорт бәйрәмен аңлаткан мәгънәсе сакланып калган.

**Таған асты** – яшьләрнең уеннары була торган җир: *Таған астына җегетләр, қызлар, җәш киленнәр барып уйныйлар.* (Ферщампенуаз)

Казан арты (лаеш) сөйләшендә *таган асты* дип сабан туе була торган мәйданны атыйлар.

### *Абстракт мәгънәле сүзләр*

**Бертын** – бераз. Мисаллар: *Бертын җөри дә тағы қайта.* (Остроленко) *Бертын ғына утырайық.* (Астафьевка)

Бу сүзне куллануда нагайбәк сөйләшенең казан арты (мамадыш), алабуга керәшеннәре һәм пермь татарлары сөйләшләре белән якынлыгы күренә.

**Бөтә** – бөтен, барлык: *Бөтә мәндә* (әд. кеше) *сыйр эзли.* (Попово) *Бөтә җирне қарадым, таба алмадым.* (Кассель)

*Бөтә* сүзе пермь татарлары һәм эчкен, сафакүл сөйләшләрендә дә кулланыла. Бу сүз башкорт телендәге *бөтәһе* сүзеннән үзгәртелеп ясалган.

**Бурсыу** – исләнү. Мисал: *Итебез әз генә бурсыған.* (Фершампенуаз)

Казан арты сөйләшләрендә бу сүз *бүрсү* вариантларында кулланылып, *чери, күгәрә башлау* төшенчәсен аңлата.

**Күчерге** – оят. Мисал: *Аңа күчерге булмасын дип эшлийем бу эшне.* (Ключевская)

**Җылайу** – җылыну: *Сыw җылаймағаммы әле?* (Фершампенуаз)

**Чигенү** – зарлану, каршы килү: *Өйөнә барырға чигенмәсен җақшы булыр иде.* (Попово)

**Киләп** – борынгы озынлык үлчәү берәмлеге, хәзерге телдә – *колач: Бистәре бер киләп булыр инде.* (Кассель)

**Қыстау** – ашыгыч, тыгыз: *Минем эшләр бик қыстау әле.*

Бу яктан да нагайбәк сөйләшенең эчкен сөйләше белән булган уртаклыгы күренә.

Касыйм, пермь татарлары сөйләшләрендә бу сүз кысынкы, тар, тыгыз мәгънәләрен аңлата: *Ишек қыстау булған.* Эчкен сөйләшендә югарыда күрсәтелгән мәгънә белән бергә бу сүз тагын тиз төшенчәсен дә белдерә.

**Маза:** маза китеү – аптырау. Мисал: *Өйләрен эрәтли алмый мазалары киткән.* (Париж)

Оренбург сөйләшендә рәт, юнь төшенчәләрен белдерә торган *маза* сүзе бар. Бу сүз үзенең чыгышы белән фарсы теленә барып

тоташа. Чагыштыру өчен казан арты (дөбьяз) сөйләшендә азаплану мәгънәсен белдерә торган *азалану* сүзен китерергә мөмкин.

**Ошаҡлы** – 1) охшаш, охшаулы. Мисал: *Ул сыйа ошаҡлы кеше* (Париж); 2) килешле, ятышлы. Мисаллар: *Ошаҡлы ғына сүләшеп утыра шундый итеп.* (Астафьевка) *Сезнең җырыу күңелгә ошаҡлы.* (Попово)

*Ошаклы* сүзен шушы мәгънәләрдә куллану казан арты сөйләшләрендә күзәтелә.

**Уңҡатлы** – уңган: *Уңҡатлы ғына булып пешкән шәңге.* (Фершампенуаз)

*Уңҡатлы* сүзе урта диалектның минзәлә сөйләшендәге *уңдару* (әд. уңдыру), казан арты (лаеш) сөйләшендәге **уңгару,** мишәр диалектының чистай сөйләшендәге **уңкайтлану** сүзләре белән бер тамырдан. Бу сүз *т – д – й* авазларының тарихи күчеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән булса кирәк.

**Әүмәт** – хәл, барлык, байлык: *Сезне генә туйдырырга әүмәтем җитә минем.* (Париж)

*Әүмәт* сүзе Зәй керәшеннәрендә дә кулланыла. Бу сүз гарәп телендәге *нигъмәт* (барлык, байлык) сүзеннән ясалган.

**Әйтәwер** – кереш сүз ролендә кулланыла торган сүз. Мисаллар: *Аҡчамны онотып ҡалдырғаммын, әйтәwер.* (Париж) *Әйтәwер, ҡайтып та җиткәнсең.* (Остроленко) *Җуҡҡа ғына кийәүгә бардым аңғар, әйтәwер.* (Кассель)

Көнчыгыш диалектның тобол сөйләшендә *әйтәүер* сүзе яхшы, олы, хөрмәтле мәгънәсен аңлата. Казак телендәге *тәүер* сүзе дә шушы ук төшенчәне белдерә. Ә каракалпак телендә *әйтәүр* көчкә-көчкә, игътибарсыз мәгънәсен аңлата.

**Өнәмәү** – яратмау, ошатмау. Мисаллар: *Мин алар затын бик өнәмийем.* (Париж) *Өнәмәгән кешеләргә барасы да кими ул.* (Ключевская)

*Өнәмәү* сүзе шушы ук мәгънәдә урта диалектның казан арты, тау ягы сөйләшләрендә дә кулланыла.

**Җүнәрү** – яхшыру. Мисаллар: *Син Мәтүк җүнәрен киткәнсең әле.* (Париж) *Тормошлары да суңғы җылларда җүнәреп бара.* (Варлам)

**Җок** – барлык, байлык: *Бар ғына җоқомны, бар ғына тапқанымны аңғар бирәм.* (Попово)

Бу үзенчәлеге белән дә без өйрәнә торган сөйләш казан арты (мамадыш) сөйләшенә якын тора. Тау ягы сөйләшләрендә *җоқ* сүзе нәсел-нәсәпне белдерә.

**Җоқор** – әд. эзе дә, бөртеге дә. Мисаллар: *Пидура майның җоқорын да қалдырмый ашап беткән.* (Париж) *Упыйның (әд. Федораның) җогоро да җуқ артыннан чығсам.* (Париж)

*Җоқор* сүзен куллану ягыннан нагайбәк сөйләше урта диалектның тау ягы сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә.

## Формасы әдәби тел белән уртак, мәгънә ягыннан үзенчәлекле сүзләр

Нагайбәк сөйләшендә яңгырашлары белән әдәби телдәгечә, ләкин мәгънәләре белән әдәби телдән аерылып торган сүзләр дә байтак. Шундыйлардан түбәндәгеләрне күрсәтеп китәргә мөмкин.

**Awаз** – әд. тавыш: *Көтүчеләрнең awазын ишетеп кенә таба алдым.* (Париж)

*Аваз* сүзен шушы мәгънәдә куллану тагын казан арты, нократ, глазов сөйләшләрендә дә бар.

**Алмашу** – әверелү, әйләнү: *Керәшен арасында торған керәшенгә алмаша инде бүтән халық та.* (Болотово)

Бу сүзне куллану белән дә нагайбәк сөйләшенең казан арты сөйләшенә якынлыгы күренә.

**Ашлық бастыру** – ашлык сугу: *Ашлықны қул белән бастырдық әле.* (Фершампенуаз)

**Бастыру** – куу: *Ат бастырып йөрдем, тота алмадым.* (Краснокаменка) *Таwықны бастырып кер әле, бақчаға кергән.* (Болотово)

*Бастыру* сүзен шушы мәгънәдә куллану эчкен, сафакүл сөйләшләре өчен дә хас.

**Батырыу** – пычрату: *Өстеңне батырма, қарап қына йөр.* (Попово)

**Баш салу** – буйсыну: *Әле генә баш салып торам мин, баш салмыйым мин аңа.* (Париж)

**Дөнҗа бетереү** – өй бетерү: *Әле генә дөнҗа бетереп чықтылар, мичләре дә җуқ әле.* (Болотово)

**Иренеү** – ялыгу. Мисаллар: *Иренә ул көм буйын әйдә утырып.* (Попово) *Нәнәү қарт инде, кешедән дә иренә.* (Париж)

**Йәш** – яшьлек: *Үзем дә эшләгәнийем мин йәшемдә.* (Попово)

**Йәшлек** – яшь: *Йәшлек бозауны суйасын да бит, ите тәмне булмый аның.* (Болотово)

**Каwын** – кабак. Мисал: *Каwын пиругқа тәмне була ул.* (Варлам)

*Каwын* сүзен шушы мәгънәдә куллану татар теленең мишәр диалекты, пермь татарлары һәм эчкен сөйләшләре өчен дә хас.

**Кабырға** – ян, тирә. Мисаллар: *Минем қабырғамда ғына утырды ул кинада.* (Париж) *Папау* (Попово авылы) *урманның қабырғасында ғына.* (Варлам)

*Кабырга* сүзе шушы ук мәгънәдә эчкен һәм пермь сөйләшләрендә дә кулланыла.

**Кыр** – тирә-ян: *Без элек магазин қырында ғына тордық.* (Варлам)

*Кыр* сүзе шушы мәгънәдә пермь татарлары, бөре, минзәлә, казан арты (балтач) сөйләшләрендә дә бар.

**Сәләм** – хат. Мисаллар: *Сәләмең килгәнче, пасылкаң килсә, җақшы булырыйы.* (Париж) *Питедән сәләм килгән, шуны уқыйлар.* (Попово)

**Сулағай** – сул: *Ул җаққа барғанда сулағай җақта қала өйләре.* (Астафьевка)

Бөре, пермь татарлары сөйләшләрендә бу сүз *сулакай* формасында әйтелә.

**Сәғәттә** – хәзер үк: *Сәғәттә килеп җитәр, бик тиз җөри ул.* (Париж)

Сөйләштә бу сүзне кыскартып *сәттә* дип әйтү дә киң таралган. Мисал: *Сәттә генә қайнап чыға торғаныйы бу самаwыр.* (Фершампенуаз)

**Тереклек** – тормыш: *Тереклекләре аларның әйбәт.* (Париж)

**Тамызыу –** ут яндыру. Мисаллар: *Тамыз әле утны.* (Краснокаменка) *Ут тамыз, қараңғы бит.* (Париж)

*Тамызу* фигылен шушы мәгънәдә куллану белән без өйрәнә торган сөйләш урта диалектның казан арты һәм минзәлә сөйләшләренә якын тора.

**Тәм** – ит: *Ашқа тәм сал, озак қына қайнасын.* (Фершампенуаз)

**Түбән** – соң. Мисал: *Иртәдән түбән казан астына ғына йағарға итем.* (Попово)

**Уwалыу** – ватылу. Мисал: *Машиналары уwалған дип әйтте.* (Остроленко) *Көтүкләрнең тәлинкәләре уwалып беткән дә инде.* (Кассель)

*Уwалыу* сүзе шушы мәгънәдә тагы пермь, эчкен, сафакүл татарлары сөйләшләрендә дә кулланыла.

**Эрәнҗеү** – авыру: *Аның қатыны эрәнҗегән, тора алмый җата.* (Болотово)

Бу үзенчәлектә дә нагайбәк сөйләшенең казан арты, зәй керәшеннәре һәм Оренбург татарлары белән уртаклыгы ачыла. Казан арты (мамадыш), Оренбург мишәрләрендә *эрәнҗү* дип авыру кешене дә атыйлар.

**Өндәү** – чакыру: *Өндәгән кешеләр табақ алып киләләр тәберсеңгә.* (Болотово)

## Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләрен чагылдырган сүзләр

**Азалану** – азаплану: *Қызы аның белән тороп, азаланып беткән.* (Болотово)

**Аннышу** – аңлау: *Син мине аннышты*ңмы? (Варлам)

**Алма-тилмә** – алмаш-тилмәш: *Бездә қәзер көтүче җуқ, алма-тилмә көтеү көтәбез.* (Болотово)

**Бағыт** – вакыт. Мисаллар: *Минем бағытым булмады сезгә килергә.* (Краснокаменка) *Бағыт булса, ул аwылға барырға кирәк әле.* (Париж)

Әдәби телдәге *вакыт* сүзен шушы рәвешчә үзгәртеп әйтү казан арты керәшеннәренең дә үзенчәлекле билгеләреннән санала.

**Гәрәз** – әд. кәрәз: *Бу гәрәзләрнең баллары алынған инде.* (Ключевская)

**Гөдрә** – бөдрә: *Гөдрә җаллы атқайым, чайқый ғына башқайын.* (Җырдан, Париж)

**Дегәнәк** – тигәнәк, әрекмән: *Дегәнәкне сыйыр җарата аны.* (Фершампенуаз)

**Ден** – дин. Мисал: *Элек ден кыwатлийе.* (Кассель)

Бу яктан да нагайбәк сөйләшенең казан арты керәшен сөйләшләре белән булган уртаклыгы күренә.

**Дән** – тән: *Дәннәрем аwырта инде, эшләп арыдым.* (Остроленко)

**Искәү** – иснәү: *Ышанмыйча, искәпләп қарый қашықны.* (Попово)

**Йуқақ** – *Йуқақ ғына ойоқбаш айағында.* (Попово)

**Заип** – зәгыйфь: *Ул баласы аның заип тыуды.* (Астафьевка)

**Қурқыч** – куркыныч: *Қурқыч кәлләр булды инде.* (Болотово)

Бу үзенчәлек, без өйрәнә торган сөйләштән тыш, казан арты керәшеннәре, нократ, глазов, пермь татарлары, эчкен сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән.

**Қызыу** – кызыгу: *Күркәнең итенә қызмағыз, артық тәмне түгел ул таwық ите күк.* (Варлам)

**Кутару** – 1) куптару, 2) ватылу: *Бақчаның қоймасы қутарылған.* (Париж) *Машинасы тағы қутарылған боларның.* (Варлам)

*Кутару* сүзен күрсәтелгән мәгънәдә куллану пермь, эчкен, сафакүл татарлары сөйләшләре өчен дә хас. Бу үзенчәлек борынгыдан сакланып килгән үзенчәлекләрдән санала. Чөнки без бу сүзне шушы мәгънәдә борынгы төрки телдә (*котар*), шулай ук хәзерге төрки телләрдә дә очратабыз. Чагыштыр: алт. *ходор;* якут. *хоторо;* каз., үзб., төркм. *котар* – вату, икенче урынга күчерү.

**Нак** – нахак. *Нақны ғына сөйлисең бит.* (Париж) *Наққа бәләгә кертерсең.* (Варлам)

**Пике** – пәке: *Пикесен җуйып қайтқан.* (Кассель)

**Тапау** – таптау: *Таwықны машина тапап китте.* (Краснокаменка)

Әдәби телдәге *таптау* сүзен *тапау* формасында әйтү бигрәк тә Урал буенда таралган сөйләшләр өчен хас. Бөре, пермь

татарлары, красноуфим сөйләшләрендә аның мәгънәсе без өйрәнә торган сөйләштәгедән аерылмый. Мишәр диалектының ләмбрә, чистай, чүпрәле сөйләшләрендә *тапау* – ваклап кисү; темников, оренбург сөйләшләрендә боз сугуга карата әйтелә. Бу күренештә нагайбәк сөйләшенең башкорт әдәби теле белән дә уртаклыгы бар.

**Туйырыу** – туйдыру: *Мине ашатып туйырып җибәрде.* (Фершампенуаз)

**Тәбәшәк** – тәбәнәк: *Урының тәбәшәк бугай синең.* (Ключевская)

*Тәбәшәк* сүзе алабуга керәшеннәре, пермь, камышлы, оренбург татарлары, эчкен сөйләшләрендә дә актив кулланышта йөри.

**Тәгәрләү** – тәгәрәү. Мисал: *Капчыкны тәгәрләп йерттек.* (Кассель)

Бу сүз эчкен сөйләшендә *тәгәрнәү* формасында әйтелә. Сөйләштә әдәби телдәге *тәгәрәү* сүзен *тәңгәрү* формасында әйтү очраклары да бар: *Әбәү, җәшен аткач, тәңгәреп киткән.* (Варлам)

**Узгару** – уздыру. Мисаллар: *Ми сөйләп узгардым инде, аны килеп алганнар.* (Астафьевка) *Тыкрыктан узгармыйлар машинаны.* (Фершампенуаз)

## Алынма сүзләр

Гомумтатар сүзләрдән тыш, нагайбәк сөйләшендә башка система телләреннән кергән алынмалар да кулланыла. Бу бигрәк тә рус, гарәп, фарсы телләреннән кергән сүзләргә карый.

### *Рус теленнән кергән алынмалар*

Без өйрәнә торган сөйләштә рус теленнән кергән сүзләрнең күп булуы күзгә ташлана. Сөйләшнең рус сүзләрен үзләштерүе бик борынгыдан башланган. Моңа нагайбәкләрнең христиан динендә булулары һәм руслар арасында күп кенә гасырлар буенча яшәп килүләре сәбәп булган.

Рус теленнән кергән алынмаларның шактый киң катламы хәрби терминологиягә карый. Чөнки нагайбәкләр, 1736 елдан башлап, казак хезмәтен үти башлыйлар. Оренбург губернасында чик буе линиясен саклауга беркетеләләр. Рус армиясендә руслар

белән хезмәт итү бу өлкәгә караган терминологиянең дә шактый бай булуына китергән. Шундыйларга түбәндәге сүзләр карый: *қазақ казачество, казачий, казачка, ыстаршуй ыстаршина, әфисәр, гарнизун, рәдүт, фарпуст, ыстан, линийә, акуп, писыр, загун, эскадрун, ахран, ыстраж, ыстражник, ыслужбы, набур, пахуд, рикрут, ыружйа* һ.б.

Октябрь инкыйлабына кадәр булган рус алынмаларының күпчелеге йорт-җир, каралты төзелеше, хуҗалык, тормыш-көнкүрешнең төрле тармакларына карыйлар. Билгеле булганча, алар сөйләшнең фонетик закончалыгына җайлаштырып үзләштерелгәннәр. Бу сүзләрне түбәндәгечә төркемләргә мөмкин.

### *Йорт-җир, хуҗалык кирәк-яракларына караган сүзләр*

**Борос** – рус. *брусья* – әд. ишек яңагы. Мисал: *Боросларны җаңғаны қуйды бабаң.* (Париж)

**Кәсәк** – рус. *косяк* – әд. тәрәзә яңагы. Мисал: *Кәсәкләрне дә сырлап җибәрергә кирәк әле.* (Фершампенуаз)

**Пыталук** – рус. *потолок* – әд. түшәм. Мисал: *Пыталугы тәбәнәк өйөбезнең.* (Кассель)

**Өчәк** – рус. *очаг* – әд. кечкенә мич. Мисал: *Өчәккә җағып җибәрим әле җылы төшсен.* (Болотово)

**Ыснач** – рус. *снасть* – әд. корал. Мисал: *Ыснач**ы** булса, кем дә эшләр ан*ы. (Астафьевка)

**Баздуш** – рус. *воздушный* – әд. саман кирпеч. Мисал: *Өй салырга баздуш кирәк булыр әле.* (Фершампенуаз)

Бу төркемгә шулай ук *магазин, лафка, зимләнкә, шалаш, кәнүшни, дывур, тәрилкә, чашкы, ыстакан, чигунка, пелитә, кәстрүл, ышкап, таз, умывалник* һ.б. сүзләр дә карый.

**Кием-салым, урын-җир исемнәренә караган сүзләр:** *кафтан, картуз, шапкы, кипкы, кәстүм, калуш, бәтинкә, баритка, сапуг, чулка, наски, адиал, пырастин* һ.б.

**Аш-су исемнәренә карый торган сүзләр:** *ши, бурыш, макарун, кампит, кампут, перәннек, пичинҗә, гәрчис, белин, курник* һ.б.

**Туганлык терминнарына караган сүзләр:** *мамау, папау, бырат, рыднуй* һ.б.

**Христиан дине белән бәйле булган сүзләр:** *батка, пуп, диакын, певчий, маслиниса, пырушти, пуст, раждыстыwа, тройсын, крешений*е һ.б.

**Бүтән өлкәләргә карый торган сүзләр:** *бида* (бик), *бран* (паром), *ден* (кавын), *начылай* (көчкә), *дастуин* (таза, зур гәүдәле), сат (гөл), *әнүс* (анис) һ.б.

**Кеше исемнәре.** Христиан дине аша кабул ителгән кеше исемнәре сөйләштә борынгы төрки типта ясалалар. Мисаллар: *Даный* – Даниил, *Ибый* – Иван, *Питрәй* – Петр, *Тырый* – Трофим, *Пилей* – Филипп, *Анный* – Анна, *Пасый* – Прасковья, *Укылей* – Окулина, *Апый* – Афанасий, *Закый* – Захар, *Назырый* – Назар, *Симәкәй* – Семен, *Үртәми* – Артемий, *Карпей* – Карп, *Метебей* – Матвей, *Сабый* – Савелий, *Барий* – Варвара, *Пасый* – Васса, *Надый* – Надежда һ.б.

Нагайбәк сөйләшенә кергән рус алынмаларының икенче төркеме Октябрь инкыйлабыннан соң кабул ителгән сүзләрне эченә ала. Мондый алынмалар күбесенчә иҗтимагый-сәяси, тормыш-көнкүреш, шушы чорда туган фәнни атамаларны, интернациональ сүзләрне эченә ала. Бу сүзләр гадәттә фонетик яктан үзгәртелмичә әйтеләләр. Шундыйлардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *колхоз, совхоз, бригадир, звено, звеновод, правление, кантур, счетаwат, учетчик, газета, журнал, сабранийе, автомат, автобус, адрес, космос, космонавт, кино, фото, телевизор* һ.б.

### *Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр*

Сөйләш вәкилләренең ислам диненнән күптән аерылган булуларына да карамастан, гарәп-фарсы алынмалары сөйләшнең сүзлек составында билгеле бер катлам тәшкил итә. Ләкин мондый сүзләр, татар теленең башка сөйләшләре белән чагыштырганда, шактый аз. Алар сөйләшнең фонетик закончалыкларына буйсынып әйтеләләр. Нагайбәк сөйләшендә кулланыла торган гарәп-фарсы алынмаларын түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

**Дини эчтәлеккә бәйле сүзләр:** *азрагил* – әд. газраил, *очтымаķ* – әд. оҗмах, җәннәт, *җәннәм* – әд. җәһәннәм һ.б.

**Абстракт төшенчәләрне атый торган сүзләр:** *багыт* – бәхет. Шушы ук төшенчәне белдерү өчен сөйләштә *тәлиға* сүзе дә актив кулланыла. Мисал: Тәлиғалары ғына булмады шушы баланың. (Париж) *Тапыйк* – әд. тәүфыйк, *азалану* – газаплану, *патуwа* – өмет, *мәтәлле* – начар, *маза китеү* – аптырау, *заип* – зәгыйфь, *әрәмләшү* – хәрәмләшү, *мәсийәт* – көлке, *тараф* – турында, хакында, *эрәнжү* – авыру, *палга керү, палга ашмау* – эшкә ашу, эшкә ашмау, *ғаслыķ* – зыян, *ķасиб* – эш, *ķәстәрләү* – тәрбияләү, җиренә җиткереп эшләү, *әүмәт* – байлык, барлык.

Шушы ук төркемгә *мәсәлә* – әкият, *сәғәтләмә* – сәгать, *сәғәттә//сәттә* – әд. хәзер генә, тиз, *сәлам* – әд. хат һ.б. сүзләрне дә кертергә мөмкин.

Нагайбәк сөйләшенең лексик үзенчәлекләре, нигездә, шулардан гыйбарәт.

Сөйләшнең тел үзенчәлекләрен анализлаудан күренгәнчә, нагайбәк сөйләше төп күрсәткечләре белән урта диалектның Казан ханлыгы җирлегендә формалашкан сөйләшләре – минзәлә, казан арты (дөбьяз), бигрәк тә зәй, казан арты керәшен сөйләшләренә якыная. Без өйрәнә торган сөйләшнең шулай ук архаик күренешләрне күбрәк саклап калган нократ, пермь, касыйм сөйләшләре белән дә уртаклыгы зур.

Билгеле бер чорда урта диалект вәкилләреннән аерылып китеп, территориаль яктан татар теленең башка сөйләшләреннән изоляцияләнгән килеш яшәү нәтиҗәсендә нагайбәкләр татар халкының аерым этнографик төркеме, ә аларның телләре урта диалектның мөстәкыйль сөйләше буларак формалашкан.

# К РЕКОНСТРУКЦИИ ТРАДИЦИОННОЙ КУЛЬТУРЫ НАГАЙБАКОВ
## (обряд и текст)

*Флёра Баязитова*

Говор нагайбаков по своим языковым особенностям относится к среднему диалекту татарского языка. Многие фонетические, морфологические, лексические особенности, отличающие говор нагайбаков от татарского литературного языка, находят параллели в заказанском и мензелинском говорах татарского языка. Например, по употреблению открытого *а*, более закрытого, чем в литературном языке, звука *ә*, глубокозаднеязычных *ķ, ғ*, аффрикат с ослабленным взрывным элементом $^{д}$*җ*, $^{т}$*ч* говор нагайбаков близок к примешинскому подговору крещеных татар Заказанья. Как и многим говорам среднего диалекта, нагайбакскому говору свойственно җоканье, т.е. *й ~ җ*: җыл – ел ‘год’, *дөнҗа* – дөнья ‘мир, вселенная’. Особенно распространено соответствие *ф ~ п*: *Марпа* – Марфа, *нәпес* – нәфес ‘желание, прихоть’, *х ~ к*: *җакшы* – яхшы ‘хорошо’. Как и в других кряшенских говорах, фарингальный звук *h* в говоре нагайбаков вообще не употребляется. Например, в начале слова: *үнәр* – һөнәр ‘ремесло’, *аwа* – һава, в середине слова: *шәгәр* – шәһәр ‘город’, *җәннәм* – җәгәннәм-җәһәннәм ‘ад’.

Грамматические особенности говора нагайбаков мало отличаются от татарского литературного языка. Многие диалектальные особенности говора имеют параллели в заказанском говоре кряшен. Например, деепричастие на *-гач/-гәч, -кач/-кәч*

литературного языка имеет формы *-гачын/-гәчен*, *-гачыннан/-гәченнән*, которые активно употребляются в говорах среднего диалекта татарского языка, в том числе в говорах кряшен Заказанья, Нижнего Прикамья, чистопольских кряшен. Глаголы 1-го лица ед. и мн. числа желательного и изъявительного наклонения имеют форму *-ыйым/-ийем*: *барыйым – барыйм* 'пойду', *күрийем – күрим* 'увижу'.

Основную часть лексики говора составляют общетатарские слова. Диалектная лексика говора также является общей и для других говоров татарского языка. Очень много общего наблюдается с говорами заказанских крещеных татар. Основные лексические группы, например термины родства, названия одежды и украшений, обрядов и обычаев почти не отличаются от других говоров крещеных татар.

По исследованиям Ф.Ю. Юсупова[1] нагайбакский говор по своим основным особенностям относится к среднему диалекту татарского языка, что является одним из доказательств генетической связи его носителей с казанскими татарами. Это подтверждено и нашими экспедиционными материалами (1986 и 2016 гг.) и исследованиями при сравнительном изучении говоров крещеных татар[2]. Все это доказывает, что формирование говора нагайбаков проходило еще на территории Заказанья. А в результате того, что нагайбаки в течение многих лет жили изолированно от основной массы татар, в окружении других тюркских народов (башкир, казахов) сначала на территории Белебеевского уезда Уфимской губернии, а потом на современной территории их проживания (Челябинская обл.), в их говоре появились и некоторые отличительные особенности.

Ниже приводятся этнолингвистические диалектологические тексты с выявлением обрядовой терминологии, зафиксированные

---

[1] *Юсупов Ф.Ф.* Урта диалектның нагайбәк сөйләше // МТД. Казань, 1974. С. 91.

[2] *Баязитова Ф.С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М., 1986.

в населенных пунктах нагайбаков Чебаркульского и Нагайбакского районов Челябинской области[1]. Основное внимание уделяется на их ценность как с точки зрения языка, так и содержания (т.е. этнографические сообщения, фольклорные и другие материалы, которые записаны у информантов старшего поколения).

В научный оборот вводится материал, «памятники» народной культуры, целиком построенные на диалектных текстах. Ценность данного материала заключается в том, что в них отражаются фрагменты древних народных представлений, образные элементы архаических уровней культуры в законсервированном виде, фрагменты язычества, которые уже не осознаются как таковые и исполняются механически (а если не исполняются, то остаются только в памяти старшего поколения).

Иллюстративный материал является также толкованием к соответвующим терминам и необходимой частью научно-исследовательской работы.

### Календарные обычаи и обряды

**Май/маслинча** ‘Масленица’, **май чабу** ‘празднование Масленицы’. По содержанию и названию этот обряд не отличается от других групп крещеных татар.

*– Җыйылабыз бер җиргә кызлар-малайлар. «Әйдәгез, бүген бит май көне, май чабыйык. Сез безгә барыгыз, без сезгә килербез». Инә-әти пешеренә. «Мин ат җигәм бүген, кашаwай бирегез безгә». Өчәр-дүртәр өйле җыйыла, урам әйләнәбез, җырлашабыз, чәбәкәйлибез. Аннан керәбез, өченче өйгә. Кемнәр*

---

[1] Использованы материалы, записанные у следующих информаторов Нагайбакского и Чебаркульского районов Челябинской области во время экспедиции в 1978 году: Нагайбакский район, с. Париж: Байкина Дарья Кузьминична, Байкина Зоя Михайловна, Байкин Иван Михайлович, Иванова Марина Федоровна, Ишимова Нина Николаевна, Иванов Никандор Герасимович, Киртянов Петр Яковлевич, Батраева Анна Васильевна, Мамедалина Мария Николаевна, Сергеева Анастасья Кузьминична и др. Чебаркульский район, Варламово, Попово: Юзеев Иван Степанович, Юзеева Василиса Васильевна, Урсаева Федора Тихоновна, Бигашева Агафья Федоровна и др.

*өйөнә. керәсен, шунын аты җигүле. Чуклыйбыз атларны, кыңгыраулар тагабыз. Берсеннән-берсе көннәшә. Мичәүдәге ат җакшы була. «Ай, май да чапмады», – диләр, көләләр май чапмаса. Үзләре суккан күлмәкләрен кийәләр, җиләннәрен кийәләр, җепәк җаулыклар бәйлиләр, тәңкәле балдаклар, тәңкәле беләзекләр, кызыл җиләннәр кийәләр, бик эйәмне була.*

**Катайса әйләнү** ‘катание на лошадях в дни Масленниц’. **Катайса көйө/май көйө** ‘песни и мелодия Масленицы’.

*– Катайса әйләнәсен атлар җигеп аwылның бер башыннан икенче башына чикле. Катайса әйләнгәндә җырлисын, аwылны әйләнеп җырлап кайтабыз, аман чабасын аwылны әйләнеп катайса көйөн, май көйөн җырлап.*

*Җырлашыйык, туганайлар, җырлашыйык*
*Җокодагы кешеләр уйансын.*
*Ай уйансын да тыңнасын,*
*Кемнәр җырлый, диб үк сорасын.*
*Икәүләр дә өчәү без булайык,*
*Җулкайларга да чыгып ук кунайык.*
*Җулкайларга чыгып җуллар уңса,*
*Айырылмас дуслар булайык.*

**Бәрмәнчекәй** ‘верба, вербный праздник’. Весенний обряд, связанный с вербой, имеется у татар-кряшен, у причепецких татар и у татар-мишарей Пензенской области (Каменский район). У крещеных татар, в том числе и у нагайбаков, вербный праздник называется **бәрмәнчек/бәрмәнчекәй.** Весной, за неделю до праздника пасхи, в вербное воскресенье, молодежь собиралась в одном доме, куда приносились пушистые ветви ивы, варили кашу – **бәрмәнчек буткасы,** веселились, хлестали друг-друга вербой. Ветки вербы, красиво завязав букетом, взрослые брали с собой в церковь. Освященные пучки вербушек – ивовых либо вербных веток, потом клали за образа. Весной, во время первого выгона скота на пастбище, ими хлестали скотину или клали их в корзину гусыни, сидящей на яйцах, затыкали ее в стены хлева, вербушками украшали божницу каждой избы. ‘Вербное

воскресенье’ под различными названиями известно и у других народов Среднего Поволжья. Например, чув. *вирем, вирмече*, удм. *пучы, пучы шуккан* (битье лозой или вербой). Этимология слова *бәрмәнчек* считается не очень ясной (тат. *бәр* – бить, рус. *верба,* вербное?)[1]. Сохранению этого обрядового празднества и моления, их названий в говорах крещеных татар способствовало соблюдение ими христианской религии.

*– Атна арты көнне оло көнгә атна калдырып бәрмәнчекәй була. Малайлар китә бәрмәнчекәйгә, монда җыйылып бәрмәнчекәй боткасы пешерәләр. «Менә бүген бәрмәнчекәй боткасы ашыйбыз», – диләр.*

*«Бәрмәнчекәй, бәрмәнчекәй,*
*Оло көндә өч күкәй», – диләр.*

*– Бәрмәнчекәйне чуклыйлар, тәтилиләр, аны тәре алдына куйалар. Аны – бәрмәнчекәйне абзарга алып чыгып кыстырып куйалар: «маллар шулай ишле булсын, таза булсын», – дип. «Бала-чагаларга суккалый, акыллы булсын», – дип. Кипкенче тора ул.*

**Оло көн** ‘Пасха, досл. великий день’, также и в других говорах крещеных татар.

*– Оло көнгә карышы күкәй буйисын йөзгә чәре. Иртә беләң кем керә, ике йә өч күкәй бирә. Ул айак сынаулы була. Ул кергән кешене мендәргә утырта да черләтә. Балалар черли, «чер-чер», – дип.*

*Җәннек-җөрөшкә* (кош-корт)*, җәннек утырырмы анда, утырмасмы, төрле кешенең төрлечә була.*

*«Малларыгыз күп булсын, ишәйсен,*
*Тawыкларыгыз күкәйне күп салсын,*
*Тауиклы булыгыз, талигалы булыгыз», –*

*дип әйтеп черлиләр аны.*

*– Капчыкка күкәйне җыйабыз, кем тәйикмәк бирә шунда. «Мийа тәйикмәк кирәкми, күкәй кирәк», – диләр. Үзенен ыруwы,*

---

[1] *Ахметьянов Р.Г.* Сравнительное исследование татарского и чувашского языков (фонетика и лексика). М., 1978.

*йакынына керә инде. Кажни өйгә керсә бит ул шоннок* (бик күп) *булырга кирәк, кажнийы үз ыруwын үзе белә анда.*

**Сөрән** 'весенний праздник'. В третий день после Пасхи, молодые люди верхом на конях едут по домам, собирают вещи, крашенки. Потом устраивают состязания и скачки. Этот обряд объясняется как обычай встречать новый год по древнему календарю, так как он проводился в апреле, в период таяния снегов. Обряд **сөрән** известен у многих народов Поволжья: тат. **сөрән,** чув. **серен,** мар. **сюрем,** удм. **сурен,** башк. **һөрән** и т.д. У марийцев летний праздник **сюрем** отмечался особенно торжественно, все марийские селения группировались по определенным сюремнем округам, каждый из которых имел **сюрем ото** – рощу, где совершалось жертвоприношение во время празднования[1].

*– Сөрән ул оло көннән өченче көнендә. Атка атлана өч кеше. Атына атлана, урам буйына чыга. Җана кийәүгә киткән җәш киленнәр була, аңар бара да кычкыра: «Ура-ура». Бистәр* (полотенце) *алып чыгалар, оло бистәр, җырлыйлар, китәләр икенчегә. Шул бистәрләргә көрәштерәләр, ничә бистәр җыйыла. Бер батыр җыкты исә бистәр бирәләр. Даган асты була, даган коралар, атыналар. Бистәр җыйганда озон көй була. Ат атланган кешеләр шуны җырлыйлар.*

**Сабанга чыгу** 'первый выход на весенний сев'.

*– Сабанга чыкканда боткасын пешерә, күкәй пешерә, күкәйне җиргә күмә.*

*«Чәчкән ашлыклар күкәй күк тук булсын, туклык булсын», – ди.*

**Труйсын/334ручын** 'Троицын день' – древний праздник весны, который проводится обычно в первое воскресенье июня. Церковь приурочила к этому празднику свой праздник в честь «троицы», триединого бога – отца, сына и святого духа[2]. *Көйө дә бар ыйы. Себеркегә, әремгә ут төртеп, зур корокның* (жердь) *башына*

[1] *Козлова К.И.* Очерки этнической истории марийского народа. М., 1978. С. 287.

[2] *Даль В.Л.* Толковый словарь живого великорусского языка: в 4-х т. М., 1978–1980. Т. 3. С. 431.

*шул себеркене бәйләрләр ийе, шулай күтәреп пештемә куwарлар ыйы катыннар җырлап. Аның җапырагы җанып бетә, чыбыгы төтәп барыр ыйы, шуннан кырау төшмәс булыр ыйы дип картлар сөйләп калдырдылар, әwәле шулай булган.*

**Нардуган** ‘святки, святочные игры’. Нардуган праздновался с 24 декабря, в эти дни проводились маскарадные увеселения и гадания на кольцах. **Нардуган өйө** ‘дом, где собирались участники святочных игр’. **Нардуган такмагы** ‘святочные частушки, песенные куплеты’.

Среди татар обряд Нардуган известен у мишарей, он распространен также среди многих народов Среднего Поволжья. Например, морд.-мокша **нардван,** морд.-эрзя **нардава,** мар. (диал.) **нардуган,** чув. **нартаван, нарту кан,** удм. **нардуган** и др.[1]

*– Нардуганда барасын бер кешегә. «Безгә өйөнне сатып бир әле». Күкәй, май алып киләбез, нардуганны сатып алабыз, дибез. Мин ипей алып киләм, син алып киләсен май. Бичуркага* (рус. вечеринка) *барасын, шунда бийешәсен, такмаг әйтәсен. Уйныйбыз бергә тикле. Өй сатып алынган, әзер. Иртә белән тагын барабыз нардуганга. Уйныйбыз, җырлыйбыз, чәй эчәбез, ашамтык* (ашамлык) *ашыйбыз. Мына җырлыйсын да бийисен чәбәкәй итеп* (кул чабып):

*Базарларга барган булган,*
*Кулугы да булмаган.*
*Нардуганга кигән булган,*
*Толыбы да булмаган.*

*Кызны төреп алып чыгып китәргә толып алып килмәгән инде җегет.*

*– Раштуа* (рус. Рождество) *көнне балалар акча җыйарга чыгарлар ыйы. Сийа керә, мийа керә, җырлый. Аның үзенең җыры бар. Унике көн нардуган булыр ыйы, ундүртенче көнне*

---

[1] *Ахметьянов Р.Г.* Сравнительное исследование татарского и чувашского языков (фонетика и лексика). М., 1978. С. 99.

*чыгарлар ыйы, кеше танытмыйчы өй борончы җөрөрләр ийе. Ат булып кийенерләр ийе, дөйә булып кийенерләр ийе җегетләр. Катын-кызлар чыгарлар ыйы думбыралар белән, сөйләшерләр ийе таwышын танытмыйчы бийерләр ийе. Куркырыйык пәри кермәсен дип, ишек боросларына тәре сызарлар ыйы. Ундүрте көнне көндез әйбәт йахшы кийемнәрен кийенеп өй борончы бийергә чыгарлар ыйы җәшләр.*

**Җөзөк салу** ‘гадание на кольцах, один из видов гадания во время святок’.

*– Унике көн нардуган, унөченче көнне кач манырлар ыйы. Унөченче көнне кич җөзөк салу булыр ыйы. Җыйылыр ыйы калык, кайда мучада, кайда өйдә. Төпчек бала белән баш бала сыу алып килерләр ийе койодан. Җөзөкне салган чагында нийәтләп салыр ыйы. Ин алдан саласын җортнын исәнлегенә дип. Шуннан килеп җеп бәйләп саласын инде кажни кешенен балдагына. Мына үзенен нардуган такмагы дирерләр ийе. Ала бирәләр сала бирәләр, җыруны әйтә бирәләр.*

*Мич башыннан җыгылган*
*Башы учакка тыгылган*

*– Көлдә аунаган, көнен күргән. Начар җыру җырларга тырышмыйсын, ару* (яхшы, әйбәт) *җыру җырларга тырышасын. Нийәтләсән белгән шикелле килеп чыгар ыйы җырулар.*

*Ишегалдым чокор-чокыр*
*Зират җулы тап-такыр,*

*ди, үләсе кешегә чыга инде йәнә.*

*Әтекәйнең акчасы*
*Ындырдагы көшелдәй,*

*ди, – у, бик җакшы җыру чыкты, диләр.*

*Салам түшәк, мамык җастык,*
*Бот күтәреп тик җаттык, ди.*

*– Балдакны өч тапкыр салалар. Әннән әре* (аннан соң) *сыwын алып чыгып койашка каршы түгәләр.*

*– Кызлар берәүнең абзарына керәләр дә сарыкның муйынына җеп бәйлиләр. Карт сарык әләктисә карт кешегә кийәүгә китә, җәш сарык эләксә, җәш кешегә китә.*

*– Әннән эре урамга чыгып көл иләрләр ийе иләк белән җулга. Тора да карый. Атлы кеше уздисә башка аwылга кийәүгә китә, җәйәуле кеше уздисә үз аwылына китә. Шундый ырымнары бар ыйы.*

**Чүг итү, чүб итү** ‘полевое моление, проводимое в засуху, когда появляются признаки надвигающегося неурожая’. В группах заказанских кряшен и у кряшен Нижнего Прикамья слова *чук, чүк итү, чүк буткасы* обозначают этот же обряд, т.е. полевое моление[1].

*– Чүг итәргә җыйылалар да инде урындыкка тәреләр куйалар, чиләк белән сыу алалар, кырга китәләр. Себертке алалар. Сибәләр инде себертке белән тәрегә сыу. Без, калыклар, барабыз, ашаулыкны җәйәбез дә җиргә утырабыз шунда. Боламык, күкәй пешерәләр карт әбиләр. Себертке белән сыу сибеп чыгалар кешеләргә. Ашаб-эчеп бетерәләр дә инде тагын казан кырыйына барасын. Бер кашыкмы, ике кашыкмы ботканы өйгә балаларга аласын. Кузгалып китә башлагач инде әзер торалар, сыу сибәләр чиләк белән. Чүг итү шул була, йаңгыр йаwып китә. Әби-сәби пешерә ботка, аларны да сыу белән кыйындыралар.*

## Семейные обряды и обычаи

### *Туй (свадьба)*

**Кыз билгеләшү** ‘обручение’.

*– Кыз билгеләшерләр ийе пыкырауда* (рус. покров день). *Качан китә, туйы качан була. Җегет качан килә. Шулай билгеләшерләр ийе, маслинчада* (рус. масленица) *туйы булыр ыйы.*

**Аклашу** ‘сосватать, просватать невесту, обмениваться подарками’.

[1] *Баязитова Ф.С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. С. 170–171.

*– Аклашырга барабыз. Мына бу тутам бит инде. Кызга китәбез җегет җагыннан. Парлы нәстә алып барасын: беләзек – сырга, бәрән кабы тун.*

*– Өч кеше килә аклашкан чакта. Әтки-әнки,– дыружки сине аклашалар. «Сездә кыз, бездә ул бар», – диләр инде. «Айаг астына бүкән, утырырга мендәр», – диләр. «Утырыгыз, кодалар» – диләр, мендәр салалар, утырталар. Аш салалар, ул аш пешә. Хуҗайкы аш утырта. «Кодалар, аштан сыудан аwыз итегез», – ди. «Киштәгез нык булсын», – дип, төйөнчеккә төйнәп акча эләләр. «Сез инде каты тормагыз, без сибәп белән килдек, синәк белән тормагыз», – диләр. Чәй эчәләр. «Безнең малай сезнен кызны җарата, кызыгызны бирәсезме?». Кайсы әйтә, бирмибез, ди, кайсы, бирәбез, ди. Аклашканда йә муйса, йә изү мийа бир, ди. Күлмәген йә бистәр бирәләр.*

*– Җегет җибәрә җаучы кыз өйөнә. Килгәчен инде исәнлегенсаулык сорашып керәләр. «Утырыгыз», – диләр өй ийәләре. «Җук, без коро җиргә утырырга килмәдек, безнең аска мендәр кирәк, айаг аска бүкән кирәк», – диләр. Шуннан инде кызны бирәсе булсалар, җаратсалар, мендәр салалар. Ошатмаган кешеләре булса, бирмиләр мендәрне, шул көйө генә утырталар. Сөйләшәләр дә шул көйө генә кайтып китәләр, чәй дә куймыйлар. Ошатсалар, чәй куйалар, май утырталар. «Сез кайтып торыгыз, без киңәш итийек тыуган-ырыу белән», диләр*[1].

**Акка салу** ‘вручение обещанного подарка во время обручения’.

*– Шушы кигән кийе аклашып кайтабыз инде кызны диләр. Шуннан болар чыгаралар бер нәмә салып калын табагы* (аклашу бүләген салу өчен әзерләнгән савыт) *бер паднусмы, тәлинкәме. Шуңа бер әйбер сала да кызның инәсе, кыз ни әзерләгән, шарып бәйләп куйгаммы, акка салырга дип, әллә әйбәт итеп бистәр чиген куйгаммы, бар кешенеке бер пурмы булмый инде ул, шулай итеп үзенең дайарлаган нәстәсен сала калын табагына*[2].

---

[1] *Юсупов Ф.Ф.* Урта диалектның нагайбәк сөйләше // МТД. Казань, 1974. С. 205.

[2] Там же. С. 206

**Аклашу җыйыны** ‘предсвадебные угощения’.

*– Инде монда аклашырга кәрендәш-ырулар да килә бит моның. Шу кигән кәрендәш-ырулар инде монда ашап эчкәннән суң: «Җәгез, кодалар, инде кода булышабыз, кодагый булышабыз, инде безгә дә барып бер самаwыр чәй эчийек бергә-бергә, болай итеп танышкач», – диләр. Китәләр инде болар игенче өйгә, өченче өйгә дә баралар. Шуннан аклашканда шуның белән бетәләр. Болар инде шулай итеп аклашу җыйынын бетәләр*[1].

**Кәбен** ‘венчание’, **кәбенгә керү** ‘венчание в церкви’. **Кәбен күлмәге** ‘подвенечное платье’.

*– Кәбенгә керә мына кызы, үзенә атап күлмәк алырлар ыйы, кәбен күлмәге дип.*

## Свадебные чины

**Туйчы** ‘ведущий на свадьбе’.

*– Тотоналар болар туйчы эзләргә. Баралар туганнарына. Туганнары барырлыгы сыразы ышандыра. Кайсыберләре бик капризныйрак булып, әле тагы бер килерләр әйе туйчы кирәк булса дип калалар. Туйга бик күп кәл кирәк бит аңа*[2].

**Төп кода, оло кода** ‘отец и мать родителей жениха и невесты’.

*– Төп кодалар инәләре-аталары була кызның да, җегетнең дә. Туйда оло кодаларга җырлыйлар кушма җырулар.*

**Кыз агасы, кыз җиңгәсе** ‘супружеская пара, сопровождающая невесту в дом жениха’.

*– Түшәк-җастык артыннан кыз агасы, кыз җиңгәсе кеше бара, үзенеке жуг икән, читтән кыз агасы, кыз җиңгәсе итеп җибәрәләр.*

**Кыйаматлык** ‘родственники (муж с женой) со стороны жениха или невесты, которые присутствуют во время венчания в церкви и при перевозки невесты в дом жениха’. Слово **кайматлык** в том же значении употребляется в чувашском

---

[1] *Юсупов Ф.Ф.* Урта диалектның нагайбәк сөйләше // МТД. Казань, 1974. С. 206

[2] Там же.

языке[1]. Ср. также мар. **кийамат ава** ‘посаженая мать’, **кийамат ача** ‘посаженый отец’, в говорах башкирского языка: **кыйаматлык атай, кыйаматлык әсәй[2], гыйаматлык/кыйаматлык** литер. **кийәмәтлек[3]** (которые исполняют роль кыяматлык, жених и невеста всю жизнь оказывают уважение и заботу, обращаются к ним **атеки, энеки –** папочка, мамочка). **Кыйаматлык кызым –** форма обращения посаженой матери к невесте. Обращение детей к посаженой матери своей матери **җәш** әбей, **җәш** бабай (букв, молодая бабушка, молодой дедушка) – также у бакалинских крещеных татар, у других кряшен **энеки әбей, этеки бабай. Җәш түтей, җәш җиңгей –** обращение детей посаженой матери к невесте.

**Уртак, уртагым** форма обращения между родственниками посаженых и родственников жениха и невесты: – *Менә минем кызымны кийәүгә биргәндә кыйаматлыкка мин уртак дип эндәшергә тийешле, алар да уртагым дип эндәшә.*

*– Кыйаматлык ул этки-энки була. Кыз киткән чакта кызны алырга бара ул. Кыз утырган җиргә килә дә мин кызны сатып алырга килдем, ди. Без кызны шу көйө бирмибез диләр, безгә акча кирәк, диләр. Кесәсеннән акча ала да бирә энки кеше. Акча бирә дә җегет белән кызны җитәкләп түргә утырта.*

## Перевозка невесты

**Ата-инәдән хәйер-фатиха алу** ‘получить благословение родителей’.

*– Ин алдан җегет күрешер ийе кызның атасы белән, аннан кызның инәсенә айаг астына баш ороп күрешер ийе. Аннан кыз күрешер ийе ата-инә белән изгелек сорарлар ыйы инәсе белән атасыннан. Әнисе ипи башлый кызның. Кисеп алган ипинең башын җегеткә бирә, җартысын кызга бирә. «Менә шуны ашап бетерегез», – ди. Ул ипи башын алар ашап бетәләр.*

---

[1] *Егоров В.Г.* Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары, 1964. С. 289.

[2] *Максютов Н.Х.* Восточный диалект башкирского языка. М., 1976. С. 256.

[3] *Миржанова С.Ф.* Южный диалект башкирского языка. М., 1979. С. 107.

*– Тәре белән бистәр тотып, айаг астына баш ороп бәхиллек сорыйлар йәшләр ата-инәдән. Ул тәрене кыз баланың үзенә биреп җибәрәләр.*

**Кодаларны каршылау** ‘встречать сватов в доме жениха’.

*– Җегетнең өйөнә кайтып ишегалдына керерләр ийе. Аттан төшәләр дә тезеләләр бер эрәт итеп кенә. Ин алдан оло кода, аннан кодалар, аннан катын-кызлар тезелеп китә. Тезелгәчен инде чыгалар тегеннән, кодагый инде май тәлинкәсе тотоп, ипи тәлинкәсе, ак бистәргә утыртып. Кодалар белән исәнләшәләр әйбәт итеп. Тегеләр ипейдән аwыз итеп алалар, тәберсен итәләр. Кодалар монда кала, кийәү белән килен китәләр кыйаматлыкка*[1].

**Кызның урын-җир әйберләрен китерү** ‘перевозка постельных принадлежностей невесты’.

*– Туй китәсе көнне бөтен нәстәне әйбәт итеп дайарлый кыз бирүче кешеләр. Кызның нәстәсен сандыгына тутыра тегендә баргач эләсе әйберләрен. Сандык өстенә түшәк көйли әйбәт иттереп. Ул өйгән әйберләрне күрергә ишегал тулып калык килә. Шуннан ул түшәк-җастыкны чанага төйиләр инде: иң аска сандык, куйкасы буса куйкасын да салалар, иң өскә мендәрләрен салалар, пакрывалларын каплыйлар. Аннан өстенә бер җәймә каплыйлар да аркан белән ныгытып төреп кысып бәйлиләр чанага. Шуннан ике рәт урамны әйләнәләр шул төйәгән көйгә бөтенесе*[2].

**Түшәк-җастык сатулашу** ‘шуточный обычай купли-продажи постельных принадлежностей невесты’.

*– Инде болар китәләр түшәк-җастык сатулашырга. Ат өстендә малайлар утыралар. Җә, аты-нийе белән бирергә килдегезме безгә. Без түшәк-җастык кына сатабыз диләр. Нинди акчага бирәсез, рәсемле акчага бирәбез. Wак балалар була бит инде. Җук, без андыйны эшлиәлмәдек бит, ак акчага бирегез. Әй, аг акча аз, безгә оло акча кирәк. Балалар сөйләшә инде шушылай анда. Калык карап тора инде кызыклык итеп. Анда шаян кешеләр була. Әллә ниләр әйтеп бетерәләр балаларга.*

---

[1] *Юсупов Ф.Ф.* Урта диалектның нагайбәк сөйләше // МТД. Казань, 1974. С. 207.

[2] Там же.

**Килен әйберләрен өйгә кертү** ‘внесение в дом вещей невесты’.

*– Түшәк-җастыкны ике кыз күтәрә, сандыгын ике кеше күтәрә. Куйкылары, әйберләре булса шулай күтәрәләр. Ничә ишек булса, шуннан кергәндә ордоралар аркылы китереп. Оролды, сыймый инде, без аны ничек апкерийек инде. Әйдә, әйдә, сыйдырырга, акчам җук, акчам аз гына. Бумас синең акчан, син бай, шуннан болар акча бирәләр инде барысына да. Акча биргәч болар ордормыйлар, әйбәт итеп кенә апкеребләр*[1].

**Киленне өйгә кертү** ‘вводить невесту в дом’.

*– Түшәк-җастык сатулашып бeткенче кыз белән җегет шунда торалар. Түшәк-җастыкны алып беткәннән суң айырылмыйлар, айырылмаска кушалар. Җитәкләшеп алалар да әйбер артыннан керәләр. Кергәчен киленне икесен җегет белән утыртып куйалар инде почмакка. Инде кодалар эрәтләнеп утыралар.*

**Килен әйберләрен элү** ‘развешивание вещей невесты’.

*– Бутка чыккачын тотоналар киленнең әйберләрен эләргә кодачалар. Берсе сандык саклый, берсе алып бирә, өченчесе элә бара. Берсе җугарыда элә. Чөй кирәк, чөй диләр, акча бирәләр. Җуг инде, алай коро чөй керми, җеwешләргә кирәк. Аннан бирәләр аракы. Ыстаканлы аракының эченә тыгалар акча. Аракысын эчеп бетә дә соңоннан ала акчасын. Әйберләрен элгәннән суң утырып чәй эчәләр ;*

*– Берәү элеп җөри тәрәзә ыштурлары, бистәрләр. Кадак кагып җөри, чуптарлап суккан ашҗаулык җәйә.*

**Яшь килен кийемнәре** ‘одежда невесты’:

*– Мин белгәндә җаулык булыр ыйы башларында, озон күлмәк. Менә тутам, инәм күлмәкне үзләре сукканнар, киҗеле күлмәкләре бороңгы.*

*– Бийем белән бийатага айак күрсәтмәс ийе килен.*

*– Теккәчен күлмәкне убурка куйа җиң ычларына, итәккә. Җилән тегә, алчүперек* (алъяпкыч) *тегә үзенә үзе итәкләп, күкерәкләп.*

---

[1] *Юсупов Ф.Ф.* Урта диалектның нагайбәк сөйләше // МТД. Казань, 1974. С. 208.

– *Сүрәкә* (муенса) *чигәләр ийе үзләренә үзләре.*

– *Түшкә тагалар ыйы муйса* (муенса), *өч рәткә тәңкә, шушында чаклы муйса, өч рәткә тәңкә, шушында чаклы муйса көмөштән.*

– *Сыргалар* (алкалар) *җасты булыр ыйы. Чәчбәүләр* (чәчүргеч) *буган тәңкәле, тәңкәле беләзек, борма беләзек, чуклы эзәр, ишкел бау, гарыстан шуны чуклап, матурлап бәйлибез.*

– *Инәмнең инәсе җыракайыбыз* (җырак әби, әнисенең әнисен шулай әйтәләр) *күрсәтер ийе сүрәкәне.*

**Яшь киленнен йөзен ачу** 'снятие свадебного покрывала, открывание лица невесты'.

– *Йәш киленне күрсәтмиләр, йепәк эшәл бәйләтәләр. Бер ир бала килә. Йәш киленнең йөзен күрсәтегез, диләр. Ир бала йаулыкны ача. Аңар акча салалар, бәйрәм иткәчен таралалар. Йөзен ачканда оло-кары бәйрәм итә.*

– *Әwәле йәш киленнең йөзен ачканда «хан кызы» дип җырлыйларыйы:*

*Хан кызы, ач ишегеңне, мин керәйем,*
*Синең йөзең матур диләр, мин күрәйем.*
*Минем йөзем матурлыгын, ай, күрмәйемсең,*
*Җиргә чыккан койашларны, ай, күрмәйемсең.*
*Хан кызы, ач ишегеңне, мин керәйем,*
*Синең буйың зиба диләр, мин күрәйем.*
*Минем буйның зибалыгын белмәйемсең,*
*Урмандускән наратларны күрмәйемсең.*
*Хан кызы, ач ишегеңне, мин керәйем,*
*Синең чәчен бөдрә диләр, мин күрәйем.*
*Минем чәчнең бөдрәлеген белмәйемсең,*
*Аwадагы ак болотны күрмәйемсең.*
*Хан кызы, ач ишегеңне, мин керәйем,*
*Синең күзең кара диләр, мин күрәйем.*
*Минем күзнең каралыгын белмәйемсең,*
*Урмандускән шомортларны күрмәйемсең.*

**Туй ашлары** ‘свадебные угощения’.

*– Күмәчләр була, піруклар, баwырсаклар, басып кисеп пешерәбез. Ипейне салабыз. Чийә пируклары, җиләк пируклары пешерәбез. Пилмән җасыйбыз. Кунаклар җыйылдисә чәй эчәбез.*

*Оло туйларга, бәйрәмнәргә алдан чәй, аннары аш утыртабыз. Ашаб-эчеп туйгачын ит утыртабыз, бутка.*

**Күчтәнәч чыгару** ‘преподнесение свадебных гостинцев’.

*– Әйбер элеп беткәч тә күчтәнәч чыга. Анда бик әйбәтләп пешерелгән әйберләр була. Бөтен үрдәге була, казы бар кешенең казы була. Әнә шуны турарга асубый бер кешесен куйа. Күчтәнәч тураган кеше кайрак сорый. «Пычак үтми, кайрарга кирәк», – ти. Акча биргәннән суң йәш киленне икесен җегет белән утыртып куйалар инде почмакка. Күчтәнәч тураучыга бирнә җабалар башына. Бүләк җапкачын бу җәш киленгә мал әйтә, сарык әйтәме, үзенең көче җиткәнен әйтә, җәнлекме, канатлы кошмы диләр.*

**Кодаларны сыйлау** ‘угощение сватов’.

*– Шуннан сыйлый башлыйлар инде кодаларны, жаркуй алдан утыра, аш, шуннан инде тегесе-моносо була да бутка чыга. Бутка чыккачын җәшләргә дә бутка бирәләр, бутка ашыйлар.*

*Кодаларны сыйлаганда кушма җырулар* (песни, специально посвященные кому-либо) *җырлыйлар:*

*Әйләр җәмне икән бу җаланнар,*
*Кайда икән аның мижасы.*
*Сез кодалар белән бер сөйләшсәм,*
*Бетеп китә дөнҗа нужасы.*
*Мендем бийек тауларга,*
*Капканнар да кордом бүрегә.*
*Җыракай җирләрне җакын итеп,*
*Наруш килдем сезләрне күрергә.*
*Шелекәй буйкайлары әле киндә җалан*
*Ак тирмәләр короп җәйләргә.*
*Кайларга барсак туганнар кирәк*
*Каршы чыгыб ук атларны бәйләргә.*

**Килен котлау, килен майы ашау** ‘свадебное угощение в честь невесты с преподнесением подарков’.

*– Кейәү өйөндә килен котлау булыр ыйы, җыйыла инде кәрендәш-ыру, җыйылгачын аш эчәргә утырталар, аш артыннан бутка, бутка чыккачын киленне апкайтырлар ыйы кыйаматлык өйөннән. Киленне алып кайтып аерым утырталар шаршау эченә. Аннан килен котлау булыр ыйы. Нәстә саласын, күлмәк саласынмы, акча саласынмы. Кайсы берсе әйтер сүзен әйтә инде кергән оңайда ук.*

*– Кыз алган җортка җыйыла җәшләр, бу килен майы ашау була инде. Килен майын утырталар. Җортның бер кешесе тәрилкәгә сала да алып чыга. Бутканы утырта. Бутканың өстенә җаба. Анда бер саwыт утыра. Бутка ашасы кигән кеше анда акча сала. Аннан май ашыйлар, килен майы дип.*

*Килен майы ашаганын ашҗаулык җәйеп куйалар, ашҗаулык котлыйлар, акча салалар.*

**Тау итү** ‘отблагодарить хозяев, сказать спасибо’. Это словосочетание употребляется во всех говорах крещеных татар. После свадебного угощения, вечеринки, гости поют песни **тау итү,** в которых восхваляют приготовленное хозяевами кушанья, выражают благодарность. В говоре подберезинских кряшен слово **тау** употребляется иногда и в разговорной речи. В лямбирском говоре мишарского диалекта употребляется выражение **тау атергә** ‘поблагодарить’. В диалектологическом словаре татарского языка зафиксированы выражения из кузнецкого говора мишарского диалекта: **таулар бирешү** ‘обычай угощения квасом друг-друга на свадьбе’. В темниковской группе мишарей во время свадьбы существует обычай **тау итәргә чыгу,** т.е. показ народу невесты и жениха, которые предлагают гостям свадебные угощения.

Слово **тау** есть и в мензелинском говоре татарского языка: *аwыз итсәң* – **тау ит.** Если попробовал еду, угощение – скажи спасибо. В чувашском языке **тав,** у удмуртов и бесермян **тау –** благодарность, спасибо[1].

[1] *Егоров В.Г.* Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары, 1964. С. 289.

*– Туйда ашаб-эчкәчен айаг өсте тора бар да: «Тау итийек», – диләр.*

*Ындыр арткайлары тигәнәк,*
*Җаңгырлар да җаwа сибәләп.*
*Ашадыкай эчтек, көрмәт күрдек,*
*Тау итийек чибәрләп.*
*Карурманның эчләрендә*
*Карагайдан бура бурадым.*
*Бүген күргән төшләремне*
*Сезне күрерләргә йурадым.*

**Гаиләдә эндәшү сүзләре** 'слова-обращения в семье', они не отличаются от говоров заказанских кряшен:

*– Килен төшкәчен үзеннән кече, кейәүдән кече кыз буса п е ч к ә ч ә м ди, иреннән олорак буса а к б и й е м , агасы буса б и й а г а й ди, кечесе буса й а н а г а й , ди. И н ә й , а т а й ди кийәүнең ата-инәсенә. Элеке б и й е м , б и й а т а й дип әйтерләр ийе. Инәбезнең инәсен җ ы р а к а й дибез, инәбезнең тутасын җ ы р а к т ү т е й диб әйтәбез.*

**Бала туу белән бәйле булган йолалар** 'родинные обычаи и обряды'.

**Бәбей майы ашау** 'угощение в честь рождения ребенка'.

*– Хәрендәш – ыруwы, күрешеләре килә бәбейне котларга, аш пешерә, ботка пешерә. Кем күлмәк, кем калпак сала. Бәбей майы ашадык әле дип сүлейләр.*

**Баланы чукындыру** 'крещение ребенка'.

*– Бала тыугачын бер атна арасыннан, ун көннәнме чукындырырлар ийы. Баланы чиркәүгә чукындырырга алып баралар, бер чиләк белән сыу алалар. Зур казан булыр ыйы, шул казанга сыу салырлар ыйы. Чиркәүдә иман укып, баланың өстенә сыу койоп алгачын, җәш атаның кулына җурганны җәйеп торорлар ыйы, китереп салырлар ыйы баланы. Алар җәш инә, җәш ата* (баланы чукындыру йоласын башкарганда катнашкан кешеләр) *булып калыр ыйы.*

**Им-томнар, ырымнар** ‘заговоры и заклинания’.

**Күз тигәннән өшкерү** ‘заговор от сглаза’.

*– Күз тигәндә күрәзәләр булыр ыйы, өшкерә белерләр ийе. Бер әби өшкереп чыгара, кашык чәйкый, ишек башын чәйкый. Менә балама күз тигән, ике күзе шушында калсын, балама тимәсен, дисен.*

**Таң суwы алу:**

*– Таң суwы алган кичтән. Чәшке чокоры белән киткән сыуга, бистәр тоткан. Белгән әбигә илтеп бирәсен, ул күмер сала, ипей сала, өшкереп бирә инде. Алып кайта. Өшкергән суны балага эчертә, ипейне ашлы сыуга сала. Сызылып таң беленгәндә бара, таң белеңгенче алып кайта сыуны.*

**Очан имнәү:**

*– Очан дигән чир булдисә Дәрҗә әбейгә керер ийем баламны күтәреп. «Дәрҗә әбей, тагын балам җылый инде, тагын очан булган». Өшкереп чыгарып җибәрер ийе.*

*Бер-ике-өч – очып китә,*
*Биш – бизеп китә,*
*Җиде – җилгә китә,*
*Тугыз – тузып китсен.*

*Бала шуннан җоклар ыйы.*

### *Погребальные и поминальные обряды*

**Үлгән кешене юу һәм озату** ‘подготовка к погребению и проводы покойного’.

*– Кеше үлгәчен аны җыwалар әйбәтләп, астына* ***җалгаш*** (тагарак) *салалар. Аны кийендерә, чәчләрен кыркалар. Катын кеше буса чәчләрен тарыйлар. Кәбер киче саклыйлар өч көн, түшәк-җастык саклыйлар. Кичен үле җыруwы җырлашалар.*

*– Кайын җапырагы салалар гырупка. Мин күргәнем җук, син күрсән әллә күргәндерсен.*

*– Кыруг сызалар балта белән, гырупны өч тапкыр әйләнәләр.*

*– Кояш чыгышына балтаны ыргыталар.*

*– Таwык сикертү була. Тере таwыкны җаңгыз гына торган бер* ***җитем*** (ятим) *әбигә бирәләр.*

*– Үле чыгып киткәч урынын җәйеп куйалар, җаулык йабалар мендәргә, пешеренәләр. Сөйәк чыгып киттисә ипи-тозларны бирәләр, онын бирәләр, тозын урынына куйалар.*

*– Ботка пешерәләр, муча керәләр күмгәч. Мунчадан чыгалар да ашарга утыралар. Коймак пешереп утырталар, май исе чыгаралар. Аны бирәсен хәйер итеп кыйаш чыкканчы.*

*Аннары тийәберсенен узгарганда, ашын бирә, өчен, тугызын, кырыгын узгаралар, җылын узгаралар, ашын бирәләр.*

*Кырыгында әйберләрен өләшәләр җыуган кешегә, сыу салганга, сөйәген тотканга. Җыуган кешегә ойок башы, тапычкы бирәләр. Кырыгында сарык суйалар, корман суйган күк.*

**Аш бирү** ‘обряд жертвоприношения в честь умерших родственников’.

*– Аш бирү болай була инде, пристулни бәйрәмнәрдә, Михайлов көннө, көҗминкә көннө. Анар атыйлар сыйыр. Башын җыwалар. Менә мин сыйырны атап суйдым затыма-зәwеремә* (нәсел-нәсәбемә). *Суйалар ишегалдында. Казан куйалар, зур казан. Каршы йакны кисеп салалар казанга айагын да, башын да, үпкә-баwырын да салалар. Үзенең кәрендәш-ырыwларын* (туган-тумачаларын) *җыйып чакыра. Кажныйы шул табакны күтәреп килә. Мал суйганда алып бара тавыкмы, казмы, үрдәкме. Суйдыра алар атап затына-зәwеренә. Мында килә. Ит ашарга әйтеп чыгалар. Өч җылга чаклы бирелә, ул инде прусты сыйырны атап суйалар. Абзардан чыкканда сыйырның мөгезенә җеп белән бистәр бәйлиләр, апчыгалар да суйалар. Аш биргән малны сул йагыннан салалар, ашны тышта пешерәләр. Аш пешерүче үзе бүтән була. Аш пешкәчен бер малайны ат атландырып чыгаралар.*

*– Икенче көнне йамбаш ашарга барасын. Аны пирwуй көнне пешерәләр, икенче көнне җылытасын, ашисын, тийәберсен итәсен. Икенче кеше чакыра. Аннан чыккач, өченче өйгә барасын, анда* **үле җыруwы** *җырлыйбыз. Кодагый, башлый беләсенме, башла, без катышырбыз.*

*Гөбер-гөбер майлар йаздым,*
*Гөбеләрдә калды әйрәне.*

*Без ашыйык, без эчийек*
*Туганнарның калдык бәйрәме.*
*Ак йаулыкның читләре*
*Бер бөккәчтен ничек сүтелсен;*
*Туганкайны күмеп куйдык,*
*Бер үлгәчтен ничек терелсен.*
*Ак кайыннарны чапканнар,*
*Җомочкасын кайа куйганнар.*
*Ак кипеннекләргә чорнап,*
*Туганкайны гүргә куйганнар.*
*Җөгөреп кердем мин өйләргә,*
*Чөй җаулыкайларым чөйдә җук.*
*Безнең туганнарны сорасагыз,*
*Очтомакка киткән өйдә җук.*

**Гүр тәберсене** ‘поминки над могилой’.

Слова **тәберсен, тәберсе, тийәберсен** в татарском языке употребляется только в кряшенских говорах. Слово **тәберсен,** видимо, вначале обозначало языческое моление около угощения, еды, т.е. молитвы благодарности за трапезу. Так как это слово произносится во время поминок, древние люди, видимо, считали что это способствует удовлетворению и успокоению души покойного. Для сравнения, урянхайцы и абаканские тюрки во время жертвоприношений к небу произносили слово *тэрь* (небо). Так как *тэрь* и *таңарі, таңрі* идентичны у древних тюрок, возможно, было такое обращение, мольба: *тәңрибирсен* > *тәрбирсен* > *тәбирсен* ‘пусть Всевышний воздаст’[1].

Видимо, этот термин относится к древнейшим пластам лексики тюркских народов. – *Пешеренәсен, ипекәйенне аласын, тийәберсен итәбез. Гүр өстенә җыйылып гүр тәберсене итәсен. Кәбер сайын тийәберсе итеп җөрибез ziratта.*

[1] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен. СПб., 1907. Ч. 9. С. 389.

*Очтомаг ашлары бусын,*
*Күңелләре хушланып җатсын,*
*Тамаклары тукланып җатсын,*
*Танауларына исләре керсен,*
*Аwызларына тәмнәре керсен,*
*Караңгы гүрең йакты булсын,*
*Барысының да җомаг ашлары булсын,*

*дисен. Ит, күкәй, тоз аппарасын.*

**Тийәберсен итү** ‘поминка’. – *Тийәберсенгә барырга әйтәбез кәрендәш-ыруга.» Ипей салабыз, әзерләнәбез. Шуннан табакны җасыйбыз үзебезчә, тейгән* (туган тиешле) *кеше үлдисә табак аппарыга кирәк. Анда җаулык аппарабызмы, бистәр аппарабызмы хәйер бирергә. Теге кешегә барып җитәбез дә табакларны өстәлгә бич утыртабыз шушылай. Утырабыз да калык җыйылганчы табак җасарга кирәк дип. Мына мынсы –* **җан табагы,** *мынсы –* **уша башы,** *мынсы –* **картлар табагы.** *Эч табакка шул табаклардан табак җасыйбыз. Каждыйына бүлеп-бүлеп саласын. Бу табакны утыртабыз уша башына, бу табакны утыртабыз өстәлгә, җан табагын утыртабыз җан чыккан җиргә. Хуҗайын үзе кемгә бирергә тиеш. Бич йөреп тәберсен итәбез. «Тисен», – дисен инде, – «бусын, ашлы-сыwлы булсын», – дисен. Без шунар атаб итәбез. «Ашлы-сыулы бусын, кодай ризыклы итсен», – дисен инде теге яктан. Теге оло табакны биргән кешегә тагын китәбез чәй эчәргә. «Әйдәгез безгә, табактан тәберсен итәргә», – дип. Кажныйы утыртып куйа өстәлгә. Бездә узгыралар икән тәберсен, минем инәмә алар табак җасый. «Ә мынысы картларга, элеке үлгән кәрендәш-ыруга, ә ансы инде исемсез, җитем балаларга ашаталар инде. Атадан-инәдән калган җола бугачын инде. Җыйылышып утырып тәберсен әйтәбез.*

*Затыбыз-зәwеребезгә,*
*Затсыз-зәwерсезләргә,*
*Йомаг ашлары бусын,*
*Очтомаг ашлары бусын,*
*Караңгы гүре йакты бусын,*

*Аwыр тупырагы йеңел бусын,*
*Бер кодай, бер тәнре өчен,*
*Олы-карылар өчен,*
*Инәсе-атасы өчен, –*

*дип, килгән кешеләрнең барысына да йаулык йабасын. Урынга итеп салабыз да утырып аш ашыйбыз. Теге оло табакны биргән кешегә тагын китәбез чәй эчәргә. «Әйдәгез безгә, табактан тәберсен итәргә», – дип. Кажный утырып куйа өстәлгә. Бездә узгаралар икән тәберсен, минем инәмә алар табак җасый. «Ә мынсы картларга, элеке үлгән карендәш-ыруга, ә ансы инде исемсез, җитем балаларга ашаталар инде. Атадан-инәдән калган җола бугачын инде.*

*– Тәберсен итә беләбезме инде, белмибез. Қәрендәш-ырыу, аwыл-күрше җыйа, җыйыштыра, кем киләсе килә, килә бар да. Үзенең күңелендә бар кеше килә бар да. Күтәргән кешеләргә бистәрләр бирәләр. Җырлаган кешеләргә җаулыклар өләшәләр. Күмеп кайткач урын сакланыла, түшәк саклау була күмеп кайткан көнне.*

*– Тәберсен итүче куҗайын көрник* (рус. курник) *пешерә. Тәберсен көнне мичкә җагасын, коймакны тугайсын, күзикмәкне басасын, җәйәсен, күзикмәк белән коймак барыннан да алдан тәберсен ителә. Кырык күмәче дибез, аны җасыйсын бер кырыкны, иллене дигәндәй. Шуны өстәлгә җыйылгачын табак җасарга кушабыз ике әбигә. Менә монсы үлгән кешегә җан табагы, монсо уша табагы, монсо картлар табагы. Өч табак җасыйлар шул кигән табаклардан кажныйыннан, анда ничек саласы килә. Шуны җасап беткәчен, теге табакларны берәү җыйып тора бушаганын. Бер күзикмәкне салып, коймакны салып, бер күмәчне салып куйа да табакларга, теге табакка тәберсен итәбез. Җан табагыннан, уша табагыннан бич җөреп тәберсен итәбез дә берсен утыртабыз уша башына, берсен монда. Шунардан тәберсен итеп беттисә, өзгән нәстәне, сыныкларны чыгарып сала түбәгә кош-җәннек ашасын дип. Җан табагын бирә бирәсе кешегә. Картлар табагы тора, уша табагы балаларга. Аш утыртабыз, ашны эчәбез, бутка утыртабыз. Бутканы утырткачын, мына*

*мин аппарам бер бистәр, теге аппара бер җаулык, теге аппара бер таwар* (ситсы, материя)*, шуларны өләшәләр, кемгә атап бирәсе кигән кешегә бирә.*

*Бутка артыннан көрник, җә ит бирә. Менә сийа тәберсен. Кырык күмәч тәберсен сайын була. Ничә кешегә әйтә, күмәч бирә.*

**Хәйер коймагы пешерү** ‘испечь блины для подаяния’.

*– Мына атап саласын табага коймак.*

*Бер тәңре, бер кодай өчен*
*Җир атасы, җир анасы,*
*Койаш атасы, койаш анасы*
*Мына оло – карыга, атам-инәмә*

*дип ул коймакны бер әбигә бирәсен. «Минем үле – теремне искә ал», – дип әйтеп.*

### *Утырмалар һәм өмәләр*

**Утырмалар һәм өмәләр** ‘посиделки и помочи’.

*– Утырмага бару инде шулай була. Утырмага инде хәрендәшырыwына илтеп куйа. Атын җигә, кабасын утырта, чыгырын утырта. Икенче аwылга алып китә. «Мин сезгә орчок җерләргә кызны китердем». Кыз шунда җерли, сара саный-саный утырмада, тәрәшле җасый. Сүсе беткәчен кыз кайта. Кунак кызын йегетләр күзли. Каз кеwек утыра да утыра ул. «Мына кызыгызны китердем, җебен бетерде», – диләр.*

**Каз өмәсе** ‘коллективная помочь при ощипывании гусей’.

*– Җәннек суйганга каршы әйтеп чыгалар. Каз җолкошырга хәрендәш-ыру килә. Кайсы берсе җегермешәр каз суйа. Аны җыwып, идән сәкесен җыйыштырып, каз боткасы ашарга чакыра. Пар каз сала. Аның өресенә суган турыйлар. Ашагач-эчкәч чәйләр эчеп таралышабыз.*

*«Каз өмәсендә күзикмәк пешер, каз күп булыр», – диләр. Бер җыл да калганым җук, күзикмәк пешерәмен. Кажни өйгә кер, кажнийында күзикмәк. Мин нәнәүнең* (әнинең) *җоласын. томамын. Аш күрсәтәбез мал суйгачын, чакырасын үзенең хәрендәшыруwынны. Алар суйгач сине чакыралар.*

**Тула сугу** ‘коллективное валяние сукна’.

*– Элгәре тула сугарлар ыйы. Аны бер кеше суга да ничә киләп буйы була инде. Төнгелеккә өмә йасарлар ыйы. Ике кыз өмәгә әйтерләр ийе киҗеле күлмәкләр кийеп. Җыйылырлар ыйы өмәгә. Өмәгә– җыйылгачын инде сыуны кайнатып торалар. Чыбыкны үткәзеп йасаган ыстаны булыр ыйы. Басарлар ыйы туланы җырлый-җырлый:*

*Ай туласы, туласы*
*Туласы кайчан буласы.*
*Бу тулалары булмаса*
*Без шушында кунасы,*

*дирерләр ийе. Җегетләр-кызлар кара-каршы җырлый-җырлый тула басып беткәчен төнгелеккә таралырлар ыйы.*

**Сүс талку, киндер эшкәртү** ‘обработка конопли’.

*– Сүс талкырга өмә булыр ыйы. Сабан беткәндә киндер чәчәрләр ийе, ул киндер үсәр ийе. Аның басасы дип көзгә таба алырлар ыйы да җиргә болонлыккарак җәйеп куйарлар ыйы. Ул җатыр ыйы өч атна, берәр ай. Ә киндерен көз көне җолкоп алырлар ыйы да орлогын сугып, киндерен сыуга салырлар ыйы. Шуны сыwдан чыгарып алып кайтып кагайтырга дип бер каралтының түбәсенә куйарлар ыйы көнгә. Ул шунда торор ыйы. Аннан муча җага да мучага куйа, киптерә. Кипкәчен әннән әре икөч кешегә әйтәме, ничә кешегә әйтә. Шул сүсне талкырлар ыйы өмә итеп. Аны талкыгачын килегә салып төйәрләр ийе. Аны килегә салып төйөп, селкеп, җә мал өйөндә, җә өйдә тәрәшле җасарлар ыйы. Тәрәшле җасап кайсы берәүләр җегерләргә өмә итәрләр ийе. Аны җерләп сарырлар ыйы. Саргачын аннан килеп җаз көне көл белән кайнатырлар ыйы, җыwарлар ыйы, чырмарлар ыйы. Чырмап аны озатырлар ыйы сугарга. Суккачын киндер итәрләр ийе.*

*Җитен сүсеннән киҗеле түшәк тышлары, бөркәүләр* (җәймә) *сугарлар ыйы, җаулык башлары сугарлар ыйы. Чүбегеннән аркауга сугарлар ыйы киндер җебеннән аркауга озатырлар ыйы. Эшләп дәнне* (тәнне) *каплаган элгәре. Хәзер күлмәк тә теккән, ипей дә пешкән.*

*– Җитен чәчә, ул чәчкә ата, өлгерә. Аны йолка, тийи арбага, алып кайта. Җәйә аны ул җитенне. Ул җитә, сүсләнә. Ул сүсне кертәсен мунчага, киптерәсен, ул сүсне талкисын. Анын талкысы койола, сүс кала. Анын тәрәшлесе бар. Аны йерли ул сүсне. Кызын илтеп куйа бер зат-зәwеренә. Ул сара, йепне кайната. Кайнаткач аны ашлый, көрпә сыwына сала, йыwа, буйи, буйагач чырми, озата. Аны суга, тегергә кирәк кәзер.*

## Мифология

**Җорт иялəренә корбан** ‘жертвоприношение домовому’.

*– Мына әтәйнең нигезе бу. Җорт ийәләре бар. Шуларга җыл да бер каз суйа торган идем. Ике җылга бер суйа торган иттем аннары, «Рәнҗемәгез», – дип. Быйыл ике таwык, бер әтәч суйдым. Тәберсен узгырасын. Мыннан былай узгара алырмынмы, җукмы. Тәберсен көнне зиратка барырга җарамый, җә икенче, җә өченче көнне барасын.*

*– Җана өйгә чыккачын сыу куйасын, ипей куйасын базга угылга төшереп.*

*«Сез мийа тынгылык бирегез.*
*Шуны ашап тукланып, хушланып йатыгыз»,*

*дип куйасын. Өй ийәсе, өй атасына дип атап төшерәләр, өй котлаганнан сун.*

**Заключение.** В этой работе традиционная обрядовая терминология нагайбаков рассматривается в неразрывной связи с особенностями самого обряда и в контексте, в зафиксированной, а точнее в графически воспроизведенной речи носителей говора. В них отражается своеобразие и богатая колоритность народной речи. Иллюстративный материал является также толкованием к соответствующим терминам.

Нагайбаки – крещеные татары, в силу исторических причин территориально обособленные от основной массы татарского народа. Их говор и традиционная культура в основном не отличается от других крещеных татар, живущих на территории Заказанья

и Нижнего Прикамья. В обрядовой и культовой терминологии нагайбаков, как и у других кряшен, довольно большое место занимают названия русско-христианского происхождения, например: *май, май чабу* ‘празднование масленицы’, *катайса әйләнү* ‘катание на лошадях в дни масленицы’, *бәрмәнчек, бәрмәнчекәй* ‘верба, вербный праздник’, *оло көн* ‘Пасха, досл. великий день’, *труйсын, тручын* – ‘рус. троица, троицын день’, *раштау, раштуа* – ‘рус. Рождество’ и другие. В содержаниях этих обрядов сохранились элементы древней языческой культуры.

Семейные обряды и обычаи, как известно, относятся к наиболее консервативной части культуры, поэтому в их терминологии почти не отмечено русских заимствований, хотя в жизни нагайбаков довольно большое место занимают церковные обряды – венчание, крестины и т.д. Наряду с общетатарскими терминами как *җаучы, кода, кодагый, кыз агасы, кыз җиңгәсе, килен, кияү, бирнә, күчтәнәч, сыра* и др. употребляются обрядовые термины, характерные для кряшенских и др. обособленных групп (нукратских, пермских, касимовских, мишарских и др.): *кәбен, тау итү, акка салу, аклашу, аклашу җыены, кыйаматлык, аргыш* и др.

В религиозных верованиях особенно выделяется культ предков, посвященный памяти умерших. Отсюда идет появление большого количества языческих молений и соответствующей терминологии: *тәберсен, гүр тәберсене, табак җасау, җан табагы, уша табагы, аш бирү* и др.

# ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ
## (Халык иҗаты үрнәкләре)

*Ильмир Ямалтдинов*

Чиләбе җирлегендә яшәүче халкыбызның фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну ике йөз елдан артык элек башлана, дип әйтсәк һич тә ялгыш булмас.

Россия Фәннәр академиясе эшчәнлегенең аерылгысыз бер юнәлеше буларак, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү өчен экспедияләр оештырыла. Казан университеты галимнәренең хезмәтләрендә дә татар халкының тарихына, рухи мирасына һәм фольклорына караган кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре яисә башка чыганаклардан алынган материаллар бар[1]. Бераз соңрак Чиләбе төбәгендә яшәүче халкыбызның халык иҗатын өйрәнү буенча эш татар галимнәре һәм әдипләре тарафыннан дәвам итә.

1960 еллар уртасыннан башлап, Чиләбе татарларының сөйләшләрен өйрәнер өчен, телче-диалектологлар әлеге төбәккә берничә тапкыр экспедициягә чыгалар. Галимнәр Фәрит Йосыпов, Флера Баязитова һ.б.лар, тел материалы буларак, халык иҗаты үрнәкләрен туплыйлар.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Чиләбенең татарлар яшәгән районнарына иң беренче

[1] *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 35–36.

фольклор экспедициясе 1978 елның июль аенда оештырыла. Экспедиция эшендә институттан өч хезмәткәр катнаша: Рәшит Ягъфәров (җитәкче), Асыя Садыйкова, Камәрия Ямалетдинова. Фольклорчылар Коншак районының Коншак, Мөслим, Үзбәгәрәк, Усман, Караболак авылларында халык иҗаты үрнәкләрен бөртекләп җыялар.

1979 елның июнь аенда филология фәннәре кандидаты И. Надиров җитәкчелегендә тагын бер экспедиция оештырыла. Экспедиция эшендә алты фольклорчы катнаша. Алар ике төркемгә бүленеп эшлиләр. Беренче төркем галимнәре Илбарис Надиров, Ленар Җамалетдинов, Асия Садыйкова Троицк шәһәрендә булалар, Октябрь районы Тирәнкүл, Варна районы Варна (Мачи), Нагайбәк районы Кили (Кассель) авылларын өйрәнәләр.

Икенче төркем галимнәре Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Рәшит Ягъфәров, Сәлим Гыйләҗетдинов Чибәркүл районының Алтынташ, Болотово, Аджетар, Варлам, Попово, Бишкил, Филимоново авыл-



Фольклорчы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов информант Зәйнәп Вахитова белән. Чиләбе өлкәсе Чибәркүл районы Алтынташ авылы. 1979 ел

ларында тикшеренүләр уздыралар. Барлыгы 4 районның 10 татар авылында булалар.

Шулай итеп, 1978–1979 елларда Институт хезмәткәрләре табышмаклар, әкиятләр, мәзәкләр, риваятьләр һәм легендалар, лирик һәм кыска җырлар, бәетләр кебек халык иҗаты жанрларына караган, фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын җыеп алып кайталар. Алар Институтның архивында саклана[1]. Әлеге материалларның бер өлеше Институт әзерләгән унике томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасында (1975–1988) һәм әлеге җыелманың соңрак нәшер ителгән «Балалар фольклоры» китабында (1993) басылган яисә җыентыкларның искәрмәләрендә вариант буларак күрсәтелгән.

Һәм, ниһаять, 2016 елның июнь аенда, дүрт дистә елга якын вакыт узганнан соң, әлеге төбәккә берничә өлкәгә кагылышлы тикшеренүләрне максат итеп куйган комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Чиләбе өлкәсенең төньягыннан алып көньягына таба татарлар яши торган шәһәрдә һәм барлыгы 4 районның 14 авылында *(Нязепетровск районы Нәзе шәһәренең үзендә һәм Арыслан, Әптерәк, Йосып (Юсупово), Постниково, Чулпан (Горшенино); Чибәркүл районы Попово, Варламово, Кундрау, Аджатар, Бишкил; Уй районы Әмин; Нагайбәк районы Париж, Кили (Кассель), Сарашлы (Остроленко) авылларында)* булып, шәхсән минем тарафтан атна-ун көн эчендә ике йөз берәмлеккә якын авыз иҗаты үрнәкләре язып алынды.

Чиләбе өлкәсендә яшәүче татарлар арасында, сан ягыннан карaганда, иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны аерып чыгарырга була. Йөз илледән артык җыр язып алынды. Аларның күбесе кыска җырлар һәм такмаклар. Алар арасында лирик, йола һәм уен-бию, бишек җырлары да бар. Нязепетровск районы Арыслан авылында Мөхәррәмова Роза Низам кызыннан (1960 елда туган) көе белән уен-бию җыры язып алынды:

---

[1] Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Колл. 90–93.

Биек тауга менеп булмый (гына ла),
Бик менәсе килсә дә (шул гына ла).

*Кушымта:*
Агыйделнең кызыл яры (гына ла)
Ярый микән чүлмәккә (шул гына ла),
Бер аерылгач күреп булмый (гына ла),
Бик күрәсе килсә дә (шул гына ла).

Берсе алтын, берсе көмеш (гына ла),
Балдагым бар, бүләккә (шул гына ла).

*Кушымта:*
Агыйделнең кызыл яры (гына ла)
Ярый микән чүлмәккә (шул гына ла),
Агыйделгә төшә яздым (гына ла),
Тотмадың беләгемнән (шул гына ла).

Тамыр җәйгән гөлләр кебек (гына ла),
Китмисең йөрәгемнән (шул гына ла).

*Кушымта:*
Агыйделнең кызыл яры (гына ла)
Ярый микән чүлмәккә (шул гына ла),
Агыйделгә төшә яздым (гына ла),
Тотмадың беләгемнән (шул гына ла).

Арыслан авылында элек күпер булмаган, шуңа күрә көймә белән чыкканнар. Әлеге җырны элек-электән Уфа елгасы буенда көймә көткәндә бии-бии җырлаганнар. Соңрак клубта җыелып шул җырны башкарганнар.

Озын көйләр һәрбер татар авылында да очрый, ләкин Чибәркүл һәм Нагайбәк районнарында яшәүче керәшен татарларында алар бигрәк тә күп сакланган.

Автор җырлары да халык тарафыннан бик яратылып башкарыла.

Ияләр, җеннәр турындагы мифологик сөйләкләр һәм хикәятләр халык арасында борынгыдан сөйләнеп килгән, халык аларга ышанган, буыннан-буынга сөйләп тапшырган. Бигрәк тә, татар халкында киң таралганнары – атның ялын үрә торган абзар иясе, төрле кыяфәткә (песи, эт, бабай, матур кыз һ.б.) керә ала торган җен-пәри-шайтан, яратмаганга күрә күзенә күренүче яки табак-савыт шалтыратучы яисә сыер бозаулаганда тәрәзә шакып уятучы өй иясеннән башлап, Чиләбе төбәгендә генә була торган, аерым алганда, Арыслан авылында төннә агачтан да биек булып күренә торган урман иясе, чыр-чор көлүче кызларны куып тотарга тырышканда, гел бер аралык сакланып барып, капкасыз читәнгә кереп китүче шайтаннар, кызыл чапан кигән, пеләш башлы ике метрлы бабай кыяфәтендәге өй иясе һәм асфальт эченнән бозау хәтле эт булып чыгып, бәрелгәннән соң кагылган зәхмәт, Йосып авылы тирәсендә кеше адаша торган Түбәк дигән җир, почмакта озын һәм ап-ак булып торган Мәгүснең җене, Чулпан авылында Кәримә карчыкка ияләшкән җен һәм Нестеровта иренә үлгән улының кайтып йөрүен әйткән өчен җен тарафыннан үтерелгән хатын, Бишкил авылында салкын мунчада бала юындырып утыручы бер әби һәм төнге мунчага бабай кыяфәтендә кереп: «Мин юынып бетергәч, сезгә барырбыз», дип әйтүче җен һәм мунча хуҗалары, Кили авылында җегерләгән җепләрне сүтеп, стенадагы сәгатьне туктатып, бикле келәткә кереп-чыгып йөргән, Максим булып ияләшкән пәри турындагылар бар.

Тарихи һәм топонимик риваятьләр язып алынды, авыл тарихларына (Әптерәк, Чулпан (Горшенино), Әмин, Сарашлы, Париж һ.б.) бәйлеләре – шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үзләренең үткәннәренә битараф булмауларының ачык мисалы. Халык сөйләве буенча, Башкортстанның Бәләбәй, Бакалы районнарынннан керәшен татарларын казак итеп, хәзерге Чибәркүл, Нагайбәк районы җирлекләренә күчереп утырткач, башта аларның авылларына саннар бирелгән булган. Соңрак, казак гаскәрләре Европа шәһәрләреннән җиңү яулап кайткач, авылларына Париж, Остроленко, Кассель һ.б. шундый исемнәр кушканнар. Шулай да, алар авылларын элек яшәгән авыллары

исемнәре белән атап йөрткәннәр. Һәм әлеге атамалар сакланып, буыннан буынга күчеп килгән. Алар бүген дә Кассельны – Кили, Остроленконы – Сарашлы дип йөртәләр. 2016 елгы экспедициядә Парижның халык телендәге татарча атамасы Яшь авыл икәне ачыкланды.

Чиләбе төбәгендә, нигездә, барлык татар халкы өчен хас уеннарның тасвирланмасы сакланган. Түгәрәк уеннан башлап, аулак өйләрдә, уен җыюларда[1] традицион уйналып килгән «Наза», «Йөзек салыш», «Йолдыз санашлар» да бар. Кич утыруларда, соңрак клубларда «Күбәләк», «Советский», «Общий» уеннар һ.б., ә балалар тарафыннан «Чүрәкә», «Күкәй» уеннары аеруча яратып башкарылганнар.

Чиләбе өлкәсе Нязепетровск районы Арыслан авылы өчен генә хас, анда гына борын-борыннан, нигездә, хатын-кызлар тарафыннан уйналган «Бот көрәштерү» уены язып алынды. Арыслан авылында ирләр белән хатыннар, кырга чыгып та, силос базында да итекләренең табанын төшергәнче бот көрәштергәннәр. Авылның хатын-кызлары Сабантуй батырлары белән дә әлеге уенны уйнаганнар һәм мәйдан батырларын җиңгәннәр. Әлеге уенда һәр көрәшченең башы көндәшенең аяклары ягында, икесе дә аркаларына яталар. Аннан аякларын өскә күтәреп берберсенең ботларын эләктерәләр дә, көндәшен әйләндереп салырга тиеш булалар. Кем көндәшен боты белән әйләндереп сала – шул җиңүче була.

Әкиятләргә килгәндә, З. Зәйнетдинов 1947 елда Коншак районы Караболак авылында Г. Хәмитовтан «Өч сорау», З. Сабитовтан «Җүләр» гыйбрәтле һәм сатирик, 1952 елда З. Даутовтан «Аучы», «Җиде ага белән бер сеңел», Б. Зәйнетдиновадан «Үги ана» әкиятләрен язып алып җибәрә. «Татар халык иҗаты»ның әкият томнарында «Өч килен» әкиятенең варианты буларак – «Өч сорау», «Тугыз Тукылдык, бер Мимылдык»ның варианты буларак – «Җүләр», «Мөлтәл»нең варианты буларак – «Җиде ага белән бер

[1] Нязепетровск районының Арыслан авылында аулак өйне «уен җыю» дип атаганнар.

сеңел», «Үги кыз»ның варианты буларак «Үги ана» әкиятләре күрсәтелә[1]. Әлеге әкиятләр Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана[2].

Институтның 1978–1979 еллардагы фольклор экспедицияләре вакытында Коншак районы Үзбәгәрәк авылында Ш. Нигъмәтуллиннан «Алдар» сатирик әкиятен К. Җамалетдинова, Октябрь районы Тирәнкүл авылында Р. Мозаффаровадан «Биш батыр үтергән Якуб», «Тугыз Тукылдык, бер Мимылдык», М. Гаффаровтан «Көтүче» сатирик әкиятләрен Л. Җамалетдинов язып ала. «Татар халык иҗаты»ның әкият китапларында «Алдар һәм мулла» әкиятенең варианты буларак – «Алдар», «Диюләрне җиңгән»нең варианты буларак – «Биш батыр үтергән Якуб», «Хәйләсез дөнья файдасыз»ның варианты буларак «Көтүче» әкиятләре күрсәтелә[3].

2016 елгы экспедициядә Нязепетровск районы Чулпан (Горшинино) авылында Мугафина Фәгыйлә Хәбиб кызыннан (1938 елгы), Чибәркүл районы Попово авылында Сошникова Валентина Ивановнадан (1949 елгы), Нагайбәк районы Париж авылында Иванова Вера Лазаревнадан (1935 елгы) күләмнәре ягыннан зур булмаган өч әкият һәм Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) «Камыр батыр» әкиятенең кыскача эчтәлеге язып алынды. Чибәркүл районы Попово һәм Нагайбәк районы Париж авылларында әкиятне м ә с ә л ә дип атыйлар.

Балалар фольклорының «Багу поэзиясе» әсәрләреннән берничә бишек җыры, юаткыч, мавыктыргыч, сөйләм такмагы,

---

[1] Татар халык иҗаты. Тылсымлы әкиятләр. Икенче китап / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 428, 433–434; Татар халык иҗаты. Көнкүреш әкиятләр. Өченче китап / томны төзүче, искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 519, 552–553.

[2] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 45 колл., 1 папка, 2, 3 сакл. бер.

[3] Татар халык иҗаты. Көнкүреш әкиятләр. Өченче китап. Б. 544, 552–553, 558–560, 563–564.

шулай ук «Күңел ачу» һәм «Уен фольклоры» үрнәкләре язып алынды.

Чиләбе өлкәсендә традицион рәвештә «Әлли бәлли бәү итә» бишек җырлары киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек.

Мөнәҗәтләр белән бәетләр сирәк очрады. Татар халкында киң таралган «Бердер Илаһем бәнем», «Укы намаз иртән торып», «Аллаһ, Аллаһ дисәң иде» мөнәҗәтләре язып алынды. Институтның 1978 елгы фольклор экспедициясе вакытында Коншак районы Коншак һәм Мөслим авылларында К. Җамалетдинова, А. Садыйкова, Р. Ягъфәров тарафыннан «Торып сахраларга чыксам», «Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран», «Якты дөньяны күреп туймадым», «Дөньядыр бу» мөнәҗәтләре язып алынган. Коншак районы Мөслим авылында Гайшә Сафинадан (1907 елгы) «Торып сахраларга чыксам» мөнәҗәте «Татар халык иҗаты»-ның «Бәетләр» томында басылып чыга һәм төп чыганак, калган мөнәҗәтләр вариант буларак күрсәтелә[1]. Әлеге мөнәҗәт Г. Кандалыйның «Бу хәсрәтләр бетәр микән?» шигыренең халыклашкан варианты булып санала.

Халыкта киң таралган «Сак-сок» бәетенең өзекләре һәм «Мөршидә бәете» язып алынды. Институтның 1978 елгы фольклор экспедициясе вакытында Коншак районы Коншак һәм Мөслим авылларында К. Җамалетдинова, А. Садыйкова, Р. Ягъфәров тарафыннан язып алынган «Сак-сок» бәетләре «Татар халык иҗаты»ның «Бәетләр» томында вариант буларак күрсәтелә[2]. Алар Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. 2016 елгы экспедиция материалларыннан чыгып, Чиләбе өлкәсендә бәет чыгару традициясе юкка чыккан, дип әйтергә була.

Табышмаклар һәм паремияләр үрнәкләре дә өлкән буын вәкилләренең күңелендә генә саклана. Чиләбе өлкәсендә егермегә

---

[1] Татар халык иҗаты. Бәетләр / томны төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 264, 340, 344–346.

[2] Татар халык иҗаты. Бәетләр. Б. 332.

якын табышмак язып алынды. Нагайбәк районы Париж авылында Алексеева Анна Александровна (1941 елгы) гомере буена мәкаль-әйтемнәрне җыйган, күбесен ул иренең әбисе Максимова Просковья Кузьминичнадан өйрәнгән. 2007 елда Анна әбинең җомаклары брошюра итеп эшләнгән, аның фотокүчермәсе алынды. Анда өч йөзгә якын татар паремияләре тупланган.

Йола фольклорына килгәндә, йолалар, гореф-гадәтләр турындагы мәгълуматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән мөмкин кадәр бер күренеш буларак язып алырга тырыштык.

Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) куркудан кургаш белән «Кот (куркулык) кою» яисә «Кот өндәү», саңгырау кешегә «Татран кычкыру», сыерның җилене шешсә – «Кайрак имләү», аяк сызласа – «Җирдән салдыру», яңгыр яумаса – «Явын теләү», «Чүп боткасы», Сәмсетдинова Гүзәлия Мозаффар кызыннан (1967 елгы) «Армиягә озату», Мөхәррәмова Роза Низам кызыннан (1960 елгы) кыз елату җырлары белән «Чеңләтү» йоласы, Чулпан (Горшинино) авылында Мугафина Фәгыйлә Хәбиб кызыннан күз тисә «Кара күздән, зәңгәр күздән...», Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) «Туй» йоласы комплексында «Колак борыштан бәреш», Нагайбәк районы Париж авылында Иванова Вера Лазаревнадан (1935 елгы) «Аш бирү», «Нардуган», искечә Яңа елга каршы «Йөзек салу», «Курку кою», «Кан теле», Сарашлы (Остроленко) авылында Артемьева Зоя Евгеньевна (1940 елгы), Байкина Евдокия Ильиничнадан (1941 елгы) солдатка киткәндә ясый торган ырымнар, «Йөзек салу» кебек мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган сүз үрнәкләре, каргышлар, ырымнар, келәүләр, имләүләр, йолалар язып алынды.

Чиләбе өлкәсенең Нязепетровск, Чибәркүл, Уй, Нагайбәк районнарында яшәүче милләттәшләребездән язып алынган, халкыбызның буыннан буынга, телдән телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә, тематик бүлекчәләргә урнаштырып) тәкъдим итәбез.

## Мифологик хикәятләр

*(ияләр, җеннәр турында)*

### *Пәри*

Ташландык өйдә була. Иске мунсаларда может булырга. Каждый кешегә күренми. Пәри булып күренми ул. То песи булып күренә ул, то көсек булып, бабай кеше булып, менә шундый төрле сурәттә күренә ул.

Күргәннәр инде элеккеләр.

Йоклап яткан ердә бабай булып керә. Кешенең өенә. Безнең Рәшидә исемле хатынга бабай барып кергән:

– Кызым, намаз укыйсыңмы? – тип сорашкан. Яшь кешегә кергән ул. Шуннан сыгып киткән.

* * *

Өйнең иясе бар дип әйтәләр дә инде. Домовой ул, кемне өй хуҗасын яратмай, аңа күзенә күренә. То кеше булып күренә, то берәр ердә шалтрай ул. Хозяинны яраткан кешегә тыныч кына йөри.

### *Урман иясе*

Ике хатын кайтып барган, каяндыр урманнан. Урманның иясе була икән. Урман иясе агачтан да биек булып күренә. Какбудто кеше килә. 7 төн уртасында кеше йөремәй дә. Ул агачтан да биек кеше юк та инде. Тавышлары ишетелмәй ди. Куркканнар да киткәннәр.

* * *

Ураза вакытында күренми. Каенлыкка (зиратка) киткәннәр. Кешегә кереп йөргәннәр шайтаннар. Төрле кыяфәткә керә, то матур гына кыз булып, сары чәчле кыз булып, күлмәге гел ертык булган шайтаннарның. Рәшидәгә бабай булып керде, ди. Хатын кешегә ир булып, ир кешегә хатын булып керә.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында*
*Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

### *Шайтан*

Төнен туйда йөредек-йөредек тә иптәшемнең кардәше белән. Төнге сәгать икедә. Көне матур көн иде. Авылның зиратка таба Фатихаларга кайтып барабыз. Китеп бара безнең алда ике кыз. Бер 20–15 метр алда. Шушындый гына матур гына күлмәк кигәннәр, 2 кыз китеп бара. Чыр-чыр көләләр. Әйдә тотаек боларны. Киттек, йөгерәбез, но шул ук ара, тоталмайбыз, якыная алмыйбыз. Килдек, килдек тә забор инде кагылган, читән, шул читән эчендә вроде бы капка кебек ике кыз матур гына әйбәт кенә кереп китteләр. Ә кызлар клубтан кайта икән. Карыйк әле, анда вроде капка юк. Тагы киттек забордан капканы эзләп, анда бернинди капка юк, кызлар кергән җир казак белән кагылган. Кире кайтып киттек шәбрәк кенә. Шайтанның артыннан йөрдек шулай.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Мингаева Сәкинә Батырбай кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Өй иясе*

Иртән 5 тә атлап чыгып китте 2 метрлы бабай. Шуннан сеңлем килде ерактан. Йокларга ятты и миңа сөйли: «Миңа килде дә, бер бабай карап тора күземне ачтым, кызыл ни таккан чапан инде и лысый, – ти инде, – пеләш башлы». Мин дә шуп-шул итеп күрдем, ул да шулай күргән.

Күземне ачып кечкә, күземне йомам килә, тагы китә. Тордым да «синнән Аллаһ Тәгалә көчлерәк» дидем дә дога укыдым. Юыштым да, тәхәрәт алдым да. И шуннан китте.

### *Зәхмәт*

Әнием минеке төнен дискотека проводить итеп төнге 3 тә кайтып барган. Анда, урамда шундый спуск, бу як чите урыс кабере, болай менгәч татарларның кабере. Ул менә шулай төшкән. Ике якта зират. Асфальт эченнән бозау хәтле эт килеп чыкты, ди, кап-кара, шул миңа бәрелде дә, ди, и юк булды, ди, күз алдымда. Атлай алмыйм, ди, 4 аякланып көчкә. Аннан уволиться итте эшеннән. Шул хәтле куркыныч, зәхмәт дип әйтәемме. Шул эшне ташлады ул.

* * *

Безнең иске клубта да бар, ди, шайтаннар. Бала-чагалар күрә. Минем внук күргән. Шундый ике генә көчек кып-кызыл үзләре, ди, бәләкәй генә, ди.

* * *

Бер түгел. Иң көчле ул пәри, әллә нинди ут булып күренә, ди, ул. Шайтан я көчек, я песи, я кеше булып күренә.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Сәмсетдинова Гүзәлия Мозаффар кызыннан (1967 елгы) язып алынды*

Элек шайтан дип сөйлиләрие. Шайтан кагылган, диләр. Үзеннән үзе адаштыра да куя. Йөрисең-йөрисең дә җиләктә. Түбәктә. Шунда адашасын. Елга буе, күпер, шул тирә.

*Нязепетровск районы Йосып авылында Шакиров Илсур Хәйри улыннан (1948 елгы) язып алынды*

### *Абзар иясе*

Әйбәт атныкын уң якка сала, начар атныкын сул якка сала үреп, ди, ялын.

Абзар иясе яратмаса ат тирли.

Бер атны абзар иясе яратмады. Гривенькадан алган идек. Аксады ул. Бозауга муенын, сыерның мөгезенә бәйлисең күз тимәсен өчен.

### *Аҗдаһа*

Давыл чыкса аждаһа. Болгап-болгап китә ул. Аждаһа дип әйтәләр инде. Каф тавы артыннан чыга торгандыр инде.

*Нязепетровск районы Йосып авылында Мөбарәкшина Асия Шәйхетдин кызыннан (1938 елгы) язып алынды*

### *Җенне урын*

Ток суккан җир бар бит. Ат белән элек ток, ашлык суктырганнар. Әнә шул җирдә *җенне* дип әйткәннәрен беләм.

### *Зәхмәт*

Аннан бер районга бардым мин. Заһит бальниска эләкте.

Зәхмәт диләр. Өчтән соң гына киттем районга. Анда дрезина тора. Утырдым да киттем. Төнге 11 дә бу якка кайта. Инәйләргә кермәдем. Җәяү олы юлдан кайтып киттем. Шул токка гына җиткәнниием кемдер минем арттан мышнаган кебек булды. Мин артка карамадым инде.

Әнә шул урында инәйне парализовать итте. Авызы кыйшаеп калды. Җылы гына җил искән булган. Мин үзем яшь чагында күрдем. Хәзер безнең авылда, Башкирияда, без үсеп киләбез. Кызлар белән. Хәзер шуны сүлим.

### *Мәгүснең җенен күрдек*

Атасы сугышта үлеп калды, инәсе гел көтте. Бу кояш баеганда киенеп куя матур иттереп, бии, кубызында уйный. Әтиең килә, әтиең килә, ди. Кояш баеса, тәрәзә тишегеннән керә икән. Атасы булып җен. Бу көннән-көн саргая. Сизеп калдылар да моны, өшкерергә кирәк, диделәр. Хәзер бу китте күрше авылга. Апасы алып китте моны. Алар урманда торалар иде, якын гына авылдан.

Дегет яндыралар иде. Ирләр юк. Без бардык уйнарга. Уйнадык, уйнадык та. Кызлар: Мәгәфирә, Рәшидә әйтә:

– Кун да кун. Кунызыз да кунызыз, апам белән. Без кунарга булдык. Хәзер идәнгә урын җәйде инде. Ятырга аякны гына салган идек. Озын, ап-ак почмакта тора. Шуннан мин апага төрттем, апа миңа, карадык та, тиз генә киендек тә, юк кунмыйбыз диеп кайтып киттек.

Инәсе китте өшкертелергә, ә җен монда калган.

Әле инәйләр йокламаган иде. Караңгы төшмәгән ие бик. Инәйгә кайтып, әниләре Мәгүс исемле иде, Мәгүснең җенен күрдек дип кайттык. Ул җенне өшкерде әбиләр. Догалар белән өшкереп терелде, карчык бик озак яшәде. Килеп менә монда – Котовода үлде.

### *Җен ияләшкән*

Кәримә карчыкка җен ияләшкән иде. Кызы белә торды ул. Карчыкның ире юк иде. Хәзер кояш баеса, теге карчык матурлана, китә икән.

– Инәй, ния син алай матурланасың?

– Ния, әтиең килә бит, әтиең килә.

Әтисе сугышта үлгән. Бу карчыкның кодагыйсы укымышлы ие. Шекалныкы ие. Постниково дигән авыл бар, үткәнсездер шуннан ие. Хлимзада карчык, шул өшкерде.

### *Җен үтергән*

Нестеровта ире белән хатынның малайлары үлгән. Инәсе бик сагынган. Бу чыгып китә икән дә, озак йөри икән. Карты әйтә икән:

– Ния син тышка чыгып озак йөрисең?

Әйттергән моны.

– Минем бит малаем кайтып йөри, малаем белән күрешәм.

Икенче көнгә теге җен үтергән хатынны.

Әйтергә ярамый, әйтсәң үтерә икән.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында*
*Мугафина Фәгыйлә Хәбиб кызыннан (1938 елгы) язып алынды*

### *Җен куркытып йөрмә*

Бәләкәй генә без. Әти кайтты пакустан. Каты яңгыр килә. Без тележка астына кереп кукла уйныйбыз. Кукла юк инде. Бүрәнәгә яулык ябындырып. Инәй чыкты да:

– Нишләп утырасыз монда? Барың, өйгә керегез!

Мин тиз генә мунчага кердем. Мунчага керсәм, бер хатын утыра. Бала юындырып. Кендегендә йөн. Мин тиз генә пүләнне ташладым да, инәйгә.

– Инәй, – мин әйтәм, – салкын мунчада бер әби утыра бала юындырып, чәче кап-кара.

– Бар, кереп кит тизрәк, җеннәр куркытып йөрмә, – диде.

Инәй әйтә шайтаннар атка утырып кайталар, ди. Ат тирләп кайткач, ди. Сездән алда кереп юынган ул, ди. Кояш баеп килә иде. Көтү кайткан иде.

Ак әби бар иде безнең. Кендек әби булып йөри иде, бәбәйләр туса. Шул:

– Ния, кояш баегач кем мунчага баланы куа, диде.

– Мин кумадым, өйгә керттем аларны, алар мунчага кереп киткәннәр.

* * *

Безнең эти сүлидерие. Тоже соң гына мунчага барган. Общий мунчае. Авылда. Әти:

– Юынып, чабынып ятам, бер бабай керде.

– Миңа су бир, мине давай чап әле, – дигән.

Әтием чапкан, сизгән.

– Ярар, син кайтасың инде, юынып бетердең, – дигән этигә. Мин җуынып бетергәч, сезгә барырбыз, – дигән.

Әти кайсы киемен кигән, кайсысы – юк, кайтып керде. Тотындылар тәрәзәләр ябырга, ишекне «Бисмилләһи-р рахмани р-рахим», – дип яптык. Бер уяндык төннә, эти белә әни утыра, бер кем килмәде.

Бу яхшы кеше дигән. Әтием юындырган аны, чапкан, сулар салып биргән.

Мунчага 3 керергә була, 4 нчегә керергә ярамый. 3 пар керде, дүртенчегә барырга ярамый. Анда мунча хуҗалары юына уже.

* * *

Инәй әйтә, әтәгез китте, ди, печән урларга. Сәгать 12 дә ул китте, ди. Көтеп утырам, ди. Ул китү белән бер бәләкәй генә хатын тәрәзәгә менгән, ди, әйтә, ди:

– Күлмәгеңне кем текте?

Мин сүгенеп:

– Шул текте дип әйттем, ди. Карыйм бәләкәй генә әби юк, ди, форточканың тәрәзәсен ачмаган, карыйм, ди, бер кеше дә юк, ди. Хәзер әтәң кайтты, ди. Шулай-шулай дип әйтәем, ди: – Ишегеңне ачмадыңмы, дип әйтте, ди.

– Юк, ачмадым, дип әйтте, ди. И кар явып торадырие әз генә, чыгып карыйм әле, кем булды икән знакомый хатынга охшаган

иде дип. Карасам, ди, кеше эзе түгел, песи эзе булды, ди. Менә шайтаннар элгәре йөрегәннәр.

Шул шайтан песи булып килгән.

*Чибәркүл районы Бишкил авылында Нигъмәтуллина Мәүлединә Фәйзрахман кызыннан (1944 елгы) язып алынды*

### Шайтан

Анда, балалар, бара күрмәгез. Анда шундый шайтан. Мин күргән шайтан 2 багам биеклеге ие, өстемнән атлап үтеп китте, егылып ятып калдым. Шуннан юк булды, дип ебәрә. Шундый историяләр сөйли. Күзләр акая без – малайларның, без куркабыз, анда бармайбыз.

### Бичура

Менә, ди, урыс авылында Бичура күргәннәр. Безнең авылга да килеп чыккан шикелле, кем берәү күргән дип сөйләйләр ие. Бичурасы үлгән мәет инде. Авыл буйлап йөри теге. Шул Бичурага эләгеп бармагыз, үпкәләре йөрәкләре күренеп тора. Алла сакласын, малайлар!

Менә каскыннар йөреп утыра, төрмәдән касканнар. Ананда тотып үтергәннәр, монанда тотып үтергәннәр, тотып куркыталар. Тәртипкә утыртырлар инде безне, куркытып, төннә йөремәскә.

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

### Пәри ияләнү

Безнең белән йөри торган бер хатынның шундый нәмәсе бар ие, дип сүлиләр. Пәри кияүләр, диләр. Төннә сәгатьне туктатып куя. Берәү ияләнгән, диләр. Капканы бикләп керәм, иртә белә торуга капка ачыла. Мәксим булып пәриләнгән аңа. Җерләгән җепләремне сүтеп бетә, ди. Стенада сәгать йөрми торганые. Идәнне буяган, келәткә кереп җаткан, келәтне бикләгән ныгытып

тырып и келәтне ачып чыгып китеп җөргән. Үзе күренмәй ул. Пәри ияләнү, диләр. Алла сакласын.

*Нагайбәк районы Кили (Кассель) авылында*
*Миняева Зоя Прохоровна (1935 елгы),*
*Букачева Роза Прохоровна (1938 елгы),*
*Хөснетдинова Екатерина Кирилловна (1939 елгы),*
*Тихонова Зоя Георгиевнадан (1940 елгы)*
*язып алынды*

## Ышанулар, ырымнар, йолалар, гореф-гадәтләр

### *Кот кою*

Минем картинәем курккан кешегә кургаш, шуны кот коябыз (кот коялар) дип сөйләде. Эссе суга төшерәләр. Төрле сурәттә булып төшә ул кургаш, коты коелса ул түм-түгәрәк кенә, йөрәк кебегрәк кенә төшә. Аны тагып куялар.

Бу баланың коты очкан – кот коям,
Бу баланың коты очкан – кот коям.
Алла ризалыгына бу балага сикәт *(сихәт)* бир!
Ләззәт бир, аң бир!

* * *

Шунан саңграу кешегә кычкыра торган иделәр:

### *«Татран кычкыру»*

Татран, татран, тарттырмамдыр мин сиңа,
Сары ала аюым бар, каптырмамдыр мин сиңа.
Татран күз, татран күз (дип колакка өрәләр)
Иләкченең ике кызы, икесе дә ефәк кыз,
Аюдагы күчте кыз, үгездәге шашты кыз,
Татран күз, татран күз (дип тагы татранны кычкыра).

Шуннан өшкерә өф-өф итеп. Аннан колагы әйбәтләнә.

* * *

*Сыерның җилене шешсә:*

– Ни имләйсең?
– Кайрак чаккан, кайрак имләем.
– Ай кайт, көн кайт,
Яман гаста (*хаста*) син дә кайт!
– Ни имләйсең?
– Кайрак чыккан, кайрак имләем.
Юкә югычны төртә:
– Янгыс кебек йомшартам,
Югыч кебек тазартам.

* * *

*Аяк сызласа:*

***«Җирдән салдыру»***

Таң суын алалар. Аны өшкерәләр. Шул таң су белән аякны юалар. Ике юл арасына ташлайлар.

Яман җиргә баскансың, диләр. Йә мәет суына баскансың, диләр.

Таң суын таң атмас борын елгадан барып ал. Таң суын алганда беркем белән дә сүләшмәскә кирәк.

Җирдән салдырганда им өчен дип алалар.

Мәетне дә таң суы белән юалар. Таң суын укып кына алалар аны. Аны муллалар ала.

Менә мәет юганда тоже шулай ике бидрә белән бара бер кеше. Аның өстен ак яулык белән генә яба, беркем белән дә сөйләшми. Елыталар да шуның белән мәет юалар. Кыш көне дә шулай. Кыш көне таң суын колонка, я коедан алалар.

* * *

***Карга боткасы*** үткәрә. Быел үткәрмәгәнбез. Ботка пешерәбез. Алып чыгабыз үзебезгә ризык. Балаларга кәнфитләр, уенчыклар. Уйныйлар төрле уен. Ботканы пешерәбез, сәй эсәбез. Калган

боткаларны агач төбенә салабыз. Кайберебез сөт аббара, кайберебез ярма.

### *Явын теләү*

Элек явын теләй идек. Өфө буена баралар. Явын була икән, безгә аяз кәрәк. Шуннан суялар ак сарык. Без бала чактан ук кашык тотабыз, тәлинкә тотабыз, йөгерәбез ашарга. Әбиләр намаз укый, теләнәләр. Явын кәрәк икән, кара сарык суялар. Шуннан су сибешештереп уйныйбыз. Әбиләр намаз укый, елап-елап Алладан сорайлар.

Явын теләүчеләр:
Явыным яу, явыным яу!
Сырлы таяк бирермен дә
Сырлы күкәй бирермен, – дип теләйбез.

* * *

Явын кирәкмәсә:
Явыным яума, явыным яума! – дип теләйбез.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Армиягә озату*

Безнең авылда армияга киткәндә туктап гел чәчне алганнар бер елгада. Курәшәй елгасында тап-такыр итеп чәч алу булган. Ул чәчләрне әнисе алып кайткан. Озатып барып, шунда чәчен алып, шуннан киткәннәр. Гореф-гадәт шундый булган. *Курәшәй елгасы* күрешүне аңлаткан инде.

Сандыкка салып куялар, әйләнеп кайтсын, дип, ризык йөретә (ипи тешләтеп).

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Сәмсетдинова Гүзәлия Мозаффар кызыннан (1967 елгы) язып алынды*

### *Туй йоласы*

Элек кыз белән егет бер-берсен яратышып йөрегәннәр, но аларны бер-берсенә бирмәгәннәр. Егеттән яучы килгән кызга.

Егетне мактаган инде. И хәзер кызныкылар күнгән, кыздан сорау да юк. Әллә бара, әллә юк ул егеткә. Шуннан хәзер җыелышканнар егетнең әниләре, яучы әби киңәшләшкәннәр кайчанга кызны кушарга, кайчанга ничегерәк. Шуннан кызны бер өйгә бикләп куйганнар, чтоб белмәсен, күрмәсен. Аны эшләгәннәр чәршәмбе көн, җырлаганнар инде анда. Җырларын мин белмим. Шунысын беләм, олы җиңгә анда командир булып йөргән инде. Ул әйткән:

– Менә бүген чәршәмбе – чаршау кора торган кич, – дип.

Шуннан яшь җиңгәйләр, иптәш кызлары чаршау корганнар караватка, шуннан инде икенче көненә.

Атнакичтә кияү килә торган кич значит.

Кияүне олы җиңгә команда бирә:

– Әйдәң, җиңгәчәләр, кияүне китерегез.

Бүген кияү белә кызны кушабыз. Биклибез өйгә. Алар кияүне китергәннәр тастымал белән биленнән бәйләп. Ике еңгә ике яктан тотып китергәннәр аны. Качмасын дип.

Олы җиңгә командовать итә:

– Чәй кайнатыгыз, коймак пешерегез, хәзер кияү коймагы белән чәйләп алабыз.

Утырып чәйләп алганнар, кызны чыгармыйлар. Шуннан чәйләп беткәч, алай-болай иткәч, кияүне кертеп бикләгәннәр кыз янына, тыштан ишекне бикләгәннәр йозак белән, чыгып качмасыннар дип. Тәрәзәдән караулап торганнар җиңгәйләр. Олы җиңгәй әйтә:

– Әйдәгез әле, мунча ягыгыз, иртәнгә мунча әзер булсын. Җиңгәйләр йөгереп су ташыйлар анда, утын кертәләр, ягалар, әйтә инде олы җиңгә:

– Әгәр дә кыз булса, кызлыгын югалтмаган булса, кияү тастымалга акча бәйләргә тиеш, и нык итеп бәйләргә тиеш, чишәлмәслек итеп. Кызлыгын югалткан булса, буш кына бәйләр. Шуннан белербез кызлыгын, дигән. Кыз булса, никах укытканнар. Кыз булмаса – алмый егет. Тикшереп ала. (Гыйбрәтле, дин кергәнче үк булган йолалар булып чыга.)

Кыз керми, качарга маташа, аны ике яктан еңгәләр тотып аппарып кертәләр. Егет инде үзе барып керә.

Элек бездә кара мунча булган.

Мин кияү йөрттем. Иремнең сеңлесенә шулай эшләдек без. 32 еллар элек.

Су куйганнар, квас куйганнар. Ипине куырып.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Микаилова Рәисә Мәгъсүм кызыннан (1952елгы) язып алынды*

### *Чеңләтү йоласы*

Бисмилләһи-ррахманир-рахим.
Әүвәлге иман башы имеш,
Әтекәйдән аерылу
Әҗәлләрдән авыр эш имеш.

Әнекәем, аш пешерсәң,
Аз пешермә, күп пешер,
Балаларың янына килсә,
Мине дә исеңә төшер.

Әнекәем өендә
Киез шыртларга бастым мин.
Әтекәемнән аерылгач,
Тимер шыртларга бастым мин.

Кил, әтекәем, каршыма
Таянаем яурың башыңа,
Яурың башың талды инде
Бәхил булып кал инде.

Бу сеңләү. Безнең авылныкы. Әйе, гомер буе авылда сеңләгәннәр, җылатканнар.

Кызны өйдә озатканнар. Чаршау астында сеңләгән, әбиләр түгәрәкләнеп, тезелеп торганнар кызның җиңгәйләре. Килен килеп әтисе белән уртада тора. Минем әтием булмады, абзыем басып торды. Шуннан алып чыгып китәләр. Туй вакытында, кызны йортыннан алып чыгып китәр чакта. Кызның өендә мәҗлес бетте, менә хәзер алып чыгарга тиешләр. Шунда тиз генә чаршауны

коралар да, коралар дип тоталар да, тотып алып калалар киленне, әтисен китереп куялар янына:

– Әтекәемнең өендә
Утырганым бары бер такта.
Бер такталарың кызганып
Сатып бирдең, әткәй, чит якка, –

дип елый.

Әтисе дә елый.

Әтисеннән соң кодагыйны тартып алалар:

– Әйдәле, бас әле тиз генә, – дип. Сүзләре күп. Җиңгәенә карата да сеңлиләр. Әнисен дә кертергә мөмкиннәр. Мин Зөлия апайдан язып алдым.

### *Чеңләү*

Ай, әнекәем, әнекәем,
Мин бит синең бәбкәең.
Кош баласын аера дип,
Аердың бит, әнкәем.

Әтекәемнең ак тастымалы
Элеп куелган чөенә,
Әтикәйем, ник елыйсың?
Сөяр балаларың кулыңда.

Абзыкай чалгы яныйсың,
Ул беләккәең талмыймы?
Яңгыратып итеп ташлар
Яшь йөрәккәең янмыймы?

Сары үрдәк балалары
Тезелеп суга бара икән,
Әтекәй белән әнекәйдән
Аерылу бик авыр икән.

Ул якта да, бу якта да
Ак тастымал бар икән.
Монда килгән кодагый,
Ак ыштаным бар, дип мактана.

Кулъяулык элдем читәнгә,
Җилфер, җилфер итәргә.
Китәр вакытлар килеп җитте,
Ат җигелгән китәргә.

(Бер кеше әйтә башлый, беренче юлын, аннан хор белән бөтен әбиләр әйтә. «Гу» итеп тора).

Минем Тәнзилә бар иде. Ат белән озаттылар, койма корылган.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Мөхәррәмова Роза Низам кызыннан (1960 елгы) язып алынды*

**Чеңләү**

Чылтыр-чылтыр чын чынаяк
Чылтыратмый ничек юармын;
Усал кәйнәләргә бирдең,
Ничек кенә итеп түзәрмен.

Сеңләү. Киленне җылатканнар.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Рәхмәтуллина Гөлнур Хәмидулла кызыннан (1953 елгы) язып алынды*

**Абага чәчәге**

Минем бабай көтүче, гомер буена көтте. Алдашуын алдашмый ул.

Төннә көтү көткәндә күрдем, ди. Папоротник прямо ялтыр чәчәк белән, ди. Прямо цветет, ди. Берәр минут торды, ди. Чәчәге серебристый, ди.

* * *

Еланга тисәң – кайгыны китерә.
Елан яткан җир әйбәт була.

*Нязепетровск районы Әптерәк авылында Хәсәнов Руфан Мәгъсум улыннан (1966 елгы) язып алынды*

**Күз тигәндә әйтелә**

Кара күздән, зәңгәр күздән,
Соры күздән, күзләре карга күтенә.
Тьфү-тьфү.

Кара күздән, зәңгәр күздән,
Соры күздән, күзләре аю күтенә.
Тьфү-тьфү.
Кара күздән, зәңгәр күздән,
Соры күздән, күзләре куян күтенә.
Тьфү-тьфү. Кем төкерәлми,
Шуның күтенә.

* * *

Яңгыр яумаса балаларны җыя идек тә, су буена китә идек, су сибешеп:

– Яңгыркай, яу, яу, – дип әйтәбез.

Шуннан явып китә иде.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшинино) авылында*
*Мугафина Фәгыйлә Хәбиб кызыннан (1938 елгы) язып алынды*

Ай түгәрәкләнеп килә, шул вакытта теләсәң кабул итә, ди, Ходай Тәгалә.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшинино) авылында*
*Сакаева Тутыя Әгъзам кызыннан (1934 елгы) язып алынды*

Уникедән соң шайтаннар чыгалар. Төннә йөремәгез мунчага, дип әйтәләрие. Бигрәк тә катын-кыз.

* * *

Үледән кайтканда артыннан килә ул, дип әйтәләрие.

*Чибәркүл районы Попово авылында*
*Уряшева Надежда Петровнадан (1953 елгы) язып алынды*

Һавага карагыз, сорагыз, ди. Раббанәне укугыз, ди, иде. Җиләккә барганда сорап барабыз:

Алла бабай савытларны тутырсын! дип.

* * *

Җидегән йолдыз, җиде имеш.
Җиде әйтсәң, савап имеш.
Җиде мәртәбә әйтсәгез савап булыр, – ди.

* * *

Бала куркса хоп-хоп дип куярга. Йөрәк потихоньку на место. Ике кул белән күкрәккә сугырга кирәк: Бисмиллаһи-р-рахмани р-рахим, хоп-хоп, – дип.

### *Кургаш белән курку кою*

Баш өстеннән коясың кургашны суга:

– Кемдән килдең, шунда кит.
Җилдән булсаң, җиргә кит.
Җирдән килсәң, җиргә кит, – дип.

Суны багана астына түгәсең. Кургаш әйләнә я эткә, я кешегә. Шуны асып йөртәсең җепкә, төшеп югалганчы.

*Чибәркүл районы Бишкил авылында Нигъмәтуллина Мәүлединә Фәйзрахман кызыннан (1944 елгы) язып алынды*

### *Колак борыштан бәреш*

Килен күчергән вакытта кияүнең өенә кияү пәке ала, шуны чыгара да бәрә урам буйлап, шуны кем беренче барып ала, пәке аныкы була, но пәкене алгач, бәргән кешене кулыннан тотарга кирәк. Иначе, колагыңны борып, икенчеләр талап ала. Әй, китә, көн буе колакларын бора торганнар ие. Колак борыштан бәреш дип атала иде. Менә егетләр сезгә пәке – колак борыштан. Бәрә дә үзе кәләше белән ычкына. Андый туйлар 1955–56 елларны бетте. Азак китте комсомольский туйлар.

* * *

Мунча яккан кешегә, өрлек астына микән, кыстырып китә акча. Егетнең җиңгәсе мунча яга торган иде.

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

### *Аш бирү йоласы*

Аш биргәндә тавык аббарасың. Тере көенә аббарасың, шунда суясың, шунда йолкып аерым казанда, дөнья тавык җыела әле

анда, каждый кеше (үзенең үлесе бар бит) үзенең үлесе өчен аббара. Хәзер алай түгел. Магазиннан алып пешерә. Тавыгы да юк.

Казакъларның сарык аббара.

Тавык башын кискәч үлгәнче сикереп йөри инде. Бөтен карны кызартып бетә. Җиденче январьда гына бирәләр, аш биргәндә ураза чыккач кына рождествода гына. Аш бирү. Если син көзге бәйрәмдә суймасаң, уже январьга чаклы ураза – мал суярга җарамый, аш бирергә ярамый. Или суеп куялар, или 7 январь җиткәнче асрыйлар малны, туйдырталар, симертәләр.

Шунда тавык аббаралар да башын кисәләр дә җибәрәләр. Буаз мал суйсаң, еще да әйбәт була, диләр. Буаз булып бозавы чыкса, еще яраталар.

* * *

Без родительский деньны «үле бәйрәме» дибез. Пешерәсең дә аббарасың, өеңдә ишең бар. Магазиннан алалар, табак тутырып аббаралар. Кабер саен йөрисең туганнарыңа вич. Барсына да салып чыгасың.

3 ндә әз генә искә төшерәләр, чәй эчәләр, киләсе килгән кеше килә. 9 нда әйтеп җыялар. Су салган кешегә кружкы, шөшке, кашык, тәлинкә, аш ашый торган зур кашык бирәләр, посуда бирәләр. Сине җуындырган кешене кыркында баштан аяк киендерәләр. Аны бик кадерле саныйлар кыркында. Хәзер яшьләр бик алай ук итмиләр, будто бы үле кире кайта. Безнекеләр кайтмады әле, ничә үле җыештырдык инде. Кыркына чаклы ут сүндермәдек, урын җәйдек. 39 или 41 дә кыркын уздыралар 40 көнендә уздырмыйлар. 40 көнендә ул сораудa тора, ди, язык – сорау алалар.

### ***Нардуган***

Чыгып китәбез. Нардуганга кайберсе баз капкачын ачып куя. Бала-чага җырулар җырлый, әллә идәннәрен таптатасылары килмәгәнме. Кергәндә: «Базларын карагыз, базларын», диләр.

Кыргызларның мичләре
Ак бур белән бурлаган,
Кыргызларның Капучлары *(малай исеме)*
Мичтән коймак урлаган.

Җырлый башлаганда тегеләрне базга сөйрәп салабыз, диләр.

Кергәндә базларын карап керегез, ди торганыем. Без кыргызлар белән уйнап үстек. Безгә өйрәнеп беттеләр, без кыргызча өйрәнәбез.

Чапайларның турларында
Өч аяклы машина,
Чапайларның малайлары
Тырма белән кашына, –

әнә шулай үчекләп җырлыйдырыек инде.

Батайларның турларында
Өч тиен акча ята,
Батайларның Иваннары
Кызы кырында җата, –

шулай изекләп җырлый идек, Нардуганда шундый җырлар.

### «Йөзек салу»

«*Йөзек салу*» барые бездә. Искечә Новый год узгачын, январь узгачын, январьның 14ндә искечә җана җыл. Январьның үндүртендә йөзек салырга мин чакрам, егетләрне-кызларны, чиләк белән су апкерәбез. Или первый туган бала булсын или последний туган бала әнә шул. Әнә шул кешене подбирать итәләр, чиләк белә су апкерәләр, өстәлгә су утырталар, суны сәгать 11 дә генә төнге. Балдакларны бәйләп саласың бер 3–4 балдакны җеп белән бәйләп. Син, бу җегет. Шул чиләкне баш бала болгата суда, аннан кайсы балдак эләгә, бер җыру җырлыйсың инде. Җыру җырла дисәң дә, балдакны чыгара. Кияүгә китәме анда.

Теләсә нинди җыру җырлыйлар.

Элек безнең Парижга шул бер чишмә. Кыш көне дә шуннан көянтә- чиләк белән су ташыдык. Бетон да юк, кадка да юк, арба да юк. Чиләкләрнең төбенә су түгелеп ката бит, мөгезләп-сосулька диләр урыслар. Шулар катып кайта торганнар ие буранда. Җәй көне чиләкләрне яртышар-яртышар иттереп нәнәүләр эшкә китте исә, үзебез ташыйбыз. 2 рәт барабызмы, 3 рәт барабызмы, су савытын нәнәү эштән кайтканчы әзерләп куя торган идек.

Шул чишмәдән бараллар. Керис бәйли чиләгенең читенә, пычак ала. Чишмәдән иманын әйтеп суны ала. Кресны креска сызып чиләкнең төбенә сала, биштәр белә каплый, апкайта өстәлгә утырта. Сәгать 12 не көтә, 12 дә балдакларны салып, «йөзек салу» диләр инде ансын.

* * *

Элек ярамый иде, хәзер төнне мунча җагып керәләр.

Безнең Олы көн алдыннан үле мунчасы диләр. Чәршәмбе көнне мунча ягабыз. Четверг көнне идәннәр җуып, үленең киемнәрен җуабыз.

### «Чүп» боткасы

*«Чүп»* боткасы, ди торганнар ие. Чишмә буенда. Чүп боткасы диләр яңгыр теләгәндә. Авыл, күрше җыела, казан белән чишмә кырында тавыкны пешерәләр. Яңгыр телиләр. Урам буенча китәләр чиләк белән су алып. Кантурларга кереп, урамда да баштанаяк су коялар ие яңгыр теләп. Әнә шулай кешеләрне йөздереп-йөздереп.

* * *

Первый көтү чыккан көнне күкәй аппарып көтүчегә күкәй бирә торганнарые элек. Андый җола барые.

### Ырым

Сул күзеңә чыкса, бу кулыңа бәйлә, балдак кеүек кара җеп. Ә уң күзеңә чыкса, сул кулыңа бәйлә. Исемсез бармакка бәйлисең. Кәтүк җебе нечкә. Кара только.

Монсы – баш бармак,
Монсы – карак бармак,
Монсы – урта бармак,
Монсы – исемсез,
Монсы – чәнтекәй.

### Курку кою

Кургашны эреткәннәр дә салганнар суга. Фигурасы төшкән. Эттән куркканмы, каздан куркканмы. Кешеләрдән ишеткәнем бар ие.

### *Кан теле*

Кисемәнне кан теленнән белгәннәр.

### *Каргыш*

Яшен суккыры,
Яшеннең кара ташы тисен.

Ачулангач әйткәннәрдер инде.

*Нагайбәк районы Париж авылында*
*Иванова Вера Лазаревнадан (1935) язып алынды*

Кара тавык суйганнар. Бутка пешереп, Гомбәй буенда сарык суйганнар. Кодайдан сораганнар:

– И, Ходаем, мине мәхрүм итмә инде.

Бир җаңгырны, бала-чага бакытыннан, безнең бакыттан, карткоры бакытыннан, – дип, шулай теләгәннәр инде.

Безгә җаңгыр җау инде,
Безне болай тилмертмә.

*Нагайбәк районы Кили (Кассель) авылында*
*Миняева Зоя Прохоровна (1935 елгы),*
*Букачева Роза Прохоровна (1938 елгы),*
*Хөснетдинова Екатерина Кирилловна (1939 елгы),*
*Тихонова Зоя Георгиевнадан (1940 елгы) язып алынды*

### *«Йөзек салу» йоласы*

«Йөзек салу» 13 январь анысы. Искечә җаңа җылга каршы ул. Суга төшкәннәр. Баш бала чиләкнең бер ягыннан тоткан, берсеннән – төпчек. Өстен бистәр белән җапканнар. Баргачын шул суны алганнар да инде, кайтканда сөйләшмәгәннәр бер-берсе белән. Кайтканнар да кайсы балдак салган. Шул балдакларны болгаталар да, берәү такмак әйтә. Нинди такмак була. Туры килдисә дә: «Бу кемнең балдагы» дип чыгара.

– Минеке, минеке.

Шул кешегә җурыйлар инде. Әйбәткә була, начарга була.

Минем бабаемның сеңлесе өйләрендә йөзек салганнар. Яшь килен белән яшь кияү яңа өйләнешкәннәр. Агасы әйткән:

– Кая, Нәстәй, миннән дә ал әле, миңа да салыгыз. Моның Нугут салган йөзек чыккан и җыруы да чыккан:

Самавыр куйдым күмерсез,
Кайнап чыгар күрерсез,
Ике матур бергә килә,
Берсе булыр ғүмерсез, – дип.

Шуннан бабаемның энесен алганнар, нигә, казачий служба булган – охранять иткәннәр безнең границаны, шунда эссегә ярамыйча Оренбургта үлеп калган, 25 яшендә. Ул үлгәннән соң бер кызы туган. Без аны туган итешеп йөрдек. Машка җиңги, ди торган идек. «Нугут» димиләр, «йөзек салу» диләр безнеңчә.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында*
*Артемьева Зоя Евгеньевна (1940 елгы),*
*Байкина Евдокия Ильиничнадан (1941 елгы) язып алынды*

### *Керәшенчә иман*

Көн дә әйтәм, кайчан башыма иманны әйтергә әйтә:

И күктәге Атабыз, данлы булып торсын исемен синең. Килсен патшалыгың синең. Җирдә дә күктәгечә булып торсын иркең синең. Көндәлек икмәгебезне биреп тор.

Бурычларыбызны кичер. Без лә бурычларны кичергән күк. Җаманнардан безне коткар, яхшылардан безне җырак җибәрмә. Амин.

Мажаровның Туганайдан өйрәнде. Без урыслар белә, күбрәк русча әйтәбез.

Үлегә барганда Святый божийның керәшенчәсен тоже beләбез:

Святый божий крепкий,
Святой бессмертный помилуй нас.
Святой Алла, Святой кодрәте
Святой үлемсез безне җарлыка.

Әбиләр бик җырлый торганнар ие. Хәзер батюшкабыз бар. Ул килә районнан.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында*
*Исаева Евдокия Артемьевнадан (1949 елгы) язып алынды*

* * *

Солдатка киткәндә ырымны ясарга тырышабыз:

Капканы ачабыз. Капкага менә шулай итеп кульяулык белә суга. Элек мич түренә карата торганыек. Яманалап йөрмәсен дип. Инәй-атай үзләренә күрә бахиллаганнар инде. Исән-сау йөреп кайт дип. Аннан ике кулҗаулыкка берсенә җиләк төрә, берсенә – акча.

Җир җиләген кульяулыкка салып малаема озатырга кесәсенә салып куйдым. Малай киткән. Җиләкне алып өйгә ташлап киткән.

Җиләкне апкитергә тиеш үзе белән. Берсенә акча төнисең, озата барабыз ана шулай, бер тын китдисә акчаны кульяулыгы белән ыргыта, кем барып ала, талашып-талашып барып алабыз. Кем беренче барып алала.

Минем энемне озатканда мамау белән тәтәү Ваныны өстәл әйләндерделәр. Чәй эчкәндә беренчесен эчә, икенчесе калырга тиеш инде, эчеп бетмәскә тиеш, ансы кала.

Сынган ипи дә, бер тешли дә, ул да кала инде.

Кульяулыкны чишеп тә булмый торган иде. Кульяулыкларны акча белән нык итеп, тыгыз итеп бәйләгәннәр. Ырымы бар аның. Тиз чишелсә, начар солдат булямы инде шунда, озаграк мәтәшсәң, сильный буламы, бернәрсәсе барые инде.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында*
*Исаева Евдокия Артемьевна (1949 елгы),*
*Артемьева Зоя Евгеньевна (1940 елгы),*
*Байкина Евдокия Ильиничнадан (1941 елгы)*
*язып алынды*

## Риваятьләр-легендалар, сөйләкләр

Юсуп белән Әптерәк икесе бергә килгән. Бер брат алар, Аргаяшский район Шуранкадан килгәннәр. Историческое название бу авылның Малая Шуранка, безнең авыл (Әптерәк) – Большая Шуранка. Әле дә йөртәләр. Олы Шураннанмы, кече Шураннанмы дип, килеп сорыйлар.

*Нязепетровсийк районы Әптерәк авылында*
*Хәсәнов Руфан Мәгъсум улыннан (1966 елгы) язып алынды*

Горшинина (Чулпан) 1939 елда буш җиргә салынган. Башкириядан килгәннәр. Анда утын юк, печән юк дип. Урманны кисеп өй салганнар. Башкирияда Чулпан авылы бар – шуннан исем кушканнар. Исәнбай, Чиялек дигән авылдан килгәннәр. Горшинино дип күптән түгел куштылар. Горшинин дигән бай кешенең заимкасы (*дачасы*) булган.

*Нязепетровский районы Чулпан (Горшинино) авылында Мугафина Фәгыйлә Хәбиб кызыннан (1938) язып алынды*

Бабау сөйлидерие. Ничек сугышта булганын, ничек Чапаев белән йөргәнен. Чапаевның секретаре булган бабаум, плясун, ерлаучы – Измайлов Егор Прокопьевич 1890–92 елларны туган.

*Чибәркүл районы Попово авылында Уряшева Надежда Петровнадан (1953 елгы) язып алынды*

Бохара ягында Нурек мирза булган, яман бай булган. Шуның ике улы булган. Берсенең исеме – олысының Чура булган, икенче улының исеме Ширин. Чура ишеткән, что Казанга урыс гаскәре килеп камап ята дип. Шул гаскәр җыеп Казанның кальгасы янына килеп яталар, чатыр корып. Шуннан Казанның ханы белән сөйләшәләр инде. Шуннан ике урыс солдаты килеп керә боларның шатерына. Чура ыргып тора да, нишләп монда рөхсәтсең кереп йөриләр дип, бер урыс солдатының башын өзеп төшерә, кылыч белән.

Икенчесенә:

– Бар кайт, – ди, – үзенең лагерына. Орышасыгыз килсә, мәйданга чыгыгыз, ә болай угрыланып йөрмәгез. Икенче көнне Чура гаскәре белән рус гаскәре арасында сугыш башлана инде. Казан ханның войскасы килеп чыга, шулар бер булып урысларны куып җибәрәләр. Чурага батыр дип исем бирәләр. Шуннан соң Чура Казаннан бер татар кызын ала. Нәселе тарала башлый. Шуннан соң үз иленә кайтырга була. Кайта инде Бухара ягына. Бер айлап торып, кире Казанга китә.

Шуннан соң Иван Грозный килеп Казанны ала. Урыслар белән сугыша-сугыша да, булалмагач, килеп Урал урманнарына килеп посалар урыс гаскәреннән.

Шуннан бу аптырый, ничек инде җиңелдек, дип. Йөреп-йөреп кайсыдыр елга буенда үлә. Шунда таш куялар. Чура батырның юлы шунда бетте, дип.

Нәселе тарала башлый. Берничә поколения үткәч, 4 нчеме, 5 ме поколениядә Госман дигән бер потомок туа инде. Бик развитый була, Дагестан ягына чыгып китә. Укырга өйрәтеп йөри. Кавказский сугыш башлангач бу якка Башкирияга килә. Башкортстанда Учалы районында Илтабан дигән авыл бар, шунда килеп утыра. Госман мулланың бер улының исеме Имангол була. Имангол Госман мулладан рөхсәт сорап, Учалы шәһәренең аргы ягына барып утыра. Аның янына төрле халык җыела башлай. Ул авылның исемен Имангол авылы дип кушалар. Иманголның 2 хатыны була. Олы хатынының уллары бу якка җәйләүгә килеп йөриләр инде. Берничәмә ел үтеп китә. 1745 елда яман ак буран була. Акбулат авылыннан Учалы районы урта хәлле Ибраһим карт була. Шуның елкысы югала. Олы улы Әмин елкысын эзләп бу якка килеп Олы тау тирәсеннән таба. Карап чыга бу җирләрне. Гали бар, ни бар, агач бу якта каралай нык булган була. Уй суында нинди генә балык, янең ни теләй бар инде. Кайта да әтисе Ибраһимга сөйләй. Бу як бик матур. Имангол балалары белән күрешеп йөриләр инде. Аралары бер 3–4 чакрым, кунакка йөриләр. Шул елны мәкаль коралар, давай шул урталыкка авыл салаек.

Җәйләүдән кире авылыбызга кайтмаек дип. Килешәләр дә шул. Әмин Ибраһим карт улы килеп утыра авылның теге як очына. Имангол уллары бу якка килеп утыралар 1746 ел. Шуннан Әмин авылы 1746 елны барлыкка килгән дигән тарих килә. Нәселләр тарала башлый.

Безнең авыл 1836 елны вынужденно казачествога керә. Җирләрне талай башлайлар. Казак булсагыз на равных правах. 1836 елны договор подписать итәләр. Әмин авылы халкына казачествога кергәч, бабайлар сөйли торган ие, бер пункт булды ди: разрешить строительство мечети и оставить вероисповедание – магометанское.

Авылда пожар булган, авыл янып беткән. 2 мәртәбә пожар булган. Управление, китаплар вич янган. Бабайлар сөйли иде –

бар иде дип шул договор, подписанный губернатором. Ул вакытта Неплюев булган и Петербургтан бер кеше, авылның старшинасы подписать иткәннәр. Элек бер өйдә укып йөргәннәр. Шул пункт булганчы. Кайсы бабайлар әйтә: специальный поджог булды, диләр. 1838 елны этигә 12–14 яшь булган. Әти әйтә: чыгып йөгердек, беркем дә, бер нәрсә дә алып өлгерә алмады, дип. Элек читән, ни булган, коры вич. Монда бер Рабига дигән карчык самовар куйган, торбасын читәнгә сөяп куйган. Как раз 31 апрель булган по-моему. И шул читәннән киткән. Ике сәгатьтә авылда бер нимә дә калмады,ди. Аргы якка чыктык та, карап тордык, ди. Шулай торып калдык Петропавловски, казаклар, урыслар безнекеләр казак булган кый инде. Шулай помогать итешеп кем тагы өй салды, кем землянка ана шулай. Берничә ел үткәч сала башладык ди. Патша Николай II, помоему, тоже помощ биргән.

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин*
*Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

Борынгы исеме Сарашлы. Аларның күчеп килгән җирләре Сарашлы булган, без бит күченгән калыклар. Күчкән һәрбер авылга номер куйганнар. Безнең № 2. Алар үзләренең элекке авылларын гел искә төшереп йөргәннәр. Шарашлы да Шарашлы. Аннан Сарашлы киткән. Белебейский районнан килгәннәр.

* * *

Мамаум Парижныкы. Мамаум әйтә торган иде, Яшь авыл дип.

Париж – Яшь авыл дип йөртелгән. Безнең авыл Сарашлы кешесе, ә алар үзләрен Яшь авыл кешесе дип йөртә торганнар иде. Белоусова бүтәнчә сүз белән язды, яшь авыл дип язмады.

Безнең казаклар ничек җиңгәннәр. Городка кергәннәр, җиңгәннәр, Париж исеме кушканнар авылга. Остроленкода җиңгәннәр – авылга Остроленко. Польшада – Остроленко. Кассель – Германиядә. Кайткачын Кассель дип кушканнар.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында Исаева*
*Евдокия Артемьевнадан (1949 елгы) язып алынды*

## Әкиятләр

### *Илкә әби (Елена әби) мәсәләсе* (*әкияте*)

Сөйләем әкият:

Бер урманда сөйләшәләр. Нинди агач күбрәк, коры агачмы или чаукамы.

– Кайсысы күбрәк?

– Коры агач күбрәк, – ди ябалак.

Төйлегән әйтә:

– Ни сүлисең инде, конечно чаука күбрәк, коры агач аз бит.

– Юк, коры күбрәк.

Аннан әйтә:

– Кем күбрәк: хатын-кызмы, ир-кешеме?

Төйлегән әйтә:

– Ирләр күбрәк. Алар сугышка да бара. Ашлык та чәчәләр.

Ябалак әйтә:

– Юк. Катын-кыз күбрәк. Син Төйлегән тик андыйны сүләмә. Мин әйткән дөрес.

Төйлегән:

– Алайса, сүлә, син нигә алай әйтәсең?

Агачның бер ботагы булса да коры бар. Мин андый агачны корыга саныйм. Ә ирләр хоть бер тапкыр хатын-кызның сүзен тыңласа – ул да хатын-кыз.

Шундый мәсәлә (*әкият*) бар.

– Илкә әби, безгә сүлә ни дибез.

– Тик кенә утырыгыз, идәнне юып алыгыз. Менә шуны эшләсәгез, аннан мин сезгә *мәсәлә* сүлим, ди иде, аннан сүлидерие.

Мин сорыйдырием Надяның мамасыннан – Аука түтидән:

– Бу Илкә әби каян ул аларны ала, ул укымый книжкалар, укымый каян ала?

– Ул үзе.

*Чибәркүл районы Попово авылында Сошникова Валентина Ивановнадан (1949 елгы) язып алынды*

### *Камыр батыр әкияте*

Борын-борын заманда кәзә команда, саескан сотник, карга үрәдник булган заманда (дип бер бабай әкият сөйли иде. Картәй

дип йөрдем инде мин аны). Әби белән бабай булган, ди. Аларның уллары булмаган. Балалары булмаган. Әби калган онын яеп, камыр баскан. Шул камырдан бер малай ябештергән үзенә. Шул малай үсеп киткән. Камыр батыр дип исем кушканнар. Теге егет үсә бер кыз белән таныша, бер патшаныңмы кызы белән. Башта 3 башлы, аннан 9 башлы, 12 башлы белән сугыша. Кайта, теге кызны кәләш итеп ала.

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

Без бәләкәй чагында бер бабай хәер сорашып йөри торганые. Никанур, балаларга мәсьәлә сөйләле, ди Люданың әнисе. Утырып ала. 8 бала. Тегеләр 4 әү, без 4 әү. Әллә нинди мәсьәләләр сөйли торган ие:

Борын-борын заманда, бер әби белән бабай булган. Аларның бер малайлары булган. Боларның утыннары беткән. Бабай:

– Безнең утын да бетте, малайны утынга җибәрик.

Малайлары ат җиккән дә утынга киткән. Каенга барган да, каенны кисеп алып арбага салалмаем, дигән. Сразы арбага гына җыгыем. Атны арбасы белән куйган да, каенны сразы арбага җыккан. Арба да уалган, ат та үлгән. Балтаны алган да кайтып киткән. Кайтып килә икән менә монда МТМ күле дибез, шунда бер үрдәк җөргән.

– Ох, менә бу үрдәкне тотып алсам, нәнәү итле аш пешереп эчертер ие, дип әйткән. Балтаны үрдәккә ыргыткан. Балта баткан, үрдәк очкан.

Шуннан инде бу кайткан, кайтса, боларга кунаклар килгән инде. Бер бәйрәм арасы булганмы инде.

Инәсе әйтә икән:

– Монсы утыннан кайткан малаема өлеш куйым әле.

Ә, әле балтаны эзләргә кергән. Күлмәк-чалбарны салган да. Балтаны тапмаган үрдәге очкан, монда чыкса күлмәк-ыштан да юк. Шәрә кайтып киткән.

Кайтып өйгә сүндәләгә менеп яткан. Өйгә керәлми. Ике бүлмәле өйләре. Ыштан да ала алмый, корсагы ачып беткән инде моның.

Шуннан сүндәләдә бернимә табып, киеп үрелеп кенә ипи аласы булган икән, сүндәләдән өстәлгә җыгылып төшкән. Җыгылып төшеп, инәсе күреп, чыгып качып, бер атна өйләренә кайтмаган.

### *Алдавыч әкият*

Өе дә таштан,
Мунчасы да таштан.
Сөйлимме баштан?

– Сөйлә.

Тагын шуны әйләндереп сүлисең:

Өйләре да таштан,
Мунчалары да таштан,
Коелары да таштан.
Сөйлимме баштан?

*Нагайбәк районы Париж авылында Иванова Вера Лазаревнадан (1935 елгы) язып алынды*

## Бәетләр

### *Сак-Сок бәете*

*(өзек)*

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе
Сак белән Сокның бәетен ишеттем
Беребез Сак булдык, беребез Сок булдык
Таң атканчы беребез юк булдык.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Мөршидә бәете*

Кем сыгарганын да бәлмәем, мин бәләкәй генә булган, каядыр ишеткән мин аны, ул минең кереп калган күңелемә.

Диде, син ирем, яратам сине,
Бу кызыңа тормыш калмады,
Сугамы батыр, приюткамы бир,
Кайда да булса үтер аны.

Мөршидә кызым, әйдә йөргергә
Урманнарга һәм зиратларга,
Туган әңкәеңнең каберен карыйк,
Чәчәкләр белән бизәп кайтыйк.

Юк, әткәй, бармыйм, барасым килми,
Әллә ниләр синең уеңда,
Барсам да, әткәй, бармыйм йөргергә,
Барам туган әңкәм каберен карарга.

Шул сүздән соң мин килдем киенеп,
Әйдә, әткәй, бараек, дидем,
Туган әңкәемнең каберен карыйк,
Чәчәкләр белән бизәп кайтыйк.

Киттек урманга, урман караңгы,
Кошлар да инде әллә ни сайрый,
Әткәй кулында ялтырый пычак,
Суйсаң да, әткәй, бәхилем сиңа
Ятим булдым бәхетсез булгач.

Суйдым кызымны, газиз баламны
Яшь хатынымның сүзен тыңлагач.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова*
*Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Сак-сок бәете*

*(өзек)*

Әткәй тиргәде, әнкәй каргады,
Китте җиләккә, җиләк җыймадык,
Сугышып кайттык.
Әткәй сорады: «Кая җиләгең?»
Әнкәй тиргәде: «Нигә җыймадың?»

менә шул куплетлары калган.

*Чибәркүл районы Бишкил авылында Нигъмәтуллина*
*Мәүлединә Фәйзрахман кызыннан (1944 елгы) язып алынды*

Безнең «Сак-Сок» дигән бәет бар:

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәйтен иштәсе.
Бокарлы мәчет, пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Сак белән Сокның бәете шулай,
Исенә төшкәндә кычкырып җылый.
Сары сандугач, кара карлыгач,
Яралды канат әңкәй каргагач.

Әңкәй, тукмачың нигә күп иттең?
Әткәй кайтканчы безне юк иттең.
Әңкәй мәчеткә үзең бардыңмы?
Сак белән Сокны күреп калдыңмы?

Урман эчендә аю үкерә,
– Ник каргадым? – дип, әңкәй үкенә.
Сарылы күлмәгем, бер дә кимәдем,
Әңкәй, җылама үзең сөймәдең.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында*
*Артемьева Зоя Евгеньевна (1940 елгы),*
*Байкина Евдокия Ильиничнадан (1941 елгы)*
*язып алынды*

## Мөнәҗәтләр

### *«Бердер Илаһем бәнем»*

Инандым бән Аллага,
Алланың барлыгына,
Алланың берлегенә –
Бердер Илаһем бәнем.

Бер Илаһым, үзең Сән
Һәрнәрсәне бар иткән,
Һәркемгә ризык биргән –
Бердер Илаһым бәнем.

Илаһым сүзе Коръән,
Пәйгамбәренә килгән.
Безгә ул китап булган –
Бердер Илаһым бәнем.

Адәмдер бәнем атам,
Һавадыр бәнем анам,
Милләтемдер – Ибраһим,
Бердер Илаһым бәнем.

Раббым – Алладыр бәнем,
Динем – Исламдыр бәнем,
Кыйблам – Кәгъбәдер бәнем,
Бердер Илаһым бәнем.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Мөхәррәмова Розалина Вадик кызыннан (2005 елгы) язып алынды*

**_Мөнәҗәт_**
*(өзек)*

Мөнәҗәтем кабул булсын,
Догаларым кабул булсын,
Догаларым кабул булсын,
Рәхимең кыйл, Рәсулулла!

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Рәхмәтуллина Гөлнур Хәмидулла кызыннан (1953 елгы) язып алынды*

*Апаемның бәете:*

Укы намаз иртән торып,
Алырсың син бик күп савап.
Үлеп кабергә кергәч,
Күрмәссең син һичбер газап
(Ходай безгә шулай кушкан).

И, Ходаем, сакла безне
Шайтан васвәсәләреннән,
Зекер-тәсбих күңелләрдә,
Җибәрмә син күңелдән.

Кыла күр гамәлләрең
Үзең исән чагында,
Картайгачтын кылалмассың
Гарифләнер бәдәннәрең.

Көндез үтеп, төнгә кергәч,
Шайтан васвәсә кылыр,
Кылган гамәлең булмаса,
Шайтан иманыңны алыр.

Иман дигән шәриф нәрсә
Саклаулары бик авыр,
Кылган гамәлең булса,
Фәрештәләр язып торыр.

Уйла, бәндә, үләсеңне,
Кара җиргә керәсеңне,
Үлеп кара җиргә кергәч,
Ниләр җавап бирәсеңне.

Сәдаканы бир ятимнәргә,
Ходай бирергә кушкан,
Сәдакасыз малың булса,
Булыр үзеңә дошман.

И, Ходаем, сакла безне
Шайтан васвәсәләреннән,
Зекер-тәсбих күңелләрдән
Җибәрмә син.

Дәфтәрләр килмәсен сулдан,
Ходаем сакласын шуннан.
Аерылмагыз иманымнан
Рәхим кыл үзең, Аллам.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Сәлимгәрәева Әкълифә Хәерзаман кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

Аллаһ, Аллаһ дисәң иде,
Аллага кол булсам иде.
Җан яраткан яным белән
Оҗмаһларга керсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәң иде,
Аллага кол булсам иде ...

*Нязепетровск районы Әптерәк авылында Нурисламова Нәфига Әдәган кызыннан (1936 елгы) язып алынды.*

### *Аллаһ, Аллаһ, дисәм иде*
*(мөнәҗәт)*

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Ян яраткан яннарыма
Якын корбан булса иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Мөхәммәт өммәтеннән булып,
Җир куынына керсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Тулы иманнарым белән
Җир куенына керсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Сигез оҗмах ишекләрен
Үзем ачып күрсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Минем гамәл дәфтәремне
Кулыма бирсәң иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Изге гамәлләрем белән
Оҗмаһларга керсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Мөнкир-Нәнкирләр килгәндә
Җиңел җавап бирсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Хәзрәти Фатыйманың
Күршесеннән булсам иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Сигез оҗмаһ эчләрендә
Дидәреңне күрсәм иде.

Аллаһ, Аллаһ дисәм иде,
Аллага кол булсам иде,
Сигез оҗмаһ эчләрендә
Ата-анамны күрсәм иде.

Ает укытканда, ает ашында, Коръән ашында шушы мөнәҗәтне әйтәбез. Ашап беткәч, коръән укылып, амин тоткач мөнәҗәт әйтәбез. Әби-бабалардан калган йола.

*Нязепетровск районы Әптерәк авылында Усманова Бибимәккә Вәли кызыннан (1939 елгы) язып алынды*

## Уеннар, аулак өйләр

### *Уен җыю*

Хәзер аулак өй дип әйтәләр, ә бездә элек уен җыю булды.

Уен җыю тип атала. Уен җыюга безнеҢ акча ла юк, картыемдың сәен урлап, күкәйдәрен урлап, авыз гармушка белән уйнап, ул вакытта мондый гармушка юк. Кемнең аулак өе бар, әбиләр үзләре генә тора бит, аннан өй һатып алабыз, урлаган сәйгә, күкәйгә. Кәрәчин алып барабыз, элек лампа белән уйнанык. Уйнап кайтабыз инде. Биеп уйныйбыз шунда.

«Күбәләк» – 4 кеше тораһың да тотышып, тагын икенче кешеләргә ураһың, тагы улар шул күбәләк булып уйнай, өерелеләр, кул чабып алабыз да, обратно әйләнәбез. Тагы ерлап биибез, табышмак әйтәбез, «*йөзек салу*» шунда.

### *«Чүрәкә»*

«Чүрәкә»не болай итәбез дә суйыл (*колга*) белән ебәрәбез. Менә шундый ни була агачтан эшләнгән туп кебек бәләкәй. Аны малайлар эшләп бирә. Без шуны сугабыз. Анан шуны сикертәбез дә сугабыз. Барып төшә. Кем нитмәй, аны уеннан чыгарабыз. Шул уйнаган кешене йомыры тупка эләкмәсә суелың син не годныйсың.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Бот көрәштерү*

Бездә авылда ирләр-хатыннар бергә бот көрәштек. Апайлар безнең гел бот көрәшеп үскәннәр алар. Ния ятасың да бот белә

алып бәрәсең бер-береңне, вальтом ятасың да. Аякны күтәрәсең дә и бер-береңне алып бәрәсең. Бот гел көрәшеп ятканнар элеккеге вакытта. Элек уйлап чыгарганнар. Кырга чыкканнар, җыелышканнар.

Армиядан кайткан мужикны алып бәргән Зифа.

Җәмилә апай мәйдан батырын алып җибәргән. Мәйдан бетте, кырга чыктык, бер 20 пар бар. Давай бот көрәштерәбез, көрәштерәбез. Сәеткәр мәйдан батыры: давай, кем ята минем белән бот көрәштерергә. Җәмилә эндәшми генә барып ятты. Мәйдан батыры ике кабат әйләнеп чыкты. Хәзер тордылар да, юк булмады, ди. Тагын яттылар. Тагын әйләндереп бәрде Җәмилә. Безнең Биби апай бөтен кешенең итеген, силос вакыты булгач итек кигәнбез икән, эрзинкә итек. Итегенең үкчәдән алып шулай гына калды, купканчы көрәштеләр.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Мөхәррәмова*
*Роза Низам кызыннан (1960) язып алынды*

### *«Советский» уен*

Өч кеше басасың. Бер егет, ике яктан кыз. 4 кыз 2 егет уйный. Кара каршы басалар да. Гармун уйный. Киләләр дә әйләнеп чыгалар. Аннан егетләр алышына. Һәр кыз белән егет бии. Егет 2 кызны да әйләндереп чыга. Каршындагы егет шулай ук 2 кызны әйләндерә. Әллә ничә төрле. Дүртенчесе егет кызны кочаклый, тегеләрне әйләндерә дә егет тагы урынына килеп баса.

### *«Общий» уен*

Күмәк төшәбез без. Ерлап йөрибез инде.

Бер вакытны бер урамда
Бергә булдык, уйнадык шул,
Кайда китте шул вакытлар,
Дип куярбыз уйланып.

Үтте инде шул вакытлар,
Үттеләр, югалдылар шул
Әкрен типкән яшь йөрәккә
Тирән эз калдырдылар.

*Нязепетровск районы Әптерәк авылында Байбакова*
*Разия Гыйльметдин кызыннан (1938 елгы) язып алынды*

«Күкәй» уйныйдырыек Олы көндә. Чокыр казыйсың да, күкәйне ыргытып җибәрәсең, кемнең күкәенә тия. Бер күкәй отасың, ике ... бөтен күкәйне отып бетерәсең. Чокыр казыйсың да әзрәк, күкәйләрне тезеп, 4 күкәй. Күп җыелабыз. Элек бала-чага уйнау күп иде. Күкәйгә тимәсә, отмасаң, дальше уйнамыйсың, икенче кеше уйный башлый.

*Нагайбәк районы Париж авылында*
*Иванова Вера Лазаревнадан (1935 елгы) язып алынды*

## Җырлар

### *Бишек җыры*

Әлли бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әңкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Нәнәемә бүләккә.

Әлли бәлли итәр ул,
Үсеп буйга җитәр ул.
Үсеп буйларга җитәр ул,
Галим булып китәр ул.

Әлли бәллү ит кенә,
Йоклап кына кит кенә.

Әлли бәлли итәр ул,
Үсеп буйга җитәр ул,
Йокла, балам, йом күзең,
Йом-йом күзең, күз нурым.

Кичтән йокың кала да
Йоклап үтә көндезең,
Кошлар да кунган инде,
Күзләрен йомган инде.

Йом, бәбкәем, күзеңне
Йом-йом күзең, күз нурым.
Йом-йом күзең, күз нурым,
Әлли бәлли бәбкәем.

* * *

Алай димәгән идем,
Болай димәгән идем,
Яшь гомерем зәңгәр чәчәк–
Үтәр димәгән идем.

Яшьлегемдә күкрәгемә
Чәчкәләр кадамадым,
Чөнки яшьлек үзе чәчәк,
Кирәк дип санамадым.

Алларым кебек күрәм,
Гөлләрем кебек күрәм,
Әллә нигә бик яратам,
Яннарым кебек күрәм.

Алай димәсен кеше,
Болай димәсен кеше,
Үзен уйласын да белсен,
Бездә булмасын эше.

Безне халык күрәлми,
Юлга читән үрәлми,
Үреп куя, сүтеп яга,
Безнең кебек булалмый.

Китәм дисең, китәм дисең,
Китәр булгач алып кит,
Суларга, я утларга,
Йәлләмәсәң, салып кит.

Агыйделләр акмый торса,
Аркылы йөзәр идем.
Алда бәхетләрем булса,
Хәзергә түзәр идем.

Китәм, дустым, китәм, дустым,
Китәм, дустым, каласың,
Мин сөймәгәч, кемнәр сөяр
Син сандугач баласын.

Бер егет белән таныштым
Алтын балдак алыштым,
Өч көн эчендә егетне
Бер тиенсез калдырдым.

Алсу күлмәкләр тектердем
Итәкләрен тар итеп,
Тар балдаклы чалбар кигән
Егетләргә пар итеп.

Бер егеткә күзем төште
Салган чакта чүмәлә,
Серләр итеп кенә әйтәм,
Кешеләргә сөйләмә.

Төшке ашка туктаганда
Димләдем Минсиягә,
Җавап бирде: йокым килә
Монда җиләс, күләгә.

Егет мени, ачык авыз,
Әйтерсең бер чүмәлә,
Адәм көләр, сиңа гашыйк
Булганымны сөйләмә.

Суга салсаң су күтәрми
Бер мыскал тимерләрне,
Эзләсәк тә таба алмабыз
Үткән яшь гомерләрне.

Каен мескен үскән икән
Яшел яфрак өчен,
Безнең башлар үскән икән
Кайгы-хәсрәт өчен.

Кыш та яшел, җәй дә яшел
Чыршы дигән бер агач,
Ул ния яшел булмасын
Бер кайгысы булмагач.

Тал бөгелә, бөгелә ул,
Яшь каен бөгелми ул,
Яр ташласа, яр табыла,
Яшь гомер табылмый ул.

Себерләргә барган чакта
Күрдем Себер мулласын,
Себер мулласы да куша
Төрттерергә дөньясын.

Авызым юр *(зур),* авызым юр
Авызым юр, нишләтим,
Уртасында мич салдырып
Ресторан эшләтим.

Телеграмм баганасы
Олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы, дип сорыйсың,
Сагынмаган кая ул.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр мичкәләр,
Шул мичкәдән карап тора
Эре-эре (юан-юан) бичәләр.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

Фәридә Кудашева 1954–1955 елларда шул ерны ерлай торган ие. Бер 2–3 куплетын беләм, шуны ерлап китәм. Хәзер авылда да, телевизорда да бер дә ерламайлар ул ерны:

Ыстаканнарым тирән
Зәм-зәм тутырып бирәм.
Сез дусларны гөлгә кунган
Былбыл белән тиң күрәм.

Каен кисәм, каен кисәм,
Төбе шартлаган саен,
Сез дусларны искә алам
Кошлар сайраган саен.

Сайрый былбыл, сайрый былбыл,
Сайрый былбыл талларда.
Сайрый былбыллар талларда,
Йөрәккәем кайларда?
Сайрый былбыллар талларда
Син дускаем кайларда?

Су буйлары кыяк үлән,
Кыеп карасы иде,
Мәңге сагынмаслык итеп
Карап каласы иде.

Зәңгәр чәчәк матур була
Сөрелмәгән җирләрдә,
Бер минут торасым килмәй
Сез булмаган җирләрдә.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Мингаева Сәкинә Батырбай кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Армиягә озату*

Кулъяулык болгап чыгып киткәннәр, армияга киткәндә:

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кайталмам инде,
Сынса сабыр канатларым,
Сабыр итәлмәм инде.

Китәм, дисең, китәм, дисең
Китсәң, мине алып кит,
Мин таянган кул башына
Ятларны таяндырма.

Китәм, дидең, китәм, дидең,
Китәм, дидең дә киттең,
Минем нурлы йөзләремә
Лимон сарысын сиптең.

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китсәм, кала күлмәгем.
Күлмәгемне энем кияр,
Сөйгәнемне кем сөяр.

Каеш биреп нечкә итеп
Будырдылар билләргә,
Искә алып хәер бирең
Кайталмасак илләргә.

Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде томаннар,
Дөнья хәлен белеп булмый,
Хуш-саубулың, туганнар.

Китәм, дустым, китәм, дустым,
Китәм, дустым, каласың,
Мин булмагач, кемнәр сөяр
Син сандугач баласын.

Элек-электән килә. Ат белән сугышка да озатканнар.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Сәмсетдинова Гүзәлия Мозаффар кызыннан (1967 елгы) язып алынды*

* * *

Кайларга барсам да дус-ишләр кирәк
Каршы чыгып аткайларны бәйләргә,
Өчәү дә дүртәү без булаек,
Жулкайларга чыгып ук кунаек.

### *Кыска җырлар*

Без андый кызлар түгел,
Без мондый кызлар түгел,
Кеше арада хур булырга
Тутыккан калай түгел.

Алла бирса, карлар яуса,
Төлке тотарбыз әле,
Без дә ат-инә баласы
Дөнья котәрбез әле.

Анда оча, монда оча
Карурман күбәләге,
Менә шулай була икән
Туганнар түгәрәге.

Йөгерә-йөгерә тоталмадым
Кырда йөргән үрдәкне,
Гомерем булса, оныталмамын
Монда йөргән чакларны.

Аллар булганда гына,
Гөлләр булганда гына,
Күтәрелә күңелләрем
Бергә булганда гына.

Биек тауга менгән чакта
Таянырсың миләшкә,
Таянырсың да еларсың,
Мин булмамын киңәшкә.

(Исмаилов Вәли абый җырлый иде).

### *Бишек җырлары*

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кайда киткән әнкәсе,
Каенлыкка җиләккә,
Эрәйсәгә бүләккә.

Әлли-бәлли итәргә
Тал бишеге бар аның,
Җырлар җырлап бәү итергә
Үз анасы бар аның.

Әткәсенең нисе бул,
Алтын ияр кашы бул,
Әнкәсенең нисе бул,
Йөрәгенең ташы бул.

Әнкәсенә көн кебек
Әткәсенә төн кебек,
Килгән-киткән кешеләргә
Чүп кадәр дә юк кебек.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Мөхәррәмова Роза Низам кызыннан (1960) язып алынды*

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөкәррәм,
Уйнап, көлеп, биеп, җырлап
Күңелемне күтәрәм.

Әйдә, дуслар, җырлыйк бергә,
Барыбыз бергә чакта,
Озакламый таралабыз
Төрлебез төрле якка.

*Нязепетровск районы Әптерәк авылында Усманова*
*Бибимәккә Вәли кызыннан (1939 елгы) язып алынды*

* * *

Без элек вечерга чыгадырыек. Аулагыйлар еш буладырые бездә. Сәгать 5 кә кадәр утырырыек. Әйләнүләр, такмаклар, төрле частушкалар. Таң атканчы без күңел ача торганыек. Бездә элек эчке булмады. Күңелле, гел җыр, төрле җырлар, совхозга эшкә барсак, без уже җырлар өйрәнәбез.

Килдек, дуслар, Идел диңгез кичеп,
Сезне сагынып, кошлар булып очып,
Кош канатлары түгел иңемдә,
Җыр канатлары минем күңлемдә.

Әйдәгез, дусларым, җырлыйк бергә
Иң матур җырларны сайлап кына,
Иң матур җырларны сайлап кына,
Яшик бу дөньяда сайрап кына.

Нинди булса да яңа җырлар теге авылдан да өйрәнеп төшәләр:

Без алай түгел идек,
Без болай түгел идек,
Сайрамаган сандугачны
Сайрата торган идек.
Ай, зилләү-зилләү, зилләү,
Сайрата торган идек.

Эх, дускаем, сиңа әйтәм,
Гармунчы булсын ярың,
Гармунчының буыннары
Саен мәхәббәт аның.
Ай зилләү-зилләү, зилләү
Ай зилләү, зилләләү.

*Нязепетровский районы Әптерәк авылында Нурисламова*
*Нәфига Әдәган кызыннан (1936 елгы) язып алынды*

* * *

Сикереп төштем төбәккә,
Ике бөртек җиләккә,
Берсен алып салдым
Әрнеп барган йөрәккә.

* * *

Ыштаныңда шөпше (чобар) бар
Күлмәгеңдә шөпше бар,
Җитәр инде күп биедең
Чыпчыгың очып чыгар, –

Юрюзәндә туйда булдым, шунда җырлаганнар иде.

*Нязепетровск районы Йосып авылында Шакиров*
*Илсур Хәйри улыннан (1948 елгы) язып алынды*

«Йөзек салу» бар иде.

Тезелешеп утырасың да. Йөзек салып китә дә, яза (*җәза*) бирәләр: биетәләр, ерлаталар:

Бас, бас, бас әле
Идәне сынмас әле,
Сынса, ямарлар әле,
Такта табарлар әле.

* * *

Ач тәрәзә, җиләк бирәм,
Җиләктән кайтып киләм,
Сезнең нурлы йөзегезне
Мин кайчан тагы күрәм.

* * *

Һаваларда оча ике аккош
Еракларга китә юллары,
Ике аккош юлы кебек
Үтсен безнең тормыш юллары.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында Галиуллина*
*Фәния Гыйльметдин кызыннан (1932 елгы) язып алынды*

### *Җырлар*

Агыйделләрдә юмасам
Агармый beләккәем,
Әллә җилләргә истеме
Теләгән теләккәем?

* * *

Ерлый утыр, дускаем,
Ер юатыр үзеңне,
Уең булса да уйлама,
Уй саргайтыр йөзеңне.

* * *

Ай да карап миңа моңсулана
Белгән кебек минем уемны,
Кем теләми сөйгән яре белән
Гомерлеккә бергә булуны.

Туп-туп итеп килгән туры атыңның
Тояклары яшел ут икән;
Төшмәсен дә күңлең матурларга,
Мәңге сүнми торган ут икән.

* * *

Кар сулары кара,
Һаваларга менсә югала,
Аталардин бала яшьли калса,
Күкрәк көче белән мал таба.

Һаваларга менгән аккошларның
Каурыйлары коела җирләргә,
Үзе дә юк, сүзе дә юк,
Калды инде сагынып сөйләргә.

* * *

Уфа, дисең дә карыйсың
Уфаның якларына,
Үкенечле сүзең булса,
Яз иркәм хатларыңа.

* * *

Ай янында якты йолдыз
Минем йолдызым гына,
Таң алдындин ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.

* * *

Шапкасы бар, шапкасы бар
Шапкасы бар кияргә,
Шапкасы булгач кияргә
Мөмкин моны сөяргә.
Ай лиләй, лиләй, Ай лиләй, лиләй
Ай лиләй, Ай лиләй, лиләйлилләләй.

Ал да булырбыз әле,
Гөл дә булырбыз,
Әле дә бергә, тагы да бергә,
Бергә булырбыз әле.

Ай яктысы якты диеп,
Таска басып су алма.
Ярым читтә сизмәс диеп,
Ятлар белән чуалма.
Ай лиләй, лиләй, Ай лиләй, лиләй
Ай лиләй, Ай лиләй, лиләйлилләләй.

### *Озын көй*

Ирәндекәй дигән, ай, биек тау
Бөгелә-сыгыла менден башына,
Нинди генә акыл табыйм микән
Гашыйк булдым кара кашына.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында*
*Сакаева Тутыя Әгъзам кызыннан (1934 елгы) язып алынды*

### *Инәй җыры*

Җирән кашка аткаем,
Башын чайкый малкаем,

Алларында солысы бетсә,
Сызыла йөрәк майкаем.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында*
*Хәсәнова Бибисара Сабир кызыннан (1936 елгы) язып алынды*

Сары-сары, сап-сары,
Сары чәчкә саплары,
Уналтыда, унҗидедә
Кызның матур чаклары.

* * *

Әйдәгез барыек,
Чия пешкән алыек.
Яшь гомерләр үтә-китә
Уйнап көлеп калыек.

* * *

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Нигә бөгелә икән?
Шул кадәрле үзәкләрем
Нигә өзелә икән?
Әйләр, әйләр, әй зиләйләр
Нигә өзелә икән?

Тал бөгелсен, тал бөгелсен,
Бөгелсен җиргә тисен,
Онытмамын, туганаем,
Онытырлык түгелсең.
Әйләр-әйләр, әй зиләйләр
Онытырлык түгелсең.

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Каен бөгелми бит ул.
Ир ташласа да табыла,
Яшьлек табылмый бит ул.
Әйләр әйләр, әй зиләйләр
Яшьлек табылмый бит ул.

Алмагачтан алма тама
Алма пешкән айларда,

Кычкырып җырлап җибәрәм
Искә төшкән чакларда.
Әйләр, әйләр, әй зиләйләр
Искә төшкән чакларда.

*Чибәркүл районы Попово авылында Уряшева Надежда Петровнадан (1953 елгы) язып алынды*

Чылтыр-чылтыр су ага
Матур кызлар су ала,
Матур кызны кияүгә алгач,
Шадра кызны кем ала?

* * *

Әйдүк-дүдек барабан
Чәчен майлап тараган,
Тараса да үрмәгән,
Матур җегет күрмәгән.

*Чибәркүл районы Попово авылында Иштулова Светлана Николаевнадан (1952 елгы) язып алынды*

Бигрәк ямьле болыт чыккан,
Яусын болын буена,
Бергә-бергә йөрерләргә
Язсын гомер буена.

*Чибәркүл районы Попово авылында Юртеева Галина Прокопьевнадан (1940 елгы) язып алынды*

Картинәем ерлый иде:

Тау башында
Әйләнәдер бер бәрән,
Әллә бәрән, әллә адәм,
Үтте гомерләр әрәм.

* * *

Ай икегез, икегез,
Икегезнең битегез;
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез.

*Чибәркүл районы Бишкил авылында Әбелханова Шәкүрә Нигъмәтулла кызыннан (1945 елгы) язып алынды*

Кистем каен, кисмә каен,
Каен кисүе кыен.
Калдым ялгыз, калма ялгыз,
Ялгыз яшәве кыен.

*Чибәркүл районы Бишкил авылында Нигъмәтуллина Мәүлединә Фәйзрахман кызыннан (1944 елгы) язып алынды*

Әй, кодалар, кодалар,
Кодалар, кодачалар.
Сездә ничек, бездә шулай
Җырлап күңел ачалар.

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

Җырла дисең, мин җырлыем
Берне түгел, икене.
Җырламас идем икене
Сез дусларым сөйкемле.

* * *

Биек тауның башларына
Кем чәчкә чәчкән икән?
Яшь гомерне чәчкә диләр,
Чыннап та чәчкә икән.

* * *

Яшьлек бит ул бер генә,
Уза икән тиз генә,
Яшьлек бит ул гомерләрнең
Татлы мизгеле генә.

* * *

Бакчадагы чәчкәләрем
Ак чәчкә атса икән,
Чәчкә кебек яшь гомерем
Әйләнеп кайтса икән.

* * *

Бакчадагы(й) алмагачның
Тамырын корытмагыз,

Мин сезләрдән аерылгач,
Мине дә онытмагыз.

* * *

Эзлә мине, тап син мине
Кешеләр арасыннан,
Тапсаң, мине ычкындырма
Күзеңнең карасыннан.

* * *

Су буена басма салдым
Каенын сайлап кына,
Нигә бер килеп китмисең
Кош булып сайрап кына.

* * *

Ана килә машина
Төягәннәр, ди, сабын,
Бер сагынмасаң, бер сагын
Онытып йөрмә тагын.

* * *

Алмагачның чәчкәләре
Тал җиленә коела,
Хәлләремне дә белмисең
Озын көннәр буена.

* * *

Йөгереп төштем, бәке тиштем,
Курай белән су эчтем,
Инде шөкер бер Ходайга
Сеңлем белән күрештем.

* * *

Ай белән кояш икесе
Бер болыт арасында,
Бер күреп сөйләшер идем
Бер минут арасында.

**Тәтәүләрнең** *(әниләрнең)* **көйләре:**

*Кунак сыйлаганда:*

Җибәрәек ерлап, китсен шырлап,
Акрын барган атлар җул алсын,
Бардыр моңнылары, бар моңсызы,
Моңнылары йокылардан уянсын.

*Җыенда җырлый торган:*

Аракылар белән баллар эчсәм,
Исергәндәй кеүек буламын,
Сез туганнар белән бер күрешсәм,
Йөз яшәгән кеүек буламын.

Карагай агачы да каты ла агач
Ак каеннар белән әле аралаш,
Узган гомерләр күренмәс микән
Карагайга басып карагач?

### Пыяла күкәй

Пыяла күкәй тәгәрәттем, аппагым,
Париж, Париж, Парижларга җитсен дип,
Сәлам язып, хат җибәрдем, аппагым,
Чәйгә, чәйгә, чәйгә кайтып җитсен дип.

### Кәтүк түти

Кәтүк түти иртә торып суга киткән,
Кайтып җиткәч абынып егылып, суын түккән.

Кәтүк түти иртә торып мунча яккан,
Черек утын булгангамы, янмый яткан.

Кәтүк түти йөри-йөри арып беткән,
Ял итәргә утырам дип, йоклап киткән.

Маржай түти сыерчык сатып туйга киткән,
Кәтүк түти урак алып кырга киткән.

Кәтүк түти, ник елыйсың авызың җәеп?
Синдә түгел кызларда да була гаеп.

*Нагайбәк районы Париж авылында Алексеева*
*Анна Александровнадан (1941 елгы) язып алынды*

### ***Җырулар***

Кодаларым, сезгә ни бирием,
Казаннардан алган малым юк,
Җаным җарып бирер идем,
Җаннан башка торыр хәлем юк.

Тустаганнар бирсәң тулулар бар,
Подносларыңа түгелсен,
Бу тустаганнарны эчмәсәгез,
Безнең кодалар түгел сез.

Чеметеп-чеметеп камчы үрдем,
Абкайларым күндәм булсын дип,
Аркам тирләп торам җырлап
Сезнең күңлегез булсын дип.

* * *

И, ямьле дә икән бу җаланнар
Ак тирмәләр корып әле җәйләрдә.
Кайларга да барсаң дус-ишләр кирәк
Каршы чыгып аткайларны бәйләргә.

* * *

Җырак бабаемның көе:

Бәйлә, дустым, билләреңне
Син бәйләсәң бушамый,
Бу дөньяда күп дус-ишләр
Аклы сез, көй ошамый.

### ***Газиз карендәшләр***

Туганнарым, сез икәнсез
Алтын баганаларым,

Сезнең белән бергә узсын
Калган заманнарым,
Газиз кардәшләр.

Шәлем көрән, шәлем көрән
Шәлем көрәндәй күрәм,
Күкрәгемдә җаным ничек
Мин сезне шулай күрәм,
Газиз кардәшләр.

* * *

Тау иткәндә:

Урамнарга купецлар килгән,
Красный товар аламсыз,
Без ашаган, эчкәннәргә
Риза булып каламсыз.

Әти хатлар яза иде сугыштан:

Безнең авыл түбән таба
Тезелеп киткән ак каен,
Ак каенга менеп карыйм
Балаларымны сагынган саен, –
бер хатына җыру язган.

* * *

Кара урманнарның бөркете,
Атка менсә, ат уйната
Парижларның батыр җегете, –

дип, шулай җырлыйлар инде.

* * *

Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Урман күкеләре үкерсен,
Кайда җөрсәң шунда якшы җөре,
Карап калган бәндәләр үкенсен.

Карурманга кергән чакта
Калды камчым каерылып,
Калмады камчым каерылып
Калды туганнарым аерылып.

*Нагайбәк районы Париж авылында Иванова Вера Лазаревнадан (1935 елгы) язып алынды*

### *Иман җыры*

Күкәй җыйганда, акча җыйганда җырлап җыйдык бәләкәй чакта:

И, Кристос, Аллабыз,
Синең тавышың белән дөньяда белем яктысы яшьнәгән,
Шул белем яктысы белән йолдызларга табынучылар
Бер йолдыздан белеп, чыннап кояшы дип сиңа килеп баш органнар.
Сине күктән иңгән, җаңа чыккан кояш дип белгәннәр,
И, Ходай, шөкер сиңа.

* * *

Чиркәвебез бар иде. Боздылар. Шуның турында:

Еравклардан узып барган чакта
Таудан гына чиркәү күренә,
Иртәнге кыңгырау авызыннан
Бар тирә-як моңга күмелә.

Юкка гынамыни борынгылар
Нигез корган шушы урынга,
Кемнәр генә белми бу яктагы
Килей атлы авыл турында.

Таулар куенына сыенып үскән
Каенкайлар тыңлый ул моңны,
Тал-тирәкле Гомбәй буйларыннан
Сөйкемлерәк җирләр булырмы.

Кайларга да барсаң күренә иде
Килей чиркәвенең башлары,
Ата-баба салдырган чиркәүне
Дошманнар ла бозып ташлады.

### *Бригада көе*

Эшкә барганда, кайтканда җырлап кайтканнар:

Урак урган җирләрем,
Печән чапкан кырларым,
Җепәк чәчем җилбердәтеп
Туып үскән илләрем.

Безнең илләр, җирләр, сулар,
Сахрада үсә гөлләр
Хәзергедән яхшы булыр
Безнең алдагы көннәр.
Әй әйләү, әлиләем әйлиләү.

## Кунак көйләре

### *Кируш көе*

Чакырып алдым (да) чакырым (ай гай) җарымнан,
Җибәрәсем килми (бит) бер дә (ай-гай) җанымнан.
Җил туздыра да җулларның (ай-гай) тузанын,
Сизми калдым (да) гомернең (ай-гай) узганын.

### *Захаров көе*

Җибәрәек җырлап (әле у) китсен шырлап (әй-ләү),
Акрын барган атлар (да ай) җул алсын (әй-ләү).
Бар моңнылары (да әй шул), бар моңсызы (әй-ләү),
Моңнылары җылап (ай) уянсын (әй-ләү).

* * *

Карагай (да (й) агач (ай-гай) каты (й) агач,
Кайрамыйча (да) балталар ник үтсен (әй-ләй-ләү).
Сезләрдән аерылгач, җамансулап
Үлә яздым бу җәйләрне.

Кайраса балта (ай-гөй) ниен куйсын,
Үз туганнарыннан (да) кем туйсын (әй-ләй-ләү).
Сезләрдән аерылгач җамансулап
Үлә яздым бу җәйләрне.

Карагай (да) агач каты агач
Ак каеннар белән аралаш,
Узган гомерләрең күренмәс микән,
Карагайга басып карагач?

* * *

Чеметеп тә чеметеп камчы үрдем,
Аткайларым җылгыр булсын дип,
Аркаларым тирләп, җырлап торам
Сезнең күңелегез булсын дип.

* * *

Йөгереп чыктым мин урамга
Урал таукайларын урарга,
Бүген төшләремдә сезне күрдем,
Тик белмәдем нигә җурарга.

* * *

Олы җуллардан (да) барган чакта (айгайлюк)
Җуйалттым (гына) эзләреңне (ай) эзләреңне
Күп эзләдем (генә) таба (й)алмадым (айгайлюк)
Узган (гына) гомерләремне (ай) гомеремне.

* * *

Олы җулның тузанын
Күрми калдым тузганын,
Күрми калдым, сизми калдым
Яшь гомернең узганын.

* * *

Ике җегет печән чаба
Үтәр(ләр) дә үтмәс чалгысы,
Әй, акрын килә, ипләп килә
Иштергә (әй) сандугач сайрауларын.

Үтәр иде (дә) чалгысы
Матур кызлар кайгысы,
Әй, акрын килә, ипләп килә
Иштергә сандугач сайрауларын.

Ике җегет киңәш итә
Сары сандугачлар тотарга,
Ай, акрын килә, ипләп килә,
Иштергә сандугач сайрауларын.

Сары сандугач тоттырмас,
Җегет үзен-үзе оттырмас,
Ай, акрын килә, ипләп килә,
Ишетергә сандугач сайрауларын

Ике җегет киңәш итә
Сату малкайларын бүләргә,
Җегет кеше риза була
Берсе өчен берсе үләргә.

* * *

Гомбәй буйкалары киңнәр җалан (да),
Түмгәкләре бар шул җаман,
Бергә җөрүләре берләр заман,
Аерылып киткәч шул җаман.

Ямьнеләр (дә) болыт чыккан диләр,
Яусын иде Гомбәй буена,
Берләргә дә бергә җөрерләргә
Язсын иде гумер буена.

Гомбәй буе гөдрә таллык,
Талларында сандугач,
Сандугач моңны тавышын
Тыңлыйм сезне сагынгач.

Еракларлан карап килəм
Синең басуларыңа,
Шунда гына тынычланам
Йөрәк ярсуларына.

Тау астында, тал астында
Салкын чишмә түгәрәк,
Очып барып күрер ием,
Булсам сары күбәләк.

* * *

Җәйге җәмне кырларда
Бик ямансу кичләрен,
Җәйге кичтә яратам мин
Кырда арыш исләрен.

Җәйге җәмне кырларда
Дулкыннана арышлар,
Йөрәктә уянып куя
Онытылган сагышлар.

Җәйге җәмне кичләрдә
Карыйм сезнең якларга,
Чык каршыма күрешербез
Эштәк кайткан чакларда.

* * *

Ак-ак чүперәк бәйләр ием,
Булавка кадар ием,
Эй артыннан барыйм микән,
Эзләсәм табар ием.
Ай, ак калфак, зәңгәр шәл
Үтә гомерем – шунсы жәл.

Ал чүпрәгем алмы әллә,
Алдыңда алма бармы әллә?
Сандугач күк син сайрыйсың
Авызыңда кош бармы әллә?
Ай, ак калфак, зәңгәр шәл
Үтә гомерем – шунсы жәл.

* * *

Кулҗаулыкларым да шул, әй, күп ие
Иптәш саен да тараттым,
Җуалды ла яка чылбырым,
Алдамам сылуым, сары былбылым,
Бар иптәшләр арасыннан.
Сезне генә бигрәк яраттым,
Җуалды ла яка чылбырым,
(Ай-яй) алдамам, сылуым, сары былбылым,

Кулҗаулыгым (гына шул) төшеп калды
Кесәмнән (генә) көзге белән,
Җуалды ла яка чылбырым.
Үтә генә гомерем, димәс ием.
Алдамам, сылыум, сары былбылым,
Яшәсәм дә сезнең беләν.
Җуалды ла яка чылбырым,
Алдамам, сылыум, сары былбылым.

* * *

Ары очтамы өегез дә
Бирге очтамы өегез?
Бергә-бергә йөргән чакта
Җырлый торган көебез.

Аргы очтан бирге очка
Агып килә җомычка.
Аргы очка бармасыем,
Сөйгән ярем шул очта.

Ак куян дип атканыем,
Булды ташка атлаулары,
Җугары очтан берәү килә
Ай зәлей атлаулары.

* * *

Кодаларым, сезгә ни бирәем,
Казаннардан алган, ай, малларым юк,
Җаннарымны җарып бирерләрием,
Җаннан башка торыр, әй, хәлләрем юк.

* * *

Һаваларда очкан аккошларның
Күреп калдым үтеп китүен,
Эх, авыр да булды озатулары
Аннан да авыр – сәлам көтүе.

Һаваларда очкан аккошларның
Канат очларында зәңгәр бар,

Исәнме икән, саулар микән?
Сугыш бетте, дигән хәбәр бар.

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары күмә коела,
Таң алдыннан тәрәзәмне чиертеп,
Кайтып керер кеүек тоела.

Сугышка киткәндә:

Ап-ак җауган кар өстеннән
Таба алмадым улымның эзләрен,
Әллә табармын эзләрен,
Оныталмам әйткән сүзләрен.
(Ап-ак җауган кар өстеннән).

Монысы сугыш беткәч җырлыйлар ие 9 майга:

Бурайлар да бурай карлар яуса,
Боекмыйдыр болан баласы,
Калдык җанын, канын биреп,
Илләрне дә саклый аның баласы.

41 нче елларда
Герман сугыш башлады,
4 ел буенча сугышты,
Безне җиңә алмады.

Өелеп-өелеп кар түгелде
Сугыш үткән җирләрдә,
Илне саклап үлеп калды
Арысландай ирләр дә.

Күрдек барысын да,
Дус дип йөредек –
Дошман булды,
Кырды бит халыкны да.

Яшь кенә хатын-кызлар да
Ни табалар үрләрдә,
Ач-ялангач эшләп йөрдек,
Дошман динне бетмәдек.

75 ел үтеп китте
Искән җил күк гомерләр,
Әле дә булса йөрәкне кисә
Үлеп калган җегетләр.

* * *

Мендем Аркаим тавына,
Бастым мин ташларына,
Җылы җилләр исә икән
Тауның иң башларында.

Аркаим тау өсләрендә
Беренче күрдем сине,
Бер күрдем дә, хушсыз калдым
Син аңгармадың мине.

*Нагайбәк районы Кили (Кассель) авылында Миняева Зоя Прохоровна (1935 елгы), Букачева Роза Прохоровна (1938 елгы), Хөснетдинова Екатерина Кирилловна (1939 елгы), Тихонова Зоя Георгиевнадан (1940 елгы) язып алынды*

* * *

Сандугачлар җыелганнар
Чия куакларына,
Нинди җырлар җырлыйм икән
Сөйгән кунакларыма.

Сандугачлар җыелганнар
Алма коелган җиргә,
Җырламыйча түзә алмыйм
Дуслар җыелган җирдә.

Сандугачлар су дип эчә
Үләндәге чыкларны,
Өзлеп-өзлеп сагынырбыз
Бергә булган чакларны.

Сандугач баласы сары
Күгәри баласы күк,
Сагынмаган көннәремнән

Сагынган көннәрем күп.
Әй-лә әй ләй ләм, әйләйләр әйләләү.

*Нагайбәк районы Кили (Кассель) авылында Хөснетдинова Екатерина Кирилловнадан (1939 елгы) язып алынды*

Стаканнарыңа салсаң, тутырып сал,
Подноскайларыңа түгелсен,
Шушы стаканны эчмәсәгез,
Безнең кодаларыбыз түгел сез.

Кайдан килдегез сезләр (дә) безгә
Төшмәенчә (генә дәй, ай) диңгезгә,
Төшәрләр дә идегез сез диңгезгә
Душой ерак торабыз (ай) без сезгә.

* * *

... дала шул ай балтырган
Җаңа бәбәк өйләргә (ай йу) утырган
Өй эчләребезгә дә җәмнәр дә кергән.
Дус-ишләребез килеп үк (ай йу) утырган.

Самый кунакларны сыйлый торган көй.

* * *

Басма очларында бала үрдәк,
Сибәек тә бодай, симерсен.
Китәек тә ерак, калсын да җылап
Бер күрергәйләргә дә тилмерсен.

Ургылып-ургылып ага кое суы да
Ник басылмый бу җөрәкнең ярсуы,
Басма очларында ла бала үрдәк
Бодайлар да ашап туйләнгән.

Без эткәйдән дүртәү калдык
Бер бишеккәйләрдә тирбәлгән,
Ургылып, ургылып ага да кар суы,

Ник басылмый бу җөрәкнең ярсуы.

Бар да борынгы җырулар.

* * *

Бергәләр дә уйнап, бергә көлеп,
Апакай-алмакай,
Бергә генә үтсен гүмерләр.
Сагыну да түгел, саргайсаң да,
Апакай-алмакай,
Килмәсен лә безгә бу көннәр.
Тәмнеләр дә татлы җырлашыек,
Апакай-алмакай,
Болар бертуганнар дисеннәр.

* * *

Сәламнәр языйм микән,
Янына барыйм микән?
Бик сагынган чакларым да
Кемнәргә карыйм икән?

* * *

Машиналар урамнан үтә
Төн караңгы булса да,
Аерылганда җыламыем
Күңелләрем тулса да.

* * *

Бас әле станокка,
Ыстаннары ыстанда.
Безнең кадерле туганнар
Яши Татарстанда.

*Нагайбәк районы Кили (Кассель) авылында*
*Миняева Зоя Прохоровна (1935 елгы),*
*Букачева Роза Прохоровна (1938 елгы),*
*Хөснетдинова Екатерина Кирилловна (1939 елгы),*
*Тихонова Зоя Георгиевнадан (1940 елгы) язып алынды*

### *Ишле җәмәгатьтә мин тудым...*

Ишле җәмәгатьтә мин тудым.
Дәдәйләр белән, түтәйләр белән
Тугыз яшьтән эшкә тотындым.

Бик күңелле ие туганнар белән
Бергә-бергә гомер итүе,
Җәйге көннәрдә таң нуры белән
Төялешеп эшкә китүе.

Күпкә бармады бакытлы көннәр,
Тиздән канлы сугыш башланды,
40 яшьтәге безнең әткәбез
Ут эченә илтеп ташланды.

Гумере күрмәгән тимер арбалар
Урамнардан узып баралар,
Әткәйдән калган туры атыбызны
Алып чыгып китеп баралар.

Зур дәдәй китте кызыллар белән
Дошманнардан илне сакларга,
Бәләкәй дәдәй мылтыгын алып,
Үз иркенә китте акларга.

Бердәгенәй көнне урман эчендә
Ишетелә мылтык тавышы,
Зур дәдәй, бәләкәй дәдәй
Атышалар кара-карашып.

– Атма, туганай, куй мылтыгыңны,
Энекәшең бит соң мин синең,
– Юк минем энем бүгенге көндә,
Туганаем түгел син минем.

– Син үзең теләп акларга киттең,
Сезнең өметегез кан түгү,
Коллыкка төшеп бәйләр
Өчен халык интегә.

Шулай диде дә мылтыгын төзәп,
Чакмасын тартырга кыймады,
Ул җитешкәнче, бәләкәй дәдәй
Итеп җөрәгенә кадады.

Бөгелеп төшә сары чәчкәләр
Көннең кызуында болында,
Каргалар белән козгыннар гына
Калды туганаем янында.

Шушы хәлләрне бәләкәй дәдәй
Кайтып җылый-җылый сөйләде
Күп тә тормады чыгып ук китте
Бүтән өйгә бер дә кайтмады.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында*
*Артемьева Зоя Евгеньевна (1940 елгы),*
*Байкина Евдокия Ильиничнадан (1941 елгы)*
*язып алынды*

### ***Париж***

Пыяла күкәй тәгәрәттем, аппагым,
Париж, Париж, Парижларга җитсен, дип.

Сеңлем язып хат җибәрдем, аппагым,
Чәйгә, чәйгә, чәйгә кайтып җитсен, дип.

Утыр, диде, урын бирде, аппагым,
Нигә, нигә, ник утырмадың микән?

Хуш бул, диде, кулын бирде, аппагым,
Нигә, нигә, ник кул бирмәдем икән.

* * *

Безнеңләргә турга суга төшмә
(Ай за, яный, ой бит Гомбәйкә буйлары)
Басмалары җомры (әйләрем) таярсың,
Сезнең(ләрдә) кеүек яхшылардан (гына)
(Ай за, яный, ой бит Гомбәйкә буйлары)
Бер җыруым ничек (әйләрем) айарсың.

Чүләгәйдә үрдәк (әле) күл(ләр)гә чума(ла)
(Ай за, яный, ой бит Гомбәйкә буйлары)
Күлләрнең(дә) асыл (әйләрем) ташы(йы)на.
Ни эшләрдә килеп (әле) ни эш(ләр) китмәй(лә)
(Ай за, яный, ой бит Гомбәйкә буйлары)
Ир җегетнең газиз (әйләрем) башына.

* * *

Менә казак озатканда шушыны җырлыйлар. Казак дигәннәр инде солдатка. Инде казакны алып китәләр төнлә, без күрмибез, озатканны күрмибез, аннан соң яшьләр:

Казак китә озатаек
Комаякка җиткәнче,
Ага торган, акмый торсын
Без аерылып киткәнче.

Казак китә озатаек
Комаякка(йларда) җирләргә(я) (лә) җиткәнче,
(Эй) аккан (да) сулар акмаенча торыр
Без аерылышып (әйләрем әле) киткәнче.

Балчыккайда чүлмәк тарлар да авыз
Кайный да диләр бит казакларның да ашлары,
Ай очып та кошлар җитмәсләр җиргә
Җитә дә диләр бит казакларның да башлары.

Кояшлар да чыга әйләнеп,
Җүкә агачларга бәйләнеп,
Исәннәр дә булып, саулар кайтыр
Җир итәккәйләрен әйләнеп.

*Нагайбәк районы Сарашлы (Остроленко) авылында*
*Исаева Евдокия Артемьевна (1949 елгы),*
*Артемьева Зоя Евгеньевна (1940 елгы),*
*Байкина Евдокия Ильиничнадан (1941 елгы) язып алынды*

## Балалар фольклоры

### *Санамыш*

«Яшеренмәк» уйнайбыз. Яшенмәккә әйтәсең:

– Әбкә, бибкә, ләмән дөпкә зәвер зәмбәр ите ямбәр эләгәч куян торна озын торна чык монда, торма, бар чык. Син чыгасың икән, син карамайсың. Аннан кешеләрне эзләп табарга кирәк. Шулай уйнай торганыек.

* * *

– Ала куян кайда барaң?

– Кәмә белән тозга барам.

– Яз килмәсәң көз килерсең, эләгерсең тозакка.

Аннан соң последний кеше, анда бит кешеләр күп тора, миңа килеп етте икән, мин карамаем.

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

### *Санамыш*

Германиядан бер абый кайтты:
Шутыр-мутыр шомыр- шу шап-шаллыгым бугум бу.
Шатыр-шотыр шум-шурук...
Хәзер оныттым, шулай чутлый иде, кем кала

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында Мугафина Фәгыйлә Хәбиб кызыннан (1938 елгы) язып алынды*

Качышлы уйныйдырыек. Өйләр артында. Считалка бар ие бит әй, ввиде стишка. По бакалински не помню. Минем бабау Казан ягыннан. Безне: Бакала, бакала 3 копейки не дала, – дип ирештеләләр.

*Чибәркүл районы Попово авылында Уряшева Надежда Петровнадан (1953 елгы) язып алынды*

Ку-ку,чыпчык, тәрәздән очып-чык,
Инәңнең башына май сөрт,
Атаңның башына бук сөрт.

*Чибәркүл районы Попово авылында Иштулова Светлана Николаевнадан (1952 елгы) язып алынды*

Шүрәле, әпәй кисеп бир әле,
Бу әпәең тәмне булды,
Тагын кисеп бир әле.

Пич башына утырабыз да. Без 10 булдык. 10 бала, әти инвалид, ул эшләде председатель булып. Инәем колхозга әпәй салды. Әпәй салгач, ач булмаганбыз инде. Әпәй исе чыга. Тары ярмасыннан күптермә пешерә идек. Инәй күптермәне счёт белән генә сала тракторисларга, отдельно ашата. Карабодай әпәен тоже тракторисларга. Шуннан хәзер кисеп бирә безгә бирәр кисәк. Без ерлап утырабыз:

– Шүрәле, әпәй кисеп бир әле..., дип.

– Балакаем, ди, абыйларыңа пешерәм бит, ди.

* * *

Картинәй ерлап утыра иде Әлли-бәлли бәбкәсен:

Әлли бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әңкәсе,
Каенлыкка җиләккә,
Минзифага бүләккә.

*Чибәркүл районы Бишкил авылында Нигъмәтуллина Мәүлединә Фәйзрахман кызыннан (1944 елгы) язып алынды*

Хәзер зүзек дудкәсе,
Пешер арыш боткасы,
Ашасын да кикерсен,
Кызын безгә китерсен, –

дип утыра торганые әби.

* * *

Кызлар кия кызыл ыштан
Безгә карасы да юк.
Кызлар безгә үзе килә,
Безгә барасы да юк.

* * *

Тәкә-мөке (әкәм-төкәм) мөгезең чыгар,
Сөтле сыер бирермен,
Сөтле сыер яратмасаң,
Артыңа чыбык бирермен.

* * *

Кача-кача уйнаганда әйтә торган идек:

– Аладан, коладан, песи йөри колгадан.
Алдат-болдат столовый солдат, син кал – син чык, – дип.

* * *

Балта-топор не надо,
Урыс мине кыйнады,
Кыйнамады, сукмады
Үтергәнче тукмады.

* * *

– Ни ашадың?
– Ботка.
– Каян чыктың?
– Басмадан.
– Ни апчыктың?
– Капчык.
– Капчык эчендә ни?
– Көл.
– Көл эчендә ни?
– Көлке.
– Ник көлми?
– Үзең көл.
– Мин пәрештә, син шайтан.

### *Санамыш*

Әкте фәкте чүкетнә. Әвел фәвел дүмәнә. Ике-пики граматика, наур, – дип, саныйдырыек.

* * *

Аннан балалар үскәндә:

– Песием, песием кая бардың?

– Әбиемә бардым (алдыңа утыртып аласың да, сөясең инде болай инде кулын).

– Ни ашадың?

– Май ашадым.

– Ник миңа да апкайтмадың? Прәс-прәс, – дип ебәрәсең.

*Нагайбәк районы Париж авылында Алексеева Анна Александровнадан (1941 елгы) язып алынды*

**Халык сүзләре, паремияләр**

Күрше хакы – тәңре хакы.

* * *

Байлык – бер айлык.

* * *

Кадерен белсәң, бала-чагаңа да кала (*хәерчелек*).

* * *

Иргә караганда, бала үлгәч бик ачы була. Бала кайгысы ачырак.

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында Сакаева Тутыя Әгъзам кызыннан (1934 елгы) язып алынды*

Белмәгәне ас, Бухардагы каз.
(умный кешене шулай әйтәләр).

* * *

Әдәм пәрештә булмый,
Тигәнәк (Әрекмән) кәбестә булмый.

*Чибәркүл районы Попово авылында Сошникова Валентина Ивановнадан (1949 елгы) язып алынды*

Сантый кешене чәчмибез, алар үзе үсә.

* * *

Жаныңа чир тисә, янчыгыңны талый.

* * *

Нәнәү әйтә: Александрга барган идем, ди, сад кырында тора, ди.

– Александр, нишләп торасың?

– Ямансулап торам.

– Нигә ямансулыйсың?

– Нәнәү, тәтәү үлде, хатыным кеше баласы, – дип әйтте, ди.

* * *

Паси әби сүзе:

– Үлгәннең көн дә бер шырпысы сүнә.
Тере хәсерәт бигрәк тә кыен, – дидер ие.

* * *

Ай күрдем айман белән,
Авызым тулы иман белән.

Ай күрсәң, әнием шулай өйрәтә торган иде. Карап кына торма, дип.

*Нагайбәк районы Париж авылында Алексеева Анна Александровнадан (1941 елгы) язып алынды*

**Табышмаклар**

Бер тычканда ике койрык,
Аның ике бавы бар ла. *(Чабата)*

* * *

Мич тулы пәрәмәч,
Уртасында бер күмәч. *(Ай, йолдызлар).*

* * *

Әбиләр әйтә торган ие:

Сылт итте, сылтыена кереп китте. *(Йозакны ачасың).*

* * *

Сары бия сия
Сигән ере тия. *(Самовардан чәй агызу)*

* * *

Бүген булды бик кызык,
Китте баҗалар кызып,
Берсе менә, берсе төшә,
Берсе тора торгызып. (*Самавыр*)

Самовар бора бит, борыны торып тора, комганнан сәй көйлиһең дә мендереп куяһың, төшереп көйләһең.

* * *

Читән аша җан тартыша. *(Кул пычкысы)*

Пычасың бит инде. Утын бысалар.

* * *

Сыңар аяклы саескан коега барып су эскән. *(Чүмеч белән су эчү)*

* * *

Бәләкәй генә көчек,
Өрми дә, керетми дә. *(Йозак)*

* * *

Бөлки генә бөлде
Миңа карап көлде. *(Көзге)*

* * *

Ток (*капчык*) – күлтәсе юк. *(Кое)*

*Нязепетровск районы Арыслан авылында Җиһанова Мәликә Мәгамүр кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

* * *

Дөбер-дөбер дүртәү,
Александр икәү,
Федор мескен берүзе. *(Сыер)*

*Нязепетровск районы Чулпан (Горшенино) авылында Галиуллина Фәния Гыйльметдин кызыннан (1932 елгы) язып алынды*

* * *

Җир астында албасты утыра
Чыкса безне куандыра. *(Кишер)*

*Чибәркүл районы Попово авылында Сошникова Валентина Ивановнадан (1949 елгы) язып алынды*

* * *

Көндез эленеп тора, төнгә тишек эзли. *(Келә, крючок)*

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

* * *

Карт әбинең җомаклары:
Яңакласаң тычкаклый, ди. *(Он иләү)*

* * *

Чытыр-мытыр арасында
Эшти (Степан) таяк ыргыта. *(Киндер сугу)*

*Нагайбәк районы Париж авылында Алексеева Анна Александровнадан (1941 елгы) язып алынды.*

**Мәзәкләр**

Урыс белән башкортның басуы рядом булган. Ашлык чәчәләр икән. Урысның мона шулай үсә, ди, ә моныкы болай гына.

Шуннан әйткән башкорт:

– Әйдә, улым, русча сөйләшеп чәчеп карыйк әле, безнеке дә урысныкы шикелле булмас микән. Шуннан чәчәләр икән.

– Сынок, принеси мешок, – ди икән. Тегесе оныткан бит мешок нәрсәкәй икәнен хәзер:

– Атай, токтымы (*капчыкмы*)?

– Токты инде, токты, тагы ач калдык инде, – дип әйтә икән.

* * *

Уполномоченныйлар авылга килеп йөргән, тикшереп, ничек эш бара.

Теге сорый икән:

– Мин бу авылда йөрим, миңа ашарга кая, йокларга кая?

Менә шул өйдә сиңа бөтен әйбер булыр. Килгән бу шул өйгә. Ашарга әзер. Бу ашаган да әйткән:

– Менә мин культурный кеше, сезгә бәйләнеп тормыйм, – ди икән.

Итмәсәң итмә, караваt шунда, ят та йокла. Ятып йоклаган, иртән торган, караса, өстәлдә бер әйбер дә юк икән.

Теге хатын, ике әтәч бер тавык, бер әтәчне ашата икән, бер әтәчне юк.

Бу:

– Нигә сез тавык белән әтәчне ашатасыз, бусын юк?

Хатын:

– Ул да синең кебек культурный, бәйләнми, аны ашатасы юк, – дигән.

*Нязепетровск районы Йосып авылында Яппаров*
*Нәкыйп Шакирҗан улыннан (1948 елгы) язып алынды*

Бер сөйләгәннәр ие. Син мунчага керсәң тиз генә юыш та чык, анда шайтан иярләшкән шикелле. Ул мунчага барып кергән. Юышкан да чабынырга утырган. Яфрагы тегенең раз, элеккән:

– И-и, шаярма, җибәр, – теге үзе яйлап кына ләүкәдән шуышып төшеп бара. Ыштансыз, күлмәксез килеп керде, ди.

– Нәрсә булды?

– Анда шайтан, яфрактан тотты.

Иртә белән кереп карасалар, кадак кәкрәеп торган. Яфрак шуңа эләккән булган. Бу тарткан-тарткан да артка борылырга курккан инде. Тайган мунчадан. Инәдән тума килеп керде, ди, өйгә.

*Уй районы Әмин авылында Дәүләтшин*
*Марс Шайкамал улыннан (1948 елгы) язып алынды*

## ЧИЛӘБЕ – ДАСТАННАР БИШЕГЕ

*Лилия Мөхәммәтҗанова*

Дастан – фольклорның борынгы һәм затлы жанры. Дастаннар, кайчандыр, чичәннәр тарафыннан әйтелеп, телдән-телгә күчкән, халыкка таралып, танылу яулап, гасырлар кичкән. Хәлбуки телдән әйтелә торган халык дастаннары бүгенге көндә – гамәлдән еракта торып калган ядкәрләр. Татарлар яши торган урыннарга уздырылган экспедицияләрдә информантлар белән аралашкан фольклорчы галимнәр кыйпылчык кына булып калган эпик җырга яисә фабула характерында гына булса да дастан сөйләүчегә юлыгуны зур уңышка саный. Чор бүтән, замана үсеш-үзгәрештә. XXI гасырда яшәүче, үз ана теленең тәмен онытa баручы, нечкәлеген тоемлап бетерә алмаучы буын эпос-дастаннарыбызны белми.

Чиләбе җирлегендә яшәүче татарлар тарихи яктан төрле этник компонентлар кушылмасыннан гыйбарәт. Биредә борынборыннан шушында көн күргән җирле халык, XVI гасырлардан алып төрле чорларда бирегә күпләп агылган Казан арты кешеләре, Идел буеннан яисә башкорт далаларыннан күченеп килгән мөселманнар һ.б. бүгенге көндә халкыбызның гаять үзенчәлекле бер катламын тәшкил итеп яшиләр. Шуңа күрә Көньяк Уралда яшәүче татарларның рухи мәдәнияте, аерым алганда фольклоры гаять кызыклы, бай, төрле яклап өйрәнүне сорый.

Бу як кешеләре фольклорны теркәп һәм теркәтеп калдыруга элек-электән зур өлеш керткәннәр. XX йөзнең 80 нче елларыннан

алып, татар халык иҗатының кайсы гына жанры буенча нинди генә җыентык чыкса да, аларда Чиләбе өлкәсендә яшәүче халык вәкилләреннән язып алынган яисә аларда саклана торган язмалардан күчерелгән фольклор әсәрләрен, я булмаса алардан язып алынган вариантлар турында мәгълүматларны очратуы кыен түгел.

Мәсәлән, 1978 елда һәм 1979 елда Институтыбыз галимнәре бу яклардан шактый зур хәзинә туплап кайтканнар. 1978 елның июлендә Чиләбе өлкәсе Коншак районы Коншак, Мөслим, Үзбәгәрәк авылларына Котдус Хөснуллин (җитәкче), Рәшит Ягъфәров, Асия Садыйкова, Камәрия Ямалетдиновалардан торган төркем экспедициягә чыккан. Ә 1979 елның июнендә Илбарис Надиров (җитәкче), Ленар Җамалетдинов, Асия Садыйкова, Сәлим Гыйләҗетдинов, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Рәшит Ягъфәровтан торган төркем, икегә бүленеп, Чиләбе өлкәсе Троицк, Октябрьск, Варна районнарында эшләгән.

Ул чорда экспедицияләр аерым бер юнәлеш буенча үтә торган булган. Галимнәр татар авылларында йөреп, халык белән әңгәмә корганнар. Бу чорда шактый берәмлектә халык җырлары, бәетләр, табышмаклар, риваять, мифологик хикәятләр, хәтта дастан вариантлары, әкиятләр җыелганлыгы турында мәгълүмат бар. Шунысы куанычлы: аларның күбесе бүгенге көнгәчә чыга килгән җыентыкларда, академик томнарда урын алган. Кульязмалар үзләре бүгенге көндә, башка кульязмалар белән бергә, Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә бик яхшы хәлдә саклана[1].

Әйткәнебезчә, Чиләбе татарлары иҗаты галимнәр игътибарын эпик фольклор, аерым алганда эпос-дастаннар җәһәтеннән гаять нык кызыксындыра торган төбәк. Көньяк Урал территориясе – татар тел-авыз иҗаты хәзинәсе өчен «тере» эпос доноры

---

[1] Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге (алга таба: ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ). Фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сакл. бер. 1–12, 13, 14, 15, 16–18, 18–21, 30–35, 36–37, 38, папка 2, сакл. бер. 19–65; колл. 90, папка 1, сакл. бер. 1–2, 19–65 һ.б.

булган Себергә барып тоташа торган төбәк, бу җәһәттән дә галимнәрдә Чиләбе өлкәсе татарларында дастани эпосның үсеш үзенчәлекләре шактый кызыклы. Дастан – халык тормышын эпик планда чагылдыра торган жанр, биредә очрый торган эпик истәлекләр шушында гомер итүче татарларның үзенчәлекле тарихы, тормыш рәвеше хакында бихисап мәгълүмат бирә ала, күп яклап гомуми нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек тудыра.

Чиләбе өлкәсе татарларыннан язып алынган дастани миraска килсәк, бу катламны бик ярлы дип әйтеп булмый. Үз чорында бу төбәктә «Сәйфелмөлек», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу», «Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет» дастаннары, шушы ук һ.б. дастаннарның эпик җырлары, фабула характерындагы хикәятләр табылган һәм теркәлгән, беренчел фәнни әйләнешкә кертелгән.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә «Кузы Көрпәч белән Баянсылу»ның Чиләбе өлкәсе Коншак авылында Сабира Шәфикъ кызы Гайнетдиновадан (1907 елгы) Рәшит Ягъфәров тарафыннан магнитофонга язып алынган язмасы[1] һәм аның күчермәсе[2], Троицк шәһәрендә Фаизә Гобәйдуллинадан Асия Садыйкова язып алган «Кузы Күрпәс белән Майсылу» варианты[3] саклана. Шушы язманың «Кузый Курпас белән Майсылу» дип исемләнгән тексты беренче мәртәбә 2004 елда «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында басылып чыкты[4]. «Кузы Көрпә белән Баян Сылу» дастаны – татар фольклорында киң таралган, аның барлыгы ике дистәдән артык варианты мәгълүм. Дастан Казан китап

---

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, 1979, кассета № 1.

[2] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 90, папка 2, сакл. бер. 19.

[3] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сакл. бер. 33.

[4] Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче – Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. Б. 187–193.

нәшриятларында 1878, 1890, 1896, 1909 елларда дөнья күргән. Сюжет сызыгы һәм сәнгатьчә үзенчәлекләре буенча вариантлар бер-берсеннән артык аерылмыйлар, бер версияне тәшкил итәләр. Татар версиясе вариантлары тугандаш халыклар иҗатындагы (башкорт, казакъ, алтай) версияләре белән шактый охшаш. Татар телле версиянең егерме өч вариантының берничәсе Чиләбе өлкәсендә гомер иткән информанттан язып алынган булу – игътибарны җәлеп итәрлек факт.

Сәйфелмөлек – безнең халыкта кульъязма булып та, китап рәвешендә дә, шулай ук сөйләмә формада һәм эпик җыр рәвешендә дә күпләп таралган, яратып укылган әсәр. Аның сюжеты атаклы язма чыганакка – «Мең дә бер кичә»гә барып тоташа. Гарәптән фарсыга, фарсыдан төрки телгә күчеп таралган әлеге сюжет татарларга бик борынгыдан билгеле. Төрки шагыйре Мәҗлисинең XVI гасыр башларында шушы сюжетка күләмле бердәнбер әсәр иҗат итүе мәгълүм. Шагыйрь үзе «Сәйфелмөлек» дастанын фарсы телле язма чыганактан алуы турында әйтә[1]:

Вә ли ул нөсхә фарсы вә нәсер,
Ирер садә хикәят сәррәхум кыср.
Кылыптыр Мәҗлиси бу сүзе пордаз.
Укысаң, кылыр җан кошыны пәрваз.

*Ягъни*: «Фарсыча прозада гадирәк кенә яңгырашлы ягымлы хикәятне Мәҗлиси бизәкле ясады, укысаң, җан кошын канатлы итәр».

Дастанның Мәҗлиси варианты – фольклор белән тыгыз бәйләнгән, әмма әдәбилеккә дәгъва итә торган гүзәл, гаҗәеп камил шигъри әсәр. Аның борынгы язуы белән бергә хәзерге әдәби телгә күчерелгән тексты бездә китап булып дөнья күрде[2]. XIX йөз башы – татарларда милли әсәрләр ныклап торып басма китап рәвешен ала башлаган чор. «Сәйфелмөлек» шушы процесста иң

---

[1] *Мәҗлиси*. Сәйфелмөлек: дастан / төзүче һәм кереш сүз авторы Ф. Яхин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 8.

[2] *Мәҗлиси*. Сәйфелмөлек: дастан... 374 б.

әүвәл катнашып китүе белән әһәмиятле, ягъни татар телле беренче дөньяви басма китап булып Казанда 1807 елда нәкъ менә «Сәйфелмөлек» дөнья күрә[1]. Бу вакыйга, татарларда гына түгел, гомумән төрки дөньяда «Сәйфелмөлек»нең тәүге мәртәбә басылып чыгуы була.

«Татар халык иҗаты. Дастаннар» томына (1984, б. 151–158) «Сәйфелмөлек»нең Ф. Әхмәтова тарафыннан Түбән Новгород өлкәсе Пильна районы Петрякс авылында Ләйлә Алимовадан (1924 елгы) язып алынган варианты кертелгән. Шушы ук текст «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында да урын алган (б. 110–118). Дастанның мәгълүм татар телле вариантлары дистәдән артып китә. Барысының да сюжетында Сәйфелмөлеккә багышланган Мәҗлиси әсәре йогынтысы, шулай ук XIX йөз башыннан Казанда китап рәвешендә чыгарыла килгән басма вариантлары белән якынлык сизелә. Мәҗлиси дастаны татар халкында «Сәйфелмөлек» сюжетының популярлашуына бик нык йогынты ясый. XIX гасыр башыннан бу әсәр, Мәҗлисинеке белән чагыштырганда, кайбер үзгәрешләр кичереп (кыскартылган вариантта яисә ниндидер өлеше төшереп калдырылып), әмма күп очракта шактый тулы килеш Казан типографияләрендә кат-кат басыла. Аның 1807, 1838, 1840, 1841, 1849, 1858, 1864, 1880, 1883, 1888, 1895, 1898, 1902, 1903, 1909 елларда Гимназия, Университет, Коковин, Чиркова һ.б.ның типографияләрендә нәшер ителүе мәгълүм.

XIX гасырдан алып XX йөз башына кадәр басылып килгән бу дастанны «Сәйфелмөлек»нең Мәҗлиси вариантына якын, әмма шактый дәрәҗәдә халыклашу кичергән вариантлары дип санарга тулы нигез бар. Боларда авторлык күрсәтелмәгән, әсәр «Сәйфелмөлек китабы», «Сәйфелмөлек кыйссасы», «Сәйфелмөлек хикәяте» исеме белән басылган. Күләме төрлесенеке төрлечә: 31 яки 52, 54, 64, 72, 115, 125 битләрдән тора. Сюжеты белән «Әлфе ләйлә вә ләйлә» («Мең дә бер кичә») әкиятләренең

---

[1] Сәйфелмөлек. Казан: Гимназия тип. Йосыф Исмәгыйль улы Апанаев нәшере, 1807. 124 б.

756–778 нче төннәренә барып тоташа торган шигъри дастаннар[1]. «Сәйфелмөлек» – басма формадагы китаби дастан. Ул яңадан халык сөйләменә күчеп, тел-авыз иҗаты буларак яшәвен дәвам итүе белән дә кыйммәтле истәлек. Аның татар версиясе XIX гасырның беренче чирегендә формалашкан булуы да ихтимал.

Әсәрнең билгеле вариантларыннан берсен Чиләбе өлкәсе Троицк шәһәрендә яшәүче Фаизә Зәбир кызы Гобәйдуллинадан (1877 елгы, тумышы белән Татарстанның Әлмәт районы Кәшер авылыннан) 1979 елда Институт тарафыннан оештырылган фольклор экспедициясендә Асия Садыйкова язып алган.[2] Сюжеттагы кайбер үзенчәлекләре, өстәмә образлар һәм текстта очрый торган морфологик-синтаксик аермалыклары булуга карамастан, дастан, нигездә, моңа кадәр басылган вариантка шактый якын. Әмма ике вариантны янәшә куеп тикшерү эпос белгечләре тарафыннан әлегәчә башкарылмаган, дастанны киләчәктә мондый махсус өйрәнү галимнәр өчен перспективада кала бирә.

Татар эпос жанрында популярлыгы ягыннан иң алдынгы урынны «Йосыф – Зөләйха» сюжеты били. «Йосыф – Зөләйха» хакында дастаннар – татарлар арасында бик киң таралган әсәрләр. Бу сюжетның безнең халыкта киң таралуына Тәүраттан ук килүче Ягъкуб һәм Йосыф пәйгамбәрләр образының исламда, Коръәндә киң яктыртылышы йогынты ясаган булса кирәк. Әмма Йосыфка багышланган дастан кулъязмаларының нәкъ менә Идел – Урал буе татарларында күпләп табылуы һәм саны 160 тан артып киткән кулъязманың һәркайсы Казан татарлары тарафыннан башкарылган булу[3] факты төп игътибарны нәкъ менә Идел буе Болгарының мәшһүр шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына юнәлтә. XIII гасыр башында иҗат ителгән бу поэманың татар әдәбиятына һәм фольклорына XIII–XVI йөздән алып, әле бүгенгәчә тирән

---

[1] Сәйфелмөлек китабы. Казан: Гимназия тип., Йосыф Исмәгыйль улы Апанаев нәшере, 1807. 115 б.

[2] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сакл. бер. 21.

[3] *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кыссаи-Йусуф» Кул Али. М: Наука. 1979. С. 19.

йогынты ясавы мәгълүм. Шәрекъ, бигрәк тә исламның бай традицияләре нигезендә барлыкка килгән бу гүзәл әсәр шушы ук сюжетка халыкта өр-яңа вариантлар тууга һәм, мондый әсәрләргә ихтыяҗ зур булу нәтиҗәсендә, аларның тиз генә популярлашып китүенә сәбәпче була.

Поэманың халыклашкан вариантлары бездә «Йосыф китабы» дигән исем белән йөртелгән, «Йосыф» дип бирелгән очраклар да бар. Яшәү һәм таралу формасы ягыннан язма формалылары да, сөйләмә дастаннар да очрый. «Йосыф китабы»ның моңа кадәр табылган күпсанлы кульъязмаларының шактые – шулай ук халыклашкан вариант. Мәсьәләнең бу ягы һәм гомумән поэманың татар фольклорына ясаган тәэсире Кол Гали иҗатына багышланган махсус хезмәтләрдә җентекләп яктыртылган һәм алар бу хакта тулы мәгълүматны җиткерәләр[1]. «Романик китаби дастан» категориясенә керә торган фольклор әсәрләреннән «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек»тән генә калышып, иң тәүгеләрдән булып, Казан типографияләрендә китап булып та басыла башлый һәм саны белән барлык дастаннарны да узып китә: 1841 елдан алып 1915 елга кадәр 80 мәртәбә басылып чыга[2].

Әсәр бик күп таралган, һәрбер вариантны исәпкә алып бетерү дә мөмкин түгел. Алар арасында тулылыгы һәм үзенчәлекле булуы белән аерылып торганнары да, «Йосыф китабы» фабуласын, я берничә эпизодын сөйләп бирә торган кыска язмалар да очрый. Халыкта күбрәк «Кыйссаи Йосыф»ның китаптан уку, китап эчтәлеген сөйләп чыгу, билгеле сюжетка ияреп, яңа вариантта сөйләү кебек формалары киң таралган булган.

---

[1] *Хисамов Н.* «Кыйссаи Йосыф» поэмасының халыкта яшәеше// Казан утлары. 1974. № 9. Б. 175–182. *Хисамов Н.* «Кыйссаи Йосыф» әсәренең халык версияләре // Тезисы докладов III научной конференции молодых ученых. Казань, 1974. *Хисамов Н.* «Кыйссаи Йосыф» поэмасының халык поэзиясенә тәэсире // Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан. Казан, 1981. Б. 23–37. *Хисамов Н.* Бөек язмышлы әсәр. Казан. 1984. 334 б. һ.б.

[2] *Каримуллин А.Г.* Татарский фольклор. Аннотированный указатель литературы. Казань, 1993.

Әсәрнең кырыктан артык варианты арасында икесе XX йөзнең 70 нче еллар азагында татар фольклорчылары тарафыннан Чиләбе өлкәсе информантларыннан язып алынган. Болар – Коншак район үзәгендә Сабира Гайнетдиновадан (1907 елгы) Рәшит Ягъфәров язып алган вариант[1] һәм Троицк шәһәрендә Фаизә Гобәйдуллинадан «Йосыф» дигән исем белән Асия Садыйкова язып алган текст[2]. Болар икесе дә шактый төзек вариантлар булуы белән әһәмиятле.

Болардан тыш, Чиләбе өлкәсендә Таһир белән Зөһрә турындагы популяр сюжетка корылган дастан вариантлары да табылган. Мәсәлән, төрки халыклардан үзбәк, уйгыр (4 версия), азәрбайҗан ике дистәдән артык, төрек, казакъ, төрекмән версияләре бар. Башкортстан территориясендә табылган текстлары мәгълүм, татар вариантлары исә дистәдән артып китә. Г. Тукайның мәгълүм сүзләре белән әйткәндә, «татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы»на[3] Чиләбе өлкәсе татарларының да битараф булмавы күп нәрсә хакында сөйли. 1978 елда Рәшит Ягъфәров Коншак район үзәгендә Сабира Гайнетдиновадан (1907) әлеге дастанның фабула характерындагы бер вариантын язып алган[4]. Информантның язып алучыга «Китаптагыча сөйлимме? Кыскача сөйлимме?» – дип сорап, әсәрнең эчтәлеген сөйләп биргән булуы турында мәгълүмат бар. Моннан тыш, Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Троицк шәһәрендә Фаизә Гобәйдуллинадан Асия Садыйкова язып алган вариант та саклана[5].

---

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, 1979, 2 нче кассета.

[2] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сакл. бер. 21а.

[3] *Тукай Г.* Әсәрләр 4 томда. Т. 4. Казан, 1977. Б. 279.

[4] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сакл. бер. 21.

[5] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 93, папка 1, сакл. бер. 21, кассета № 1.

Уртак дастани сюжеттан боларда Кормаши вариантында да очрый торган баласызлык, бер алманы икегә бүлеп бирү мотивлары, багучы карт, гарәп, Таһирның апасы, ырымчы карчык образлары, сәхрәгә чыгу, мәктәптә уку, сандыкка салып диңгез суына агызу, тәрәз астына килеп җырлау эпизоды һ.б. очрый. Информантлар эпик җырларны да игътибарсыз калдырмаган. Вариантларның Рәшит Ягъфәров тарафыннан язып алынганында ике урында тезмә юллар китерелгән. Аның беренчесе – Зөһрәнең кызларына әйткән җыруының ике юлы:

Әйдәң, кызлар, йөгерешик,
Таһир каберенә җитешик,
Энҗе-мәрҗән сибешик.

Ә икенчесе исә, Таһирның үлеме турындагы хәбәрне ишеткәч, Зөһрәнең җырлаган җыруы:

И татарсыз, татарсыз,
Бер-береңә ук атарсыз,
Базарда ит беткәнме,
Таһир итен ашарсыз.

Юлларның һәр икесе бераз гына үзгә рәвештә Кормаши вариантында да бар.

Троицк шәһәрендә Фаизә Гобәйдуллинадан Асия Садыйкова язып алган вариантта исә тезмә юллар бераз үзгәрәк һәм түбәндәгедән гыйбарәт:

И ата, миңа салган сараеңның
Эченә ут сал инде, ди.
Ялкын итеп бер яндырып,
Бер кызынып кал инде, ди.

Эт зәйтүнен китерерсең, ди,
Аны кунак итәрсең, ди,
Миннән башка кызың булса,
Аны кияү итәрсең, ди.

«Бүз егет» – төрки халыклардан татар, башкорт, нугай, казакъ, кумык, балкар халыкларында версияләре мәгълүм фольклор әсәре. Татар халкы аны кульъязмадан да, басма китаптан да укыган, язма «Бүз егет» тәэсиреннән кабат халыклашканмы, я булмаса элгәрләребез телендә актив яшәгән булганмы, халкыбызда аның сөйләмә вариантлары да очрый. Күбрәк өлеше шигъри юллардан гыйбарәт гаҗәеп матур, күләмле әсәр. Баһави вариантында да, Кормашида да төрки-татар ханлыклары дәверендә үк актив кулланылышта йөргән йола җыры – «Яр-яр»ның үзенчәлекле текстлары китерелү факты әһәмиятле. «Бүз егет»нең һәр варианты – татар дастаннарының тел-стиленә, хикәяләү рәвешенә, шигъри үлчәменә һәм рухына туры килә торган гүзәл әсәрләр. Фольклорчы Р. Ягъфәров 1978 елда Чиләбе өлкәсе Коншак районы Үзбәгәрәк авылында Нәгыймә Мөстәкыймовадан (1906) «Бүз егет»нең бер вариантын магнитофон тасмасына язып алган[1], аның күчермәсен биргән[2]. Күчермә чәчмә тексттан гыйбарәт. Информант Кормаши вариантының кыскача эчтәлеген сөйләгән. Түбәндәге эпик җыр өлешен үзенчәлекле көй белән әйткән булуы хакында беләбез:

Карлыгыч карлыгачка җим бирде,
Карендәш карендәшкә дим бирде.
Ялгызлыкка төшептер моңлы башым,
Мин ятып йөргәнемне кем белде.

Уйлыймын җанымны монда аласыңмы, дип,
Моңлы башым бу җирләрдә каламы, дип,
Кем үлмәкин калма, ди, яраткандин соң[3],
Куркамын гүр-кәфенсез калам дип.

---

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, 1979, кассета № 2.

[2] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 90, папка № 2, сакл. бер. 19–22.

[3] Кем үлмә, кем калма, ди, яраткандин соң – ягъни: җиргә яратылган берәү дә үлми калмый.

Ходайга тәкъдиремдин калганым юк,
Борылып качарга һич дәрманым юк,
Каһһәррәхим әйләсәң, Кадир алла,
Синдин башка һичкемгә егъларым юк.

Агачның башын киссәң, төбе калыр,
Икәүнең бере үлсә, бере калыр,
Ялгызның үзе үлсә, нәрсәсе калыр?
Менәр аты, кигән киеме, юлы калыр.

Әйтәем, дисәм, бу илләрдә сүзем сынык,
Булмас ахры гарубәттән[1] күңелем тынык,
Аллага нә кыйлсаң да чарамыз юк,
Котылмас йиргә очрады гарип башым.

Югарыда телгә алынган (телгә алынмый калганнары да шактый), үткән гасырда бу якларда туплап алып кайтылган материаллар, барысы да бик пөхтәләп Мирасханәгә – Институтның архив фондларына тапшырылганнар. Алай гына да түгел, ул чактагы экспедицияләрдә халыктан җыелган фольклор үрнәкләре бик күп җыентыкларга кертелгән, шул исәптән 1989 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган 12 томлык академик «Татар халык иҗаты» җыентыгының «Әкиятләр», «Дастаннар», «Риваятьләр һәм легендалар», «Табышмаклар», «Мәкальләр», «Җырлар», «Мәзәкләр», «Бәетләр» томнарында лаеклы урыннарын тапканнар, яисә теге я бу фольклор әсәренең варианты буларак күрсәтелгәннәр.

Элекке чор фольклор экспедицияләре вакытында Чиләбе информантларыннан фольклорчы галимнәр язып алып кайткан, бүгенге көндә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында саклана торган кайбер дастаннарның текстларын әлеге басмада

---

[1] Г а р у б ә т – горбәт: гарәп сүзе, мосафирлык, туганнарыннан аерылып, чит илдә булу.

Сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәбез. Коншак авылында язып алынган «Сәйфелмөлек» дастаны да, «Кузы Күрпәч белән Баянсылу» да шушы ук сюжетка корылып, моңа кадәр дөнья күргән вариантларыннан үз үзенчәлекләре белән аерылып тора; «Йосыф – Зөләйха» дастанының Троицк шәһәрендә язып алынган вариантында исә «Китабы дәдәм Коркыт»тагы сюжет килеп кергән, биредә Йосыф пәйгамбәрнең Кәнган белән Мисыр арасында казылган кабергә кереп ятуы турында сөйләнә. «Таһир белән Зөһрә» дастаннары Кормаши вариантының фабуласы характерында, күп өлеше чәчмә тексттан тора, әмма чорына күрә аерым информантлар авызыннан язып алынган эпик сюжет чагылышы булулары белән кыйммәт. Дастан текстларыннан тыш, Чиләбе өлкәсендә вариантлары табылган эпос-дастаннарның моңарчы билгеле булган музыкаль өлешләрен ноталары белән бирүне кызыклы булыр дип уйладык. Ноталы текстлар Ф. Әхмәтова төзегән «Татар халык иҗаты. Дастаннар» (1984) томында теркәлгәннәр. «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» дастанының көй үрнәге, «Сәйфелмөлек», «Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә» (ике вариантта) дастаннарындагы эпик җыр, «Бүз егет» дастаннарының көй үрнәкләре Ф. Әхмәтова тәкъдим иткән варианттагыча бирелә. Дастанның фольклористикада эпик җыр дип атала торган мондый өлеше, ягъни «тере» музыкаль фольклор ул – бүгенге көн фольклорчысы өчен шулай ук аеруча кадерле мирас. Бүгенге көндә «тере» эпос-дастаннарга юлыгу сирәк күренеш, шуңа күрә аларны популярлаштыру – изге бурычыбыз. Чиләбе өлкәсендә яшәүче яисә яшәгән милләттәшләребез белгән, үз иткән дастаннар – гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөргән идеяләр белән сугарылган милли эпик ядкәрләребез. Алар узган гасырның җитмешенче еллар фольклор экспедицияләре кайтавазы буларак кадерле һәм кызыклы. Шушындый истәлекләрнең Көньяк Урал итәгендә гомер иткән информантлар авызыннан язып алынган булуы татарларның уртак тамыры, бердәй мәдәнияте хакында сөйли.

## Сәйфелмөлек[1]

Була бер патша. Ул әле өйләнмәгән була. Сөләйман пәйгамбәр бирә бер тун, бер балдак. Менә, ди, бу тунны карама, ди, һәлак булырсың, ди. Синнән була торган балам бу, ди. Шуннан патша өйләнде, бала туды. Сәйфелмөлек була бу. Вәзир хатыны да бәбәйләде. Сәгыйть исеме куйдылар. Боларны бер ана карый, бер ана тәрбияли.

Шуннан бу унсигез яшенә җиткәндә патша сарай салдыра. Болар икесе бергә шул сарайда торалар инде. Өй салып, кунак булганда, атасы Сәйфелмөлеккә тун белән балдакны бирде. Шуннан соң и ябыга, и ябыга. Патша әйтә, моның берәр җире авырый торгандыр, көннән-көн ябыга бара, ди. Анасы сорый, юк, бер җирем дә авыртмый, ди. «Сәгыйть, син сора, сез бергә үскән, сиңа ул әйтер» – ди. Сәгыйть сорый.

– Минем бер җирем дә авыртмый. Менә әти биргән тун эчендә бер сурәт күрәм, – ди. – Шулхәтле матур, – ди, – шул сурәткә мин гашыйкмын.

– Җүләр син, – ди Сәгыйть, – син сора аннан. Кайсы шәһәрдән син? Исемең кем, атаң-анаңның исеме кем? дип. Ул сиңа әйтер төшеңдә, – ди.

Шуннан моның төшенә керә. Бу сорый:

– Син адәми затмы, пәри затмы? – ди. Җирлегең кем синең? – ди. Шәһәрең ни исемле? – ди.

– Исемем Бәдигыльҗамал, – ди. – Атам, – ди, – адәми зат, анам, – ди, – пәри кызы, шәһәребез – Иран-бак шәһәре, – ди.

Әтисенә сөйли Сәйфелмөлек:

– Мин патша кызы Бәдигыльҗамалга гашыйк булдым. Дөньяда аннан матур кыз юк. Мин аны эзләргә китәм, – ди.

Патша бердәнбер улына каршылык күрсәтми.

– Балакай, кайсы якта икән соң ул Бәдигыльҗамал? Нинди патша кызы икән ул? – ди.

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 91 (93), папка 1, сакл. бер. 21.

– Мин аның нинди патша кызы икәнен дә, башкасын да белмим. Бары дөньяда гүзәлләрнең гүзәле икәнен генә беләм. Аны күпме эзләрмен, кая барып табармын, нинди җирләр үтәрмен, белмим. Ләкин мин аны эзләп табарга тиеш, – ди Сәйфелмөлек.

Әтисе моңа да каршы килми:

– Бәлки сәфәрең ерак булыр, балакай. Сиңа ярдәмче кешеләр кирәгер. Юлчы иптәшләр, ашау-эчү әйберләре, кием-салымнар, кораллар кирәк булыр. Хәзерләнә башларбыз, – ди.

Әтисе аның белән илле кол солдат юллый. Сәйфелмөлекнең иң якын дусты вәзир улы була. Калганнары кол солдатлар. Илле йөккә төяп әйберләр, ашамлыклар, кием-салымнар җибәрәләр. Яхшы дөяләргә атланып, сәфәр чыгып китәләр.

Баралар, баралар болар һич тә белмәгән җирләргә. Кая барганнарын үзләре дә белми, һәр шәһәргә, һәр авылга кергән саен алар:

– Патша кызы гүзәл Бәдигыльҗамалны кайсыгыз белә? Нинди җирдә тора икән ул? – дип сорыйлар.

– Без андый патша кызын ишеткәнебез дә юк, белмибез дә, – дигән сүз генә ишетәләр.

Бу өметен өзми, һаман алга бара, эзләвен дәвам итә. Шуннан соң болар чүлләр, ком бураннары эченнән баралар. Илле дөянең кала яртысы гына. Кешеләрнең дә яртысы гына кала. Ком бураны күмеп китеп, сусызлыктан, азыклары беткәнлектән боларның иптәшләре дә, дөяләре дә харап була. Ком бураннарын үткәч, яртылаш калган иптәшләре белән, тагы бик авыр хәлләрдә бер ел йөриләр. Ике ел йөриләр. Бик аз иптәшләре кала. Соңыннан өчәү генә калалар.

Шуннан аның белән тагын бер кеше, үзенең иң якын дусты гына кала. Ашаулары бетә, киемнәре ертыла.

Чүлләрдә болар кая барырга да белми йөриләр. Кая барсалар да – Бәдигыльҗамалны белүче юк. Дөнья йөзендә яшиме ул, кая булса бармы – аны кем дә белми. Ләкин Сәйфелмөлек эзләвен туктатмый.

Шуннан болар килеп җитәләр бер шәһәргә. Бу урында бер нәрсә юк кебек иде, кинәттән зур шәһәр күрәләр. Шәһәрдә

боларны яхшы каршы алалар. Дөяләрен дә алып куялар, үзләрен дә хөрмәт итәргә телиләр.

Шәһәр патшасы боларны үзенә китерә. Аның кызы Сәйфелмөлеккә гашыйк булган икән. Ул этисенә боерык биргән:

– Бу егетне тотып калыгыз, мин аңа гашыйк, аны бер кая да җибәрмәгез, – дигән.

Ә ул җеннәр патшасы Зәнки булган. Зәнки кызы озын буйлы, чандыр, төскә ямьсез бер кыз икән. Сәйфелмөлек белән кич уздырырга уйлый. Зәнки патша бердәнбер, үзе өчен бик гүзәл булган кызының сүзен тыңлый. Кич белән үзенең кунак каршылый торган бүлмәсенә Сәйфелмөлекне китерергә тиеш була. Сәйфелмөлек бу хәлне белми башта. Ялгызын шундый бер шомлы бүлмәгә керткәннән соң, ни хәлләр була, дип көтеп тора. Аның иптәшен башка бүлмәгә урнаштыралар.

– Сез безнең кунак. Без сезне хөрмәт итәбез. Без кушмыйча сез бер җиргә дә китә алмыйсыз. Кайчан сезне җибәрербез, шунда гына китә алырсыз, – дип, боларны ябып куялар.

Кичен Сәйфелмөлек утырган караңгы, шомлы бүлмәгә, ишек ачып, җен Зәнки кызы килеп керә. Аның колагына, алка урынына, сарымсак, суганнар эленгән. Өстендә ямьсез күлмәк. Башына бәйләве дә кеше сынлы түгел, кешегә охшамаган була. Шундый җен кыяфәтендә була инде.

Шунда Сәйфелмөлек:

– Бу нинди гаҗәеп бер зат? Минем яныма нинди нәрсә килә икән? – дип көтеп тора.

Караса, кеше сыйфатында бер кыз. Үзе бер сүз әйтми. Шактый торгач, җеннәр патшасы Зәнки кызы:

– Мин сиңа гашыйк булдым, сине бик яратам. Мин синеке булыр идем, – дип, үзенең мәхәббәтен белдерә.

Сәйфелмөлек:

– Юк, Зәнки кызы, сез патша кызы булсагыз да, минем күңелне били алмыйсыз. Яныгыздан суган-сарымсак исләре генә килә. Матур кешегә охшамагансыз, гүзәллегегез юк. Мин сезгә өйләнә алмыйм. Минем яраткан кешем бар, ул – Бәдигыльҗамал. Мин аны эзләп йөрим. Мине биредә тотмавыгызны

телим. Ничек кенә булса да, син миңа кирәкмисең, – дип ачык әйтә.

Шуннан Зәнки кызы бик ачулана:

– Ә, шулаймыни! Син мине яратмыйсыңмыни? Минем яратуымны кабул итмисеңмени? Ә мин сине бар йөрәгем белән яратам. Шулай булгач, мин сиңа җәза бирергә тиеш булырмын. Мин әтиемә әйтсәм, ул сине алай гына калдырмас. Дөньядан юк итүгә кадәр барыр, үзенекен итәр, – дип Сәйфелмөлек яныннан чыгып китә.

Иртә таң атканда патша:

– Нигә син минем кадерле, гүзәл кызыма шундый төс күрсәттең? Ул сине саф мәхәббәт белән ярата. Ул минем бердәнбер гүзәл кызым. Ә мине Зәнки патша, җеннәр патшасы, диләр. Теләсәм нинди кыяфәткә керә алам, теләсә нәрсә эшли алам. Ә син шуңардан курыкмыйсың, уңайсызланмыйсыңмы? Сиңа киләчәктә нинди авыр юллар үтәргә туры киләсен уйламыйсыңмы? – ди.

– Юк, сез мине тотарга тиеш түгел. Минем мәхәббәтем юк сезнең кызыгызга. Минем гүзәл Бәдигыльҗамалым бар. Мин аны эзләп ике ел йөрим. Газаплар кичердем, күп кайгылар күрдем, иптәшләремне югалттым, күп мал түктем. Шулай да мин эзләвемнән туктамыйм. Сезнең кызыгыз миңа кирәкми, – дип җавап бирә Сәйфелмөлек.

Зәнки бернишли алмый, кызына күндерә алмый. Моны иптәш егете белән бер караңгы җир асты төрмәсенә ябып куя.

– Сез шунда мәңге торырсыз. Кайчан минем кызыма риза булырсыз, шунда якты тормышка чыгарсыз, – ди.

Шуннан болар бик каты газапта, җир астында, караңгы зинданда калалар. Ләкин нинди юллар беләндер, сакчылар ярдәм итепме, ниндидер, яхшы кешеләр ярдәмендәме, бу куркыныч җирдән котылалар. Төн ярыгында, бөтен шәһәр йоклаганда болар качып китәләр. Җеннәрдән качып котылалар. Кесәләрендә акчалары да, бернәрсәләре дә юк. Сәйфелмөлекнең кулында патша уллары кия торган яхшы алтын йөзеге генә кала. Ә ул тарихи йөзек Сөләйман пәйгамбәрнең йөзеге була.

Шуннан баралар болар, ниндидер бер сихри диңгезгә килеп җитәләр. Ул диңгез дулкынланып тора. Шуның яр кырыенда салам шикелле чыбыклардан гына үреп эшләнгән кечкенә ызбада бер карт тора икән. Болар шунда килеп туктыйлар икәү, карт белән сөйләшәләр. Бу карт башта ни әйтергә дә белми:

– Бик арып килгәнсез, ашап-эчегез, – дип боларны хөрмәт итеп каршы ала.

– Нинди юл белән йөрисез, кайсы як сәфәрдән? Кемнәр буласыз? – дип сорый.

Сәйфелмөлек үзенең гүзәл кыз Бәдигыльҗамалга гашыйк булуы, аны эзләп йөрүе турында сөйләп бирә.

– Белмим, – ди карт, – нинди ул Бәдигыльҗамал. Аның кайда икәнен дә белмим. Тик диңгез төбендә дию яшәвен беләм. Дию пәрие ул. Дию пәрие кулында ничә ел бер кыз тора, дип ишеткәнем бар. Каян ул, кая аның юлы, мин белмим.

Бу бабай – шушы тирә кешесе. Авыр тормыштан качып киткән була. Шул диңгез янында балык, төрле кыргый җәнлекләр тотып, үзенең көнен итә торган була. Бу тирәдәге юлларны белә.

– Җир астына төшә торган юлны да беләм. Бәлки, шул диңгез төбендәге дию юлыдыр ул. Аны багып карарга кирәк булыр. Мин диңгез төбенә төшеп караганым юк. Шул юлдан дию йөри шикелле, дип әйтәләр. Менә шунда нинди дә булса хәбәр булмасмы? – ди.

Сәйфелмөлек китә шул карт белән, баралар бер куыш янына, диңгез төбенә төшә торган юлга. Карт юл күрсәткәч, егет төшеп китә диңгез төбенә.

Бара, бара тар юллар белән, диңгез төбенә бара. Бер заман зур ишек кебек нәрсә күрә, болдырдан ишекне ачып керсә, бер ыңгырашкан тавыш ишетелә. Шуннан бу баскычтан төшеп карый. Анда аяк-куллары богауланган, йөзе сап-сары саргаеп кипкән бер матур, гүзәл яшь кыз күрә. Кыз куркынып китә бу егетне күрү белән. Бер үк вакыт шатлана да. Егет аның яткан караваты янына килеп, аяк-куллары богаулы икәнен күрә.

– Син соң кем буласың? Ник бу диңгез төбендә болай богаулы килеш ятасың? – дип сорый.

– Минем исемем Мәликә. Унбер яшемдә, күлдә коенган вакытта мине дию пәрие урлап качкан иде. Хәзер инде ничә ел үтте, мин шул дию пәрие каршында диңгез төбендә яшим. Кулларым-аякларым чылбырга бәйләнгән. Мине, качар дип, бәйләп куя. Ул китә дә югала. Аннары бер вакытны күк күкрәгән тавышлар ишетелә дә, минем яныма килеп богауларымны чишә, – ди. – Ашап-эчәбез, шуннан үзе киткәндә тагы мине богаулап калдыра. Менә шул көенчә, мин инде сигез ел торам, – ди.

Унсигез яшеннән узган була ул кыз. Шулай бәйләнгән тимер богау эчендә, кайгы эчендә, саргаеп кипкән була гүзәл Мәликә.

– Ничә ел инде кеше йөзе күрмәгән идем, – дип елап җибәрә. – Син кем буласың? Нинди адәм баласы? Әллә күземәме күренәсең? Әллә миңа яхшылык итәргә килгән кешеме? – дип гаҗәпкә кала.

– Әй, гүзәл Мәликә, мин бик авыр юллар кичердем. Менә өч ел инде мин патша кызы гүзәл Бәдигыльҗамалны эзлим, таба алмыйм. Ул кая тора? Ни эшли икән? Менә бу диңгез ярында бер карт сөйләде: «Диңгез төбендә бер кыз тора, дию аны урлап киткән, дип сөйлиләр». Юлларын күрсәткәч, мин синең яныңа килеп кердем.

– И Сәйфелмөлек, гүзәл Бәдигыльҗамал – патша кызы ул. Ул минем яшьтән бергә уйнап үскән дустым була, – ди.

Шуннан егет бик шатлана:

– Морадыма ирешәм. Мин хәзер Бәдигыльҗамалның дөньяда бар икәнен белдем.Ул дөньяда бар икән. Мин аны дөньяда юкны эзләп йөрим, дип тә уйлый идем. Алай да өметемме өзмәдем. Мин аңа төшемдә генә күреп гашыйк булдым. Хәзер дөньяда барлыгын, дусты белән уйнаганын, аның кайсы илдә, кайсы җирдә икәнен дустыннан сорашып беләм инде.

– Мин хәзер анда барыр идем, – ди Мәликә. – Туган җиремә кош булып очар идем. Әти-әниләрне күрер идем. Бәдигыльҗамал дустымны күрер идем. Үзем дә бик ашкынам, тик мин богауда, дию пәриендә. Мине моннан кем җибәрә? Моннан котылсам иде, мин сине Бәдигыльҗамал дустым белән күрештерер идем.

Бу Сәйфелмөлеккә бик тәэсир итә, анда кызга ярдәм итү, аны коткару теләге туа. Кызның да аңа ярдәм итәчәгенә ышана. Мәликә әйтә:

– Диюнең килер вакыты җитә. Ул килсә, сине шунда ук үтерер. Ул явыз дию, син аны һич тә җиңә алмассың, икебезне дә харап итәр. «Ә, син кеше йөртәсеңмени?» – дип, миңа ни булса да эшләр, сине дә шунда үтереп ташлар. Син нинди юл белән килдең, шул юл белән кире чык. Ул юк вакытта тагын күрешербез, ничек тә булса аңлашырбыз, – ди.

– Сине ничек тә коткарырбыз, – ди Сәйфелмөлек.

Кыз бу сүзләргә бик шатлана, өметләнә. Шуннан соң еракта күк күкрәгән тавыш ишетелә. Бу кыз:

– Тиз генә, Сәйфелмөлек, чык, дию килә, аның тавышы ишетелә башлады. Тиз чыгып киткән бул! Икебезне дә харап итәр, – ди.

Сәйфелмөлек йөгереп чыгып китә. Баскычтан менеп киткәндә аның бер башмагы төшеп кала.

Кыз үз урынында ятып кала. Аяк-куллары бәйле, диюнең килүен көтә. Дию килеп керә үзенең юлыннан. Кереп башмакны күрә.

– Бу нинди башмак? Каян алдың моны? Әллә кем дә булса бире кереп йөриме?

Аннан соң Мәликәгә каты кычкырып, куркыныч тешләрен ырҗайтып килә дә:

– Бүгеннән ары мин сиңа ышанмыйм. Кешеләр китереп йөртәсең икән өемә. Богавыңны үзем килгәч тә чишмим. Син шулай мәңге богаулы тор. Башка вакытта бүтән кеше китермәссең, – ди.

Мәликәнең кулларын да чишми, тагын чыгып китә. Ике көннән килерлек эше бар икән.

Икенче көнне билгеләнгән вакытта егет килә.

– Башмагым төшеп калды, алырга вакыт булмады, – ди.

– И шул башмак өчен дию миңа күрмәгәннәремне күрсәтте. Каһәрләде, чылбырны да чишмәде. Миңа инде тагы да авыррак булды, – ди Мәликә.

Сәйфелмөлек башмагын алырга тели.

– Юк, инде башмакны урынында калдыр. Әгәр алып киткәнне белсә, тагы мине җәзалар, – ди кыз.

Болар сөйләшәләр.

– Аның жаны кайда икән? – ди Сәйфелмөлек. – Әгәр син аңа ягымлырак булсаң, ул сиңа ышаныч белдерер. Ышанып, җаны кайда икәнен әйтер.

– Җаны кайда икәнен белсәк, без нишләрбез? – ди Мәликә.

– Ә аны белсәк, нәрсә эшләргә белербез. Син шуны гына бел, миңа сөйләрсең, – ди Сәйфелмөлек.

Шуннан бу чыгып китә. Моның бире килгәнен кем дә белми, башмагын да алмый. Дию килә. Башмак – урынында, кем дә килмәгән дип белә. Өйгә килеп кергәч, Мәликә инде җыларга тотына:

– Кулларым-аякларым авырта инде. Ничек торыйм? Хәлем калмады, мин инде үләм. Син мине бер дә җәлләмисең. Мин бит сине иң якын дустым күрәм, бөтен киңәшем-серемне сиңа сөйлим. Мин инде беркая китмим, синең турылыклы дустың, – ди.

Дию пәрие моңа ышана да кулларын-аякларын чишә.

– И Мәликә, мин бит сине күлдә коенган чагыңда урлап качтым. Хәзер кая да китә алмыйсың, мин сине каян да эзләп табам. Син беркемне китерә дә алмыйсың. Китерсәң дә мин ул кешеләреңне табам, – ди.

– И дустым, син үлсәң, берүзем бу диңгез төбендә мин нишләрмен? – ди Мәликә.

Дию пәрие әйтә:

– Юк, юк, мин мәңге үлмим, картайсам да үлмим. Минем җаным бик еракта тора, аны беркем дә ала алмый.

– И дустым, җаның соң кая тора синең? Мин бит ялгыз калырмын да нишләрмен дип кайгырып яшим.

– Ярар, кемгә дә әйтмәгән серемне сиңа гына әйтәм. Минем җаным бик еракта, диңгез төбендә. Анда зур сандык. Зур сандык эчендә кечкенә сандык. Кечкенә сандык эчендә күгәрчен. Шул күгәрчен эчендә минем җаным тора. Ул күгәрченне беркем тота алмый. Әгәр аны тотып муенын сындырсалар, шул чагында

гына минем җаным чыккан булыр. Мин дөньяда яшәмәм, шунда үлгән булырмын, – дип аңлатып бирә. – Ул зур сандыкны диңгез балыгы гына тартып чыгара ала. Ә ул балыкны эшкә кушар өчен Сөләйман пәйгамбәр йөзеген кигән кеше кирәк. Менә шул йөзекне кигән кешене генә тыңлар ул балык. Андый кеше дөньяда юк. Сөләйман пәйгамбәр йөзеге бер генә ул. Ул бер патша кулында йөри, аның нәрсәгә яраганын да беркем белми. Шулай булгач, мине беркем дә үтерә алмый, – ди.

Ә Мәликәгә шул гына кирәк иде. Шуннан соң дию йокларга ята. Икенче көнне тагын үзенең эшенә китә.

Дию киткән арада Сәйфелмөлек тагы керә. Кызның кулларын чишә. Мәликә бик җылый, яшьләр түгә.

– И Сәйфелмөлек! Ничек кенә сөйләшсәк тә, безнең эшебез барып чыкмый. Бу дию мәңге яши торган икән. Аның диңгез төбендәге җанын алу өчен Сөләйман пәйгамбәрнең йөзеге булу кирәк икән. Шул кешегә генә диңгез балыгы йомышка йөри икән, диңгез төбеннән сандыкны тартып чыгара икән, – ди.

– Мәликә, менә бит ул йөзек минем кулда! – ди Сәйфелмөлек. – Менә хәзер инде син рәхәтләнеп диңгез төбеннән чыга алырсың.

Икесе дә бик куанышалар. Хәзер инде Мәликә бөтенесен төшендереп бирә, ничек эшләргә кирәкне. Иң беренче йөзек кигән кулны суга тыгып болгарга кирәк. Шуннан соң балык йөзеп килә икән. Балык зур сандыкны тартып китерә. Зур сандыкны ачарга, аннан кечкенә ящикны ачарга, аны бик саклык белән ачып, күгәрченнең муенын кыеп төшерергә, шул вакыт дию үләргә тиешлеген аңлата Мәликә.

Шуннан Сәйфелмөлек үзенең башмакларын тотып чыгып китә. Әлеге карт янына кайта. Аның белән диңгез буена киләләр, балыкны чакыралар. Балык боларның йомышларын үти, зур сандыкны тартып китерә. Эчендәге ящикны ачалар, күгәрченнең муенын кисеп төшерәләр. Шул вакыт күк күкрәгән, җир тетрәгән тавышлар ишетелә, һавадан башы киселгән дию килеп төшә. Диңгез төбенә төшеп юк була. Бөтен диңгез өсте кып-кызыл кан белән тула.

Дию бу тирә-яктагы кешеләргә зыян итеп торган. Кайсыларын урлап китә, малларын алып китә торган булган. Шуннан инде бу диюдән куркып яшәүче кешеләр аннан котылалар.

Мәликәне дә диңгез төбеннән тартып чыгаралар. Богауларын чишәләр. Яр кырыендагы бабайның өенә китерәләр. Мәликә ябык, саргайган була. Ашаталар, эчертәләр аны. Мәликә бик дәртләнә, куана. Бу дөньяда иң беренче шатлыгы – иркенлеккә чыгу шатлыгына ирешә.

Берәр көн ял итәләр болар. Мәликә бөтен башыннан кичкәннәрен сөйләп бирә.

Хәзер алар юлга чыгарга тиеш булалар инде. Бабай бу яктагы бөтен юлларны күрсәтеп озата бара.

Мәликә, Сәйфелмөлек, аның дус егете өчәү бергә сәфәр чыгып китәләр. Өч ай баралар. Сораша-сораша авыллар, шәһәрләр үтәләр. Аларга кешеләр ярдәм итә. Һәр өйдә аларны якты йөз белән каршы алалар. Мәликә матурланып, тазарып, алсуланып китә. Үзе бик сак, тәрбияле кыз була. Сәйфелмөлекнең дусты бу кызга гашыйк була. Мәликәне бик хөрмәтлиләр, туган сеңелләре шикелле йөртәләр.

Өч айдан Мәликә шәһәренә якынлашалар.

– Мин элекке яшәгән кырларымны, һаваны сизәм. Тиздән килеп житәргә тиешбез, – ди Мәликә.

Таныш урман, таныш һава, күк йөзенә хәтле якын, ничектер үз урыны кебек тоела аңа. Ул бер күл янында булганын хәтерли:

– Бәдигыльҗамал белән тагын бер ун кыз су коенганда бер болыт чыгып, томан кебек, мине күтәреп алып китте, һушыма килгәндә мин шул диңгез төбендә идем. Күпме вакыт, күпме ара үткәнбездер, мин аны һич аңламаганмын. Менә хәзер таныш җирләр исен сизәм, – ди.

Шуннан бу шәһәрне күргәч:

– Менә ул безнең йорт, менә Бәдигыльҗамал торган җир, – дип боларны кинәндерә. – Ләкин сез туры Бәдигыльҗамалга кермисез. Аның әтисе патша, алай ярамас анда барып керергә. Без хәзер өчәү безгә китәбез. Минем әти-әниләрем

мине суга баткан дип беләләр, мине дөньяда юк дип уйлыйлар инде, – ди.

Мәликәләр өенә киләләр. Әнисенең кызы өчен җылап күзе сукырайган була. Хәзер кызын кочаклап җылый. Инде кич була. Әле күп кеше бу хәбәрне ишетә алмый. Әнисе ашлар әзерли, күзе дә ачылган кебек була.

Мәликә:

– Менә мине коткаручы иптәшләрем, – дип, егетләр белән таныштыра.

Әнисе инде болар өчен ни төзергә, ни корырга белми йөри. Мәликә тиз генә дусты Бәдигыльҗамалны дәшеп килергә китә. Мәликә кергәч, Бәдигыльҗамалның исе китә, җылашалар.

– Баштан үткәннәрне сөйләргә вакыт кына юк, Бәдигыльҗамал, син инде безгә кил, – ди.

Китерә моны. Сәйфелмөлек ашкынып көтеп тора. Тәмам төшенә иңгәненчә икәнен күрә. Шул ук киемдә. Башында да, өстендә дә матур киемнәр Бәдигыльҗамалның.

– Гашыйк булдым, күрер өчен өзелдем,

Үлек идем, сәне күргәч терелдем.

Тере булса да, ярым үлек хәлендә аның өчен азаплар күргәнен оныта. «Үлек идем, сине күргәч терелдем», – дип, кызга бәет әйтә. Бәдигыльҗамал да аңа бер күргәч үк гашыйк була. Бик тиз арада берсен-берсе аңлап, сөйләшәләр. Шуннан Бәдигыльҗамал өенә китә.

– Иртәгә сөйләшербез. Мин сине көткән идем. Башка кеше миңа кирәкмәс, – дип, саулыклашып чыгып китә.

Шуннан икенче көнне күрешәләр, өченче көнне. Егет әтисенә дә керә кызның. Патшаның үзенә кереп сөйләшә. Патша кызын ерак җирләргә җибәрергә теләми. Әллә нинди бер егеткә тоттырып та җибәрәсе килми. Монда да күп патша егетләре, ди. Хатыны да риза булмый кызын биреп җибәрергә.

Шуннан Бәдигыльҗамал кайгыра башлый. Егет тә нихәтле азаплар күреп тапкач, алып китә алмавына кайгыра.

Ә Мәликә белән теге егет инде бергә булалар.

Бәдигыльҗамалның этисе мәҗлес җыя, шул мәҗлескә үзенең бөтен батырларын чакырта. Алар ачык аланда кылыч белән сугышырга тиеш булалар. Сугыша Сәйфелмөлек, бөтен батырларны җиңеп чыга. Бәдигыльҗамал да инде этисенә әйтә:

– Җиңде бит, сүзеңне үтә инде, – ди.

– Ярый, кызым, син дигәнчә булсын, – ди патша. Ләкин үзе эчтән риза булмый.

– Тагын бер сынап карыйк. Өчкә хәтле сыныйм, шуннан соң җиңсә генә алыр кызымны, – ди.

Җыр белән уздырышырга тиеш була. Анда да уза Сәйфелмөлек. Шигырь кичәсе була, анда да уздыра. Өченче мәҗлестә дә җиңеп чыга инде. Әтисенең бирмичә хәле юк. Туй мәҗлесе дә ясата. Шулай итеп гомер итәләр.

### СӘЙФЕЛМӨЛЕК



## Йосыф[1]

Бер патша була. Хатыны тугыз бала таба. Ул тапкан балаларның берсе кыз бала була. Яшь хатынның ике баласы. Яшь хатыны үлә патшаның, Йосыфның анасы.

Шулай патшаның ун улы, бер кызы – барысы унбер баласы була. Шул ун улы арасында иң сөеклесе Йосыф икән. Ул башка туганнары арасында ягымлы да, сөйкемле дә, әтисенә дә охшаган, төскә дә бик матур була. Матур булганы өчен аңа һәр күргән кеше соклана икән. Әтисе аңа кечкенә чагыннан ук, күз тимәсен өчен, йөзенә пәрдә ябып йөрткән. Кешеләр аңа сокланып гашыйк була торган булганнар. Йосыфның чәчен озын йөртергә рөхсәт иткән, толымга үреп йөрткән. Зиннәтләп, үз куллары белән унике толымга үрә икән әтисе. Башка балалары шуннан көнләшкәннәр.

Бервакыт Йосыф көзгегә караган да, пәрдәсен ачып, үзенең матурлыгына үзе исе китеп сокланган.

– Миңа тиң бер матур юктыр, – дигән. – Әгәр мин кол булсам, минем бәһамны тутыра алмаслар иде. Күп акча торыр идем мин, – дигән. Матурларның матуры икәненә ышана үзенең.

Бервакыт Йосыф төш күрә, төшен әтисенә сөйли.

– Әтием, мин бер төш күрдем, төштә миңа ун йолдыз сәҗдә кылды, – ди.

Әтисе Йосыфка мондый сүз әйтә:

– Йосыф, балакаем, бу төшеңне башка туганнарыңа сөйли күрмә. Мин сине иң яраткан улым итеп әйтәм, башка туганнарың белмәсеннәр бу төшеңне. Әгәр алар минем сине шулай яратуымны белсәләр, көнләшерләр. Көнләшүдән сиңа нинди дә булса зыян итәргә тырышырлар. Бу төшеңне мин болай юрыйм. Син һәр туганнарыңа караганда да бөек кеше булырсың. Менә синең ун туганың сиңа сәҗдә кылырлар, синең алдыңда тезләнеп торырлар. Арысланның арка баганасын сындырган көчле абыең да, телгә оста булган чичән абыең да, чапса һәркемне уза торган

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сакл. бер. 21 а.

йөгерек абыең да, ерткычларны тотып үтерә торган укчы абыең да, ат өстендә оста йөрүче абыең да, үзләре кай яклары беләндер синнән өстен булсалар да, көнләшерләр синнән. Син беркемгә дә бу төшеңне сөйләмә.

Бу сүзләрне ишектән бер туганы тыңлап торган. Ул моны башка туганнарына сөйләп биргән:

– Әти Йосыфны безгә караганда артык ярата, без һәммәбез аңа сәҗдә кылабыз икән, – дип аңлата.

Башка туганнары бу хәбәрне ишеткәч, дөрестән дә, көнләшеп калалар, һәм алар үзара киңәш кылалар:

– Без Йосыфны ауга барган вакытта үзебез белән алып барыйк та аны үтерик. Яшәмәсен дөньяда. Әти аны бездән артык ярата икән, без аңардан котылыйк, – дип сөйләшәләр.

Әтиләренә килеп әйтәләр:

– Әти, без кырга, болынга ауга чыгабыз. Йосыфны да үзебез белән алырга уйлыйбыз. Кырларны күрсәтеп кайтыр идек. Ул һаман синең яныңда өйдә генә утыра. Без аны алып барып, иркен ачар (*күңел ачар*) идек.

– Юк, мин рөхсәт итмим, – дигән аталары. – Ул кечкенә әле, арыр. Сезнең белән йөрсә хәлдән таяр. Я арып авырыр, – дип рөхсәт итми.

Теге туганнары ничек булса да ялынып, әтиләрен күндерергә тырышалар. Шуннан әтиләре риза була.

– Ярар, алып барыгыз. Ләкин арыса, аны чиратлашып күтәреп йөрегез, аңар тәмлерәк ашлар ашата торыгыз, – дигән.

Йосыфның чәчен үргән, яхшы киемнәрен киендергән, тәмле азыклар әзерләткән.

– Йосыфымның иркен ачыгыз, аңа күңелле булсын, – дип, юлга озатып калган.

Шуннан сигез бертуган, тугызынчы Йосыф, авылны чыгып, кырга киткәннәр. Сахрага җиткәннәр. Авылдан чыкканда әтиләре күргәнче бик яхшы барганнар. Авылны чыккач инде, сигез туган берләшеп, Йосыфтан үч алырга теләгәннәр. Күтәреп тә йөртмәгәннәр, өстерәп йөрткәннәр, кайсылары типкәләгән, кайсылары суккалаган. Йосыф еларга тотынган.

– Сез мине этиемнән шулай җәберләргәме, кыйнаргамы алып киттегез, абыйларым? – дигән. – Әтием бит алай итәр өчен җибәрмәде.

Коега салырга булалар абыйлары Йосыфны.

– Үзеннән-үзе үләр, без эти каршында да, тәңре каршында да гөнаһлы булмабыз, – дип, барысы бер фикергә килгәннәр.

Йосыфны бер тирән кое янына алып килгәннәр. Кое төбенә салганчыга кадәр, этигә ничек җавап бирербез, дип төрле киңәшләр корганнар.

– Без этигә болай дип җавап бирик: әнә, очып барган бер карганы үтерик тә аның канын Йосыфның күлмәгенә буйыйк. Кайткач этигә, Йосыфны бүре ашады, без ау ауларга киткән идек, ераграк киткәнбез, ерткыч җанварлар килеп ашап киткәннәр, диярбез. Җәнлекме, бүреме ашап киткән. Менә аның канлы күлмәге, дип китереп бирербез, – дигәннәр.

Шул киңәш белән эш итеп, Йосыфның күлмәген салдырганнар, үзен кое төбенә салганнар. Карганың канын сөртеп, этиләренә күлмәген алып кайтканнар. Әтиләре, сигез улы кайтып, алар арасында Йосыф кайтмавын күргәч, бик куркынган.

– Кая китте Йосыфым? Кая калды? Нигә алып кайтмадыгыз? – дип, болардан сораша башлаган.

Болар өйрәтелгәнчә сөйләп биргәннәр һәммәсе. Менә, имеш, ауга киткән идек, ераграк киткәнбез. Кайтуыбызга Йосыфны бүре ашап киткән. Менә ертык күлмәге генә калган, дигән хәбәр белдергәннәр.

Якуб бик җылаган:

– Юк, минем баламны ашаган бүрене тотып китерегез. Ул ни сәбәптән минем баламны ашаганын үз теле белән сөйләсен, – дигән.

Шуннан балалары кырга кире киткән. Юлда баручы гөнаһсыз бер бүрене тотып, менә шул бүре Йосыфны ашаган, дип, этиләре каршына китергәннәр.

Якуб бүрегә караган да сорау ала башлаган.

Якуб әйдер: Йосыфымны нәтә җидең,
Күлмәгене ертмадың, бөтен куйдың?

Нәма нидән халикъдан[1] куркумадың?
Пәйгамбәрне мәхрүм, мәхзүн[2] куйдың имди.
Бүре телгә килгән.
Әйдер: валлаһ, Йосыфыңны мин күрмәдем,
Һәм дәхи кайдалыгын мән белмәдем.

Шуннан соң әтисе:

– Бу бүре үзе дә кайгы-хәсрәтле, минем шикелле баласын югалткан. Илтегез аны каян алдыгыз шунда. Сахра буенча баласын эзләп йөрсен, – дигән.

Уллары бүрене илтеп куйганнар. Бүре үз юлы белән баласын эзләп киткән.

Якуб һәр көнне, һәр төнне Йосыфы турында елап үткәрә торган булган. Күзләре сукырайган баласының хәсрәтеннән, күрмәс булган. Үзе картайган.

Беркөнне туганнары:

– Әйдәгез, теге кое янына барып карыйк. Анда Йосыф әле үлмәде микән, – дип, җыйнаулашып әлеге кое янына киткәннәр.

Карасалар, кое янына кәрванчылар туктаган. Сирәк кенә очрый торган кәрванчылар узган-барганда бу коеның берәр кашыклап булса да суын җыеп ала торган булганнар. Хәзер инде бу кое кипкән. Карасалар, анда бер ир бала утыра.

– Мине алыгыз! Туганнарым мине коега ташлады, – дип кычкыра.

Шуннан болар сиксән метрлы бау төшереп, Йосыфны тартып чыгаралар. Менә шул вакыт Йосыфның туганнары килеп чыга. Бу кәрванчыларга сүз кушалар.

– Нишләп сез моны алдыгыз? Ул кое төбендә ятсын иде. Нигә кирәк ул сезгә? Ул алдакчы, карак. Ул безнең колыбыз. Без аны кое төбенә салып җәзаладык, – дигәннәр.

Йосыф, ни әйтергә дә белмичә, туганнарын тик тыңлап утырган. Шул вакыт аның кайчандыр көзге алдында үзенең матурлыгына сокланып, «мин кол булсам, бәһамә җитәрлек акча да булмас

[1] Х а л и к ъ – бар кылучы, Алла.
[2] М ә х з ү н – кайгылы.

иде», дип уйлаганы исенә төшкән. Бу көферлек булгандыр инде, дигән дә эченнән генә үзен тиргәгән.

Туганнары, бу безнең кол, дигәнгә каршы кәрванчылар:

– Алай булса, безгә сатыгыз ул колыгызны. Без аны үзебез белән алып китәбез, – дигәннәр.

Аның гүзәллегенә сокланып, бәһасе күпме торуын сораганнар. Туганнары:

– Карак, качак колның бәясе күпме булсын! Күпме бирсәгез дә ярый, – дигәннәр.

Кәрванчылар, бик әз акча биреп, Йосыфны кол итеп алып киткәннәр. Аны бер иң арттагы дөягә утыртып, юлга чыгып киткәннәр. Йосыфлар авылы аша үткәндә каберлек өстенә җиткәннәр.

Дөя Йосыф әнисенең кабере яныннан үтеп бара икән. Йосыф аяк-кулы бәйләнеп утыра. Әнисе кабере өстендә җылап, шунда төшеп калган. Кәрванчылар әйләнеп карамый байтак юл үткәннәр. Йосыф әнисе кабере янында күп җылаган, бәхетсезлеге турында сөйләгән.

Күпмедер үткәч, кәрванчылар әйләнеп карасалар, Йосыф юк, аның дөясе буш бара. Болар гаҗәпкә калганнар:

– Әйе, качак, дигәннәр иде бит аны. Менә күрсәтте дә инде үзен, – дип, иң усал бер кешене аңа җибәргәннәр.

Бу усал кол аяк-кулы бәйле Йосыфның әнисе кабере өстендә елап ятуын күргән. Аны-моны сорамый, үзенең тимер очлы камчысы белән Йосыфка кизәнеп суккан да ул:

– Синең ияләрең дөрес әйткән, син чыннан да качак икәнсең, менә бер хатаңны күрсәттең инде, – дигән.

Йосыф үзенең әнисе каберенә бәхетсезлеге турында гына сөйләргә төшеп калуын әйткән.

Мин бит кол түгел, мине туганнарым үч алыр өчен генә сезгә саттылар, – дигән. – Әтиемнең иң сөекле улы булганга көнләшеп, алар мине кол итеп саттылар, – дип аңлаткан.

– Бусы тагын алдау. Синең икенче хатаң да беленде. Әле син ялганчы да икәнсең, – дип, тагы камчы белән суккан. – Әйдә, икенчеләп качсаң, сине бөтенләй кыйнап үтерербез, – дип алып киткән.

Яңадан сәфәр чыкканнар. Озак та бармый, боларның баш түбәсендә калфак кадәре генә болыт күтәрелгән. Бу болыттан боз яварга тотынган. Боз шундый көчле булган, кәрванчыларның йөзләрен, борыннарын канаткан, башларын тишкән, кулларын каерган. Бу кешеләр барысы җәзаланган боз яңгырыннан. Шулар арасында барган Йосыфка бер боз да төшмәгән. Болар, шуны күреп, монда ниндидер хикмәтле хәл бар, дип уйлаганнар. Бу колның бер җире яраланмагач, аның сүзләре чын булуына ышанганнар. Аны бүтән рәнҗетмәскә булганнар, кул-аягын чишеп, иреккә җибәргәннәр.

Барганнар, барганнар да болар, үзара киңәшкәннәр.

– Мондый гүзәл колны сатсак, безгә күпме акча керер! Без аны патшага илтеп тапшырыйк. Патша безгә аның өчен алтын белән акча түләр, – дип килешкәннәр.

Патша сараена килеп җиткәч, хәбәр биргәннәр. Патшаның ир баласы булмаган. Ул Йосыфны үзенә балалыкка алырга уйлаган. Хәзер шунда тукталабыз да Зөләйха турында сөйләргә күчәбез.

Зөләйха патша кызы була. Әтисенең тезе өстенә башын куеп, калгып киткәндә күз алдына бик матур бер егет килеп баса. Зөләйхага әйтә:

– Мин Мисыр патшасы Йосыф булам, – ди.

Шул вакыт Зөләйха уянып китә. Уянса, бу төш кенә булганын белә. Шуннан бу төшен беркемгә сөйләми, эчтән генә тына. Үзе, дөресме бу, юкмы соң, дип, һәрвакыт уйланып йөри башлый.

Шулай әтисенә дә, беркемгә дә белдермичә, бер ел вакыт үтә. Бер ел үткәннең соңында Зөләйха тагын төш күрә. Тагы шул ук егет, «Мин Мисыр патшасы Йосыф булам», дип тора имеш.

Кыз, моннан бер ел элек бу төшне күргән идем, тагы шул ук матур гәүдәле, күркәм йөзле егет Йосыфны күрдем, дип уйлап йөри.

Ашамый-эчми, йокламый. Әтисе, сарай кешеләре гаҗәпләнә, бу ни хәл булды икән Зөләйхага, диләр, кайгырыша башлыйлар.

Көннәрдән бер көнне патша Зөләйханы үзенең каршысына чакырып ала:

– Кызым, сиңа ни булды? Син көннән-көн кибәсең, суласың, нурлы йөзләрең саргайды. Күзләрең моңлы карый башлады, – дип сорый әтисе Зөләйхадан.

Зөләйханың әтисе аның һәр сүзен, һәр теләгең үтәгән, аның тугрында кайгыртып торган. Зөләйха аңа үзенең бер еллык серен сөйләп бирергә булган.

– Синең итәгеңә башым куеп калгып киткән арада, моннан бер ел элек төшемдә бик матур егетне күргән идем. Ул, Мисыр патшасы Йосыф булам, диде. Янә бер ел үткәч, мин шул ук төшне күрдем, әтием, һәрвакыт шул күз алдымда, мин бер эш тә эшли алмыйм. Мин синең бердәнбер кызың, җибәр мине Мисыр иленә, – дип, әтисеннән үтенә.

Әтисе әйтә:

– Кызым, кәрван белән барганда өч айлык юл бит ул. Анда ничек барып җитмәк кирәк? Бик зур азапларга очрарсың.

Шулай да, Зөләйха бик үтенеп сорагач, аны, кәнизәкләрен, ялчыларын, колларын, күп маллар төяп, кәрван белән Мисыр иленә озата.

Юлда азаплар күреп, суга интегеп, кызу көннәрдәге эсселеккә түзә алмыйча, дөяләре дә, кайбер картрак коллары да һәлак булалар. Өч айда болар Мисыр патшасына килеп җитәләр, патшага хәбәр бирәләр:

– Зөләйха исемле кыз Мисыр патшасына гашыйк булган. Бик бәяле, затлы бирнәләре белән сезгә кәләш булып килә, – дип хәбәр бирәләр.

Патша исә Йосыфка бөтенләй охшамаган, карт, ямьсез кеше булып чыга. Ризалыгын белдереп, Зөләйханы бирнәләре белән, коллары, кәнизәкләре, яучылары белән сарайга кертергә рөхсәт итә. Патшаны күрүгә Зөләйха:

– Бу түгел, мин ялгыштым, миңа ул кирәкми, – дип җылый башлый.

Кире кайтып китәргә уйлый. Ләкин ни азык, ни су, ни акча калмаган. Кайбер кешеләре дә һәлак булган. Дөяләре дә бик

арган, кешеләре дә хәлсезләнгән. Шулай булгач, кире кайтып китәргә һич мөмкин түгел.

Кәнизәкләре Зөләйханы юаталар:

– Син бит төшеңдә Мисыр патшасын күрдең, Мисыр патшасы шул була инде. Ни хәл итмәк кирәк? Син бит үзең теләп килдең. Бәлки төшең дөрес булмагандыр, – диләр.

Зөләйха күнгән кебек була. Мисыр патшасына күренми, кәнизәкләрен генә йөртә аның янына. Патша кызы Зөләйха сүзенә бер кәнизәге дә каршы килә алмый. Ул кушкан сүзләрне үтиләр.

Көннәрдән бер көнне, шулай яшәп яткан вакытта, сиксән метр тирәнлектәге коедан тартып чыгарган коллары белән кәрванчылар килеп җитә. Бу кол – унике яшьлек Йосыф була. Аны Зөләйха белән Мисыр патшасы каршына китерәләр.

– Сезнең балагыз юк, падиша. Сезгә бер кол китердек. Бәлки бала итәрсез, бәлки колыгыз булыр, – дип, аның пәрдәсен күтәреп җибәрәләр, йөзен ачуга кояш кебек балкып киткән гүзәллеген күрәләр. Зөләйха:

– Менә мин төшемдә күргән шул бала бит! – дип, иң якын кәнизәкләренә белдерә. Ире патшага белдерми.

Патша:

– Күпме хакы бу баланың? Без аны балабыз урынына алырбыз. Безнең ир балабыз юк, – ди.

– Гүзәллегенә аның тиң юк. Бәһасе үзе күтәрерлек алтын, – дигәннәр.

Патша икеләнеп тора. Зөләйха патшага:

– Безнең ир балабыз юк. Бу бала безнең тормышыбызга ямь кертер иде, – ди.

Патшаны күндерә дә, сарайдагы бөтен алтыннарны китерергә куша. Үлчәүнең бер ягына Йосыфны, икенче ягына үз авырлыгы алтын куялар. Кәрванчылар күп алтын алып кайтып китәләр.

Патша да гүзәл Зөләйханың сүзеннән чыкмый. Шуннан Йосыф бу патша белән Зөләйхага бала булып кала.

Көннәр үтә. Йосыф үсә. Матур бер егет булып җитә. Аның гүзәллегенә, күркәмлегенә сокланмаган бер кеше калмый.

Үзенең асрау баласы булуга карамастан, Зөләйха Йосыфка гашыйк була. Төшендә күргән егетне танып, көне-төне аны гына уйлап йөри.

Көннәрдән бер көнне патша ауга китә. Йосыф бик матур киенгән, үзенең бүлмәсендә утыра. Шул вакыт, Зөләйха:

– Патша өйдә юк, Йосыф белән сөйләшергә дә булыр. Ничә еллар йөрәгемдә саклап йөргәнемне, мәхәббәт серләремне аңлатсам да ярый торган вакыт, – дип, Йосыфның янына керергә тели.

Йосыф бүлмәсенә керә, Йосыфның чәчләреннән сыйпый, аннан иркәләргә тели. Йосыф уңайсызланып, читкә китә. Зөләйха үзенең ни өчен кергәнен, дөньяда аның өчен генә яшәгәнен белдереп, мәхәббәт серләрен аңлата. Шуннан соң Йосыф ни әйтергә белми аптырап кала. Зөләйха Йосыфны кочакларга тели, аның янына ул җиде кат ишекне ябып кергән була.

Йосыф әйтә:

– Син минем әнием буласың. Үзе тудырган әнием булмасаң да, син минем әнием саналасың. Ничек мин үз әниемә гашыйк булыйм да мәхәббәт тотыйм? Ана буларак кына мин сине ярата алам.

– Ә, син каршылык күрсәтәсеңме? Мин синең өчен ничә еллар янып көям. Син минем йөрәгемне дә аңларга теләмисеңме? – дип, Зөләйха Йосыфка бәйләнә башлый.

Кочаклап алыйм дигәндә, Йосыф йөгереп кача. Качмасын дип, Зөләйха Йосыф артыннан йөгерә. Бер ишекне ачып чыга, икенчесен ача, шулай җиде ишекне ачып чыга, Йосыфның җилән итәгенә тотына. Егет тартылуга – чабуы ертылып китә. Йосыф качып котыла. Шуннан Зөләйха бик үчләнә.

– Ярар, мин сине нишләтергә белермен! Мин сиңа аңлатырмын әле кем икәнемне, – ди.

Ире кайткач, бу хәбәрне иренә сөйли.

– Менә без асрарга бала алдык. Ул миңа мәхәббәт сүзләре сөйли башлады. Мин бүлмәдә торган вакытта бүлмәмә кереп, мине кочаклый башлады. Мин аның белән тарткалашканда аның җиләне ертылды, – ди.

Патша бик ачулана.

– Ничек ул алай, асрау бала булып, минем хатыныма әдәпсезлек күрсәтә? Мин аны хөкемгә бирермен, – ди.

Йосыфка хөкем каршында җавап бирергә туры килә. Судья, эшне тикшергәч, мондый нәтиҗәгә килә:

– Әгәр дә Йосыф сине кочаклаган икән, син аның белән тартышкансың икән, Йосыф җиләненең алгы өлеше ертылырга тиеш иде. Ләкин Йосыфның бит арткы итәге ертылган. Ничек соң алай булган?

Шуннан Йосыфның үзеннән сөйләтергә булганнар. Йосыф:

– Ул мине үзе артымнан куды, куган чакта арткы чабуым өзелде, –дигән.

Судья:

– Менә бусы дөрес булыр. Нигә сиңа гаепсез кешене гаепләргә иде? – дигән.

Ләкин патша үзенең хатынын гаепле санамаган.

– Бу бала чаядыр. Аны болай калдырырга ярамас йортта. Ул асрау бала. Мин аны үзем хөкем итәм. Зөләйха нинди киңәш бирер, шул хөкем булыр аңа, – дигән.

Зөләйха унике ел зинданда тотарга боерык биргән. Йосыфны шунда ук унике елга зинданга салганнар. Зинданда иптәшләре төш күрсә, Йосыф аларны юрый торган булган.

Патшага каршы булган бер кеше төш күргән:

– Мин кызыл камыт кигәнмен, Йосыф, ни булыр икән? – дигән.

– И, гаебең булмаса да, патша синең муеныңа кылыч куярга тели, – дигән.

Таң белән бу кешене, зинданнан алып чыгып, палачлар башын чапканнар. Иптәшләре шуннан белгән кызыл камытның ни икәнен. Шуннан соң Йосыфка тагын бер иптәше төшен сөйли:

– Син дөрес әйтәсең ахры. Бүген төшемдә җиде симез сыер, җидеябык сыер күрдем. Бу ни булыр икән?

– Җиде симез сыерың халыкка җиде ел туклык елы булыр. Халык шул елларда ашлык запасын әзерләп куярга тиеш булыр.

Ә җиде ябык сыерың шуны күрсәтә, җиде ел ачлык булыр, – дигән.

Дөрестән дә бу шулай булган. Мисыр халкы җиде ел туклык күргән, аннан соң җиде ел ачлык күргән.

Шулай торганда патшалыкка яу килә, патша яуга китә. Зөләйха ире урынында кала. Йосыф инде җиде ел зинданда яткан була. Шул вакыт патшаның үлгән хәбәре килә. Зөләйха Йосыфны зинданнан чыгара да һаман аны үзенә каратырга тели. Зөләйха Йосыфны саф, чын мәхәббәт белән ярата. Үзе Йосыфтан олырак яшьле була. Йосыф аны үги анасы буларак хөрмәт итә. Ләкин мәхәббәт тотарга тиеш түгеллеген аңлый, аның мәхәббәтен дә кире кага.

Зинданнан чыгаргач, Зөләйха аны үзенең асрау улы дип йөртә. Үзе һаман җылый, күзләре сукырая. Күзләре сукырайгач, патшалыкны Йосыфка бирә. Менә шуннан инде Йосыф Мисыр патшасы була. Һәркем аның Мисыр патшасы булуын тели.

Зөләйханың мәхәббәте көннән-көн арта. Мисыр илендә гайбәт тарала. Имеш, Зөләйха үзенең колына гашыйк булган, аны ире дә белгән булган. Шул Йосыф өчен җанын фида кыла икән, дип, хатыннар гайбәт тарата башлаганнар.

Зөләйха, бу гайбәтне ничек юк итим икән, ничек бу хатыннарга мәхәббәтем саф булганы хакында сөйлим икән, дип уйлый.

Бер көнне дүрт йөз хатынны сараена кунак итеп чакыра. Барлык хатыннарга да берәр тәлинкә, берәр пычак китереп тоттыра. Йосыфның чәчләрен үзе тарап үреп, зиннәтле киемнәр киендереп, пәрдәсен йөзенә ябындырып, әлеге дүрт йөз хатын утырган зур залга кертә. Бу хатыннар алдына китереп, Йосыфның битеннән пәрдәсен ачып җибәрә. Бер минут та тотмый, алып чыгып китә. Бичара хатыннар, моны күргәч, һуштан язалар. Йосыфның матурлыгын күреп бары да гашыйк булалар.

Хәзер Зөләйха бу хатыннарга берәр җимеш китереп бирә. Бер кулларына җимеш, бер кулларына пычак тоттыра.

– Тәлинкәгә куегыз да турый башлагыз, – дип боера.

Үзе шул вакыт тагы Йосыфны дүрт йөз хатын утырган бүлмәгә кертә. Барлык хатыннар, күзләрен Йосыфка текәп, җимеш тураган бармакларын кисәләр. Үзләре бармаклары киселгәннең әрнүен дә тоймыйлар. Йосыфның чибәрлеге сихерли шикелле боларны. Шуннан Йосыфны алып чыгып китәләр. Зөләйха дүрт йөз хатынның алдына килеп баса:

– Менә күрдегезме? Үз кулларыгызны, үз бармакларыгызны җимеш итеп турадыгызмы? Белдегез инде хәзер, минем гайбәтемне ни өчен сатасыз икән. Бер генә минут күрдегез дә бармакларыгызны турадыгыз. Ә мин Йосыф кайгысыннан ничә ел янам. Аны күргәнемә генә җиде ел, аннан соң күпме яндым. Шулай да мин түзәм, бармакларымны да тураганым юк. Сабырым сездән көчлерәк икән, – дип, хатыннарга үзенең бәетен әйтә.

Хатыннарның исләре китә:

– Дөрес, Зөләйха, синең сабырлыгың безгә караганда көчле икән, – диләр.

Шуннан соң Мисыр хатыннары Зөләйха турындагы бу гайбәтне сөйләмиләр, һәрберсе үзләре гайбәткә кала. Йосыфны бер күреп тә гашыйк булмау мөмкин түгел икән, диләр.

Бервакыт Йосыф патша ат өстендә сарай алдыннан үтеп барган була. Аның кулында камчысы. Зөләйха Йосыфның каршысына чыгып, килгән юлында көтеп тора. Җылап күзләре сукырая башлаган, яхшы күрми дә. Йончыган, йөзе нурсызланган, Йосыфка булган мәхәббәтеннән картайган Зөләйха. Юлда утырып тора икән. Йосыф:

– Нигә бире утырып торасың? – дип сүз кушкан. Зөләйха әйткән:

– Йосыф, сиңа бер генә сүзем бар. Бир әле камчыңны, – дигән.

Йосыф камчыны Зөләйхага сузган. Зөләйха камчы сабын авызына китереп өргән дә шунда ук Йосыфка тоттырган. Камчы сабы янып китәр дәрәҗәдә кызу булган. Йосыф кулы пешүдән камчыны ташлап җибәргән. Шуннан соң Зөләйха:

– И Йосыф! Син камчыны тоттың да ыргыттың. Кулың пеште. Минем ничә еллар буе йөрәгемдә шул ялкын янып тора, мин

түзәм. Ә синең кулың минем бер өргән сулышымдагы кайнарлыкка, утка да чыдамады. Күр минем мәхәббәтем ничек көчле икәнен! Шунда да исбат итмәсәм, ничек итеп аңлатыйм сиңа? Бу бит ничә йөздән бер өлеше генә. Менә мин ничә еллардан бирле гыйшык утында янам, – дигән.

Йосыф бер уйга килгән.

– Зөләйха, мин сине аңлыйм. Шундый ялкын эчендә син тугрылыклы мәхәббәт белән генә түзә аласың, шулай сөя аласың икән. Мин синең барлык газапларыңны алам, мәхәббәтеңне үземә кабул итәм, – дигән.

Шуннан Зөләйхага өйләнергә риза булган. Зөләйха шатлана, аның эчендәге кайгылары бетә бара. Көннән-көн йөз сарылыгы кими. Ул бит әле яшь. Картаеп җыерчыкланмаган йөзләре, кайгыдан гына. Икәү бергә тора башлагач, Зөләйха бөтенләй башка кешегә әйләнә. Матурлыгы, гүзәллеге кире кайта. Йосыф аны күреп соклана, тиң итә. Йосыф – Зөләйханың мәхәббәте аларның бәхетле, тигез гомер итүләре белән бара.

Шуннан ачлык ел килеп җитә. Дөрестән дә җиде ел халык, ачыга, интегә.

Көннәрдән бер көнне Якубның уллары әтиләренә бер хәбәр ишетеп кайталар.

– Әти, илдә ачлык. Мисыр иленең патшасы бик юмарт күңелле икән. Ачка үлә торган кешеләргә ярдәмләшә икән. Анда барып карасак ярамасмы икән, – дигәннәр.

Әтиләре риза булган. Уллары чыгып киткән. Мисыр патшасы алдына килеп басканнар.

– Мисыр патшасы бик миһербанлы, дип ишеттек, Безгә сукыр атабыз хакына, туганнарыбыз хакына, ачтан үлмәслек кенә булса да ярдәм итсәң иде, – дигәннәр.

Йосыф үзенең туганнарын танып алган да:

– Минем бүлмәмә керегез! – дигән. Шунда аңа сигез туганы сәҗдә кылганнар. Йосыф:

– Мин сезгә ярдәм итәрмен. Менә бер олау иген төяп алып китәрсез. Әтиегез ни хәлдә? Ул нишли? Дөньядамы? – дигән.

Болар әйткәннәр:

– Әтиебез дөньяда. Тик аның күзләре күрмәс булды. Безнең бер туганыбыз бар иде, шул туганыбыз үлгәннән соң, ул, елап, сукырайды.

Йосыф пәрдәле булгач, белмиләр. Йосыф биргән малларны алып, кайтырга чыгалар. Йосыф озата чыга.

– Сезнең тагын туганнарыгыз бармы? Алар исәннәрме? – ди.

– Бар. Атабыз бер, анабыз башка туганыбыз Ибне-Әмин бар, сеңлебез Динә бар.

– Ә ул Ибне-Әминне нигә алып килмәдегез?

– Атабыз аны җибәрми. Сөекле улым Йосыфны адаштыргач, Ибне-Әминемне дә юк итәрсез, ди ул.

– Ярар, башка вакытта Ибне-Әминне дә алып килегез, әтиегезгә сәлам әйтегез, – ди Йосыф.

Моны кайтып әтиләренә сөйләгәч, әле улы һаман да исәндер, дип өметләнеп яшәгән ата, бу сүзләрне әйтүче кеше Йосыф үзе түгел микән, дип шикләнә башлаган.

Икенче елны Ибне-Әминне дә алып китәргә кушкан.

– Әгәр аны да адаштырсагыз, шул минутта үләрмен. Аталык хакына Ибне-Әминне саклап йөртегез, – дип әйтеп калган.

Уллары, ант итеп, Ибне-Әминне алып киткәннәр. Йосыф боларга тагы ашлык биреп җибәргән. Ләкин Ибне-Әминне бер бүлмәгә чакырып, үзенең кем икәнлеген әйткән, барысын сер итеп кенә сөйләшкәннәр.

– Мин сине янымда калдырыр идем, – дигән Йосыф.

– Ә юк, мин монда калсам, әтиебез бик кайгырыр, шунда ук үләр, – дигән Ибне-Әмин. Йосыф шундый фикергә килә. Ике олау иген бирә. Ибне-Әмин саклый торган олауга алтын тустаган яшерә. Капканы чыгып киткәндә, алтын тустаганны урладылар, дип тентү ясата. Алтын тустаган Ибне-Әмин олавыннан чыккач, аны хөкемгә тарткан кебек алып кала. Әтиләренә язып җибәрә: «Ибне-Әмин ышанычлы кулда. Мөмкин булса, үзегез дә килеп чыгыгыз».

Агаларына:

– Үзгә вакыт атагызны да алып килегез, – дип әйтеп җибәргән.

Болар хатны тапшыргач, әтисе ул кешене күрер өчен ашкына башлый. Икенче барганда әтиләрен дә, Динәне дә алып китәләр. Инде ун туганы моның алдында сәҗдә кылалар. Шул вакыт Йосыф үзенең пәрдәсен ача:

– Менә кайчан әтиемнең, төш юраганы дөрескә килде. Ун туганым минем алдымда сәҗдә кылалар, – дигән.

Шуннан Якуб патша улын кочаклап, елап, яңадан күрә башлый. Йосыф әйтә: «Сез, туганнарым, миңа яманлык эшләдегез. Ә мин сезгә яманлык белән җавап бирмәдем, чөнки сез минем кан кардәшләрем, – ди, әтиләре алдында туганнары моны нишләткәннәрен сөйләп бирә.

Шуннан: «Мин сезне гафу итәм, – ди. – Үземнең сараемда сезне рәхәттә яшәтәм», – ди туганнарына. Сөенешәләр.

**ЙОСЫФ КИТАБЫ**



**ЙОСЫФ ВӘ ЗӨЛӘЙХА**




## Кузыйкурпас белән Майсылу[1]

Борын-борын заманда бер авылда Күчәрбай исемле бай белән Күчмәсбай дигән кешеләр яшәгәннәр. Беркөнне алар икесе дә урманга ауга чыкканнар.

Урманга кергәч, алар аерылганнар, бераз йөргәч, тагы бергә туры килгәннәр. Алар урманда ниләр күрүләре турында бер-берсеннән сораштыра башлаганнар.

Күчмәсбай:

– Мин бер болан күрдем. Атыйм гына дигән идем, ике имчәгеннән дә сөт ага башлады, – дигән.

Күчәрбай:

– Мин дә бер болан күрдем. Атыйм дигән идем, ике имчәгеннән сөт ага башлады, – дигән.

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 90, папка 2, сакл. бер. 19; колл. 91, папка 1, сакл. бер. 33; Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче – Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. Б. 187–193.

Боларның икесенең дә хатыннары йөкле булган икән. «Алар мөгаен үрчегәннәрдер», дигән карарга килгәннәр дә кайтып киткәннәр.

Кайтканда сөйләшеп кайталар:

– Әгәр дә беребезнең кыз, икенчебезнең ул булса, икесенә хәзердән үк никах беркетеп куябыз, – дип, берсенә-берсе сүз биреп куялар.

Кайтсалар, Күчәрбайның кызы, Күчмәсбайның улы бар, ди. Боларга никах беркеткәннәр. Күчәрбайның кызына Майсылу, Күчмәсбайның улына Кузыйкурпас исеме кушканнар.

Еллар бер-бер артлы узганнар да узганнар, кыз белән егет тә үскәннәр.

Бердәнбер көнне Күчмәсбай үлә. Кузыйкурпас әнисе белән ятим кала. Әтисе үлгәч, улы тәртипсезләнә. Урамда шар сугып уйный, балаларны кыйный да кайтара икән.

Бер көнне шар сугып йөргәндә шар бидрәгә төшкән, төбен тишеп тә чыккан. Икенче көнне бер кортканың улын кыйнап кайтарган.

Монсы торып торсын, хәзер Күчәрбайга күчик. Кузыйкурпасның әтисе үлгәч, Кузыйкурпас теләсә ничек йөри башлагач, Күчәрбай моңа кызын бирмәскә була. Барлык малларын алып, бу авылдан күчеп китә. Болар бара торсыннар. Хәзер Кузыйкурпаска күчик.

Кузыйкурпас теге малайны кыйнап җибәргәч, аның әнисе килә дә Кузыйкурпасны тирги башлый:

– Җүнле булсаң, сине сөйгәнең ташлап китмәс иде, – ди. Моңа Кузыйкурпас аптырый, корткадан бу хәлне аңлатып бирүен сорый. Кортка аңа әйтә:

– Әгәр беләсең килсә, кайт та әниеңә борчак куырырга куш, – ди. – Ул сиңа борчакны тәлинкә белән бирер, син аны алма. Син алмагач, кашык белән бирер. Син анысын да алма: «Учың белән бир», – диген. Ул сиңа учы белән бирер. Учы белән биргәндә, учын кыс та: «Минем сөйгәнем кем?» – диген. Шуннан белерсең, – дигән.

Кузыйкурпас кайткан да, әнисенә борчак куырырга кушкан. Борчак куыргач, әнисе аңа тәлинкәгә салып биргән. Ләкин Кузыйкурпас алмаган. Әнисе кашык белән биргән. Тагын алмаган.

– Учың белән бир! – дигән.

Әнисе борчакны учына алып бирәм дигәндә генә улы аның кулын эссе борчак тоткан көйгә кысып тоткан:

– Минем сөйгәнем кем? Әйт, – дигән.

Әнисе башта, «белмим, белмим» дип, кызу гына әйткән. Кузыйкурпас алай гына җибәрмәгән. Кулы пешә башлагач, әнисе:

– Майсылу иде, алар киттеләр, – дигән.

Моны ишетү белән Кузыйкурпас теге корткага йөгергән:

– Әби, әни минем сөйгәнемне әйтте, мин аны ничек табыйм? – дигән.

Кортка:

– Синең атаңның ат көтүе бар, ул көтүдә алты колачлы ала бия бар, шуны ал да юлга чык, табарсың, – дигән.

Шатланып риза булган егет. Бер көнне атлар су эчә торган күл буена барып, атлар төшкәнне көтеп ята. Атлар уйнаклый-уйнаклый су эчәргә төшәләр. Алты колачлы ала бия күл кырыена су эчәргә килә. Егетне күргәч, кире чабып китә. Ике рәт шулай эшли. Өченчесендә егет аркан белән атны эләктереп ала да тиз генә атланып та ала.

Ат телгә килә:

– Син минем хуҗам булырсың, мин сиңа буйсынам. Минем аркамнан ярып ал, анда синең әтиеңнең көмеш балтасы белән көзгесе бар. Шуларны ал да мине шушы күл буена бәйләп куй. Кырык көннән килеп алырсың, минем ярам анда төзәлгән булыр, – ди.

Кузыйкурпас кайтып китә. Кырык көн узгач, тагын күл буена бара. Атның ярасы төзәлгән. Атны алып кайта, әнисенә үзенең китүе турында әйтә.

Әнисе аның китүенә риза булмый:

– Көтү-көтү малларны кемгә куясың, бәбкәем? – ди.

Кузыйкурпас:

– Ач бүреләргә булырлар, юкка пошынма, әнкәем.

Әнисе:

– Калын кара урманнарны ничек үтәрсең, бәбкәем?

Кузыйкурпас:

– Әтинең көмеш балтасы бар, юкка кайгырма, әнкәем.

Әнисе:

– Бик киң олы суларны, ничек үтәрсең, бәбкәем?

Кузыйкурпас:

– Әтинең ялтыр көзгесе бар, кайгырмачы, әнкәем.

Әнисе:

– Җиде кабып бер йотар бүредән ничек котылырсың, бәбкәем?

Кузыйкурпас:

– Алты колачлы ала биям ярдәм итәр, әнкәем, – ди. Атына атланып чабып китә. Бераз баргач, бик зур калын урманга очрыйлар. Алты колачлы ала бия көмеш балтаны ташларга куша. Кузыйкурпас ташлый. Боларга юл ачыла. Урманны чыккач, балтаны алып, үз юлларына юнәләләр.

Бара торгач, бик зур суга очрыйлар. Алты колачлы ала бия көзгене ташларга куша. Кузыйкурпас ташлый, шунда ук пыяла күпер хасыйл була. Шул күпердән чыгып китәләр дә көзгене алалар.

Бара торгач, болар бик биек тау күрәләр. Тау башына менеп җитсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, җиде кабып бер йотар бүре тешләрен ыржайтып тора. Ала бия Кузыйкурпаска әйтә:

– Миңа бик каты итеп камчы белән уң ягыма сук, сул ягымнан кан чәчрәп чыксын, шул вакытта син күзеңне йом, без бу бүредән котылырбыз, – ди.

Кузыйкурпас ат әйткәнчә эшли. Күзен ачып җибәргәч, алты колачлы ала бия:

– Артыңа әйләнеп кара! – ди.

Караса, ни күзе белән күрсен, әнисе чәчен-башын туздырган, тау башында елап утыра:

– Син киткәч, чәчләремне кара урман иттем, күз яшьләремне зур су иттем, ике колагымнан, ике күземнән, ике танау тишегемнән, авызымнан җиде кабып бер йотар бүре итеп карадым, булмады, тыңламадың, киттең. Шуның өчен, китәр юлың булса да, кайтыр юлың булмасын, – дигән.

Кузыйкурпас анасының сүзенә карамый, үз юлын дәвам итә. Баралар-баралар болар, бара торгач, бер көл өеме кырыена ял итәргә тукtыйлар. Кузыйкурпас көлне актара, аннан көл күмәче килеп чыга, суынып беткән. Моны Майсылу калдырган була.

Бара торгач болар, тагын шундый ук көлгә очрыйлар. Монда да төче күмәч табалар, монысы җылырак була. Бара-бара тагын көл өеме кырыена туктыйлар. Кузыйкурпас тагын төче күмәч таба, монысы эссе була.

Бара торгач, бер куй көтүчесенә очрыйлар. Бу көтү Күчәрбайныкы була. Кузыйкурпас көтүчедән:

– Мине дә бай көтү көтәргә алмас микән? – ди.

– Тай көтәр өчен, байга көтүче бик кирәк, – ди куй көтүчесе. Кузыйкурпасны бер куй танып алып, аның килүе турында Майсылуга хәбәр итәргә йөгерә. Бу вакытта Майсылу Кузыйкурпасны сагынып, елап утыра икән. Куй тәрәзә каршысына килә дә, арт аякларына басып:

Майсылу, Майсылу, Кузыйкурпас килде лә, Кузыйкурпас килде лә, – ди дә йөгереп китеп тә бара.

Моны ишеткәч, Майсылу бик шатлана.

Кузыйкурпас тай көтүчесе булып яллана.

Кыш җитә. Бервакыт каты буран була. Бу буран вакытында тайларны бәйләп куялар. Атны бәйләшергә Майсылу да чыга. Майсылу атларны бәйли бара, Кузыйкурпас бауларны кисеп бара икән. Майсылу моңа аптырый, кырыенда гына басып торган Кузыйкурпасны күрә. Майсылу Кузыйкурпасны бер сарайга алып керә, шунда сөйләшеп утыралар.

Күчәрбайның Колтырбашлы Колтыртаз исемле вәзире була, аның бичәсе Саесканнансак исемле була. Бу хатын Майсылу белән Кузыйкурпасның сөйләшеп утырганнарын энә кебек тишектән күреп ала да иренә кереп әйтә. Колтырбашлы Колтыртаз Майсылуны икенче хатынлыкка алырга йөри икән. Бичәсе моны белми. Колтырбашлы Колтыртаз моны Күчәрбайга әйтә.

Күчәрбай чыгып, кызын алып керә, аны беркая чыгармый башлыйлар, Кузыйкурпасны үтерергә план коралар. Аңа Майсылуны бирәбез дип туй ясап, Кузыйкурпасны шунда үтертмәкче булалар.

Майсылу моны ишетеп ала да туй әзерлеге башлангач, Кузыйкурпаска әйтә:

– Сине үтерергә җыеналар. Син туйда бер дә эчмә. Мин сиңа бер савыт бирермен, шуны муеныңа асарсың да биргән аракыны

шуңа салып торырсың. Аннан соң сиңа биергә кушарлар. Синең урынга мин биермен. Мин ике мәртәбә әйләнеп чыккач, өченче мәртәбә әйләнгәндә атыңнан алган кылыңны көйдерерсең. (Кузыйкурпаска аты, авырлыкка очрасаң – көйдерерсең дип, өч бөртек кылын биргән була.) Аннан соң синең атың килер, мин шәл чугымны селтәп җибәрермен, син атланып чабарсың, – ди.

Туй җитә. Кузыйкурпаска кияү дә кияү дип, эчемлек бирә башлыйлар. Ләкин кияү кеше алар биргән эчемлекне эчми. Эчкән булып, үзенең эчтәге савытына сала бара. Аңа биергә кушалар. Шул вакытта Майсылу: «Аның өчен үзем бием», – дип, биергә башлый. Ике мәртәбә әйләнеп чыга. Өченче мәртәбә әйләнгәндә Кузыйкурпас кылны яндыра, шул вакыт алты колачлы ала бия чабып килеп җитә. Майсылу шәл чугын селтәп җибәрә, Кузыйкурпас атка атланып кача.

Шул вакыт кешеләр аны куа барырга дип атка барсалар, атлар барысы да тышаулы, моны Кузыйкурпас шулай эшләгән була. Алар атны рәтләп киткәнче, Кузыйкурпас хәтсез генә юл ала. Колтырбашлы Колтыртаз аны чак кына тотмый кала.

Кузыйкурпас арып-талып, Сөн суы буена барып туктый. Бу бик матур су буе була.

Кузыйкурпасның карыны ача. Агач башындагы каргага:

– Зинһар, бармак бите кадәр генә язуны Майсылуга илтеп бир, – ди.

Карга аңа:

– Менә син үлсәң, миңа азык булыр иде, – ди дә очып китә. Саескан килеп куна, аңа әйтеп карый, ул да тыңламый. Сандугач килеп куна да матур итеп сайрый башлый.

Кузыйкурпас аңа:

– Зинһар, сандугачым, Майсылуга бәләкәй генә язу илтеп бир, – ди.

Сандугач риза була. Кузыйкурпас бер яфрак алып хат яза, сандугачның канаты арасына кыстырып җибәрә. Сандугач Майсылу тәрәзәсе каршындагы агачка барып куна, бик матур итеп сайрый башлый. Аннан соң тәрәзә кырына куна да Майсылуның алдына кунып сайрый башлый. Майсылу яфракны күреп алып, тиз

генә укый, зәйтүн мае белән катырып эшләнгән чикләвек кадәр туклыклы азык җибәрә.

Сандугач болар арасында хәтсез вакытлар йөри. Бу вакытта Кол-тырбашлы Колтыртаз көн дә Майсылуны әтисеннән сорый. Бу хәлне Саесканнансак белми әле.

Бер көнне Майсылу бүлмәсендә Саесканнансак Майсылуның башын карый. Майсылу йокыга китә. Нәкъ шул вакытта сандугач килә дә Майсылуның кулбашына кунып сайрый башлый. Саесканнансак сандугачны тотып ала, йонын йолка башлый:

– Кузыйкурпас кайда? Кузыйкурпас кайда? – ди.

Сандугач:

– Мин белмим, – ди.

Иң азакқы бер бөртек йоны калгач, «Сөн, сөн» дигән тавышка Майсылу уянып китә. Майсылу бу хәлне күреп аптырап кала:

– Харап иттең сандугачны! – ди. Саесканнансак тиз генә чыга да әйтә:

– Кузыйкурпас Сөн суы буенда икән, – ди. Колтырбашлы Колтыртаз тиз генә ат җигеп китә. Сөн суы буена барып, Кузыйкурпасны үтереп кайта. Майсылу бу хәлне белеп, бик кайгыра, елый. Бер көнне ул әтисеннән сәхрәдә йөреп кайтырга рөхсәт сорый:

– Колтырбашлы Колтыртаз белән чыгам, – ди.

Әтисе рөхсәт бирә. Майсылу Колтырбашлы Колтыртазга әйтә:

– Әгәр мине Кузыйкурпас кырына бер мәртәбә алып барсаң, мин сине яратырмын, икәү бик рәхәт гомер сөрербез, – ди.

Колтырбашлы Колтыртаз моңа шатланып риза була. Ат җигеп китерә, Майсылу чыгып утыра да Сөн суы буена китәләр.

Бик матур айлы кич була. Сөн суына карап, Майсылу яр буенда утыра. Колтырбашлы Колтыртаз да аның белән рәттән утыра икән. Майсылу гаять матур була. Үзенең шәүләсен суда күрә дә әйтә:

– Миңа иптәшкә анавы су төбендәге чибәр кызны алып чык, миңа да иптәш булыр, бергә-бергә күңелле булыр, – ди.

Колтырбашлы Колтыртаз кызны карыйм дип суга иелгәч, Майсылу аны суга төртеп төшерә. Зур пычакны Кузыйкурпасның күкрәгенә куеп, үзе шул пычакка ята, пычак туп-туры аның йөрәгенә керә, Кузыйкурпасны кочаклап үлә.

Моннан юлчылар үтә. Бу юлчылар Күчәрбайга фатирга керәләр. Күчәрбай кызының кайтмавына бик аптырап тора икән.

– Ягез, юлчылар, дөньяда нинди хәбәрләр ишеткәнегез бар, сөйләп җибәрегез, – ди.

Юлчылар:

– Ишеткәнне сөйләүгә караганда күргәнне сөйләү яхшырак булыр, – диләр. – Сөн суы буенда өч кеше үлеп ята, шуларның икесе яшь, берсе кыз кеше, икенчесе егет кеше. Алары кочаклашып үлгәннәр. Берсе картрак кеше, бер үзе генә, – ди.

Күчәрбай боларның берсе үзенең кызы икәнлеген белеп, Майсылуны Кузыйкурпаска бирмәгәнлегенә бик үкенә. Чөнки Майсылу аларның бердәнбер балалары була.

Тиз генә атлар белән барып, Майсылу белән Кузыйкурпасны икесен бер кабергә Сөннең уң як ярына, Колтырбашлы Колтыртазны Сөннең сул ягына күмәләр. Майсылулар кабере өстенә алмагач үсеп чыга. Колтырбашлы Колтыртазның кабере өстенә тигәнәк үсеп чыга. Ул су аркылы үтеп, Майсылулар кабере өстендәге ике алмагач арасыннан уралып үсә башлый.

Бу ике алмагачка бер пар сандугач оя ясаган була. Бервакытны алмагачка бер бала, үрмәләп, оя ботарларга менә башлый. Ул Колтырбашлы Колтыртазның улы була. Бу пар сандугачлар:

– Дөньялыкта атаң яшәргә ирек бирмәде, әле син ирек бирмисең, – дип, китәләр.

**КУЗЫ КӨРПӘ**



## Таһир – Зөһрә[1]

Бер патша була. Патшаның да баласы юк, вәзирнең дә баласы юк. Шуннан вәзир белән патша чыгып китәләр сәхрәгә. Барып кerделәр бакчага, бер карт утыра. Кулына каләм тоткан, алдында – кәгазе. Килеп болар сәлам бирәләр. Шуннан соң: «Балам, – ди, – кулыгызны бирегез», – ди карт әйтә. Шуннан соң кулларын бирәләр дә карый.

– Сез, – ди, балага мохтаҗ икәнсез, – ди. – Сезгә бала кирәк, – ди.

Бер алманы ала да алманы кап-кари урталай яра, урталай яра да берсен патшага, берсен вәзиргә бирә. Шуннан соң:

– Менә, – ди, – икегезгә бер алманы ярдым, бу алма, – ди, – ашагыз, – ди. – Берегездән туар ир бала, – ди. – Берегездән туар кыз бала, – ди. – Боларны, – ди, – никах вәгъдәсенә җиткәч, берсен икенчесеннән аермагыз, – ди. – Башыгызга бик зур бәла килер, – ди.

Шулай булды, тегеләр алманы алып кайттылар, ашадылар инде, хатыннары корсакка калды. Вәзир хатыны тапты ир бала, патша хатыны тапты кыз бала. Таһир белән Зөһрәне.

Шуннан бер вакытны, бер ана тәрбияли боларны, балаларны бер-берсеннннән аермыйлар. Мәктәпкә йөриләр болар. Боларның инде яшьләре җитә башлады инде, үсәләр. Таһирның җимеше төшеп китә. Авызыннан үбә. Зөһрә әйтә:

– Сиңа – ди – оят түгелме, – ди. – Мин синең, – ди, – карендәшең, – ди.

– Нишләп мин синең карендәшең булыйм, – ди. – Мин – вәзир баласы, син – патша кызы, – ди.

Шуннан бер вакытны моны бик нык әрләде. Бу кыз моңа эндәшми дә, сөйләшми дә моның белән. Шуннан:

– Әй, Ходаем, – ди, Таһир әйтә, – үзенә дә бирсен икән мәхәббәтне, – ди. Патша кызына да гыйшык төшә. Бу әйтә:

---

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ ЯһММҮ. Фольклор фонды, колл. 93, папка 1, сакл. бер. 21, кассета № 1.

– Таһирның сүзе рас бит, – ди. – Мин, – ди, – патша кызы, ул вәзир баласы, – ди. – Ничек инде, – ди, – туган булабыз, – ди. Гыйшыгы төшә Таһирга. Шуннан соң болар йөриләр шул. Бер гарәпләре була. Теге гарәп әйтә: «Кызыңны аздыра», – ди. Шуннан әйтә:

– Никах вәгъдәсе җиткәндер, – ди. – Алдан безгә шулай дип әйтте бит, – ди, – теге бабай, – ди. Шуннан хатынына әйтә:

– Син әзерлән, – ди. – Зөһрәне Таһирга бирәм, – ди.

– О, – ди [хатыны]. – Минем кызым патша кызы булсын, – ди, – ул вәзир баласы булсын, – ди. – Мин нигә кызымны вәзир баласына бирим, – ди.

Бер ырымчы карчык китерә дә патшага өшкереп, Таһирдан биздерә. Бизә теге. Шуннан ярар. Теге гарәп йөри тегеләрнең арасында азар-мизәр китереп.

Шуннан бер вакытны патшага әйтә:

– Таһир, – ди, – аздыра кызыңны, – ди.

Патша бара да качып карап йөри. Зөһрә утыра бер агач төбендә, Таһир утыра бер агач төбендә. Шигырь әйтешәләр.

Шуннан бер вакытны патша әйтә: «Никах вәгъдәсе җиткән», – ди тагын. Бичаракай Таһирны зинданга ябалар. Зөһрә әйтә:

– Әти, – ди. – Миңа өй сал, – ди.

Салдырды өй кәрванның юл өстенә. Зөһрә шунда тора. Таһирны озаттылар инде. Шулай бервакыт кәрваннар үткәндә Зөһрә хат яза да таш бәйләп кәрванчыларга атып бәрә. Хатка язган шул Таһир турында. Төшәләр нәкъ төрмә янына.

– И, – ди, – безнең яктан килгән кәрван икән бу, – ди [Таһир].

Шунннан соң теге бәйләгән нәмәне ташладылар. Таһир егыла. Шул арада ис кереп, күзләрен ачып җибәрә, тегеләр юк. Шуннан бу елый, елый бичара. Шул вакыт, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, төрмәнең ишеге ачылып, кулларындагы баулары чишелеп, Таһир тагын үзенең өенә кайта.

– Ачыгыз, мин кайттым, – ди инде. – Зөһрә, мин кайттым, – ди инде.

[Зөһрә] атасына әйтә:

– Таһир кайткан, Таһир кайткан, – ди.

Атасы әйтә:

– Ничек кайтсын, әллә кайдагы Таһир кайтамы? – ди.

Тыңлап-тыңлап тора да [Зөһрә], тагын:

– Таһир кайткан, Таһир кайткан, – ди.

Өйгә алып керәләр, бу монда тора әле. Шуннан бер вакыт теге карт боларны күрә. Тагын патша күрә. Патша сандык ала, сандыкка сала да диңгез суына агызып җибәрә. Шуннан моңа Зөһрә яза. Гөлпатша дигән патшаның өч кызы була. Агыза да шул, шигырь әйтеп бара патша кызы Зөһрә турында. Кызлар тотып алалар теге сандыкны. Сандыкны ачсалар – егет. Өч кызның берсе әйтә – миңа, ди, икенчесе әйтә – миңа, ди, өченчесе дә миңа, ди. Таһир әйтә, мин сатлык товар түгел, ди. Жирәбә салыгыз, ди, кайсыгызга чыгармын, ди.

Җирәбә салсалар, иң кечкенә кызга чыкты. Ярар, туйларга әзерләнәләр болар. Әкертен генә Таһир тая боларның кулыннан. Китә инде, кача. Шулай бер вакытны бер чишмә буена барып ятса, йокыга китә. Бер карт моның янына килеп, өшкерептөкереп, уятып, Таһирны җибәрә.

Таһир кайтып керде, апасына кайтып керде.

– Ни хәбәрләр бар? – ди, – Зөһрәнең ни хәлләре бар? – ди.

– Зөһрәләр туйга әзерләнәләр, – ди апасы.

– Апа, – ди, – киемнәреңне бир, – ди, – туйга барыйм, – ди.

– Үтерерләр сине, – ди апасы.

– Бир әле, бир, – дип, апасының шәлләрен, күлмәкләрен киеп бара Таһир. Кызлар моны күтәреп алалар инде. Шуннан бу качарга әйтә. Әлеге имансыз гарәп тагын боларны тоттыра. Шуннан моны асарга боералар. Таһирны үтерергә совсем. Шуннан ул [Зөһрә]:

– Үзең акыллы патшасың, – ди, – халыкларга акыл бирә торган, – ди. – Ул малайны үтертеп сиңа ни файда? – ди. – Ул ярдәмче булыр, – ди.

Патша әйтә, ярар, ди, Зөһрәне кушып бернинди җыру әйтмәсен, ди. Шуннан соң ике рәкагать намаз укыйм, дип, патшадан рөхсәт сорый, шуннан Зөһрә килеп чыга:

– И ата, миңа салган сараеңның
Эченә ут сал инде, – ди.
Ялкын итеп бер яндырып,
Бер кызынып кал инде, – ди.

Эт зәйтүнен китерерсең, – ди,
Аны кунак итәрсең, – ди,
Миннән башка кызың булса,
Аны кияү итәрсең, – ди.

Шуннан Таһир янына килә дә, күкрәгенә башын куя да Таһир да үлә, Зөһрә дә үлә. Аларны кеше үтерми, алар үзләре үләләр. Алар, шулай итеп, бергә була алмыйлар. Алар икесе бер алмадан яралганнар. Китабыннан укып карасаң, күп инде ул.

## ТАҺИР ЖЫРЫ



## БУЗ ЕГЕТ


♩= 80
1. Коль- һү әл-хәм сү-рә-се коръ-ән-нең ба-шын-да-дыр,
йар-йар, пәй- гам-бәр-ләр хо-дай-ның кар-шын-да-дыр, йар-йар. Бе-
рең а - па, бе-рең җиз-нә, ку-шы-лып-сыз, йар-йар. Бе-
рең ай-дыр, бе-рең көн-дер, ку-шы-лып-сыз, йар-йар. Бе-
рең ал-ма, бе-рең хөр-мә, те-зе-леп-сез, йар-йар. Бе-
рең я-кут, бе-рең гәү-һәр, те-зе-леп-сез, йар-йар За-
ман а- хы-ры бул-га-ны-ча а(е)-рыл-ма-гыз, йар-йар.

# ЧИЛӘБЕ ТАТАРЛАРЫНДА СҮЗ СӘНГАТЕ

*Лилия Мөхәммәтҗанова*

Чиләбе өлкәсе – татарлар күпләп яши торган төбәкләрнең берсе. Халык санын соңгы исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, биредә яшәүче халыкның 5,4% ы үзен татар милләтеннән дип саный, бу сан аларның монда күпчелекне тәшкил иткән милләтләр арасында икенче урында булуларын күрсәтә. Әле нагайбәк дип язылган туганайларның рәсми төстә татарлар исәбенә кермәгәнен истә тотсак, биредәге милләттәшләребезнең саны тагын да арта. Шуңа да Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы фәнни экспедицияләрнең берсе быел нәкъ менә Чиләбе өлкәсенә булу бер дә очраклы хәл түгел. Институтыбыз – татарларны һәрьяклап фәнни өйрәнә торган академик оешма, Чиләбе өлкәсе татарлары белән кызыксыну тел, халык иҗаты, тарих, археография, сәнгать белгечләрен бергә туплады. 2016 елның июнендә без Чиләбе өлкәсендә яшәүче кан-кардәшләребез янына юл тоттык.

Экспедициянең җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты Ильмир Ямалтдинов, белгечләрдән телче, филология фәннәре докторы Флера Баязитова, фольклорчы, филология фәннәре докторы Лилия Мөхәммәтҗанова, сәнгать белгече Людмила Шкляева, археограф Айгөл Әхмәтова – комплекслы экспедиция әлеге составта эшләде, татар авыллары буйлап безне Институтыбыз автобусында Наил абый Шәрәфетдинов йөртте.

Бу тирәләрдә татарлар турында тарихта иң беренче мәгълүматлар XI гасырга ук барып тоташа. Шул чордагы фарсы галиме Әл-Гардизи Көньяк Урал территориясенең, шул исәптән бүгенге Чиләбе өлкәсенә карый торган җирләрнең урта гасыр төрки дәүләтләренең берсе булган Кимак каганлыгына керүе хакында язып калдырган. Кимак каганлыгы составына җиде үзара якын кардәш кабилә кергән, шулар арасында Татар һәм Кыпчак кабиләләре дигән исем белән билгеләләре дә булган. Татарлар каганатта идарә итүче йорт исәбендә торганнар, каганлыкның көнбатышын, ягъни хәзерге Чиләбе өлкәсе урнашкан территорияне биләгәннәр. XIV йөз тарихчысы Ибне Халдун шулай ук кыпчаклар арасында татарларның аерым этногенетик тармак тәшкил итүләре турында яза[1].

Татар этносы ныгып формалашу чорында Чиләбе өлкәсе җирләре данлы һәм шанлы татар дәүләте Алтын Урда территориясе булган, биредә батырлар дан алган, нигезләр корылган, төрки нәсел дәвам иткән... Алтын Урда чорында хәзер Чиләбе өлкәсенә керә торган җирләрнең көньяк өлешеннән кәрван сәүдә юллары үтә торган булган, бу исә мондагы татарларның әле урта гасырларда ук сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләрендә актив катнашкан булуы турында сөйли. Бүгенге көндә Чиләбе өлкәсендә Алтын Урда чоры кайтавазы булып татар шәһәрлекләре, «Тамерлан манарасы» исеме белән билгеле һ.б. борынгы төрбәләрнең табылып торуы, әлеге төрбәләрнең төзелеш архитектурасы, төзүдә кулланылган материаллары, бигрәк тә квадрат формалы «татар кирпече» һ.б. – болар барысы да татар мәдәнияте эзләре, элгәрләребез тормышының урта гасырлар катламына карый торган ядкәрләре.

Алтын Урда таркалгач, бу җирләрнең төньяк өлеше – Себер ханлыгына, көньяк өлеше Нугай Урдасына керә[2]. Чиләбе туфрагының Казан ханлыгы яулап алынганнан соң ханлыктан көнчы-

[1] *Исхаков Д.М., Измайлов И.Л.* Этнополитическая история татар в VI – первой четверти XV века. Казань: Иман, 2000. 136 с.

[2] *Долгих Б.О.* Родовой и племенной состав народов Сибири в XVII веке. М., 1960. С. 62.

гышка таба качып китәргә мәҗбүр булган кан-кардәшләребезне сыендырган урын икәнлеге дә мәгълүм. Себер ханлыгы алынганнан соң, XVII йөздә бу территорияләр татар административ идарәсенә әверелә, рус дәүләте колонизацияләгән җир буларак, йомышлы татарлар урнашып эшли торган биләмәне тәшкил итә. Мәсәлән, Алексей Иванович Тәфкилев исеме белән патша хезмәтендә полковник дәрәҗәсендә йөргән Котлымөхәммәд исемле татарның биредә Миасс, Чиләбе, Чибәркүл һ.б. ныгытмалар салдыруда зур роль уйнавы билгеле. Бу ныгытмаларда исә казак отрядлары белән бергә татарлар да хезмәт иткән. Соңгырак чорда – XIX–XX йөзләрдә – Чиләбе җирләренә Оренбург, Уфа губерналарыннан татар мигрантлары агыла, алар да, биредә төпләнеп гомер итәргә дип, Урал итәгенә утырып кала.

Димәк, биредә татарларның тупланып яшәүләре әле мең еллык тарихка ук барып тоташа икән. Ун гасырны эченә алган төрки тарихлы җирләр булуында шик юк Чиләбе өлкәсенең. Милләттәшләребез биредә һич кенә дә килмешәк түгел, алар биредә – җирле халык. Сакланып калган матди һәм матди булмаган мәдәният үрнәкләре арасында монда яшәүче татарларның бик борынгы төрки тамырларын раслый торган кыйммәтләр, чыннан да, күп.

Чал гасырлардан бирле биредә күпме сулар аккан...

Казаннан шактый ерак юл аша безне бирегә китергән максатыбызны тормышка ашыру Нязепетровск районыннан башланып китте. Биредә Нәзенең (Нәзе елгасы буендагы Нязепетровскины татарлар шул исем белән атый) үзендә, татар авыллары – Арыслан, Әптерәк, Йосып, Постниково, Чулпанда булдык, андагы милләттәшләребез белән аралаштык. Халык ачык күңелле, ипитоз, чәк-чәк, җыр-моң белән каршы алалар, безнең белән бик теләп сөйләшәләр, Казан турында сорашалар, күңел хәзинәләре белән бик җиңелдән уртаклашалар.

Алдан ук уйланылган маршрут буенча юлыбыз, җыясы ризыгыбыз безне Чибәркүл районына алып килде. Биредә Варламово авыл җирлегенә карый торган Попово авылында нагайбәкләр яши. Эчкерсез, гади, җыр-моңга, төрле йолаларга бай да соң

керәшеннәребез! Попово, Бишкил авылларында эшләдек биредә. Уй районына керә торган Әмин авылына тукталып, андагы халык белән дә аралаштык. Шулай экспедициядә йөри торгач, хәтта Парижга чаклы барып җиттек. Нагайбәк районында шундый исемдәге авыл бар. Эйфель манарасыз нинди Париж булсын диптер инде, авыл уртасына шуңа охшаш биек каланча да корып куйганнар. Бу районда Париждан тыш Кили (Кассель), Сарашлы (Остроленко) авылларында да булдык. Өчесе дә нагайбәк керәшеннәре яши торган зур-зур авыллар.

Барыбызга да билгеле: бүген – фән-техника заманы, шулай ук халкыбызның кабат исламга, китапка, уку-гыйлем эстәүгә кайтып барган бер чоры. Бу галәмәтләр никадәр генә алгарыш булып саналса да, нәкъ менә шушы алгарышның күңел сандыкларына яшерелгән тел-авыз иҗаты истәлекләренә урынны шактый тарайта төшкән булуы гаҗәп түгел. Моңа әле гади халыкның яшәү шартлары катлаулана баруы да өстәлә... Шушындый шартларда Чиләбе өлкәсендә көн күреп ятучы милләттәшләребездә фольклорның торышы ничек соң? Мәгърур тарихыбызны барлый-барлый, бүгенгегә таба килеп, шушы сорауга җавап эзләдем мин Чиләбе өлкәсе татар авылларында экспедициядә йөргәндә. Милләттәшләрем язмышын, биредә телебезнең, традицияләребезнең яшәү-торышын күзәтүләрем, бер яктан, куанычлы уйлар тудырса, икенче яктан, бик нык борчыды да. Булган рухи хәзинәләребезне туплап калырга әле өлгерәбез, җор телле халкыбыз, татарча сөйләшә торган әби-апаларыбыз, абыйларыбыз исән-сау әлегә. Монысы өчен шөкер дияргә була. Тагын биш, ун, егерме елдан болары да табылмас кебек. Яшь буын, мәктәп балалары белән әңгәмә корып карыйм, яшерен-батырын түгел – он суы да, тоз суы да юк.

– Тукайны беләсеңме?

– ...

– «Су анасы»н да укыганың юкмыни?

– ...

Күрәм: татарча биргән сорауларымны аңлый бала, әмма ни татарча, ни русча җавап бирергә фикере юк. Бер дә булмагач,

«Су анасы»н үзем сөйләп киттем. Тарак, басма кебек сүзләрне русча аңлатып барам, юкса ни турында сүз барганын аңламый.

– Бу әкиятне ишеткәнең бармы? – димен, «Су анасы»н сөйлисөйли. Малайга унбер яшь. Тырыша торгач, ачылып китте бу:

– А! Это тот, кто расческу украл, а тот его прищемил!

«Прищемил»ы бөтенләй башка әсәрдән булмаса, җавапны ничек тә кабул иткән булыр идем. Булмады.

– Син татармы?

– Татар.

– Татар шагыйрьләреннән кемне беләсең соң?

– ...

– «Су анасы»н, «Шүрәле»не кем язган?

Бу соравыма каршы, бераз уйлап торганнан соң, малай кычкырып әйтеп салды:

– А-а! Этот – Пушкин!!!

Яшь буын вәкилләре белән әлеге әңгәмәнең руслар белән катнаш авылда түгел, ә саф татар авылында – Әптерәктә булуы кәефне кырды. Яхшырак нәтиҗә көткән идем, ник дигәндә, боларның ата-ана, әби-бабалары шуның кадәр матур итеп үз телебездә сөйли торган буын бит әле, аларыннан дөнья кадәр фольклор материалы язып алуга ирештем. Ә балалары – менә шундый. Тел белмәүләре турында әйтмим дә инде, милли мәдәнияткә игътибарлары һәм гомумән ихтыяҗлары күренми яшь буынның... Монысы бик аяныч. Бер-ике дистә елдан: «Бу җирләрдә элек үз телендә сөйли белгән татарлар яшәгән, кыз алып, кыз биргәннәр, татар-башкорт катнашып, никах туйлары уздырганнар, мулла чакырып, балаларына татар исемнәре кушканнар, бакыйлыкка күчкәндә мәетне ислам кушканча җирли торган булганнар», – дип, үткән заманда сөйләргә калырмыни? Турысын әйткәндә, бик ихтимал.

Бу җәһәттән караганда, башларына «Сез – татар түгел, ә нагайбәкләр – төрки телле аерым бер халык, телегез дә нагайбәк теле» дигән фикер ныгытып сеңдерелгән. Россия законы белән алар рәсми төстә азсанлы халыклар исәбенә кертелгән.

«Нагайбакща – русща, русща – нагайбакща» дигән сүзлекләргә кадәр төзеп бастырганнар. Чынлыкта гомумтатар халкының керәшен этник төркеменә карый торган нагайбәкләр биредә рәсми рәвештә татар дип саналмыйлар, аларның балаларына мәктәпләрдә татар теле укытылмый, үз телләре дә өйрәтелми, нәтиҗәдә яшь буынга ана телен өйрәнү фәкать гаиләвазифасына гына кайтып кала. Татарның электән үткәрелеп килгән Сабан туе да уздырылмый икән хәзер нагайбәкләрдә. Ник дигәндә, татарлар яшәмәгән авылда аның милли бәйрәмен уздырып яту бөтенләй дә шарт түгел ләбаса!.. Ә бит Республикабызның Мамадыш районы Җөри авылында татарларның керәшен этник төркеме гореф-гадәтләренә, йолаларына багышлап уздырыла торган атаклы Питрауны Чиләбе өлкәсе керәшенәре дә яхшы беләһәм бик тә үз итә, әлеге зур бәйрәмгә алар ел саен киләләр, Питрауда үзләренең фольклор коллективлары чыгышлары белән катнашалар. Татарстан белән Чиләбе өлкәсенең мәдәни бәйләнешләрен ныгытуда Мамадышта үтә торган республикакүләм Питрауның әһәмиятен зурлап бәялиләр нагайбәкләр. Үзебезнең якның якты данын бирегә – Көньяк Уралга килеп ишетү шәхсән минем өчен бик күңелле булды.

Тупланган фольклор материаллары арасында иң зур күпчелекне авылның килеп чыгышына багышланган тарихи, урман-таулар исемен аңлатуга корылган топонимик риваятьләр, бу төбәккә генә хас үзенчәлекләре булган календарь һәм көнкүреш йолалары, милли уеннар, уен-бию җырлары, йөрәккә үтеп керә торган моңлы да, шаян да керәшен җырулары, җен-зәхмәтләр турында мифологик хикәятләр тәшкил итә. Моңа кадәр ишетелмәгән табышмаклар, бер-ике генә булса да әкият сөйләүче, дини темага хушаваз әйтүчеләр дә очрады хәтта. Информантлардан язып алынган, ягъни халык белән турыдан-туры аралашу нәтиҗәсендә тупланган фольклор үрнәкләрендә биредә яшәүчеләрнең шатлык-куанычларын да, әрнү-борчуларын да, үткәнен-бүгенгесен дә – барысын да тоемларга мөмкин. Бүгенге көндә Чиләбе өлкәсендә гомер сөрүче милләттәшләребез яшәү рәвешләре, холык үзенчәлекләре, сөйләшләре, иҗатлары белән

татар милләтен үзләренә генә хас милли этник төсмерләргә бизи – безнең экспедиция тукталган авылларда язып алынган фольклор үрнәкләре шуны ассызыклый.

Унике көн буена дәвам иткән экспедициядә унике татар авылында җыелган тел-авыз байлыгы хәзинәсен сезнең игътибарыгызга да тәкъдим итәм. Материал Чиләбе өлкәсенең Нязепетровск, Чибәркүл, Уй, Нагайбәк районнарын колачлаган маршрутыбыз эзлеклелегендә урнаштырыла.

*ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ НЯЗЕПЕТРОВСК РАЙОНЫ*
*ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА ЯЗЫП АЛЫНГАН*
*АВЫЗ-ТЕЛ ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ*

## НЯЗЕПЕТРОВСК ШӘҺӘРЕ

### Нязепетровск исеме каян килеп чыккан
*(топонимик риваять)*

Унике мең кеше яши торган бу шәһәр Нәзе елгасы буена урнашкан. Бер татар-башкорт кызы, әтиләренең рөхсәтеннән башка, Петр исемле урыс егетенә кияүгә чыга. Алар бу тирәгә урнашып, яши башлыйлар. Элек бу җирләр башкорт җирләре булган. XIX гасырда бу җирләрне өч сумга Чиләбе губернасына сатканнар.

*Нязепетровск шәһәрендә Рәхмәтуллина Гөлнур*
*Хәмидулла кызыннан (1953 елгы) язып алынды*
*(тумышы белән Арысланнан).*

### Нязепетровск
*(топонимик риваять)*

Петров дигән урыс бае булган. Нәзе елгасы буена килеп утырган. Бу бай җирләрне үзенеке иткән Петров. Шуннан шәһәрне Нязепетровск дип атаганнар.

*Нязепетровск шәһәрендә Мугафин Гафур*
*Мугаф улыннан (1933 елгы) язып алынды*

## Ике шайтан

*(дини-мифологик хикәят)*

Ике шайтан булган, ди. Берсе бик таза, икенчесе үтә ябык икән. Утыралар болар, сөйләшәләр. «Син ник шулкадәр ябык» – ди икән, тазасы ябыгыннан сорый. Тегесе әйткән: «Минем хуҗам гел бисмилла әйтеп ашый, нәрсәгә генә тотынса да, гел бисмилла әйтә», – ди икән. Таза шайтан шатланган: «Минеке беркайчан әйтми бисмилланы. Ярый әле бисмилласын оныта. Мин гел аның белән бергә ашыйм, йоклыйм, җырлыйм, аның иңнәренә утырып йөрим» – ди икән.

## Чеңләү йоласы

Кияүгә киткәндә кызны елаталар. Ата-анасын онытмасын, бәхетле яшәсен, дип. Кыз өстенә чаршау коралар. Чаршауны кызның җиңгәләре, туган тиешле кешеләре тотып тора. Кыз шунда басып тора. Шуннан чеңләтәләр. Чеңләүчеләр – шул ябынгычны тотып торучылар инде, бу йоланы белгән апалар, кыз ягы туганнары. Кайвакыт кызның этисен дә шунда кертәләр.

Ак чүпрәккә төргәнсең дә, акыт кына идең, атакаем,
Артык кына итеп сатып бирдең, артык идаме балакаең?

Әтекәемнең өендә утырганым бары бер такта,
Бер такталарың кызганып, сатып бирдең, эти, чит-ятка.

Чылтыр-чылтыр чын чынаяк, чылтыратмый ничек юаем,
Усал кайнәләргә бирдең, ничек кенә итеп түзәем?

*Нязепетровск шәһәрендә Рәхмәтуллина Гөлнур*
*Хәмидулла кызыннан (1953 елгы) язып алынды*
*(тумышы белән Арысланнан)*

## АРЫСЛАН АВЫЛЫ

## Арыслан авылы

*(тарихи риваять)*

Арыслан – ир кеше исеме. Ул монда Иван явыннан качып килгән. Арыслан үзе татар булган, хатынга башкорт кызы ал-

ган. Шулай татар белән башкорт катнашып, Арыслан авылында үзенчәлекле сөйләм барлыкка китергәннәр. Арыслан авылының исеме шул Арысланнан киткән. Татар белән башкорт кушылган кавем монда. Авыл 1659 елны барлыкка килгән, диләр.

*Арыслан авылында Хәбибуллина Земфира*
*Фатыйх кызыннан (1972 елгы) язып алынды*

## Татар егете Арыслан белән башкорт кызы риваяте

Арыслан – Чиләбе өлкәсенең иң төньягындагы авыл. Монда элек-электән татарлар яшәгән.

Урал буена килеп чыккан Арыслан Өфе елгасы буена урнаша. Урманда ерткычлар мыжлап тора, Арыслан ауга чыгып, җәнлек аулап гомер итә. Биредә башка бер җирдә очрамый торган имәнлек, тау куышлары бар. Табигать матур. Арысланның башкорт кызына гыйшкы төшә. Кыз да ярата Арысланны. Әмма кызның аталары каршы килә, чөнки Арыслан, бердән – ярлы, икенчедән – татар. Арыслан белән кыз, җир астыннан качып китеп, өйләнешәләр. Шушы авылга урнашып, яши башлыйлар, балалары туа.

Арыслан авылының исеме элек Кусим булган. Кусим – авылга нигез салучы. Арыслан белән башкорт кызы вакыйгасыннан соң авыл Арыслан дип атала башлый. Ата теле белән ана теле кушылып, Арысланда татарчалы-башкортчалы сөйләшәләр.

*Арыслан авылында Галиева Алинә*
*Илшат кызыннан (2000 елгы) язып алынды*

## Өйләнешү йоласы

Кызны соратып алалар. Кодалау була инде. Шунда никах көнен билгелиләр. Шунда сөйләшенгәнчә, кыз ягында никах укыталар мулла чакырып. Килә туганнар – яшьләр түгел, олылар.

Никахтан соң бераз вакыт узгач, туй була. Өч көн ясыйлар туйны. Беренче көнне кызда кунак булалар, икенче көнне күченү була. Кызның кияү йортына күченүе. Күченү алдыннан кыз ягы туганнар кунак җыялар. Күченү үзе парлы сәгатьтә булырга

тиеш. Күченгәч, икенче, өченче көннәрдә егет ягында туй үтә. Күченгәндә чеңләтәләр. Зур ябынгыч тоталар усне каплап. Кыз ябынгыч астында басып тора. Ябынгычны тотучылар чеңлиләр. Чеңләтүнең мәгънәсе – ата йортыннан аерылучы кызны елату. Кызгандыра торган йырлар йырлап. Авыр була. Әтисен дә чакыралар. Кыз елый.

*Арыслан авылында Хасбуллина Луиза*
*Нургани кызыннан (1967 елгы) язып алынды*

## Чеңләтү (чеңләү) җырлары

*Чеңләтүчеләр – бу йоланы белгән апалар, кызның туганнары. Хәзер чеңләтүче җыручыларны махсус та чакыргалыйлар.*

Бисмиллах-ррахмани-ррәхим. Әүвәле иман баш имеш,
Әтекәйдән аерылу – әҗәлләрдән авыр эш имеш.

Әтекәемнең өендә йомшак нигезләргә бастым мин,
Әтекәемнән аерылгач, тимер шыртларга бастым мин.

Әнкәй, аш пешерсәң, аз пешермә, күп пешер,
Балаларың яныңа килсә, мине дә исеңә төшер.

Әнкәй, мине ник таптың, ник таптың да ник саттың?
Мине сатып, ниләр алдың? Газиз баласыз калдың.

Әткәй, бирдең якынга, якын гына түгел, ялкынга,
Янар да сүнәр ут түгел, йән генәем тынар йир түгел.

Әткәй, балам, диденңме, кулларыңа алып сөйденңме,
Ачуларың килгән чакта «Бәхетсезкәй булсын», – диденңме?

Кил, әтекәем, каршыма, таяныйм яурың башына,
Яуры башың талды инде, бәхил генә булып кал инде.

Әтиемнең ак тастымалы элеп куелган чөенә,
Әтекәем, ник елыйсың, сөяр балаларың кулында.

*Арыслан авылында Мөхәррәмова Роза*
*Низам кызыннан (1961 елгы) язып алынды*

### Таң атканда
*(җыр)*

Таң атканда, ай батканда
Талпына дәртле күңел,
Уй уйламый, йыр йырламый
Түзүе мөмкин түгел.

Уй уйланып, йыр йырланым,
Уйланым һинең хакта,
Һин һаман да ил чигендә
Торасың, иркәм, сакта.

*Арыслан авылында Мөхәррәмова Роза*
*Низам кызыннан (1961 елгы) язып алынды*

### Арысланда Сабан туе
*(йола)*

Арысланда Сабан туе электән ел саен чәчү беткәч тә үткәрелә торганые. Хәзер чәчү бик юк бит инде. Совхоз беткәч, һәркем үзенчә. Сабан туе хәзер дә ел саен шул июнь аенда үтә.

Сабан туена олырак яшьтәге хатын-кызлар милли киемнәрдән килә. Күбесенең күлмәкләре – үзләре тегеп, чиккән күлмәкләр, яулыклар, камзуллар – бар да ачык төсләрдә. Ирләр башында – түбәтәй.

Сабан туенда үзәктә – милли көрәш. Кем көрәш карый, кем концерт, милли уеннар, үзе уенда катнаша ала. Туган-тумача җыелышып чирәмдә ашап-эчеп, ял итеп утыра.

Сабан туена төрле җирләрдән кунаклар килә. Сабан туе – зур бәйрәм. Биредә ул сугыш вакытында гына үткәрелми торган.

Сабан туе алдыннан бүләк җыялар. Элек яшь киленнәр булган авылда. Алар чиккән сөлге бүләк иткәннәр. Сабан туена район акчаны аз бүлә. Күбрәк спонсорлар хисабына үтә Сабан туе. Батырга – тәкә.

*Арыслан авылында Хатавова Җәүһәрә*
*Мирсәет кызыннан (1962 елгы) язып алынды*

## ӘПТЕРӘК АВЫЛЫ

### Әптерәк авылы

*(топонимик риваять)*

Әптерәк башкорт авылы булган элек. Соңыннан монда татарлар килеп урнашкан. Утын күп бу якларда. Утын дип килгәннәр. Хуҗалык әйбәт булган монда, шуңа да килгәннәр. Шуннан катышып беткәннәр. Телебез татар-башкорт катнашмасы. Татар авылы бу хәзер. Әптерәктә элек-электән үткәрелә килгән йолаларны бүген әби-апалар яңарта. Чабата өмәләре күрсәтәбез.

*Әптерәк авылында Хәсәнов Руфан Мәгъсүм улыннан (1966 елгы) язып алынды*

### Кашкаш урманы

*(топонимик риваять)*

Бу урман тау өстендә утыра. Шул урман тавына килеп чыккannар да урман күрмәгән халыклар, шаккатып, кулларын әле бер, әле икенче кашлары өстенә куеп, тирә-якка карап торганнар, ди. «Нинди матур урманнары!» – дигәннәр. Матур бит бу яклар. Монда яшәүчеләр дә, шул урман тавына менеп, кулларын маңгайга куеп, тирә-якны, килүчеләрне күзәтә торган булганнар. Шуннан урманның исеме Кашкаш урманы булып калган.

*Әптерәк авылында Дәүләтшина Рәмзия Наил кызыннан (1958 елгы) язып алынды*

### Сандык сату йоласы

Килен алырга киләләр. Кыз ягыннан берәү сандык өстенә менеп утыра. Сандыкта – бирнә. Кияү кеше бүләк бирергә тиеш. Бүләкләрен бирми торып, сандык өстеннән төшмиләр. Кияү кыз ягы сораган әйберләрне бирә, акча сибә. «Байлыкка, бәхеткә!» – дип әйтә. Килен төшерер алдыннан шулай сандык саталар.

*Әптерәк авылында Бикбаева Нәсимә Мәгасүм кызыннан (1957 елгы) язып алынды*

### Авыл көне

*(йола элементы)*

Кем кая киткән туган авылыннан – бар да кире кайта бу көнне. Сабан туе кебек үтә. Көрәш, җыр, бию. Сөйләшеп, пикник ясап утырабыз күңелле итеп.

*Әптерәк авылында Байбакова Гүзәлия*
*Кадерьян кызыннан (1964 елгы) язып алынды*

### Абага чәчәге

*(сөйләк)*

Минем бабай көтү көткән. Совхозда суткага китеп көткәннәр. Бабай төнлә көтү көткәндә абаганың чәчәк атканын күргән. «Бер минут торды. Көмеш төсендәге ялтырый торган чәчәк» – дип сөйләгән. Абага чәчәк атканны күргән бабай исән әле. Абага чәчәк атканны күргән кеше шул вакытта теләк теләсә, теләге кабул була, ди.

*Әптерәк авылында Хәсәнов Руфан*
*Мәгъсум улыннан (1966 елгы) язып алынды*

### Җеназа

*(дини йола)*

Мәетне юалар. Ясин укыйлар. Җеназа укыйлар эчтә. Аннан соң тышка алып чыгып, кабыкка салалар, җеназаны кабатлыйлар. Шуннан алып китәләр. Аякларын алга куеп чыгаралар өйдән. Өчесен, җидесен, кырыгын үткәрәбез. Аннан елы укыла.

*Әптерәк авылында Нурисламова Нәфыйга*
*Әдһәм кызыннан (1936 елгы) язып алынды*

### Әптерәктә татар-башкорт берлеге

*(топонимик риваять)*

Әптерәк карт килгән дә бу урманлы авылга утырып калган. Әптерәк башкорт булган. Атлар алып килгәннәр, ат үрчетеп яшәгәннәр. Юсуп белән бергә. Гаиләләрен дә монда алып килгәннәр

башкорт ягыннан. Аннары монда татарлар килгән. Авылның иң озын урамын сатып алганнар он, тәңкәләр биреп башкортларга. Утын эзләп килгән булган бу татарлар. Шуннан татар белән башкорт катнашып, яшәп киткәннәр. Татармы, башкортмы – аерып тору юк. Урыс белән катышырга ярамаган.

*Әптерәк авылында Әкрамова Гөлнәзирә*
*Фәхрислам кызыннан (1965 елгы) язып алынды*

## Карга туе

*(йола)*

Карга туе яңгыр булмый торган эссе елда үткәрелә. Карабодай боткасы пешә зур чанда. Чәйләр кайнатабыз. 1 нче порция – кошларга – уңыш булсын, дип, 2 нчесе – балыкларга – тынычлык булсын дип, 3 нчесе – җыелган кешеләргә – дуслык булсын, дип. Шуңа карга туен уңыш бәйрәме дип тә әйтәбез. Аннары милли уеннар, йырлар, «Йөзек салу», «Кабырчак», «12 таяк», йомыртка белән йөгерү, аркан тартышу, көршәк вату, капчык киеп йөгерү кебек уеннар уйнала. Көянтә белән су ташыйлар, капчык белән бәрешү була. Атлар гына юк хәзер. Бәйгеләр – җыр, бию бәйгеләре уза. Бәйрәм итәләр көн буе.

*Әптерәк авылында Дәүләтшина Рәмзия*
*Наил кызыннан (1958 елгы) язып алынды*

## Кабырчык уены

Ике төркемгә бүленеп, ике якка кара-каршы басалар.

– Кабыр-кабыр, кабырчак,
Кабыргасы ялтырак,
Ал кирәк, гөл кирәк,
Безгә матур кыз кирәк.

Шулай дип җырлагач, каршы төркемнән чакырылган кеше йөгереп килә. Тотынышып торган кулларны аера алса, бер кешене үз ягына алып чыга, аера алмаса, үзе монда торып кала.

*Әптерәк авылында Хәбибуллин Равил*
*Искәндәр улыннан (1952 елгы) язып алынды*

## Туралган җеп кыйссасы

Миңа әбекәй сөйләде. Чегәннәр килгән авылга. Бабай сугышта чак. Бакканнар. Банкага җеп турап салганнар. Караңгы җиргә куярга, бер елдан алып карарга кушканнар. Кемнең турап салынган җебе тоташкан, шуның ире исән кайтачак дигән чегәннәр. Банкадагы җеп туралган килеш булса, үлгән. Дөрес чыккан. Бер ел үткәч караганнар икән, чыннан да, кемнең турап салынган җебе тоташкан – ире сугыштан исән кайткан. Күрше хатынының җебе туралган килеш икән – анықының үгән хәбәре килгән.

*Әптерәк авылында Бикмөхәммәтов Нурислам*
*Мингаян улыннан (1969 елгы) язып алынды*
*(әби-бабайлары Кукмара ягыннан)*

### ЮСУПОВО АВЫЛЫ

## Юсупово

*(топонимик риваять)*

Юсупово Әптерәктән аерылган. Юсуп белән Әптерәк икәү килеп урнашканнар бу җирләргә. Әптерәк авылыннан монда китеп урнашкан Юсуп бабай. Соңыннан бу авылга татарлар килеп утырган Казан ягыннан. Утынлы, печәнле җирләр эзләп килгәннәр монда татар бабайлар.

*Юсупово авылында Хәйруллина Вәсилә*
*Нуретдин кызыннан (1964 елгы) язып алынды*

### ПОСТНИКОВО АВЫЛЫ

## Кияүләп йөргән чаклар...

*(йола элементы)*

Кыз ягында никах укыйлар. Кияү үзенең иптәш егетләре белән кияүләп кала шунда никахтан соң. Ике-өч кич кунып кайта кияү кыз йортында. Дүртәр көн кияүләп йөргән чаклар була торганые. Шуннан кызны алып кайтабыз гармун уйнап. Килен төшерү була бу. Бал эчү була торганые инде анда. Эчәбез дә җырлыйбыз. Кияү егете булып йөрисең инде шулай. Кияүләп йөрү, диләр.

Каян кая барабыз?
Ерак түгел арабыз.
Алтын кебек кызыгызны
Алып китеп барабыз.

Шулай дип җырлый торганыек кызны алып, капкадан чыгып киткәндә.

*Постниково авылында Мостаев Фәһим*
*Камилән улыннан (1927 елгы) язып алынды*

## ЧУЛПАН АВЫЛЫ (ГОРШЕНИНО)

### Чулпан авылы

*(топонимик риваять)*

Чулпан авылына 1939 елда Башкортстаннан күченеп килгән татар кешеләре нигез салган. Урман кисеп, урын ясап, шунда авыл корганнар. Башкортстанда Чулпан дигән авыл бар. Шуннан килгән кешеләр кушкан Чулпан дип. Горшенино дигән исемне күптән түгел куштылар. Монда Горшенин исемле урыс баеның заемкасы булган. Заемка – бай утары, кәртәләп (киртәләп. – *Л.М.*) алынган җир. Урыслар шулай бүлеп алганннар инде үзләренә. Менә шулай урысча Горшенино, татарча Чулпан дип атала бу авыл.

*Нязепетровскида Мостафина Фагыйлә*
*Хәбиб кызыннан (1938 елгы, тумышы белән Чулпаннан)*
*язып алынды*

### Биюле уен

Бу уенда бөтенесе бергә бииләр. Парлап басалар. Берәү алда күрсәтеп тора ничек биергә, нинди хәрәкәтләр ясарга. Башкалар шуны кабатлап биеп бара тыпырдап. Гармунчы уйнап утыра. Парлап басып биисең. Егет-кызлар шунда таныша торганые. Биегәндә җырлыйсың:

Ач тәрәзәң, җиләк бирәм,
Җиләктән кайтып киләм,
Сезнең нурлы йөзегезне
Мин кайчан кайтып күрәм?

*Чулпан авылында Галиуллина Фәния*
*Гыйльметдин кызыннан (1952 елгы) язып алынды*

**Зәхмәтле урын**
*(мифологик хикәят)*

Бу тирәдә бер җенле урын бар. Ураемга таба барганда, элек ашлык суктырган җирдә. Бервакыт төнге унбердә кайтып киләм. Токка җитсәм, кемдер артта мышнаган кебек булды. Курыктым, бисмилла әйтеп, белгәннәремне укыдым. Шул урында инәйне парализовать итте. Җылы җил исеп киткән дә авызы кыйшаеп калган шуннан.

**Мунча – җенле урын**
*(мифологик хикәят)*

Мунчага төнге 12 дән соң барырга ярамый. Җенле була, ди.

*Нязепетровскида Мостафина Фагыйлә*
*Хәбиб кызыннан (1938 елгы, тумышы белән Чулпаннан)*
*язып алынды*

**Җен иялә шкән**
*(беренче мифологик хикәят)*

Берәүнең атасы сугышта үлде. Анасы гел ирен көтте. Кызларына җен иялә ште. Кояш баткан турга матур киенеп куя бу көн саен. «Әти килә», – ди дә, өенә кереп китә. Кич белән атасы булып җен килә икән. Ул кызны өшкерделәр. Җен бит ул төрле сурәткә керә ала. Аның нинди булуын сөйләргә ярамый.

*Чулпан авылында Сакаева Тутыя*
*Әгъзам кызыннан (1934 елгы) язып алынды*

## Җен ияләшкән

*(икенче мифологик хикәят)*

Кәримә карчыкка җен ияләште. Кызы белән торды ул. Кояш баеса, теге матурлана икән. «Нигә матурланасың?» – дип сорый икән кызы. «Ниг, әтәең килә бит», – ди икән. Җен моның янына ире булып килеп йөргән. Нишли ул җен – аны беркем белми. Сөйләргә ярамый ул турыда. Ул хатынны өшкерделәр.

*Нязепетровскида Мостафина Фагыйлә Хәбиб кызыннан (1938 елгы, тумышы белән Чулпаннан) язып алынды*

## Җен ияләшкән

*(өченче мифологик хикәят)*

Шулай бер хатынның улы атылып үлгән булган. Бу көн саен кич җыенып чыгып китә икән. Ире әйттергән моңа кая йөргәнен:

– Улым килә бит, аның янына барам, – ди икән. Аны шул җене үтерде. Җенне нинди булуын сөйләргә ярамый.

*Чулпан авылында Сакаева Тутыя Әгъзам кызыннан (1934 елгы) язып алынды*

## Табышмак

Дөбер-дөбер дүртәү, Александр – икәү, Федор мескен берүзе.

Җавабы: сыер (дүрт имчәк, ике мөгез, бер койрык).

*Чулпан авылында Галиулина Фәния Гыйльметдин кызыннан (1932 елгы) язып алынды*

## Алтын колын

*(әкият)*

Борын-борын заманда булган бер тутыккан йозак, кем ача, шуңа – әкият.

Булган әби белән бабай. Малайлары булган боларның. Ашарларына юк икән. Ярлы яшәгәннәр. Малай әйткән: «Әтәй, –

дигән, – заработкага китәм», – дигән. Күрше авылга киткән. Кергән бер йортка, байга. «Эш эзлим» – дигән.

– Сине эшкә алам. Көтү көтәрсең. Ел да бер атым колынын югалта. Колынны югалтмасаң, мин сиңа түләрмен, – дигән хозяин.

Бер көн, ике, өч көн көтә бу көтүне. Ул-бу юк. Шуннан йокысы килә башлый моның. Шул вакыт ат кача. Колынлар вакыты җиткән. Колынын качырырга кача. Йокысы килсә дә, малай артыннан күреп кала моны. Ат артыннан чаба.

Ат чабып бара-бара да күл эченә кереп китә, шунда колынлый. Алтын колын таба. Малай күреп тора моның барысын, артыннан чапты бит инде. Хозяинга алтын колынны алып кайтып бирә. Теге шатлана, ярты байлыгын моңа бирә, благодарить итә инде моны. Тегесе өенә баеп кайта.

## Җырлар

Бас, бас, бас әле,
Идәне сынмас әле,
Сынса, ямарлар әле,
Такта табарлар әле.

Ач тәрәзәң, җиләк бирәм,
Җиләктән кайтып киләм,
Сезнең нурлы йөзегезне
Мин кайчан кайтып күрәм?

Чәй эчәләр үзләре,
Тәрәзәдә күзләре.
Май ашаган песи кебек
Ялтыраган күзләре.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәүләп килдек сезгә,
Алты, җиде, сигез, тугыз,
Унаулап барыгыз безгә.

Утырыйк әле, утырыйк әле,
Әле таң булмас әле,
Безнең болай утырулар
Гомергә булмас әле.

*Нязепетровскида Мостафина Фагыйлә Хәбиб кызыннан (1938 елгы, тумышы белән Чулпан авылыннан) язып алынды*

*ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ ЧИБӘРКҮЛ РАЙОНЫ НАГАЙБӘКЛӘРЕННӘН ҺӘМ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА ЯЗЫП АЛЫНГАН АВЫЗ-ТЕЛ ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ*

**ПОПОВО АВЫЛЫ**

**Әлләрәйләзәйлирәйлә**

*(җыру)*

Тал бөгелә, тал бөгелә, нигә бөгелә икән?
Шул кадәрле үзәкләрем нигә өзелә икән?
Әлләрәйләзәйлирәйлә, нигә өзелә икән?

Тал бөгелсен, тал бөгелсен, тал бөгелсен, җиргә тисен,
Онытмамын туганайны, онытырлак түгелсең.
Әлләрәйләзәйлирәйлә, онытырлак түгелсең.

Тал бөгелә, тал бөгелә, каен бөгелми бит ул,
Ир ташласа да, табыла, яшьлек табылмый бит ул.
Әлләрәйләзәйлирәйлә, яшьлек табылмый бит ул.

Алмагачтан алма тама алма пешкән айларда,
Кычкырып җырлап җибәрәм искә төшкән чакларда.
Әлләрәйләзәйлирәйлә, искә төшкән чакларда.

*Попово авылында Бегашева Галина Григорьевнадан (1948 елгы) язып алынды*

**Тауларга ла менсәм, таулар биек**
*(җыру)*

Тауларга ла менсәм, таулар биек,
Юлкайларга чыксам, юл кыек,
Безнеңкәй дә узган гомеребез
Сахралардин искән җил кевек[1].

Биек таукайларга менәр идем,
Төшәр җиркәйләре камырлык.
Без бер Ходайдан бик телибез
Газиз башкайларга сабырлык.

Көмешкәй дә йөзек мин койдырдым,
Ялан гына көмеш акчадан.
Эзли генә лә торгач сезне таптым,
Гөл чәчкәсе аткан бакчадан.

Түгәрәккәй генә, әй, аланда
Балан чәчәкләре лә бар анда.
Җыелышкан чакта сайрашыек,
Җыелышып булмый җалан да.

Әй гомеркәй, гомеркәй,
Су өстеннән аккан күбеккәй,
Су диңгезгә аккан кебек
Үтеп китте яшьлек гомеркәй.

Тәрәзәләр ачып карап тордым
Печәннәрнең лә, ай, кипкәнен.
Сез әйтмәсәгез дә белеп тордым,
Яшь гомернең узып киткәнен.

Тауларга менү ниләр файда,
Тау киеген атып алмагач.
Буй үстерүләре ниләр файда,
Уйнапкай да көлеп калмагач.

---

[1] К е в е к – [kewek] кебек.

Урак урган җирләрем,
Печән чапкан җирләрем,
Күк чәчкәдәй күкрәп калды
Туган үскән җирләрем.

Әй ямьле дә болытлар, әй, киләдер,
Яусын иде урман буена.
Әлекәй дә йөрибез бергә-бергә,
Язсын иде гомер буена.

Аягыңа кигән итегеңнең
Үкчәсендә булыр замугы,
Кайсы илләрдә йөрсәң хур булмассың,
Син беләсең дөнья закунын.

Иртәләрдә торып, шул, тышка чык,
Чөйдә бистәрләрең лә ак булсын.
Иртәнге җокыларың татлы булсын,
Кичке җокыларың ак булсын.

Җибәрәек җырлап, китсен гөрләп,
Юл алмаган атлар юл алсын.
Бардыр моңлылары, бар моңсызы,
Моңлылары елап уянсын.

Уң кулыма кигән лә, ай, йөзегем,
Сул кулыма кисәм лә буш була.
Җырлаеммы, дусларым, гөрләеммe?
Кайсы күңелегезгә хуш була.

Биеккәй дә тауның башларыннан
Менеп бара болан көтүе.
Кыйблалардан искән җилләр кевек,
Бу – гомеркәйләрнең үтүе.

Биеккәй дә тауның башларына
Менеп бара болан көтүе.
Җыелышкан чакларда җырлашаек,
Бу – гомеркәйләрнең үтүе.

Күпләп исәпләдем, күп уйладым
Исәпләрдән кибән куймадым.
Бик күп исәпләрне исәпләгәч,
Татлы йокылардан туймадым.

Ак Иделкәйләрне чыккан чакта
Бер җырларбыз ишкәк ишкәндә.
Безләр җырларбыз, бер җырларбыз
Яшьлек гомер искә төшкәндә.

Җир җиләккәйләре пешәдер
Җитмеш төрле үлән эчендә.
Кеше башкайлары ниләр күрми
Азмы-күпме гомер эчендә.

Әй үтәдер гомерләр, әй үтәдер
Үтмәстәй дә гомер бир Ходай.
Үтмәскәй дә гомерләр шулар булыр,
Кимемәстәй дәүләт бир, Ходай.

Йөгердем дә урманнар, әй, буенча,
Ашадым да шомыртлар туйганчы.
Көннәр кыска булганда төннәр озын,
Сөйләшәек күңелләр булганчы.

Әй үтәдер гомерләр, әй үтәдер
Үтмәстәй дә гомер бир Ходай.
Булган гомерләрнең кадрен белик
Берләр үткәч килмәс әйләнеп.

Җибәрәек җырлап, китсен гөрләп,
Юл алмаган атлар юл алсын.
Бардыр моңлылары, бар моңсызы,
Моңлылары җырлап уянсын.

Уянсын да утырып тыңласын,
Кемнәр җырлый диеп сорасын.

Кычкырды ла күке баш очымда,
Кычкырсана агач башында.
Кычкырмасаң да мин моңаям,
Төрле исәп минем башымда.

Баракайда торгач мин утырдым
Биеккәйдә тауның битенә.
Безләр дә генә түгел кош моңая
Чит җирләрдә йөргән_чагында.

Алҗапкычларың алмы әллә,
Алларында алма бармы әллә?
Сандугачлар кебек сайрыйсың,
Авызыңда былбыл бармы әллә?

Алҗапкычларың, и, атластыр,
Сукайларга салсаң, батмастыр.
Безләр ашыек, без эчәек
Үткән гомер кире кайтмастыр.

Карамада дуга без бөгәек,
Сырлауларын кайчан сырларбыз.
Җыелышкан чакта җырлашаек,
Кайчан җыелышып җырларбыз.

Алдырмас та куян һич алдырмас
Алгы аяклары сау булса.
Кайгырта ла егет маллар өчен,
Газиз башкайлары сау булса.

Җирсәйдер лә егет, ай җирсәйдер,
Карлар эреп бозлар акканда.
Ямансу да булыр шул чакларда,
Чалгы янап печән чапканда.

Ашасың да килсә, аша ипи,
Ашаганда саен май булмас.
Бер-беребезне гаепләшмик,
Бар кеше дә тигез, бай булмас.

Биеккәй дә тауның башларында,
Карчыгалар микән кагынган.
Очкылыклар тотсаң, тот исеңдә
Без булырбыз сезне сагынган.

Тәрәзә төбем гөл генә,
Үстерәсең килсә үр генә.
Безләр көлик, безләр ашыйк,
Яшь гомерләр килә бер генә.

Бадыяннар микән, баллар микән,
Бал суларын эчкән бар микән.
Җырламый торсаң, бер зар микән,
Күкрәтеп җырлап кал икән.

Ай-һай-лүк дигән тавышка
Елан кача диләр камышка.
Йокылардан булса да уянырсың,
Без җырлап йөргән тавышка.

Кара урманкайларның эчләренә
Төшми диләр кояш яктысы.
Безләр җырлаек та, безләр көлик
Үтте гомеркәйнең яртысы.

Ике як яркайларым, ай күренде ди
Үрентекәйләргә бүлендең.
Ишекләр дә ачып кергән чакта
Әүлияләр кебек күрендең.

Яңа өйкәйләрнең түшәмнәрен
Ярыпкай да салдым балта үтми.
Сез дусларым исемә төшсә,
Шикәрләр дә түгел бал да үтми.

Кычкырыпкай торып бер җырласам,
Яңгырап төшәр микән илләргә.
Яңгырапкай төшсен ай илләргә,
Ишетелсен ерак җирләргә.

Ат аякларыннан үтәр-үтәр,
Сәхрәләрдән искән җил үтәр.
Бу гомерләр бездән үтәр китәр,
Тату йөрешкәннәргә ни җитәр.

*Попово авылында Бегашева Галина*
*Григорьевнадан (1948 елгы) язып алынды*

## Төшмә суга

*(җыру)*

Төшмә суга, төшмә суга,
Басма йомры, таярсың.
Сезләр кеүек яхшыларны
Кайдан эзләп табарсың.

Җырла, дисәң, мин җырлаем
Берне түгел, икене.
Җырламас идем шул икене,
Сез дусларым сөйкемле.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле, иптәшләр!
Иптәшләр үзебезнеке
Беркая да китмәсләр.

Безнең турга төшмә суга,
Басма йомры, таярсың.
Сезләр кеүек яхшыларны
Кайдан эзләп табарсың.

*Попово авылында Уряшева Надежда*
*Петровнадан (1953 елгы) язып алынды*

## Җәй көннәре

*(җыру)*

Җәй көннәре бигрәк җәмле
Җиләк чәчкә атканда,
Төнлә төшләремдә күрәм,
Җуям таңнар атканда.

Кимә ката, ки чабата,
Ката аякны кабарта,
Китмә читкә, кал шушында,
Читтә ямансулата.

Кунаклар да килгән безгә,
Иптәшләр дә килгән безгә,
Кунаклар безгә килгәч,
Тагын ни кирәк безгә?

Һавада ай бер генә,
Йолдыз сиксән мең генә,
Бу авылда син бер генә,
Сине сөйгән – мин генә.

Һаваларлардагы йолдызларны
Нигә бер санамадым,
Күзләреңә күз тиереп,
Туйганчы карамадым.

*Попово авылында Уряшева Надежда Николаевнадан (1958 елгы) язып алынды*

## Чук итү йоласы

Иртә белән ике-өч катын продукты җыярга чыга. Кем күкәй, кем он, сөт бирә. Бу катыннар алып китәләр җыелган продуктыны чук иткән җиргә. Ул махсус урын шундый. Анда су ага, елга. Яңгыр булмаган елны үтә Чук. Яраслау (Ярославка. – *Л.М.*) елгасы буенда пешерә башлыйлар. Казан куялар, боламык пешерәләр. Ботка инде. Аерым казанда, сөт салып, күкәй пешерәләр омлет шикелле итеп. Чәй кайнатыла. Катын елгадан су ала итәге белән һәм үзенә сибә. Анысы соңыннан. Башта «Символ веры». «Отче наш»ны укыйлар. Аннары Яраслауга төшәләр иконаны күтәреп, яңгыр сорыйлар. Менә аннары катыннар итәк белән су алып, өсләренә сибә башлыйлар. Балалар сибенә.

Шуннан боламыкны ашарга баралар. Боламык – он боткасы. Тоз, май салып, сөттә пешерәләр, он сибеп, куерталар, болгатып торалар пешкәнче. Тәлинкәгә боламык салалар, кырыена омлет куялар, өләшәләр бөтен кешегә.

И яңгыр ява башлый шуннан соң! Туктамый да туктамый. И правда ведь.

*Попово авылында Селеверстова Марина Павловнадан (1959 елгы) язып алынды*

## Нардуганда

*(йола)*

Мин бәләкәй чакта. Яшьләр мунча ягалар. Җылы булсын. Шул җылы мунчага җыелып, общались. Нардуган көннәрендә.

Олы кешеләр, туннарын кирегә киеп, балаларны куркытып, өйгә кереп китсеннәр дип, йөриләр. Кереп йокласыннар дип. Киенгән кешеләр урамда да йөриләр иде, өйдән өйгә дә керәләр. Нардуганнар йөри дип өйтәләр аларны. Нардуган йөрүчеләрнең өйгә кергәч әйтә торган сүзләре бар:

Бакыт килсен йортыгызга,
Тавык-чебешләрегез күкәй салсын,
Мал-туарларыгыз исән улсын,
Үзегез исән булыгыз.

Аларны өстәлгә утыртып ашатасың, аракы саласың, нардуганнар арпа, бодай сибеп чыгып китәләр. Ярма сибәләр. Туклыкка, дип. Нардуган иске Яңа елда була берничә көн.

## Нардуганда йөзек салып багу

*(йола)*

Нардуган атнасында йөзек салына. Инәле-аталы ике кызны сыуга җибәрәләр коега. Крис коесыннан су алып кайталар. Су алганда суга пычак салалар. Өстенә бистәр ябалар. Ябып алып кайталар. Кайткач да артка борылып карарга ярамый,

сөйләшергә ярамый. Чәндекәйгә элеп, алып кайталар сулы чиләкне.

Кайда җыенганнар катыннар йөзек салырга, сулы чиләкне шунда алып кайталар. Судан пычакны алалар. Аннары һәр кеше үз йөзеген сала суга. Суны болгаталар. Бер баланы бастыралар чиләк янына. Ул берәмләп йөзекләрне ала судан. Такмак әйтеп торолар. Кемгә нинди такмак – ел буена чынга аша.

*Попово авылында Федорова Пелагея*
*Федоровнадан (1970 елгы) язып алынды*

**Нардуган көннәрендә**
**йөзек салыш җырлары**

Эдек-дудык барабан,
Чәчен майлап тараган,
Тараса да үрмәгән,
Матур егет күрмәгән.

Чылтыр-чылтыр сыу ага,
Матур кызлар сыу ала,
Матур кызлар арасында
Шадра кызны кем ала?

Сары, сары, сап-сары
Сары чәчәк саплары,
Уналтыда-унҗидедә
Кызның матур чаклары.

Ал синең киячәгең,
Гөл синең киячәгең,
Фал китабында күренә
Саргаеп кибәчәгең.

Әйдәгез, барыек,
Чия пешкән, алыек,
Яшь гумерләр үтеп китәр,
Уйнап-көлеп калыек.

Ак келәтнең тәрәзәсе
Сиксән сигез өлгеле,
Начар кызларга бәйләнсәң,
Хур буласың билгеле.

Ак чабата, ак оек,
Кимәсәң соң ни була?
Булыр-булмас ярлар белән
Йөрмәсәң соң ни була?

Өй артында ак келәт,
Ишегендә зур йозак,
Көтә-көтә арып беттем,
Нишләп тордың бик озак?

Безнең капка буй-буй такта,
Секретный бикләнә,
Башка ярларың бардыр дип,
Күңелләрем шикләнә.

Попово ындыр артында
Кәбестә түтәлләре,
Кла,ниться не годится,
Табылыр бүтәннәре.

Базарлардан алып кайткан
Киемеңне карап ки,
Чибәрлеге белән түгел,
Нәселләрен карап сөй.

Ары якның капкалары
Ачыла да ябыла,
Төнлә җөргән җегетләргә
Матур кызлар табыла.

## Нардуган нинди бәйрәм?

*(йола)*

Нардуганда яңа елны каршылыйлар. Уеннар уйнала, багалар. Хәзер дә бар. Бакканда «Нардуган» көенә җырлар әйтү була. Тирән тәлинкәгә, я табакка су салалар. Ул су таң белән алып кайтылган чиста су булырга тиеш. Шунда йөзек салына. Бөтен кеше сала. Яшь кызлар, киленнәр дә сала. Шуннан йөзекләрне берәү бутый. Савытны каплыйлар да, җыр башлыйлар. Җыр җырланган вакытта йөзекләрнең берәрсен судан тартып чыгаралар. Кем йөзеге чыкса, җыр шуңа аталган була инде. Төрлечә җырлыйлар. Яхшыны әйтеп тә, кайвакыт начары да туры килә. Нәрсәгә юрасаң, шуңа китә ул. Шаяруга борсаң, шаяру була инде. Күңел ачу бит.

## Сандугач идем илемдә

*(җыру)*

Сандугач идем илемдә.
Сайрый торган җиремдә,

Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.
Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.

Сандугач күк сайрый-сайрый
Саргайдым йөргән җиремдә.

Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.
Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.

Сандугачның, мескенкәйнең
Канаты каерылган,

Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.
Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.

Бер без генә түгел әле
Иленнән аерылган.

Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.
Әйләр-әйләр, ай, зиләләй,
Ай, зиләләй, айхайлүк.

*Попово авылында Шитулова*
*Эмма Григорьевнадан (1948 елгы)*
*язып алынды*

**БИШКИЛ ПОСЕЛОГЫ**

## Кыз урлау

*(йола элементы)*

Картым мине урлап алып кайтты. Кыз урлау була торган иде элек. 18 яшьтә идем. Аннан никах укыттылар бер авылда мулла өендә.

*Бишкил авылында Нигъмәтуллина Мәүлединә*
*Фәйзрахман кызыннан (1944 елгы, тумышы белән*
*Башкортстаннан) язып алынды*

## Мунча шайтаны

*(мифологик хикәят)*

Мунчага төнге 12дән соң барырга ярамый. Анда мунча шайтаны була. Мунча шайтанының зәхмәте каты. Ялгыз мунчага бармыйлар. Мунча шайтанының зәхмәте тисә, чирләп китәсең.

Күренми үзе. Балалар көйсезләнсә: «Хәзер мунча шайтанына илтәм!» – дип куркыталар.

## Убыр

*(мифологик хикәят)*

Ямьсез, карт, чәче тузган кешегә «убыр» диләр. «Әнә убыр килә» – дип әйтәләр.

## Ызба иясе

*(мифологик хикәят)*

Ызба иясе бар дип әйтәләр. Ызба иясе алып китмәсен, дип, кечкенә баланы ялгызын гына калдырырга куркалар. Янына пычак куеп калдыру бар.

Кеше йоклап китә, төшләнә. Шунда «Ызба иясе килгән янына» – диләр. Бисмилласын укырга кушалар. Моны бәләкәй чакта, мин Чувашиядә чакта әйтәләр ие.

## Әйтем

Яхшы булса да бәндә башыннан уза, начар булса да бәндә башыннан уза.

## Мәзә

*(нәсел кушаматы)*

Мәзә – мич торбасы. Безнең бабайлар нык булганнар – мич торбасы кебек. Төз гәүдәле, таза. Бабай 93тә үлгән. Нык нәсел, дип, Мәзә дигәннәр нәселебезне.

*Бишкил авылында Чураева Флера*
*Рәхим кызыннан (1947 елгы, тумышы белән*
*Чувашиядән) язып алынды*

*ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ УЙ РАЙОНЫ*
*ӘМИН АВЫЛЫНДА ЯЗЫП АЛЫНГАН*
*АВЫЗ-ТЕЛ ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ*

## ӘМИН АВЫЛЫ

### Исем кушу йоласы

Бала тугач, исем сайлыйлар. Баланы кырык көн кешегә күрсәтмиләр. Шул кырык көн эчендә мулла чакыртып, исем куштыралар. Мәҗлес ясап. Мулла укый. «Ходай кушкан, мулла биргән исемең шундый булсын!» – дип, баланың колагына әйтә өч кат. Баланың исем хәерен тараталар.

### Сөт теше

*(сөенчегә әйбер бирү, йола, теләк)*

Баланың сөт теше төшкәнен күргән кеше: «Тычканга – камыр теш, сиңа – тимер теш» – дип теләк тели. Сөенче итеп хәер бирә, сөт төшен ярыктан базга сала.

### Бала тәпи киткәндә

*(теләк)*

Бала тәпәй киткәндә аны җиргә бастыралар. «Җир, җир, балама (исемен әйтәләр) көч бир, бир! Аягы йөгерек булсын! Нык булсын!» – диләр.

### Су сату (йола)

Киленгә су юлы күрсәтәләр. Җыр, гармун белән Уй буена төшәләр. Килен су алып кайткач, ул китергән суны шундагы кешеләргә саталар. Бөтен кызыгы шунда.

*Әмин авылында Биккулова Фәнүзә*
*Хаҗимөхәммәт кызыннан (1959 елгы,*
*Башкортстаннан күчеп килгән) язып алынды*

## Хушаваз

*(дини хушаваз)*

Иртә торып, ал тәхарәт,
Иртә намазыңны укы,
Хафаланма, төш күрдем, дип,
Ниләр күрсәтми ул йокы.

Иртә торып карасаң син,
Таңнарны сөярсең микән,
Әйме син, син, әй, мөселман,
Укы намаз, укырлар микән.

Барлык хәлләребезне дә
Бер Ходай белеп тора,
Укы Коръән Аллаһыдан,
Вә һәм ял барып сора.

Иртә торсаң, фәрештәләр,
Сабак шәмдә килерләр,
Һәр көн саен, һәр кич саен
Безнең хәлне белерләр.

Иртә торып, тәхарәт алу –
Безгә фарыз булган ул.
Укы Коръән, әйт салават,
Корьән безгә иңдергән ул.

Барып кергәч тә кабергә:
Җан, диярләр хәзер анда
Ни китердең, ни гамәлләр,
Дип сорарлар бездән анда.

Кырык адым җир киткәч тә
Җавап алыр фәрештәләр,
Җавапны бирә алмасак,
Газаплы булырбыз анда.

Фәкыйрьләрнең хәлен белеш,
Шәфәгать әйлә куллар,

Бакый йортка барып кергәч,
Анда җавап бирерләр алар.

Бу хәлләр бит, мөселманнар,
Башыбызга киләчәктер.
Кылдан нечкә сират күперен
Барыбыз да үтәчәктер.

Әҗәлдән котылып булмый,
Нинди илләргә барсак та,
Дөнья малы бездән кала,
Алтыннарга мансак та.

Бу дөнья алдый безне,
Һаман җыябыз малларны,
Әҗәлеңнең вакыты җитсә,
Куябыз бит бу малларны.

Дөнья малы алдый безне,
Томанлыйдыр күзебезне,
Әй, туганнар, гамәл кылыйк,
Гафиллек басты үзебезне.

Никадәр дөнья кусак та,
Аллаһ җыя безне куенына,
Ялангач тәнебезне юып,
Кәфен салып тәнебезгә.

Караңгы гүрдән, җәннәтләрдән
Ишек ачык булса иде,
Ни хуш булыр инде анда,
Яшел кошлар килеп кунса иде.

Караңгы гүрдән, җәннәтләрдән –
Курыкырбыз[1] алардан,
Елан-чаяннар килеп тулса.

---

[1] Курыкырбыз – куркырбыз.

Беләсеңме, идәндә син,
Каберләргә керәсеңне?
Уйлыйсыңмы, ул кабердә
Сөаль – җавап бирәсеңне?

Әҗәл угы каты уктыр,
Кадалса, чокымый калмас,
Күзләргә кем кыймыйча,
Бу нәфес дөнья туймас.

Газраил ушны алганчый
Әҗәл угы кадалганчый
Укы намаз, укы Коръән,
Укы намаз, укы Коръән.

Бу фәлән кеше, дими.
Балалары калды, дими,
Калганнарның йөрәгенә
Ялкынлы ут каба, дими,

Бу яхшы, бу – яман, дими,
Моның яше таман, дими,
Берәү үлемне тилмереп көтә,
Вакытсыз алырга килми,

Бу малны сарыф микән, дими,
Таныш җирдә микән, дими,
Чит илләрдә ялгыз үлсә,
Ни хәл итәр икән, дими.

Берәүгә дә киңәш итмәс,
Әҗәл килсә, алмый китмәс,
Тикшерми ул, бу – карт, бу – яшь.
Алып китә вакыт җиткәч.

Пигамбәрләр[1] дә калмаган,
Табиплар да дәва тапмаган,

---

[1] П и г а м б ә р – пәйгамбәр.

Зөлфәтләр юл таба алмаган,
Аеручы үлемдер бу.

Туганнар шуны уйлыйк:
Бу дөньяда беркем калмый,
Ахирәткә безнең белән
Дөнья малы бармый.

Акыллыны кыйла хәйран,
Сайраны кыйла вәйран,
Дәва табылмый һичкайчан,
Аеручы үзе үлемдер бу.

Якыннарга килсен, дими,
Әйтәсе сүзләрен әйтсен, дими,
Бу аларны күрсен, дими,
Үкенечсез китсен, дими.

Бу дөньяга килеп киткән
Адәмнәрнең хисабы юк,
Үлем килми калыр сиңа
Дип язылган китапларың юк.

*Әмин авылында Биккулова Фәнүзә*
*Хаҗимөхәммәт кызынан (1959 елгы)*
*язып алынды.*

*ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ НАГАЙБӘК РАЙОНЫ*
*КЕРӘШЕН АВЫЛЛАРЫНДА ЯЗЫП АЛЫНГАН*
*АВЫЗ-ТЕЛ ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ*

## ПАРИЖ АВЫЛЫ

### Чук итү

*(йола)*

Әбиләр чыга чук итәргә. Ботка пешерәләр. Яңгыр сорыйлар. Чукыналар. Бакыты җиткәч, җаңгыр җава шуннан соң.

*Париж авылында Герасимова Надежда*
*Геннадьевнадан (1969 елгы) язып алынды*

## Париж авылы

*(топонимик риваять)*

Безнең ата-бабалар Наполеон белән сугышкан. 1812 елда. Париждан кире монда әйләнеп кайтканнар. Башкириянең Бакалы районыннан булган алар. Казаклы отрядлары ясап, аларны монда китереп утырткканнар. Авылны Париж дип атаганнар шул Франциядән кайткан кешеләр булганга. Алдан Яш авыл дип йөрткәннәр, 1842 елда рәсми Париж дип теркәлгән.

*Париж авылында Батраева Екатерина*
*Дмитриевнадан (1969 елгы) язып алынды.*

## Туганайлар
## (Әйләрем)

*(җыру)*

Җибәриек җырлап, китсен шырлап,
Акрын барган атлар җул алсын,
Әйләрем, әйлем туганайларым.
Бардыр моңлылары, бар моңсызы,
Моңлылары җылап уянсын.
Әйләрем, әйлем туганайларым.

Авыллары каен, урамы тар
Читләреннән читән үрергә,
Әйләрем, әйлем туганайларым.
Атналарым ай күк, айларым – җыл,
Зарлар булам сезне күрергә.
Әйләрем, әйлем туганайларым.

Челтәрле дә күпер асларыннан
Алтын тәңкә тартым әләли.
Әйләрем, әйлем туганайларым.
Алтын тәңкә безгә зур мал түгел,
Бер күрешүләре әлләни.
Әйләрем, әйлем туганайларым.

## Озын көйгә җыру

Синекәй дә белән без икебез
Табаларда пешкән лә икмәк,
Синең сөюләрең әллә ничек,
Мин сөямен сине – шушы икмәк.

Өстеңә лә кигән күлмәгең,
Буй-буй күренәдер күземә.
Кызарыпкай чыккан кояш кебек
Күренәсең минем күземә.

Синең чәчкәйләрең бигрәк кара
Нинди майлар сөртеп тарыйсың?
Кайсы илләрдә сине бик мактыйлар,
Нинди телләр белән ярыйсың?

Аякларыңа бик килешә
Казаннардан алган ботинка.
Күз алкайларымда тотар идем,
Әгәр булсагыз ла кәртинкә.

Шелкәй буйкалары, әй, наратлык,
Наратлыкка бадыян тараттык.
Акыл-фигылен сынамадым,
Төскә матур булгач яраттык.

Әй шаулыйдыр наратлар,әй шаулыйдыр,
Башларында былбыл сайрыйдыр.
Бөдрә лә чәчләрен җилфердәтеп,
Тәрәзәләр ачып карыйдыр.

Кулларындагы, ай, пирчәткәңне
Ат өстенә салып калдырма.
Дөнҗаларда ярлар күпләр диеп,
Үз ярыңның хәтерен калдырма.

Өстеңә лә кигән ай күлмәгең
Буй-буй күренәдер күземә.
Дөнҗаларга чыккан кояш кебек,
Күренәсез минем күземә.

Синең чәчкәйләрең шома була,
Вак тараклар белән тарасаң.
Минем җаннарымны эретәсең,
Күзләреңне сирпеп карасаң.

Синең чәчкәйләрең бигрәк сары,
Сары майлар сөртеп тарагач.
Минем хәлләремне китәрәсең,
Күзләреңне сирпеп карагач.

Иртәләрдә торып, шул, тышка чыксаң,
Чөйдә бистәрләрең лә ак булсын.
Кичке йокыларың татлы булса,
Иртәнге йокыларың сак булсын.

Синең чәчкәйләрең бигрәк кара,
Кара тарак кирәк тararга.
Синең буйларың бигрәк зифа,
Куштан ярлык кирәк ярарга.

*Париж авылында Иванова Раиса*
*Осиповнадан (1934 елгы) язып алынды*

**Ай-гай безнең ил**
*(җыру)*

Иртәләрдә торып, тышка чыксам,
Кош тавышы килә авадан.
Ай-гай безнең ил – былбыл кошлар сайраган җир.
Сез кайлардан гына, ай, килдегез,
Әллә төштегезме авадан?
Ай-гай безнең ил – былбыл кошлар сайраган җир.

Аваларда[1] кошлар, әй, авалый[2],
Бер төшмәсә, җирләргә бер төшәр.
Ай-гай безнең ил – былбыл кошлар сайраган җир.
Безнең болай бергә утырулар
Бер төшмәсә, исләреңә бер төшәр.
Ай-гай безнең ил – былбыл кошлар сайраган җир.

*Париж авылында Арапов Вячеслав*
*Федоровичтан (1960 елгы) язып алынды*

**Париж**
*(җыру)*

Урманнардан чыгар түше чуар
Кара урманнарның бөркете,
Атларга да менсә, ат уйната
Парижларның асыл җегете.

Пар гына күкеләр чакырганда
Шаулый безнең урман буйлары,
Җанган җөрәкләрне баса
Безнең Париж чишмә сулары.

Җирле җиркәйләрен бик мактыйлар,
Париж авылына ни җитә,
Бу гомерләр бездән үтә китә,
Татулыккайларга ни җитә?

Шелкәй буйларында йөргән чакта
Аякларым батты тирәнгә,
Тирәннәр дә булмый, сайлар кайда?
Парижлардан асыл җир кайда?

---

[1] А в а л а р д а – һаваларда.
[2] А в а л ы й – очып йөри.

## Дускайларым
*(җыру)*

Таудан тауларгай тузаннар да тузай,
Арыслан-киекләр, ай-гай дусларым, чапкандай,
Дуслар сөенәй, дошманнар да көенәй
Ир-җегетләр малларны, ай-гай дусларым, тапкандай.

Биек тауларның ай-гай башларында
Арыслан дай киекләрнең, ай-гай дусларым, төяге[1]
Утларда җанмый, суларда да батмый
Асыл җегетләрнең дәй, ай-гай, дусларым, зейрәге

## Балансы куак[2]

Балансы куаклар, әйләрем, балансы,
Баланнарын җыйгачтын, җалансы[3]
Ә-ә-йләр...
Сез әйләрдән аерылгач, җамансы да буладыр быелгы җәйләр.

*Париж авылында Иванова Раиса*
*Осиповнадан (1934 елгы) язып алынды*

## Туганайлар

Иртәләрдә торып тышка чыктым,
Һаваларда күрдем тулган ай.
Шул тулган айларга карый-карый,
Бик сагынам сине, туганай.

Урманнарга керсәм, исерәм
Төрле үләннәрнең исенә.
Исермим үләннәр исенә,
Сез төшәсез минем исемә.

---

[1] Т ө я г е – урыны.
[2] Б а л а н с ы к у а к – балан куагы.
[3] Җ а л а н с ы – ялангач.

Чәчтем бодай, чәчтем бодай,
Аның камылларын кем урган,
Ташлашмаек, туганнар, ташлашмаек,
Туганнарын ташлап кем уңган.

Туганай, туганай, дигән чакта,
Туладыр ла минем күңелем.
Сез туганайларым килеп кергәч,
Буладыр ла минем күңелем.

Арылар да үтсәң, кер, туган,
Биреләр дә үтсәң, кер, туган,
Кергән генә саен сыйлар булмас,
Безнең исәнлекне бел, туган.

Сандугачлар гына кайда сайрый,
Урман буйларында, каенда.
Мин сагынам сезне сәгать саен,
Сез сагынасызмы аенда?

Таш савытта үскән гөлләрем,
Ал чәчәкләр аткан түгелме?
Ал чәчәкләр аткан гөлләр кебек
Безнең туганнарыбыз түгелме?

Безнең өйләребез бик кечкенә,
Аның тәрәзәсе дә өч кенә.
Карагызчы безнең туганнарга
Чикләвек эчендәге төш кенә.

Туганкаем, рәхмәт ашыңа.
Дәүләт яусын синең башыңа.
Бүдәнәләр кебек юргылып,
Ризыклар килсен синең каршыңа.

Ямьле болытлар, ай, киләдер,
Җаусын иде болын буена.
Бергәкәйдә бергә йөрешергә,
Язсын иде гомер буена.

Агыйделкәйләрне без кичәрбез,
Колачларны җәеп җөзәрбез.
Кычкырырлар күке, сайрар былбыл,
Шул чакларда ничек түзәрбез.

Аклыкай да яулык бәйләгәнсең
Күз өскәйләреңә төшереп.
Рәхмәт, туганаем, килүеңә,
Безне искәйләреңә төшереп.

Авыл буйларының чишмәсеннән,
Чынаяклар белән су эчтем.
Индекәйдә шөкер бер Ходайга
Туганнарым белән күрештем.

Гөл бакчаларына керер идем,
Гөл мамыкларына буялам.
Сез, туганнар, искә төшсәгез,
Йокылардан елап уянам.

Аклы күлмәк эчләрендә
Лоп-лоп итә минем тәннәрем.
Сез туганайлар белән күрешкәчен,
Булды минем хәлләрем.

Җирәнчәкәй атларга шул килешә,
Чыгырлапкай ишкән дилбегә.
Әйдәгез дә, туганнар, җырлашаек.
Тавышыбыз калсын билгегә.

Сезнең ара белән безнең ара,
Араларга үскән чуклы тал.
Чуклы талның чугын без өзмиек,
Берләр-беребездән бизмиек.

Ашыйсың ла килсә, аша икмәк,
Ашаганнар саен май булмас.
Ташлашмыйк, туганнар, без ташлашмыйк,
Бар кеше дә тигез, бай булмас.

Икәү дә өчәү дус булаек
Сәхрәгә чыгып кунаек.
Сәхрәләргә чыгып юлыгыз уңса,
Аерылмас туганнар булаек.

Көмеш йөзекләрне мин койдырдым
Ялан гына көмеш акчадан.
Эзләки дә торгач, сезне таптым
Гөлчәчәге аткан бакчадан.

Басма өйләрендә бала үрдәк
Бодайлар да ашап түләнгән.
Сезнеңкәй дә белән без икебез,
Бер бишеккәйләрдә тирбәлгән.

Түтәлкәй дә түтәл суганым
Аның арасында куш суган.
«Ничек кардәшләр?» – дип сорасагыз,
Безнең әнкәйләр бертуган.

Чылтырап аккан чишмәләрдән
Стаканнар белән су эчтем.
Икекәй дә шөкер бер Ходайга
Сез туганнар белән күрештем.

Урманнарга кердем, капкан салдым
Сусар балаларын тотарга.
Төсләреңне төшереп алыр идем,
Күз алкайларында тотарга.

Ай киләдер болытлар, ай киләдер
Яусын иде болыннар буена.
Сезнең белән безгә лә йөрешергә,
Язсын иде гомер буена.

Шелкәй генә лә елга буйларында
Кыякларны җыеп ла җөрдем мин.
Сез туганнар килеп сәлам биргәч,
Сары майлар кебек лә эредем мин.

Сары да ла сары чикләүекне
Дүрткә генә, бишкә бүлиек.
Без бит барыбыз да бертуганнар
Бер-беребез өчен дә үлиек.

Биеккәй тауларның башларында
Озын икән җирнең межасы.
Сез туганнар белән бер утыргач
Онытылды дөнҗа нужасы.

Җырлыйлар да җырлыйлар без эчиек,
Байлар бал эчэдер,әй, дисеннәр,
Тәмлеләрдән татлы сөйләшәек,
Туганнары килгән, әй, дисеннәр.

Гөл-гөл бакчасына гөлләр чәчтем,
Гөл-гөл бакчалары ла тулганчы.
Гөл-гөлләргә былбыл, ай, кунганчы
Аерылмыек, туган, үлгәнче.

Бәйрәмнәрдә генә бәйләр ием
Чит-читләре чуклы җаулыкны.
Очырашкан чакта сорашыек
Исәнлеккәй белән саулыкны.

Быел гына чәчкән гөлләремнең
Алсу чәчәкләре коела.
Сез туганайларны сагынганда
Көннәрне уздыруы кыен ла.

Әй, аланда әле, аланда,
Мәкнең чәчәкләре бар анда.
Җыелышкан чакта җырлашыек,
Җыелышып булмас җалан да.

Туганаем, сиңа ни бирием,
Мәкәрҗәдән алган малым юк.
Җаннарымны җарып бирер идем,
Җаннан башка торыр хәлем юк.

Аллар булыйкчы без, туганнар,
Гөлләр булыйыкчы ла, туганнар.
Алларыбыз уңар, гөлебез шиңәр,
Тату булыйыкчы ла, туганнар.

Каен урманына кергән чакта.
Күренепләр калды кыр бите.
Сез туганнар белән бер утырсак,
Булыр оҗмагъларның бер чите.

Кара урманнарның уртасында
Төлке көтүләре лә көттем мин.
Сез туганнарымның килер көнен
Төн җокымны җокламый көттем мин.

Бер беләзеккәем беләктә,
Бер беләзеккәем келәттә.
Сөйләгән адәмнәр тик сөйләсен,
Без җөрибез изге теләктә.

Өстегезгә кигән киемегез
Җем-җем күренәдер күземә.
Дөнҗаларда чыккан кояш булып
Күрендегез минем күземә.

Күк кабаккайлары, ай, ачылса,
Күк өсләрен шунда күрербез;
Ходай бәхетләрен ким итмәсә,
Гомеренә бергә җөрербез.

Бәләкәй бакчаның бөтнеге,
Сахраларга чыккан хуш исе.
Сез туганнар белән утырулар
Мең тәңкәлек булды бер киче.

Биек кенә тауның башыннан
Тимер арба килә шөлдерәп;
Сез туганкайларым искә төшсә,
Күз җәшләрем килә мөлдерәп.

Тауның буйларында йөри торгач,
Алтын тәңкә таптым әлләли.
Алтын тәңкә безгә зур мал түгел
Бер күрешүләре әллә ни.

Су буйкайларында балтырган,
Яңа бәбәйләрен тутырган.
Өстәл башкайларын матур итеп,
Туганаем килеп утырган.

Аппакайда бодайлар мин киптердем,
Җәйге кояшларга таратып.
Сез туганнарга безләр килдек
Чын күңелләр белән яратып.

Быелкай ла уңган бодайларның
Камылларын өстен кем урган?
Ташлашмаек, туганнар, ташлашмаек,
Туганнарны ташлап ла кем уңган?

Туганаем, туганай, ай, килгәч
Туладыр ла минем күңелем.
Сез туганайлар сөеп килгәч,
Буладыр да минем күңелем.

Биеккәйдә тауның башларында,
Шаулыйдыр ла нарат башлары,
Шикәрләрдән тәмле балдан татлы
Безнең туганнарның ашлары.

Самаурлар куйдым мин кайнарга,
Казаннардан килгән башларга.
Сез туганайларны ошатамын
Кызарыпкай чыккан айларга.

Түтәлләр дә түтәл яшел суган,
Аның арасында сарымсак.
Бөтен туганнарым арасында
Син, туганкаем, гел тартымсак.

Биеккәй тауның башларында
Алтын чыккан җире күренә.
Үзебезнең туган үзебезгә
Алтыннардан артык күренә.

Француз яулык дүрт почмаклы,
Дүрт почмагы саен бадыян.
Сез туганкайларым искә төшкәч,
Бадыяннар кабып хәл җыям.

Ай алмагач, диләр, ай алмагач
Алмагачы саен сандугач.
Ул алмагач белән мин нишлим,
Үз туганкайларым булмагач.

И ашыңа, туганаем, и ашыңа,
Дәүләт яусын синең башыңа.
Бүдәнәләр кебек юргалашып,
Бәхетләрең килсен каршыңа.

*Париж авылында Иванова Раиса*
*Осиповнадан (1934 елгы) язып алынды*

### Элекке казак көе[1]

Чуеннар да чүлмәк, тарлар авыз,
Кайный диләр, кайный диләр казакларның ашларый,
Очыплар да кошлар җитмәс җиргәй
Китә икән казакъларның башларый.

---

[1] Бу җырны («Элекке казак көе»н) яздырам дип, унсигез яшендә бу авылга Геннадий Макаров килеп чыккан. Бер картны күрсәткәннәр «ул беләә», дип. Геннадий Макаров бабай янына киткән. Бабай әйтә икән: «Йөз граммсыз җырлый алмыйм», – ди икән. Салып биргән моңа Геннадий Михайлович. «Булмый әле», – дия-дия шулай әллә ничәне салдырып эчкән бабай. Исереп ауган аннары. Җырлый алмаган. Шулай итеп, ул килүендә Г.М. Макаров «Элекке казак көе»н яздыра алмый кайтып киткән *(Париж авылында информантлар сөйләгәннәрдән).*

Казакыйлар китә, озатыек.
Агымсукай, агымсукайларга җиткәнчей,
Агымнарда сулар да акмый торды
Без аерылышып киткәнчей.

**Каз канаты**

*(җыру)*

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынгандай.
Туганайларга карыем
Мин сезне сагынгандай.

Каз бәбкәләрен санадым
Егерме сигез балай.
Әйткәй-әнкәй кулларында
Кайгысыз үсә балай.

Каз канатларын какканда
Мамыкларын җил алай.
Безнең болай җөрүебез
Сагынып сөйләргә калай.

Каз канатларын эзләргә
Төштем су буйларынай.
Су буйларында йөргәндә
Сез генә уйларымдай.

*Париж авылында Иванова Раиса*
*Осиповнадан (1934 елгы) язып алынды*

**КИЛИ (КАССЕЛЬ) АВЫЛЫ**

## Встречальный / Каршы алганда

*(җыру)*

Аргавыллардан[1] сез килдегезме?
Бирге авыллардан килдегезме?
Аргаваллардан сез килдегезме?
Бирге авыллардан килдегезме?
Без сагынганнарны белдегезме?
Әллә үзегез сагынып килдегезме?

Таулардан тауларга җепәк тарттым,
Тарталар да тарталар ай taрактым[2].
Таулардан тауларга җепәк тарттым,
Тарталар да тарталар ай тарактым.
Сез туганнар безләргә килә, дигәч,
Көтәләр дә көтәләр шул, ай, зарыктым.

Авылымда ак болытларга җитеп,
Ике аккош уйный, ай, кагынып.
Авылымда ак болытларга җитеп,
Ике аккош уйный, ай, кагынып.
Җырак җулкайларны җакын итеп
Туганкайлар килгән шул ай сагынып.

## Капканнар

*(җыру)*

Капканнар да куйдым әле мин бүрегә,
Капканнар да куйдым әле мин бүрегә,
Имәннәр дә кистем, имәннәр дә кистем шүрегә.
Ич[3] бер җомышларыбыз да жукларые,

---

1 Аргавыллардан – аргы авыллардан.
2 Тарактым – арыдым.
3 Ич – һич.

Ич бер җомышларыбыз да җукларые,
Наруш сезне, наруш сезне килдек күрергә.

Карлыганнан карай әле, ай, күзегез,
Карлыганнан карай әле, ай, күзегез
Бөрлегәннән кызыл, бөрлегәннән кызыл йөзегез.
Бөрлегәннән кызыл әле йөзегезне,
Бөрлегәннән кызыл әле йөзегезне
Күреп туя алмай бит, күреп туя алмай бит күзебез.

Җәмнеләр дә икән әле бу җаланнар,
Ак тирмәләр корып, ак тирмәләр корып җәйләргә,
Кайларга да барсам әле, дуслар кирәк,
Кайларга да барсам әле, дуслар кирәк
Каршы чыгып атлар, каршы чыгап атлар бәйләргә.

**Гөмбәй буйлары**

*(җыру)*

Гөмбәй буйларына төшсәм,
Дулкынлай камышлары.
Бигрәк җәмле ишетелә
Керәшеннәрнең тавышлары.

Җидегән йолдыз таң алдыннан
Айрата гына якты була.
Керәшен көйләрен тыңласаң,
Күңелләргә генә моң тула.

Атлар килә акрын атлап,
Җиләк кенә чәчкәсен таптап.
Әрбер җирдә сокланалар
Керәшеннәрне генә мактап.

Чулпан кебек талгынгы
Кояшлар да чыга кырларга,
Шул бакытта бигрәк җәмле
Керәшенне тыңларга.

## Мин керәшен

*(җыру)*

Мин күкрәк киермимен,
Кулымнан бар эш килә.
Берәүгә дә бирешмимен,
Туган җирем көч бирә.

Мин керәшен, мин керәшен,
Мин – керәшен баласы.
Көрән күзем, кара чәчем
Күз алдында каласы.

Үзем матур, үзем чибәр
Үземнең буем зифа,
Миңа карап сокланалар
Чиләбе, Магнит, Уфа.

Мин уйлыем, мин җырлыем
Туган җирнең көйләрен,
Искә төшереп җылыем,
Читкә китсәм, нишләрем.

## Күгәрчен

*(җыру)*

Күгәрченнәр, гөрли-гөрли, күккә менә.
Ир-җегетләр җырлый-җырлый күккә менә.
Ир-җегетләрнең меңләп аты – йолдыз кашка.
Башларымда – җепәк нокта, төене башка.

Аклы яулык тузмый, диләр, тузмый, диләр,
Чит-читеннән барыбер дә туза икән,
Яшь гомеркәйләрне аны узмый, диләр,
Уйнап ла көлеп кенә, ай, уза да икән.

## Урал

*(җыру)*

*А.И. Артемьев сүзләре*

Урал таукайларның арасында, әйләр,
Оялчан гына тора шул бер авыл
Кайсы якка чыгып карасаң да, әйләр,
Керәшенчә шаулый бит үскән камыл, әйләр.

Карагай гына урман әле шул
Ник дигәннәр, әйләр.
Кара булган микәнни ай утыны, әйләр.
Кызыл булып җанай әле шул бөрлегәннәр.

Нигә кызыл урман шул димиләр,
Таш араларында тетрәп пешкән чия.
Чемен өзеп, чиләгемне тутырдым.
Җанкайларым минем шуңар көя.

Җырак түгел ялгыз үскән каен,
Җаңгыз каен кыры киң җалан.
Исләремә килеп төшкәннәр саен
Җыламыйча түзмәм шул мин аман.

## Казак көе

Ир балага кәгазь килә
18 яшь тулгач та, әй әйлиләр,
Исәнләшеп чыгып китә,
Бакыты шулай булгач, әй әйлиләр.

Казак китә, озатыек
Уйсу җиргә җиткәнче дә, әй әйлиләр,
Таң, таң ата, чулпан калка
Без аерылып киткәнче дә, әй әйлиләр.

Чуен чүлмәк, тарлар авыз –
Пешә казак ашлары, әй әйлиләр,
Кошлар очып җитмәс җиргә
Җитә казак башлары, әй әйлиләр.

## Әлүк-бәлүк (тал бишек)

*(җыру)*

Әлүк-бәлүк итәдер, ай-гай, тал бишек
Мин сагынам сезләрне, ай-гай, сез ничек?

Җил туздыра бит жулларның, ай-гай, тузанын
Сизми калдым бит гумернең, ай-гай, узганын.

Бер алманы дай өчләргә, ай-гай, бүләек,
Беребез өчен дә беребез, ай-гай, үләек.

Чакырып алдым шул чакырым, ай-гай, ярымнан
Җибәрәсем дә килми бит, ай-гай, җанымнан.

Агыла болытлар җилләр дә, ай-гай, искәндә
Өзелә үзәкләр исләргә, ай-гай, төшкәндә.

## Атларым-җөгәннәрем (җыру)

Атны җиксәң, җик җирәнен,
Урта жулдан җөргәнен.
Җәрне[1] сөйсәң, сөй зейрәген[2],
Белсен дөнья кирәген.

Һәй-лә-мәй-лә әйлиләр әйләү.

---

[1] Җ ә р н е – ярны.
[2] З е й р ә г е н – булдыклысын.

Сары каеш дилбегәләр
Безнең атларда гына.
Иртә торсам, ике күзем
Сезнең якларда гына.

Һәй-лә-мәй-лә әйлиләр әйләү.

Атларым, җөгәннәрем,
Каеш дилбегәннәрем…
Җепәк чәчем җилпердәтеп
Туып-үскән илләрем.

Һәй-лә-мәй-лә әйлиләр әйләү.

Күз алдымнан туры юлда
Туры атлар үткәне;
Тик белмәдем шул юлларда
Гумеремнең үткәнен.

Һәй-лә-мәй-лә әйлиләр әйләү.

Җулларның тузган тузаны
Куна җулаучыларга.
Рәкмәт гармун уйнаучыга,
Рәкмәт тыңлаучыларга.

Һәй-лә-мәй-лә әйлиләр әйләү.

## Җахшы аталарның балалары

*(җыру)*

Кызлар дигән кыз кешенең,
Чигүле лә була бистәре.
Кайда гына йөрсәң, яхшы йөре,
Китсен әдәмнәрнең исләре.

Җырларга да кушканны мин көтмәдем,
Булды йөрәккәем сабырсыз.
Яхшы ата-аналарның баласы,
Кайда йөрсә, булмас кадерсез.

Иртәләрдә торып, кич утырып,
Ак җефәктән җөйләр тектем мин.
Капка төпләренә чыга-чыга,
Сез балакайларымны көттем мин.

Күк күгәрченкәй һавада уйный,
Аның күләгәсе лә җирдә уйный.
Җахшы аталарның балалары
Көн күрәселәрен дә лә көн дә уйлый.

Тимерчеләр киткән тимергә,
Тимерләргә түгел, күмергә.
Кодаем[1] балаларны кушсын иде
Айга, елга түгел, гомергә.

Тубылгыда агач озын булмас,
Тубылгылар аша юл булмас.
Җахшы ата-аналарның балалары
Кайда гына йөрсә хур булмас.

## Җака чылбыры

*(җыру)*

Карагай гына агач – каты агач
Кайрамыйча балта ник утсен.
Җугалды ла җака чылбырым,
Алларым, алдамам, сылуым, сары былбылым.
Каерасаң балта ниен куйсын,
Үз туганнарыннан кем туйсын.

---

[1] Кодаем – Ходаем.

Өстегезгә кигән киемегез
Алып карасам да ал түгел.
Җугалды ла җака чылбырым
Алларым, алдамам, сылуым, сары былбылым.
Сезләрнең кеүек яхшыларга
Җаным җарып бирсәм, җәл түгел.

**Кили урамнары**
*(җыру)*

*А.И. Артемьева сүзләре*

Безнең Кили урамнары
Адым саен багана.
Безнең Кили бигрәк җәмле,
Карап күзләрем тала.

Гөмбәй суы җем-җем итә
Дулкыны киртә киртә.
Килинең җәмнеләренә
Сокланабыз кич-иртә.

Каршы тауга менеп карыем
Кили авылы тауларын,
Агачларның шаулауларын,
Ашлыкларын дулкынлавын.

Җегетләре бигрәк матур,
Җылтырый итекләре.
Атка менсә, ат уйната
Килинең җегетләре.

Кили кызларының итәге
Аклы-күкле шакмаклы.
Килиләрдән сезгә сәлам
Урал таулары чаклы.

Кили урамнары җәмле,
Бәйрәм көннәр булганда
Килигә кушып җырлыйбыз
Сез дуслар җыелганда!

*Кили авылында Бидянова Клавдия Георгиевна (1950 елгы) җитәкчелегендәге «Ностальгия» фольклор коллективыннан язып алынды*

**Аш бирү**

*(йола)*

Аш бирү була кеше үлеп 3 җылдан. Ноябрь ае була, уразага кергәнче. Үзләренең үлеләренә атап, малның башына бистәр бәйләп, аны капкадан алып чыгалар. Иконалар белән чукынып тәре янында. Аннан башта кан чыгарып тавык чалалар. Чалып, җибәрәләр, каны агып беткәч, тыпырчынып чабуыннан үлә. Бу нигездә әллә кемнәр торгандыр. Тавык каны – шуларга, «Бир», – дип кулын сузып торганнарга, тиеш дип торганнарга. Кан чыгару – аларны ризалату өчен.

Шуннан мал суялар. Ашка чакырып җөргәннәр. Ашарга аш тышта пешкән. Табаклар белән килгәннәр. 12 дә җан-башын тураганнар. Җан-башын урлатсалар, җәза биргәннәр. Анысы – уен шундый.

Аш бирер алдынан атыйлар. 12 дә җан-баш турап, таралалар. Бу – бәйрәм. Үле турында әйбәт сүз әйтергә тырышалар. Аш биргәндә җырлыйлар. Бүләкләр бирәләр. Эчәк жуучыларга да бирәләр.

*Кили авылында Миняева Зоя Прохоровнадан (1935 елгы) язып алынды*

## САРАШЛЫ (ОСТРОЛЕНКО) АВЫЛЫ

**Поминальный**

*(мәет озатканда җырлау)*

Урамнардан урап өйгә керсәм,
Түр бистәркәйләрем лә түрдә юк.
Безнең туганайны сорамагыз,
Оҗмахларга киткән, өйдә юк.

Атларны да җибәрдем мин үрләргә,
Үрмәләпкәй менмәс җирләргә.
Безнең туганыбыз ташлап китте,
Күзләребез күрмәс җирләргә.

Өстәл өскәйләрем гел җимеш
Ашасым да килми туксыман,
Өйләргә дә керсәм тышка чыгам,
Шул туганымны юксынам.

Авыл урамнары киңнәр урам,
Уртасыннан канау казылган.
Якты дөньяда яшәр идем,
Язмышыма шулай язылган.

Ишек алларыңны себереп куй,
Алма тәгәрәтеп уйнарсыз.
Бу җырларымны тот исеңдә,
Безне сагынганда җырларсыз.

Ишек алкайларыңны ачык тот,
Туплар тәгәрәтеп уйнарсың.
Бу җыруларымны истә тот
Безне сагынганда җырларсың.

*Сарашлы авылында Исупова Елизавета*
*Андреевнадан (1950 елгы) язып алынды*

## Питрау җитми җәй җитми

Урман буйларына бардык,
Урман буе каенлык, ай, каенлык.
Питрау бәйрәмнәре җитте,
Бәйрәм итик бергәләп, ай, бергәләп.

Болыннардан җыеп кайттым
Мин чәчәкләр бәйләмен.
Һәрвакытта ямьле үтсен
Шушы ла Питрау бәйрәме.

Каен башлары уелган,
Яфраклары шул коелган.
Питраудa бергә җырлаек,
Бар туганнар ла җыелган.

Безнең гомеркәйләр узып бара,
Минутын-сәгатен санамый.
Җыелышкан чакта сайрашаек,
Питрау үткәч, кош та сайрамый.

Ай булса иде лә, ай булса иде,
Ул сипмәгән баллар булсаые.
Питрау бәйрәмен башлап җибәрик,
Изге сәгатьләрдә генә лә булсаые.

Питрау керде, җәйнең кыл уртасы.
Их, барасы иде урманга.
Их, җыясы иде мәтрүшкәләр,
Җәй үзәге зеңләп торганда.

Бу көннәрдә тыныч тымызык җирдә
Бөрлегәннәр тулып пешәдер.
Җәй уртасы гомеркәйләрнең дә
Урталары ургып үткәндер.

*Сарашлы авылында Исупова Елизавета*
*Андреевнадан (1950 елгы) язып алынды*

**Ай-гай, керәшеннәр**
*(җыру)*

Кайгыга калды керәшен халкы:
Патшаның сүзләре бик каты,
Бүген без сезне казак итәбез,
Иртәгә сез моннан китәсез.

Ай-гай, керәшеннәр,
Ай-гай, керәшеннәр –
Гөмбәй буйларында яшиләр.

Саубуллашып җыелып киттеләр,
Арбага атларын җиктеләр,
Туган илләрен ташлап киттеләр,
Гөмбәй буйларына җиттеләр.

Ай-гай, керәшеннәр,
Ай-гай, керәшеннәр –
Гөмбәй буйларында яшиләр.

Араларында олы кешеләр
Тукталырга урын сайлыйлар,
«Шушында тормыш башлагыз», – диеп,
Сандугачлар килеп сайрыйлар.

Ай-гай, керәшеннәр,
Ай-гай, керәшеннәр –
Гөмбәй буйларында яшиләр.

Казаклар озак яланда яттылар,
Дошманнарга юлны яптылар,
Сабаннар сөреп, ашлыклар үстереп,
Яңа җирдә тормыш башлыйлар.

Ай-гай, керәшеннәр,
Ай-гай, керәшеннәр –
Гөмбәй буйларында яшиләр.

*Сарашлы авылында Исупова Елизавета Андреевна (1950 елгы) җитәкчелегендәге «Сарашлы» фольклор коллективыннан язып алынды*

# КӨНЬЯК УРАЛ ТАТАРЛАРЫ XX ГАСЫР БАШЫ МАТБУГАТЫНДА, ШӘҖӘРӘЛӘРДӘ

*Зөфәр Мөхәммәтшин*

Хәзерге Чиләбе һәм Оренбург өлкәләренә караган җирләр – борынгыдан төрки каганат, кыпчак кабиләләре яшәгән урыннар. Рус дәүләтенең басып алу сәясәте нәтиҗәсендә бу территориядә төрки кавем вәкилләре юкка чыга. XVIII гасырда Россия империясе тарафыннан рус булмаган милләтләрне христианлаштыруның сәяси мотивлары йомшара башлый, мәмләкәт тышкы һәм эчке сәясәтне ныгытуга күбрәк игътибар юнәлтә. Бигрәк тә императрица Екатерина II идарә иткән елларда татар халкына Чиләбе, Оренбург якларына күчү һәм казакъ дәүләте белән сәүдә итү өчен мөмкинлекләр тудырыла. Монда Россиянең төп максаты, һичшиксез, казакъ-кыргыз җирләрен үзенә буйсындыру һәм Пётр I нең «Яшерен васыяте» нигезендә Һиндстанга таба хәрәкәт итү ниятен тормышка ашыру күздә тотыла. Шул дәвердән башлап, әлеге төбәк төрек-татар халкы өчен туган җиргә әйләнә. Инде XIX гасырның икенче яртысында, төгәлрәге 1861 елда крепостной хокук бетерелгәннән соң, авыл кешеләре, җирсезлектән, көчләп чукындырудан качып, чит төбәкләргә күченеп китәләр. Ул күченүчеләрнең күпчелеген Казан артында яшәгән татар кешеләре тәшкил иткән. 2011 елда Казакъстанның Уральск шәһәрендәге Кызыл мәчет тарафыннан алып барылган метрика дәфтәрләрен күзәткәндә шуңа инанырга

туры килде. Күчкән татарлар югалып калмаган әлбәттә, үзләренең сәүдәсен барлыкка китергән, соңрак җитештерүчәнлек белән дә шөгыльләнгән.

1905–1907 елгы инкыйлабтан соң татар милләте күпләп яшәгән төбәкләрдә мәдәни тормыш җанланып китә. Яңача укыту кертелә, театрлар оештырыла, вакытлы матбугатка нигез салына... Болар барысы да алдынгы карашлы татар байларының катнашлыгы һәм хәйрияви ярдәме белән тормышка ашырылган. Вакытлы матбугат, белем бирү, нәшриятлар эшчәнлеге көчәйгән. Шул рәвешле XX гасыр башы татар иҗтимагый хәрәкәте тәэсирендә Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Җаек (Уральск), Троицк, Орск кебек шәһәрләр татар милләтенең мәдәни мәркәзләренә әвереләләр. Хәтта, дистә еллардан соң, вакытлы татар матбугатында «Казан татарның мәркәзе түгел» дигән бәхәс тә булып ала.

Көньяк Уралдагы Троицк һәм Орск кебек шәһәрләрдә XX гасыр башында милли тормыш гөрләгән. Мәсәлән, Троицкида «Акмулла», һәм казакъ телендә «Айкап» журналлары, Оренбургта «Вакыт» газетасы, «Чүкеч» һәм «Кармак» журналлары, Орскида «Шәрык» басмаханәсе эшләгән. Татар, казакъ-кыргыз халкына күп кенә мөгаллим, дин әһелләре тәрбияләгән «Рәсүлия» мәдрәсәсе дә шул төбәктә. Мәдрәсәнең җитәкчесе – танылган дин галиме Зәйнулла ишан Рәсүлев.

Чиләбе һәм Троицк яклары – Г. Тукайның шәхси тормышына да уңай тәэсир иткән җир. Тукай 1912 елда бу якларда кымыз эчеп дәвалана һәм, азга гына булса да, гомерен озынайта. (Тукайның Троицк байлары, алардан күргән изгелекләрен язу бу язманың максатына керми.)

Татар халкының бөек шәхесе һәм рәссамы Габделбакый Идрис улы Урманченең Татарстан Сынлы сәнгать музеенда саклanган шәхси архивында Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә яшәгән татар байларына караган чыганаклар да бар. Әлеге чыганаклар хакында сүз алып барыр алдыннан, иң элек, кыскача гына булса да, Б. Урманче шәхесе турында бер-ике сүз әйтеп узу урынлы булыр мөгаен. Б. Урманче 1897 елда, бүгенге Буа районы Күл-Черкен авылында алдынгы карашлы Идрис хәзрәт гаиләсендә

дөньяга килә. 1907–1914 елларда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый.

Б. Урманче – ХХ гасырны иңләгән дәһшәтле тарихның шаһиты, бу чорның бөек кешеләре белән якыннан аралашып яшәгән шәхес. Ул ХХ гасырның 70–80 нче елларында алар хакында «Кыска хатирәләр» язу белән шөгыльләнә. Рәссамның әлеге шәхесләрне ни дәрәҗәдә белүенә карап, күләмнәре төрлечә – бер я берничә җөмлә яисә бер-ике бит булуы мөмкин.

Сүзне озакка сузмастан, Троицкида яшәгән кайбер байларның шәҗәрәләре һәм аерым истәлекләре, табын традицияләре хакында укучыларга тәкъдим ителәчәк чыганакларга кыскача аңлатма биреп узу да урынлы булыр. Югарыда искә алганча, бу материаллар Б. Урманченең шәхси архивында сакланган «Кыска хатирәләр» исемле язмалары арасыннан алынды. Әлеге материаллар Чиләбе төбәге татарлары өчен кызыклы булыр дигән ният белән әзерләнде.

Б. Урманче язмаларының күбесе карандаш белән гарәп хәрефләрендә язылган. Җөмлә төзелешләре дә төгәл түгел, урыны белән аңлашылып бетмәгән урыннары да бар. Шунысы ачык: рәссамнең бу материаллары каралама хәлендә. Текстлар автор тарафыннан төзәтелгән, сызган урыннары да шактый очрый. Шәҗәрәләрне төзегәндә, ул шәхесләр хакында кыска-кыска искәрмәләр биреп баруны да кирәк санаган. Мәсәлән, шәҗәрәләр арасында түбәндәге аңлатмаларга игътибар итмичә булмый: Уразаевлар шәҗәрәсен төзегәндә «Апанаевларның кодалары», ә Хөсәен Рәхманкол хакында сүз барганда «Хөсәен Бәрәскәдән килә Троицкка. Сәүдәләре: мех, тире-яры, такта сәүдәсе», Мөхәммәтҗан Вәлиевлар шәҗәрәсенә «Троицкта һәм Чиләбедә өч катлы зур магазин», дип, искәрмә дә язган. Кайбер шәхесләрнең кем булулары, кайда яшәүләрен шакмаклар эченә дә теркәгән. Шәҗәрәләрдән күренгәнчә, Б. Урманче аларны төзегәндә бары үзе белгән кешеләрне, аларның балаларын гына урнаштырган, борынгылыкка төшеп тормаган. Мәсәлән, Троицк байларыннан Һилаловлар, Бакиров һәм Ибраһим Ирисовларның нәсел шәҗәрәләрен ачыклап бетермәгән, күрәсең, алар фәкать фамилия бу-

ларак кына язып куелган. Рәссам бу фамилияләрне киләчәктә барлауны күздә тоткан дип фаразларга мөмкин. Шәхесләр хакындагы язмаларга килсәк, бу урында Б. Урманче XX гасырның беренче яртысында татар мәдәниятендә сизелерлек эз калдырган кешеләргә кыскача аңлатма биреп уза. Болар да тарих өчен әһәмиятле һәм кызыклы чыганаклар. Гомумән, Чиләбе өлкәсе татарлары арасыннан күтәрелгән күренекле шәхесләр, аларның тормышлары һәм кылган гамәлләре турындагы бу материалларны кыйммәтле чыганаклар дип бәяләргә кирәк.

Икенче материал исә, XX гасыр башында Оренбург һәм Троицкида басылган вакытлы матбугаттан Троицк һәм якын-тирәдәге авыл, шәһәрләрдәге татар халкының яшәү рәвеше, проблемаларын чагылдырган хәбәрләрдән гыйбарәт. Бу хезмәттә игътибар үзәгенә Троицк шәһәренең эчке тормышын төрле аспектта ачкан кыска хәбәрләр генә алынды. Ягъни, XX гасырның башына характерлы мәчет һәм мәдрәсәләр тормышы, яшьләр мәсьләсенә карата язма, сатирик журналларда исә, шул заманың иске карашлы бай һәм муллаларыннан көлгән кызык хәбәрләр тәкъдим ителә. Болар белән таныштыруның төп максаты, иң беренче чиратта, бүгенге укучыга XX гасыр башында Чиләбе өлкәсе Троицк шәһәре тормышыннан азрак мәгълүмат бирү өчен дә эшләнде.

Бер гасыр вакыт үтү сәбәпле, әлеге газета һәм журналлар турында да укучыга азрак мәгълүмат биреп узу урынлы булыр. «Вакыт» газетасы Оренбург шәһәрендә XX гасырның күренекле шәхесләре, алтын приискалары хуҗалары һәм татарның милли-мәдәни үсешенә бервакытта да битараф булмаган Мөхәммәдшакир һәм Мөхәммәдзакир Рәмиевләрнең (шагыйрь Дәрдемәнд) матди ярдәме белән, танылган язучы, журналист Фатыйх Гыйльман улы Кәримев мөхәррирлегендә 1906–1918 елларда Оренбургта басыла. Бу еллар эчендә газетаның барлыгы 2308 саны нәшер ителә. Газета шул заманның мөһим вакыйгалары, шәхесләре белән таныштырып барган, русның башка милләтләргә каршы язылган мәкаләләренә кискен җаваплар бирүдән дә курсып тормаган. Гомумән, газета XX гасыр башының сәяси, икътисади һәм милли-мәдәни, дини вакыйгаларын мөмкин кадәр

ачык күрсәтеп барырга тырышкан. «Акмулла» журналы Троицк шәһәрендә 1911–1916 елларда Хәбибрахман Ганиев наширлеге һәм мөхәррирлегендә басылган. Аның барлыгы 51 саны дөнья күргән. XX гасыр башы матбугаты «Акмулла» журналында юмор-сатираның йомшаклыгын еш кына тәнкыйтьләп чыккан. Әмма шуңа да карамастан, журнал Троицк һәм шул төбәкнең сатира объекты булырлык күренешләреннән көлгән, кайбер очракларда бәхәсләр дә тудырган.

Оренбургта 1915–1917 елларда «Кармак» журналының Мәхмүт Галәветдинев (күренекле дин галиме, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең оныгы, танылган әдип Мәхмүт Галәү. – *З.М.*) наширлеге һәм мөхәррирлегендә барлыгы 60 саны дөнья күрә. 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр Троицк, аңа якын шәһәр һәм авылларның күбесе Оренбург губернасына кергән. Шул сәбәпле «Вакыт» газетасы һәм «Кармак» журналында бу төбәк вакыйгаларын шактый очратырга мөмкин. Болар шул яклары белән дә әһәмиятле.

